# КАЗАН УТЛАРЫ

ӘДӘБИ-НӘФИС ҺӘМ ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ЖУРНАЛ

1922 ЕЛНЫҢ МАЙ АЕННАН БАШЛАП ЧЫГА


## Бу санда


ШИГЪРИЯТ ҺӘМ ЧӘЧМӘ ӘСӘРЛӘР

Халисә ШИРМӘН. Җылы көтә күңелем... *Шигырьләр.* .......... 3
Лилия ГЫЙБАДУЛЛИНА. Әлиф ләм мим. *Повесть.* .......... 8
Мөнир ВАФИН. Миңа таулар – ястык урынына... *Шигырьләр.* .......... 44
Фәтхулла АБДУЛЛИН. Чәчкә идек илләрдә... *Повесть.* .......... 49
Фәнил ГЫЙЛӘҖЕВ. Күңелләрдә утлар дөрли, тынмый... *Шигырьләр.* .......... 86
Солтан ШӘМСИ. Миләш. *Хикәя.* .......... 91
Галия ГАЙНЕТДИНОВА. Мәхәббәтнең ике колы без... *Шигырьләр.* .......... 102
Рөстәм ГАЛИУЛЛИН. Хикәяләр. .......... 105

ЯҢА ИСЕМНӘР

Гөлүсә МОРТАЗИНА. Ышан миңа, ышан тылсымга! *Шигырьләр.* .......... 116

«ОЯСЫНДА НИ КҮРСӘ...» ӘДӘБИ КОНКУРСЫ

Әлфирә ГАЛИЕВА. Бизмәннәр ни диләр? *Хикәя.* .......... 119

*Әдәби тәнкыйть:* Лилия ХӨСНЕТДИНОВА. Бикләр ачылырга тиеш. .......... 138

*Публицистика:* Улданай БӘХТЕГӘРӘЕВА. «Телнең башка яшәеше»: туган тел яки чит (башка) тел. .......... 144

*Хәтер:* Динә МОСТАФИНА. Күк асты иленнән – Казанга. .......... 152

*Китап күзәтү:* Ихтыяр КЫЯМОВ. Саллы хезмәт. .......... 158
Нурфия ЙОСЫПОВА. Мәңгелек сагышлар ярында... .......... 161

*Әдәби берләшмәләрдә:* «Чылбырдагы безнең урын...» *(Роза ХӘМИДУЛЛИНАның кереш сүзе белән шигырьләр).* .......... 165

*2024 ел – Россиядә Гаилә елы:* Җәмил ЯҺУДИН. Хәтеремдә мәңге калыр туган җирем… .... 172

*Замандашыбыз:* Гаделлек сагында (*Алинә ХӘБИБУЛЛИНАның Динар ШАКИРОВ белән әңгәмәсе).* .......... 176

*Хатлар яздым утырып:* Нурия ИЗМАЙЛОВАның Рәдиф ГАТАШка язган хатлары. .......... 178

*Газиз тавышлар:* Татарчасы барыбер кызыклырак... *(Кыям Миңлебаевның тууына – 95 ел).* .......... 181
Җырчы янарга тиеш... *(Хәйдәр Бигичевның тууына – 75 ел).* *Сәхифәне Нәсим АКМАЛ алып бара.* .......... 182

*Шаян сәхифә:* Әмирҗан МОТАЛЛАПОВ. Уены-чыны бергә. .......... 183

Әдәби сканворд. *Рәис ГАБДУЛЛА төзеде.* .......... 187

*Фотоархив:* Хуш, Лилия! .......... 188

Иҗтимагый-мәдәни тормышыбыздан. .......... 190

КАЗАН УТЛАРЫ
*№ 6 (1220) 2024*

*БАШ МӨХӘРРИР –*
**Рөстәм Госман улы**
**ГАЛИУЛЛИН**

*ИДАРӘ:*
**Ирада Әюпова**
**Рәдиф Гаташ**
**Искәндәр Гыйләҗев**
**Айрат Зарипов**
**Дания Заһидуллина**
**Ркаил Зәйдулла**
**Илгиз Зәйниев**
**Илфак Ибраһимов**
**Зиннур Мансуров**
**Ким Миңнуллин**
**Газинур Морат**
**Рүзәл Мөхәммәтшин**
**Айдар Сәлимгәрәев**
**Равил Фәйзуллин**
**Илсур Һадиуллин**
**Данис Шакиров**
**Ленар Шәех**

---

*Баш мөхәррир урынбасары:* **Вакыйф Нуриев.**
*Җаваплы сәркатип:* **Ландыш Әбүдәрова.**
*Бүлек мөхәррирләре:* **Фәнил Гыйләҗев, Рафис Корбан.**
*Мөхәррирләр:* **Лилия Гатауллина, Элеонора Җамалиева, Гөлия Сәлахова.**
*Сайт мөхәррире:* **Ләйсән Зарипова.** *SMM-белгеч:* **Алинә Хәбибуллина.**
*Исәп-хисап бүлеге:* **Эльвира Камалова** (өлкән бухгалтер)**.**
*Машина йөртүче:* **Наил Кадыйров.**

---

✉✉: Редакция адресы: *420066, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2.*
☎☎: *Кабул итү бүлмәсе – 222-09-83 (өст.1618).*
*Баш мөхәррир урынбасары – 222-09-83 (өст.1612).*
*Җаваплы сәркатип – 222-05-50 (өст. 1617).*
*Шигърият, сәнгать һәм хатлар бүлеге – 222-09-83 (өст.1616).*
*Исәп-хисап бүлеге – 222-09-80 (өст.1267), касса – 222-09-84 (өст.1874).*
Сайт: kazanutlary.ru; электрон почта: kazanutlari@yandex.ru

---

★Авторлар фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.
★Редакциягә килгән кулъязмалар рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
★Басмаханә гаебе белән киткән җитешсезлекләр өчен редакция җавап бирми, брак журналларны алыштыру мөмкинлеге юк. Алар хакында 519-44-61 телефоны белән басмаханәнең техник контроль бүлегенә хәбәр итәргә кирәк.

---

Гамәлгә куючы – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче – «ТАТМЕДИА» акционерлык җәмгыяте.
Нәшер итүче адресы: 420097, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Академия урамы, 2.
Журнал редакциянең компьютер үзәгендә җыелды һәм битләргә салынды. Айга бер тапкыр чыга.
Басарга кул куелды 31.05.2024, график буенча 31.05.2024, басылып чыгу вакыты 06.06.2024
Офсет ысулы белән басыла. Кәгазь форматы 70Х108 $^{1}/_{16}$.
Нәшер-хисап табагы 14,2. Басма табак 12 (16,8). Заказ А-1217. Тираж 4560.
Журнал Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2020 елның 13 ноябрендә теркәлде.
Теркәлү таныклыгы ПИ № ФС77-79467.
Индекслар: ПО277 (Татарстаннан читтә яшәүче физик затлар өчен),
П2365 (Татарстанда яшәүче физик затлар өчен), П2368 (юридик затлар өчен). Бәясе ирекле.

---

Республика матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.
«ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылды.
420066, Татарстан Республикасы, Казан шәһәре, Декабристлар урамы, 2.
12+
© «Казан утлары», 2024 ел



Халисә
Ширмән

# ҖЫЛЫ КӨТӘ КҮҢЕЛЕМ...

***

Аһ син, дөнья! Миллион еллар элек
Матур булгансыңдыр тагын да!
Табар өчен нәсел-нәсәбемне
Җырлап кайтам туган ягыма.

Ханнар узган, Урдалага туктап,
«Сугышлы»да корал алышкан...
Ә мин кайтам атсыз, җәя-уксыз,
Итегемә дала ябышкан...

Ябышкан да дала, «Син – типтәр!» дип,
Язып куймак булган маңгайга!
...Ә йөрәктә никтер урман моңы,
Таулар җыры сызыла тугайга...

Белмим, дала. Әйтә алмыйм әле,
Кайда оям, кайда багалмам?
Бөркетме мин, әллә чаптар атмы,
Кайсы юлда икән югалмам?

Итегемне юып инешемдә,
Тауга менгәч, уйга каламын:
Типтәре дә, башкорты да түгел,
Мин – баласы газиз дөньяның!..

...Аһ син, дөнья! Миллион еллар элек
Матур булгансыңдыр тагын да!
Табар өчен нәсел-нәсәбемне
Кайтам әле туган ягыма...

Халисә ШИРМӘН (1969) – *шагыйрә, язучы, галимә; С.Сөләйманова исемендәге әдәби премия лауреаты. «Яшәү моңы!», «Ерактагы йолдызым», «Асылъяр» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

***

Төнге Казан йоклый белми, ахры.
Диварларга шәүлә сарылган.
Тынлык, куркып, төтеннәргә поскан,
Йолдыз арасына таралган...

Йоклый алмый шәһәр. Мең ел инде!
Йокы керми Казан күзенә.
Тулпар аттай чапкан шук гасырлар
Бер-бер артлы алга тезелә...

Тагы ике сәгать калган таңга.
Тәрәзәне ачам: җил керә.
Урам яктан Казан рокерлары
Каһкаһәле итеп йөткерә...

Тынлык сөйми алар. Ә мин, җүләр,
Тынлык эзләп, төнгә табынам.
Табигатьне мәңге иптәш иткән
Авыл урамнарын сагынам...

Мин бит үзем Казан кебек түгел,
Күзләремә йокы сарыла...
...Туган җирен ташлап адашканга
Тик төшендә тынлык табыла...

***

Бер якты нур сызылды да күктән,
Юл күрсәтте йолдыз җиленә.
Нинди гүзәл сихри бу кич дисәм –
Кадер киче иңә Җиремә.

Җылы дулкын күңел ярларына
Кагыла да кире чигенә.
Бу рәхәтлек каян килә дисәм –
Кадер киче иңә Җиремә.

Аяз күктән талгын бер моң ява,
Барлык дөнья нурга күмелә.
Иркәли лә җанны килер көнгә өмет –
Кадер киче иңә Җиремә.

## И дөнья!

...Мин әле яратып туймадым
Дөньяның мең төрле төсләрен.
Көннәрем кояшлы, чалт аяз!
Нур ява йолдыздан төннәрен...

Мин мәңге сокланып туймамын
Яшәүнең тылсымлы көенә!
Күңелем бу җирдә барлыкка,
Сәламәт булганга сөенә...

И дөнья! Ләззәтле һәр көнең!
Тылсымлы һәр узган мизгелең!
Тик, зинһар, әкренәйт аз гына!..
Тормышның йөгерек тизлеген...

***

Кашлары чаларган бер этнең.
Чаларган... Бабайдай ак кашлы.
Этләр дә кешеләр шикелле
Бик төрле, күп төрле язмышлы...

Кадерләп, куенда үстергән
Көчекләр бәхетле. Сүз дә юк.
Нигә дип картайсын андыйлар –
Өс бөтен, дөнья киң, тамак тук...

Ә моның кашлары чаларган...
Күргәнме тормышның ачысын?!
Өздерә рәнҗүле карашы –
Таягын ашатыр кайсысы?!

Кемнәрдән игелек көтәргә
Картайган, ач урам этенә?!
Шундый зур шәһәрдә беркем юк...
Ялгызы гомере читендә...

Әнисе, әтисе ташлаган.
Туганын танымый, белми дә.
Яшәргә омтылыш – шул гына...
Кануннар катгый эт илендә...

Минем дә чигәдә – ак чәчләр...
Кешеләр тормышы – эт көне...
Кемнәрдән игелек көтәргә?!
Ашарлар үзеңне – әйт кенә...

Әйт кенә, ялгышып, берәр сүз.
Каршы әйт, чынлыкны син якла!
Гомерең чигенә җиткәндә,
Куарлар урамга таяклап...

Типкедә яшәгән эт сыман
Үзем дә рәнҗимен илемә...
...Чаларган кашларын җыерып,
Эт калды юлымның читендә...

***

*Төн. Тиле җил! Ник, тәрәзәмнән кереп,*
*Яндырып куйган шәмемне сүндереп,*
*Син качып киттең?!*

Һ.Такташ

Җил шундый ул. Килеп сырпалана,
Борыннардан тарта, колактан,
Читкә китеп, усал сызгыра да
Йодрык селки аннан ерактан...

Үпкәләмим. Җилнең эше шундый.
Холкы шундый − килде-киттеле.
Шунысы гаҗәп: кеше арасында
Кайберләре нәкъ җил шикелле...

Янга килә, көлә, сырпалана,
Эч серләрен ала елмаеп.
Ә соңыннан читкә барып чәчә...
Каласың син шунда моңаеп...

Кайберләре авыр чакта терәк,
Якын дус-иш кебек кылана,
Ә аннары, синнән ерак китеп,
Йодрык селкеп читтән, куана...

Белеп алдым тормыш хикмәтләрен.
Шул көннән соң күңдем бушлыкка:
Җилдәй иптәшләрне читкә тибеп,
Җил иптәшне дәшәм дуслыкка...

***

Сорамагыз, дуслар: «Бу хисләрнең
Кайсысы соң, − диеп, – синеке?»
Мин, ахрысы, яралганмын Күктә,
Хисләрем дә түгел Җирнеке...

Яралганмын Кояш нурларыннан –
Шатлыгым бар күңел очарлык!
Көлтә-көлтә нурга чума кальбем,
Барыгызны бергә кочарлык!

Яралганмын каурый болытлардан –
Җиргә аз-маз сагыш тараткан...
Моңсу була кайчак шигырьләрем...
Минем дә соң бар ла яраткан...

Юлларымда хәсрәтлене күрсәм,
Кайгы тама никтер җырымнан...
Үкенгәннең үкенече йога –
Узган чакта аның юлыннан...

Йөрәгемә сездән мең төрле хис,
Мең төрле моң шулай җыелган...
Тик бер генә чикләү – шигырьләрдә
Үземнекен әйтү – тыелган...

Шуңа да сез, зинһар, сорамагыз,
Юрамагыз моң-зар күзләрдә...
Мин бәхетле сезнең күңелдәген
Әйтеп бирә алсам сүзләрдә...

***

Сине көтәм.
Җир шарының башка ягында,
Беләм, син бар. Син булырга тиеш.
Анда җилләр барып җитә ала,
Бәлки, яңгыр. Ява арган килеш...
Син бар!
Кулларымда глобус әйләнгәндә
Туктатам да төртәм ноктага.
Торган җирең бигрәк матур икән...
Гади авыл, түгел башкала...
Тау өстендә кара урман шаулый.
Нарат башларына
Ак болытлар ятып ял итә.
Болан кызы назлы ханбикәгә
Гашыйк булган мәргән-хәлифә...
Шул урманда яшисеңдер, бәгырь!
Барыр идем! Юллар адаша...
Җилләр җитәкләми. Яңгыры да
Соң тамчыга тикле алдаша...
Әмма син бар. Минем көткәнемне
Беләсеңдер. Син белергә тиеш.
Ак бүренең муеныннан кочып,
Минем якка кузгалгансың, имеш...

***

Ярсып, яңгыр ява. Һәр тамчысы − ядрә.
Балкып, кояш чыга. Һәрбер нуры − кылыч.
Тик асфальтны ярып, башын төрткән үлән
Дәшә кебек миңа: «Әй, син! Тырыш, тырыш!

Әй син, дустым, тырыш, яшә, уйлан, күзәт!
Гомерләр бик кыска, ахыры – барыбер үлем.
Шуны белгән хәлдә, ашык талпынырга:
Дөнья – матур мизгел, дөнья гүзәл бүген!»

Сөйгән ярым сөйли... Һәрбер сүзе – ядрә.
Кагылмавы миңа – гүя үткен кылыч.
Шуны тойган килеш, мин елмаям әле.
Дөнья – матур мизгел... Дөнья – шундый кырыс...

***

«Мин сине бәхетле иттемме?!»
Күзләрең гел тоташ моң гына...
Көзге көн... Чаларган чәчеңә
Вак яңгыр сибәли тын гына...

Вак яңгыр, тымызык пышылдап,
Җанымның иң түрен чылата:
«Мин елыйм! Син исә беркайчан
Сөйгәнең алдында елама!»

Еламыйм.
Сибәли вак яңгыр, коела –
Керфегем читеннән шуыша.
Һәр бөртек чәчеңдә – гаебем
Гомерлек чал булып тулыша...

Елмаям...
Минем дә чигәләр – бәс кенә...
Вак яңгыр астында – икебез...
Гомернең ахырына җиткәндә,
Бәхет тә, гаеп тә – бертигез...

***

Җылы күңелем... Син иренмә,
Чык та бүген урам чатына,
Алып керче миңа яз сулышын,
Матур сүз әйт сөю хакына –

Диген: «Котлыйм, бәгъерем! Бүген бәйрәм!
Хатын-кызлар көне дөньяда!
Син – чәчәгем минем тормышымда!
Яшәү ямьле тик син булганда!» –

Алда әле шулай... Мин, ышанып,
Бер елмайыйм синең сүзеңә.
Хатын-кызга тагын ни кирәк соң?!
Шатлык кунсын көләч йөземә!

«Иң ягымлы ир-ат – син ул!» – диеп
Баш салырмын таныш иңнәргә.
Алда әле, бәгъерем! Алданырмын!
Алданасым килгән көннәрдә.

«Мин бәхетле!» – диеп юанырмын,
Лалә чәчәкләре кызарыр.
Матур ялган бизәр тормышымны,
Яшәү көче алга юл ярыр...

...Җылы эзли күңел, сүзгә сусый!
Матур сүзләр җанга уела.
Назлы сүзең шифа, сихәт миңа!
Дөнья матур... Матур тоела!

***

Син суыктан кайтып кердең бүген.
Пирчәткәңне салдың кулыңнан,
Туңган бармакларга исең китми.
Тик күзләрең язны сагынган...

Чәй утырттың газга, кәстрүл куйдың.
Юылмаган савыт юылды.
Күнегелгән тормыш янә кайтты.
Аш та пеште, чәй дә суынды...

Бар да кабатлана. Тормыш үтә,
Кыш артыннан язлар эз сала...

Тик мәхәббәт көзге кояш сыман
Күренә дә кабат югала...

Тиле күңел һаман нидер көтә.
Ник жылытмый гаилә учагы?
Әйтерсең лә кар астында калган
Шашып сөйгән парның яшь чагы...

...Син суыктан кайтып кердең тагы.
Пирчәткәңне салдың кулыңнан.
...Тик күзләрең килер язны түгел,
Өшегән бармакларны назлый-назлый
Өреп жылытыр ярны сагынган...

***

Кайчандыр ишекләр ябылыр.
Ачылмас яңадан. Берсе дә.
Онытып калдырган киемең
Югалыр билгесез күршедә...

Кайчандыр матур сүз, ялганнан
Синең дә күңелең суыныр.
Бер ишек, бер тупса, бер күңел
Иң кирәк әйбер күк тоелыр...

Бер йөрәк тибешен тыңларга
Теләрсең яңа көн туганда.

Һәм жилкә эзләрсең башыңны
Салырга күңелең тулганда...

Әлегә...
Назларың жилләргә сибелә.
Ай саен яңа йөз, яңа тән...
Нигә соң яшьлекне хатасыз
Башларга ярамый яңадан?!.

Тузган тән, ясалган кашлардан
Син гарык. Аңлыйсың. Беләсең.
Тик ишек ябылмый әлегә...
Көтәсең
Келәнең кайчанрак төшәсен...

## Бер рәсем...

Бер рәсем ташладың дөньяга.
Шатланып, лайклар куйдылар.
Рәсемең астына чит-ятлар
Иң матур сүзләрне уйдылар.

Бер сурәт. Көләсең кояштай.
Нур тама балкыган күзләрдән.
Ә минем ихтыяр житмәгән,
Каршыңда йомшарган тезләр дә...

Ничә кат, керфегең санарга
Кыймыйча, яныңнан үтелгән?!

Мин үзем, тик үзем гаепле,
Кыюсыз йөрәгем биртелгән...

Күпме төн сулышың тоярга
Хыялым хыялга үрелгән!
Иң садә, иң нечкә хисләрем
Бик тирән... бик эчкә күмелгән...

...Бер рәсем. Сез – икәү. Янәшә.
Кулларың – сөйгәнең билендә.
...Бер тамчы су юк ла үлгәндә
Жавапсыз мәхәббәт илендә...



Лилия
Гыйбадуллина

# ӘЛИФ ЛӘМ МИМ*

ПОВЕСТЬ

Ул калтыранган куллары белән китапка үрелде дә, чормага сак кына саркылган көн яктысында «Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар» дигән сүзләрне искәреп, үрелгән кулы һавада асылып калды. Бер мәлгә башы әйләнеп, күз аллары караңгыланып китте, чигәсендә нидер сулык-сулык суга башлады, йөзе кызышты. Ярдәм эзләгәндәй, тирә-ягына карады. Торган саен куерган төтен арасыннан иптәшләренең сыннары шәүлә кебек кенә шәйләнә, ул шәүләләр өй кыегыннан чорма түренә, чормадан кабат өй кыегына туктаусыз кымырҗыйлар. Егет китап белән күзгә-күз иде.

– Вагизов, чего встал как истукан?! Шевелись, ... Не то самого выброшу...

Күзләрен йомды һәм йорт кыегына җитәрәк кенә бәбәкләрен көн яктысына ачарга кыйды ул. Көн каралып, шәфәкъ томаланган, Богарыслан өстенә эңгер-меңгер җәелгән. Ихтимал, эңгердән өстәрәк, бик күпкә өстәрәк ай кабынгандыр, әмма егет күккә бакмады.

Китап, саргайган ак канатларын соңгы кат җилпеп, аска очты...

Китап арты китап битләрен ялмап үрсәләнгән учак өстән аермачык күренә, уты йөзне пешерә иде хәтта. Ялкын телләре шашып бииләр. Менә берсе «әлиф» булып күккә үрелде, икенчесе – «ләм», өченчесе «мим» сыман боргаланып сузылды...

Егет, йөзен учактан яшереп, артка борылды да кабат чормага кереп китте...

* Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе тарафыннан оештырылган II әдәби бәйгедә повесть номинациясендә өченче урынга лаек булган әсәр.

Лилия ГЫЙБАДУЛЛИНА (1987) – *шагыйрә; «Белла» халыкара әдәби премия лауреаты. «Мин бәхетне күрәм!..», «Тынлык кайтавазы», «Кайту» исемле китаплар авторы. Чаллыда яши.*

***

Шәмсехәят карчыкның үзе сыман торган саен туфракка сеңә барган иске йортының ишеге шыгырдап ачылды, һәм ап-ак бу булып кыш суыгы килеп керде. Шул иләс аклык арасыннан тәгәрәп кенә бер малай килеп чыкты.

– Әссәләмегаләйкем, әби! Иминлекме, саулыкмы? Инәй сиңа садакага иртәнге сөт җибәрде. Мә! – Малай, өй эчен яңгыратып, борын тартып алды һәм, җитди кыяфәт белән үрелеп, савытны өстәлгә куйды.

– Вәгаләйкемәссәлам, олан! Сөбханалла. Менә рәхмәт! Әле кайчан килер дип көтеп утыруым иде. Бәрәкалла! Атаң-инәң ни хәлләрдә? Иртәнге чәеңне эчтеңме? Яле, өс-башыңны сал да чәйләп алыйк...

– Сабакка килдем. Тиз генә өйрәт тә, әби. Малайлар белән тау шуарга чыгасым бар. Кичәгенәк тә чыкмаган идем. – Малай инде киез каталарын мич янына сөяп куйган, йон бияләйләрен салып, тунын яхшылап буып торган путасын чишеп маташа иде.

– Һай, шулчаклым да кыбырсык булырсың икән. Тач атаң инде... – Шәмсехәят карчык балага беравык сокланып карап торды, аннан, күз тидермим дигәндәй борылып, чәй хәстәренә кереште.

Үз тезләрендә сөеп үстерәсе олан иде лә юкса, насыйп итмәгән шул... Ярый инде авылында, күз уңында үсә. Теге чакта каты торып, дөрес эшләгәндер, Ходай үзе кичерсен инде. Каты тормаса, хәзер бердәнбер оныгын бер күрергә тилмереп яшәр иде ләбаса. Иии, килененең ул чактагы елаулары исенә төшсә, әле дә йөрәге чемердәп куя. Тәгәри-тәгәри елады бит, тезләнеп ялварды. Көч-хәл белән каерып, ат арбасына чыгарып салдылар үзен, чак алып киттеләр. Өзелгәндер үзәккәйләре, Раббым кичерсен... «Улымның бердәндер баласы шәригать буенча миңа тиеш. Баламның нәсел дәвамчысы шушы нигездә үсәргә тиеш», – дип кистереп әйтте Шәмсехәят, аяк терәп нык торды. Кайлардан гына көч тапкандыр. ...Тик оныгыңны үз нигезеңдә үстерә алмадың шул, кортка. Үстерә алмадың, бирештең...

Кунак малай, карчыкны бимазалы уйларыннан бүлеп, тупырдап, өстәл янына килеп утырды:

– Мин чәйне шикәр белән эчәргә яратам!

Малайның почык борын очына тир бәреп чыкканчы чәйләр эчкәч, амин тотып, тәүге сабакка утырдылар.

– Бисмилләһи әр-рахман әр-рәхим. Менә бу таяк әлиф дигән хәреф, балам. Аллаһ, әнкәй, әткәй сүзләре әлиф белән башлана...

Чана шуарга чыгасым бар дип бераз хәйләләде малай. Тау шуасы әллә ни килми дә аның. Шууын шуа инде. Авылны икегә ярып төшкән Пыяла юлдан малайлар белән узыша-узыша шуалар. Кышын нәкъ пыяла кебек ялтырап торганга шулай атыйлар икән бу юлны – әнкәсе әйтте. Ат чанасы эзеннән шулайга әйләнә диде. Алар шушы урамда яшиләр. Урамның иң биек башыннан кузгалып китәсең дә Чуваш Байтуганы күперенә кадәр выжылдап төшәсең. Менә шул күпер янында кайбер көннәрне теге матур апа очрый.

Ул апаны моңарчы бер дә күргәне юк иде, быел кышын гына таныштылар. Малайның күпергә кадәр шуып, чанасын сөйрәп, кабат югары очка менеп барышы иде:

– Сәләй, балам, кил әле яныма, – дигән ягымлы тавышка аптырап туктап калды.

Кара калын шәл япкан таныш түгел бер апа кулларын сузып тора. Үзе шундый матур. Сәләйнең аңа таба берничә адым атлавы булды, апа үзе йөгереп диярлек килде дә шундый итеп кочаклады. Кысып-кысып! Нык итеп! Малайны моңарчы берәүнең дә болай кочканы юк иде. Сәләй кара шәл эченә керде дә бетте менә. Әллә ничек кенә бик рәхәт булып куйды. Җылы. Үзе уңайсыз да. Бәби сыман кочактан чыга алмый тор инде. Малайлар күрсә, көләрләр иде бугай. Шуннан теге апа аның кесәсенә ике прәннек белән бер уч кәнфит салды. Сәләй рәхмәт әйтте дә авылга таба торып йөгерде.

Шуннан бирле апа ике көннең берендә аны күпер янында көтә. Шулай ук кочаклый, хәлләрен сораша, үзе туктаусыз елмая. Ә күзләре һәрвакыт яшьле.

Шәмсехәят әбидән шуңа да тизрәк чыгып китү җаен карады малай. Апа көтәдер, туңып та беткәндер инде. Үпкәләп кайтып китә күрмәсен генә. Сәләйнең ул матур апаны бер дә үпкәләтәсе килми.

Югары оч малайлары Хәкимулла белән Галинур урамга чыкканнар икән инде.

– Сәләй, Сәләй – тишек калай! – Галинур, авызын ерып, кар йомарламы томырды.

– Галинур, Галинур, үзең карак, атаң бур! – Сәләй җавапсыз каламы! Үчекләү сүзе белән бергә Галинурның битенә үк кар «гранатасы» барып чәпәлде. Тегесе борынын тотып чәрелдәп җибәрде:

– Аааа, Сәләй-сәпәй! Әтәйгә әйтәм мин сине... Синең бит инәң дә үзеңнеке түгел! Әтәң дә үзеңнеке түгел! Аааа...

– Яңгаллама! Үземнеке! Үземнеке! Әтәем дә үземнеке, инәем дә... – Сәләй, нәни йодрыкларын төйнәп, һөҗүмгә ташланды...

...Өй ишеген кубарырдай ачып, керә-керешкә:

– Инәй, миннән урамда малайлар көлә. Әтәң дә, инәң дә үзеңнеке түгел, диләр. Ник алай әйтәләр? Сез минеке түгелмени? – диде дә сызылып елап та җибәрде.

Гайшә, йон эрләп утырган җиреннән кузгалмый гына, малайның тырналган, кызарып беткән бит-йөзен, җиңе ертылган тунын, балагына кар тулган киез каталарын күздән кичерде. Аннан карашын тәрәзәгә, күршедәге мәчет ишегенә күчерде. Гататдине намазга кереп киткән иде, чыгып җитмидерме.

– Итекләреңне кагып кер, туныңны кибәргә эл. Өс-башыңны рәтлә дә яныма кил.

Мыш-мыш борын тартып, әнкәсе янына килеп чүмәшкәндә, Сәләй тынычлана төшкән иде. Гайшә малайның тирләп чуалган чәчләрен сыйпап тарады, маңгаеннан үбеп алды. Улының елап шешенгән коңгырт күзләренә туры карады. Кулындагы орчыгы шапылдап идәнгә төште, җебе өзелде.

– Кешедән ишеткәнче, үземнән бел, улым. Сине тудырган инәй – бүтән хатын. Мин түгел. Атаең да башка. Ходай үзебезгә бала бирмәде. Бар нәрсәбез җитеш, балабыз гына юк иде. Раббым елый-елый ялваруларымны ишеткәндер: сине бүләк итте ул безгә. Асрамага алганда, алты гына айлык бишек баласы идең, бәбкәм. Атаң Миңнегалим атлы кеше иде. Шушыннан, үзебезнең Байтуганнан. Аны, башка берәү белән бутап, кыйнап үтергәннәр. Атаең үлгәч, инәң Гайниҗамал, сине калдырып, үз авылына кайтып киткән. Кирәксенмәгән ул сине, җирбит. Ташлап киткән, аңлыйсыңмы? Инәй түгел ул сиңа! Тапкан – ана түгел, баккан – ана...

Сәләй ишетте дә, ишетмәде дә. Кинәт бөтен дөнья әйләнә башлады. Зырылдап торган дөнья уртасында ул, идәндә яткан орчыкка күзен текәп, тик утыра бирде. Каядыр эчтә, күкрәк читлегендә ниндидер бик кадерле бер җеп шартлап өзелде. Кинәт дөньяның бик суык булуын сизеп алды малай. Шулкадәр салкын: умыртка баганасы буйлап туң йөгерәмени. Их, теге апаның калын шәле эченә керергә иде хәзер. Кереп югалырга иде дә беркайчан да, беркайчан да чыкмаска иде...

***

– Бүген кәчтүм минеке, Сибгат!

Сәләйнең яңгыравык тавышы тулай торак бүлмәсенә генә сыймыйча, тәрәзәдән ташып чыкты да, трамвайлар гөрелтесенә ияреп, Казан урамнарына таралды. Сибгатнең, гадәтенчә, каләм тотып, кәгазь өстенә иелгән чагы иде. Җыйнак гәүдәсен урындыктан кубаруны кирәк санамады гына түгел, бүлмәдәшенең сүзенә бөтенләй илтифат итмәде. Кул гына селтәде. Кәчтүм кайгысы түгел, янәсе, комачаулама.

Сәләй җил-җил килеп кергән уңайга, шкафтан аксыл-сары кәчтүмне алып, әйләндереп-әйләндереп карады. Кичә Сибгат чираты иде, пычратмаганмы. Бүлмәдәш дуслар кызлар белән очрашуларга кия торган бердәнбер кәчтүмне кадерләп кенә тоталар анысы. Шулай да алдан барлап куймый ярамас. Кызы соң нинди бит! Үтүк йөзе күрмәгән таплы кәчтүм-чалбар белән свиданиега килерлек түгел.

Егет бәхетле елмайган хәлдә караватына сузылды.

...Ярый ла алмалар аласы иткән. Казакъ даласыннан, ерактан, җитмәсә бераз акча эшләп тә, буш кул кайтып керү ярамас дип, биштәренә алма тутырган иде. Тулай торак ишек төбендәге утыргычта ялгызы утырган чибәркәйне күреп, юлдан шактый арган булса да, туктыйсы итте. Беренче курска килгәндер, моңарчы бер дә күзгә чалынганы юк кебек.

– Сылу туташны алма белән сыйларга рөхсәтме? Тартынмагыз, сезгә иң тәмле алма!

Кызый сүзгә кесәгә керә торганнардан түгел икән:

– Үзе алма ди, үзе алма сузган була! – диде дә пырхылдап көлеп җибәрде. Егет тә кушылды. Кыз алманы йөзенә якын китерде, ләкин авыз итәргә ашыкмады. Яңагына терәде. Шул мизгелдә Сәләй кызның чәч бөдрәләре белән уйнап искән җәйге җилдән көнләшеп куйды. Ә күзләре! Төпсез зәңгәр икән. Керсәң, чыгармын димә бу күзләрдән.

– Сәләй Оренбурлы бу юлы кайсы итәк җиленнән исергән дип белик?

Һай, бу Сибгатнең теленә тилчә чыккыры!

– Карашыннан исердем, брамат! – Егетләр аерата кәефле чакларда «такташча»лап сөйләшүне хуп күрәләр иде. – Кәгазь бимазалаудан тукта инде син. Чынлап торып шагыйрь булып китүең бар, ләхәүлә!..

Сибгат, кыйгач кашларын җәеп, көләч күзләреннән яшь килгәнче рәхәтләнеп көлде:

– Сиңа түзгән кәгазь миңа гына күнәр әле, һич кайгырма! Оренбурда ук китап чыгарып килгән кеше бит син, карале. Әллә Казан шигырьдән биздерде үзеңне, әллә кызлар...

– Оста барда телең тый ди, браматым. Шигырьне син яз инде аны, яме.

Минем мөһимрәк эшләрем дә бар. Бу юлы мин язмышымны язам, ахры... – Сәләй дустына күз кысып, балкып елмайды.

Ә аның Рәмзиясе бик матур бии икән. Тулай торакның «кызыл почмагы»нда үткән кичәләрнең берсендә берничә кыз белән татар халык биюен башкардылар. Шул кичне Сәләй кызның исемен белде, шул кичне тәү мәртәбә озатып куйды һәм зәңгәр күзләр чоңгылына үз теләге белән әсир төшүен аңлады.

Яшь шомырт бөреләре салкын дөньялыкка чәчәк китергән бер кичтә, алар гомерлеккә бергә булырга вәгъдә бирештеләр. Аңа кадәр кыз, егетнең күкрәгенә башын салып, беркемгә дә сөйләмәгән серен чиште:

– Син минең хакта барысын да белергә тиеш. Шуннан соң да бергә булырбызмы – анысын үзең хәл итәрсең, дустым – диде ул калтыранган тавыш белән. – Мин Рәмзия Вәлитова түгел, чын фамилиям Баязитова минем. Әткәем Гыйләҗетдин яклап алтын байлары Рәмиевләрнең туганы мин. Аңлыйсыңмы?! – Кыз Сәләйнең күзләренә үтәли тишәрдәй туры текәлде.

Салкынча җил исеп куйды. Шомырт чәчкәләре үзара пышылдашып тибрәлделәр. Егет сөйгәнен кочагына ныграк кысты да тирә-ягына каранып алды. Дөнья тын иде. Дөнья шомырт исеннән исергән иде. Рәмзия пышылдап кына сүзен дәвам итте:

– ...Әнкәем Зөһрә исемле иде. Аның әткәсе Галләметдин бабам да хаҗи. Алай гына да түгел, унике авылда мәчет-мәдрәсә салдырган кеше. Стәрлетамакта зур матур йортта, җитеш гаиләдә кадерле бала булып туганмын мин. Ике абыем, энем бар иде. Ах, белсәң икән, Сәләй, ничек бәхетле идек без! Бүгенгемдә ул рәхәт көннәр төш кебек кенә тоела... Дүрт яшьлек чагымда энем, аннан газиз әткәем үлеп китте. Ике елдан әнкәем дә өзелде. – Кыз тыенкы гына сулкылдап елый иде. – Олы абзыкаем Кадыйр ул вакытта Казанда иде инде. Татар коммунистик университетында укый иде. Әнкәебез җеназасына кайткач, кече абыем Кәрим белән икебез ике ягына сарылып үкседек. Безне кая алып китәлсен инде ул бичара... Детдомга урнаштырды. Детдомга илтер алдыннан, туган йортыбыздан бөтенләйгә чыгып киткәнче, ишек-тәрәзәләрне бикләде дә болай диде: «Сез Баязитовлар түгел, сез Вәлитовлар. Документта да шулай. Баязитов дигән фамилияне онытыгыз, исегездән чыгарып ташлагыз. Кем сораса да, сез – Вәлитовлар». Абый кат-кат әйтте. Детдомга барганчы юл буе эчемнән генә «мин Рәмзия Вәлитова, мин Рәмзия Вәлитова» дип тәкрарлап бардым. Яңа фамилиямне ялгыш онытып җибәрмәгәем дип курыктым.

– Абыйларың турында бер дә әйткәнең юк иде, Рәмзиям. Казандамы алар?

– Әйе, Казанда. Казан зиратында, икесе дә... – Аның тавышыннан кабер салкынлыгы бөркелгән кебек булды. Кыз инде еламый иде. Зәңгәр күзләре каядыр бушлыкка, билгесез ноктага төбәлгән. Ничек таныш Сәләйгә бу караш... «Бәгыренә боз урнашкан...» Сәләй үз уйларыннан үзе сагаеп калды. Бәгырьгә боз урнаштыручы да, шул бозны эретергә сәләтлеләр дә – кешеләр бит: замандашлар, дуслар, танышлар, туганнар, сөйгән һәм сөймәгән ярлар... Кешеләр бер-берсенең бәгыренә боз атып уйныйлар да шул уенны гади генә итеп «тормыш» дип атыйлар. Башка берәүнең кайнар җанына туң йөгертергә тырышучылар гадәттә үзләре дә бәгырьләрендәге

боз салкынышнан интегүчеләр булмыймы икән. Алай дисәң, күкрәгендә бер йомарлам боз йөртеп тә, гомере буе кешеләргә җылылык өләшүчеләр, башкаларның күңелен җылытырга тырышучылар да бар бу дөньяда. Җир җылылыгын, асылда, кояш түгел, әнә шундыйлар саклыйдыр. Шул рәвешле, тамчылап-тамчылап, үз бәгырьләрендәге боз да эридер. Бәлки бердәнбер җылыну чарасыдыр бу, дөнья туңыннан сакланып калуның бердәнбер мөмкинлегедер. Сәләй дә бәгыренә боз урнашкан шушы ятим җанны салкыннардан аралап, бәгыренә бөялгән бозны эретерлек итеп яшәргә тиештер. Бәлки Рәмзия – аның коткаручысыдыр...

– ...Кадыйр абзыкаем берничә елдан Кәрим абзамны да Казанга алдырды, Промэкономтехникумга укырга урнаштырды. Комсомол постында сакта торганда атып үтерделәр минем Кәрим абзыкаемны, Сәләй... Аннан Кадыйр... Аспирантура тәмамлады ул, Авыл хуҗалыгы институтында эшли башлады. Миңа гел хатлар язып, җае булганда, Стәрлегә кайтып, хәлләремне белешеп, ярдәм итеп яшәде. Утыз өченче елны «абыең үлде» хәбәрен алгач, үзем ярым үлдем. Казанга җеназасына ничек килүемне дә хәтерләмим. Туберкулез диделәр... Үләсен белгән, дусларына «сеңлемне ташламагыз» дип әйтеп калдырган. Алар мине Казанда калырга, педагогика институтына укырга керергә күндерделәр...

– Рәхмәт яусын аларга. – Егет кызның чәчләреннән үпте. – Алар миңа бәхетемне юнәлткәннәр.

– Ә мин сине танышканчы ук белә идем. – Беркавым тын торгач, күңелендә йөрткән йөктән котылгандай, күкрәк тутырып тирән сулыш алды да егеткә ныграк сыенды кыз. – Институт коридоры стенасына билгеләрне язып эләләр бит. Синең «бишле»ләрне кызлар белән шаккатып санап торган идек. Кем икән бу «бишле»гә генә укучы Сәләй Вәгыйзов дип.

Егет елмаеп куйды:

– Их, бәгърем. Минем дә чын исемем алай түгел шул. Тугач та үз ата-анам кушкан атым – Сөләйман Хәлиуллин...

Шомырт салкыны белән шомырт аклыгы тулышкан бу төндә, Рәмзиясен озатып кайткач, Сәләй төш күрде.

...Ул калтыранган куллары белән китапка үрелде дә, чормага саран гына саркылган көн яктысында «Мифтах әл-Коръән» дигән сүзләрне искәреп, үрелгән кулы һавада асылынып калды. Бер мәлгә башы әйләнеп, күз аллары караңгыланып китте, чигәсендә нидер сулык-сулык суга башлады, йөзе кызышты. Ул, ярдәм эзләгәндәй, тирә-ягына карады. Торган саен куерган төтен арасыннан иптәшләренең сыннары шәүлә сыман гына шәйләнә, ул шәүләләр өй кыегыннан чорма түренә, чормадан кабат өй кыегына туктаусыз кымырҗыйлар. Егет китап белән күзгә-күз иде.

Йорт кыегына җитәрәк кенә бәбәкләрен көн яктысына ачарга кыйды ул. Көн каралып, шәфәкъ томаланган иде. Ихтимал, эңгердән өстәрәк, бик күпкә өстәрәк ай кабынгандыр, әмма ул күккә бакмады.

Китап, саргайган ак канатларын соңгы кат җилпеп, аска очты.

Китап арты китап битләрен ялмап үрсәләнгән учак өстән аермачык күренә иде, уты йөзне пешерә иде хәтта. Ялкын телләре шашып бииләр. Менә берсе «әлиф» булып күккә үрелде, икенчесе – «ләм», өченчесе «мим» сыман боргаланып сузылды...

Кинәт шул учак эчендә, китаплар өстендә һәм хәрефләр арасында Рәмзиянең сыны күренде. Менә ул ялкын телләре белән бергә очынып-очынып бии башлады. Китап битләрендәге хәрефләр, вак-вак күл очкыннары булып, аның аксыл йөзенә, бөдрә чәчләренә куналар. Тик Рәмзия аларны күрми, очынып-очынып бии, үзе Сәләйгә кулларын сузып елмая, елмая... Сәләй аны учак эченнән тартып алмакчы булып үрелә, ләкин хәрефләр, ялкын теле булып, Рәмзияне уратып алганнар. Алар, егетнең кулларын өтә-өтә, күкрәгенә үрмәли иделәр...

***

...Чишенергә боердылар.

Анадан тума калган ирләрне туң җиргә тезләндерделәр. Алар күп түгел иде. Чолганышта калгач та, әсирлеккә төшүдән кайсы кайда качып изаланган, әмма барыбер фашист богавына килеп тарган солдатлар кара язмышларына күнгән хәлдә, башларын түбән иеп, тезләнеп тора бирделәр. Озак тоттылар аларны, сөякләргә туң йөгерде, әчкелтем март җиле аркадан какты. Тешләр тешкә тиеп шакылдый, калтырата башлады. Уң янбашыннан кан саркыган берәүнең тезләнгән урынында кызыл күлләвек җәелде. Бераздан ул күлләвеккә бичараның хәлсез гәүдәсе авып төште. Аннан соң ату тавышы...

Түзәргә, ничек тә түзәргә... Байтуганның текә тауларында җил белән куышып чыныккан аякларым, Бигәш тавыннан мәтәлчек атынып ныгыган бәдәнем, ничек тә чыдагыз...

Сәләй күзләрен йомды. Һай, бу ачы җил һич тә чит җирләрнең салкын җиле түгел, Кылыч тау йөзеннән исеп, Тимер Казык Теш таулары арасыннан үтеп, Байтуган малаен иркәләп исүче туган якның бәрхет җиле икән лә. Бу җил – Рәмзиясенең чәч бөдрәләре белән уйнап искән уйнак җил икән... Кичер мине, газизем!..

Кинәт аркасына сугудан ир күзләрен ачты. Чайкалып куйды, әмма егылмады. Каршында немец офицеры аңа бармак төртеп тора. Янында тагын бер хәрби, анысы күзлекле, кулында кәгазь белән каләм.

– Jude. Erschießen! – Офицер март җилен кылыч кыеп төшергәндәй тавыш белән ярды.

Шул мизгелдә Сәләй башына автоматның салкын көпшәсе терәлүен тойды.

– Ләә иләһә иллаллаһ...

Ләкин аны бүлдерделәр.

– Как вас зовут и какой вы национальности? – Немец хәрбиенең сөаленнән җаны ике дөнья арасында тибрәлгән ир бермәлгә һушын җыя алмый торды.

– Вагизов Саляй Гататович. Татарин.

Баш чүмеченә терәлгән автомат сабырсыз кымшанып куйды. Күрәсең, палачның тәкате корый иде.

– Сугышка кайчан һәм каян алындыгыз? Званиегез?

Колагыма гына ишетелде, ахры, дип, Сәләй аңгырайган кыяфәттә күзлекле хәрбигә карап тора бирде. Гомеремне кыяр алдыннан туган телемне ишеттереп, газраил саташтырадыр.

– Сорауга җавап бирегез! – Тәрҗемәченең тавышы бу юлы яшен камчысыдай шартлап чыкты.

– Мең тугыз йөз кырык өченче елның 18 мартында Татар АССРының Арча район хәрби комиссариатыннан алындым. Рядовой. Өченче армиянең 179 танк бригадасы составында сугыштым. Миналар ташыдым. Атарга яраксыз мин...

– Ни өчен? – Монысы инде кызыксынудан гына ташланган сөаль иде кебек.

– Күзләрем начар күрә.

– Сугышка кадәр һөнәрегез?

– Мөгаллим. Татар теле мөгаллиме.

Тәрҗемәче, янындагы офицерга борылып, алманча нидер әйтте. Алар берничә кәлимә сүз алышкач, автомат көпшәсе Сәләйнең башыннан аерылды. Хәер, аннан соң ул, берничә тапкыр яңгырап, адәм балалары тарафыннан үзенә йөкләнгән бурычны төгәл башкарды... Ләкин Сәләй боларны ишетерлек хәлдә түгел иде. Ул инде бернидән дә курыкмый да, бернигә дә өметләнми дә, хәтта дөнья салкынын да сизми иде. Гәүдәсе туң туфракка тезләре белән береккәндәй чайкалып тора бирсә дә, җаны монда түгел иде аның.

...Тирәлеген караңгылык уратып алган. Әмма шулкадәр дә рәхәт, шулкадәр тыныч. Кап-кара калын шәл эчендә икән бит. Колак төбендә генә кап-кайнар йөрәк тибә. Дөп-дөп-дөп... Күмәч исе, җир исе, сөт исе, яз исе – кара шәл эчендә дөньядагы һәммә исләр буталып, борынны кытыклап, яшәү исе килә. Дөнья салкыныннан качарга теләгәндәй, ул бөтен булмышы белән шушы кайнар кочакка сыенды. Җылыт мине, инәем, җылыт. Яшер мине... Мин бит исән. Мин бар бит! Их, теге чакта әнкәм икәнлегеңне белсәм, кысып-кысып кочаклар идем дә үзеңне, кара шәлең эченнән беркайчан чыкмас идем...

***

...Әсирләрне башта җәяүләп Харьковка кудылар, аннан этап белән Германиягә. «Берлинга болай тиз барып җитәрбез дип кем уйлаган», – дип шаяртырга тырышты Сәләй, үзе шикелле биш йөзләп әсир белән Берлинга килеп кергәндә. Араларында төрле чиндагылар: гади солдаттан башлап генералга кадәр бар. Карантин баракларында ике ай тирәсе ябып тоткач, барысын да шушында төяп китерделәр. «Ausbildungslager», ягъни «агарту, укыту» өчен алып килгәннәр – барак башлыклары шулай аңлатты. Ай ярым тирәсе лекция тыңларга йөрттеләр. Сәләй шаккатты: чеп-чи рус кешеләре Советлар Союзының һичшиксез җиңеләчәге, сугыш беткәч, Европада немецлар урнаштырачак тәртипләр турында шулкадәр ышандырырлык итеп сөйлиләр. Телләре телгә йокмый. Каян җыеп бетергәннәр боларны... Укулар төгәлләнгәч, әсирләр дә шушы фикерләрне башкаларга җиткерергә тиеш, янәсе. Ләкин аның кайгысымы, үтереп ашыйсы килә. Ашату – ачтан үлмәслек кенә, кешеләр ачлыктан шешенә, кем ни таба ала, үсемлек тамырларына кадәр казып ашыйлар.

Сәләй баракта бергә булган иптәшләреннән аерылды, укыту үткәннәрне төрле якка чәчтеләр, күрәсең. Аларны кайсыдыр бер шәһәр янындагы лагерьга китерделәр...

– Сталин... иптәш Сталин, беләсеңме, ни дигән? Кызыл Армия солдаты

әсир була алмый дигән. Аңлыйсыңмы? Без юк, без – тере мәетләр... – Николай, очарга талпынган гарип кош шикелле, кулларын як-якка җәеп җибәрде.

Николай – кызык, әмма ышанычлы кеше. Саша белән – Сәләйне биредә күпчелеге шулай атый – беренче көннәрдән үк женнәре килеште. Украинаның Макаров посёлогында туып үскән, аннан хәрби хезмәт вакытында сугышка китәргә мәҗбүр булган бу яшь, гаярь егет ихласлыгы, күзләрендәге җылы моң белән үзенә җәлеп итә иде. Монда ул Сәләйдән берничә айга иртәрәк килеп эләккән.

– Булмас... Без монда меңәрләгән бит.

– Әйе. Без генә түгел, союзниклар да бар бу лагерьда. Алар ничек яши дә, без ничек тилмерәбез... – диде Николай, французлар яшәгән бараклар ягына ымлап.

Алар белән бергә заводта французлар да, поляклар да, чехлар да эшли. Сәләйнең башкалардан да ишеткәне бар: болар эт типкесендә җан асрамыйлар. Конвойлары да немецлар түгел диләр, хак булса. Посылкалар да алалар икән.

Узган төнне генә нарның Сәләйдән өске ятагында йоклаучы егет Женева конвенциясе турында, союзник әсирләрнең шул конвенция аркасында адәм рәтле яшәүләре турында акыл сатып яткан иде. Заводтан баракка кайтып аугач, тоткыннар бераз шулай үзләренчә пар чыгарып, сөйләшеп алалар. Әллә ниләр ишетергә була монда. Кемнең язмышы нинди бит... Университет профессорлары да, җырчылар да, борын асты кибеп өлгермәгән килеш сугышка киткән егетләр дә, колхозчылар да бар. Хәзер барысы да бер калыпта, бер читлектә, шулай да һәркемнең бәгыре үзенчә сулкылдый.

Кемнең норма тутыруы, тырышып эшләве аерым исәптә. Яратмыйлар андыйларны... Темасына карап, тавышлар үзгәрә. Кичә дә, конвенция турында искә алганда, Гриша тавышын нечкәртеп сөйләде. Кем сөйләвен тавышыннан һич танырмын димә...

Ә яшәүләре... яшәү дип әйтергә яраса, чынлап та, шәптән түгел.

Иртәнге алтыда торырга, команда булу белән барысы да юынгычлар янына ашыга. Һава торышы нинди булуга карамастан, көн саен бил тиңентен сап-салкын су белән юыну мәҗбүри. Бозлы су шыр сөяккә калган бәдәннәрне куырып ала, әмма күзәтеп кенә торалар: ашык-пошык чылангандай гына итсәң, дөмбәсләп атачаклар. Акрынрак кыймылдап, юыну чиратының ахырына калучыларны кыйный ук башлыйлар:

– Шнель, шнель...

Бу мәхшәрдән соң, барак диварлары буйлап тезелеп басасы. Бүлмә башлыгы, тоткыннарны бик игътибар белән санап, барак башлыгына хисап бирә, барак башлыгы – «эсэс» чыга. Барлау тәмамлангач, иртәнге аш китерәләр. Ул шикәрсез-нисез бер чынаяк кайнар каһвәдән гыйбарәт. Аннан соң строй белән заводка. Баштагы мәлләрдә тоткыннарның барысын да эшкә кумыйлар, сайлап кына җибәрәләр иде. Баракта калучыларга да эш табыла анысы: чишенергә һәм киемнәрдән бет чүпләргә кушалар... Тәрәзәләр көндез һәрвакыт ачык, ябарга ярамый. Шыр сөяккә калган тоткыннар, бер-берсенә аркалары белән сөялеп, салкыннан калтырап утырырга мәҗбүр. Заводта, тукмак астында, көне буе аягөсте басып тору баракта салкыннан катып утыруга караганда мең өлеш артык.

Лагерь биек таш койма һәм койма өстеннән югары вольтлы ток тоташтырылган тимерчыбык белән әйләндереп алынган. Тирәли бик күп вышкалар, аларда «эсэс»чыларның автоматлары ялгыш кына бер адым ясаган тоткынны чүпләргә әзер тора. Тәмуг авызы төсле зур лагерь капкасыннан сул якта – агач бараклар, уң якта – мунча, ашарга пешерү йорты һәм крематорий. Аннан көн-төн кара төтен ыргыла. Дөньяда кеше ите янган ис...

Иртән торалмаучылар көн саен була. Төн чыкканчы җаннары бу тәмугны ташлап качкан ул бичараларны, бараклардан чүпләп, лагерь ишегалдына чыгарып ташлыйлар.

Заводта эшләгәндә, бер генә секунд та туктап торырга ярамый – «эсэс»чылар кыйнап ташлаячак. Торалмасаң – ятып каласың. Гадәттә, төшке аш вакыты җиткәндә, аяктан калучылар шактый җыела: үлгәне дә, тересе дә... «Эсэс»чылар хәллерәк тоткыннарга гәүдәләрне бер өем итеп җыярга кушалар. Кичен эш беткәндә, бу өемне алырга махсус арба килә. Адәмнәрнең гәүдәләрен әрдәнәләп, арбага аталар. Бичара кешеләр арасында әле исәннәре дә була, алар арба төбендә кала, өсләренә мәетләр өелә. Коточкыч акырулар, ыңгырашулар... Ләкин моңа берәү дә игътибар бирми.

Лагерьга кергәндә – исәп. Үз аягы белән кайтучыларны санап бетергәч, арбаны әйләндереп кенә бушаталар да, берәмләп санап, кабат тутыралар. Тереләр – кичке ашка юнәлә, үлеләрне, киемнәрен салдырып, крематорийга илтәләр. Аллаһның һәр бирмеш көнендә крематорий өстеннән кара төтеннең өзелеп торганы юк...

Ракеталар ясый торган хәрби завод лагерьдан ерак түгел. Сәләй айга якын йөк төяү эшендә. Аларның бригадасы вагоннарга цемент, эшкәртүдән калган металл калдыклары төйи. Үзәккә үтәрлек салкын, ыжгырып торган үтәли җил, ышыкланыр һичбер урын юк. Бу суыктан тоткыннар төренеп изаланган сәләмә киемнәр генә коткарырлык түгел. Бияләйләр юк, яланкул эшлиләр, вагоннарны ахыргача тутырырга кирәк. Утыз-кырык килограммга калган ирләр, вагон өстенә менеп сикергәләп, йөкне тыгызлыйлар... «Эсэс»чылар исә учак янында җылына, киемнәре дә калын. Лагерьдан эшкә чыгып киткән тоткынның үз аягында кайтуы – җан исәбе мәҗбүри түгел алар өчен, тән исәбе генә тулсын, калганы өчен «эсэс»чылар җавап бирми.

Аяклар гөбедәй шешенде, куллар көч-хәл белән хәрәкәтләнә. Җаны гына чыкмаган бу гәүдәне нинди көч һаман йөртәдер – Сәләй үзе дә аптырый. Ләкин бирешергә ярамый, ярамый. Ничек тә егылмаска, түзәргә кирәк. Сугыш тиздән бетәчәк, безнекеләр инде фашистны өненә ныклап куа диләр әнә. Телдән-телгә әсирләр сөйли моны, пышылдап, бик сагаеп, колактан-колакка... Әлбәттә, мәхбүсләргә таратыла торган «Фолькишер Беобахтер» исемле немец гәҗите киресен яза. Әмма алман телен сукалаучы кайбер егетләр, анда язганнарның аркылысын буйга салып та, фашистның хәле хөрти булуын чамалый. Сугыш беткәнче исән каласы иде, үләргә ярамый! Әмма йөрәк ышыгында лепердәп торган ул ышаныч торган саен сүнә-сүрелә бара. Ир яхшы аңлый: болай дәвам итсә, тиздән аяк сузачак ул. Көннәр суытканнан-суыта, җилнең тынганы юк. Япа-ялан кырда вагон төяүдән ничек тә котылырга, ничек тә завод эченә, ышыкка эләгергә кирәк.

Иртән тора алсам да, көндез аякта кала алмам дип уйлады Сәләй.

Иптәшләре ташламас анысы, лагерьдан култыклап алып чыгарлар чыгуын, әмма кырда аны сөйрәп йөри алмаслар. Күрәләтә кемнең пуля аласы килсен. Егылыр ул. Гәүдәсен арбага төягәнче тәненнән җаны аерылып өлгерсә ярар иде лә, Раббым...

– Арагызда слесарьлар бармы? – Ишек катына кереп баскан немецның әче тавышыннан барактагылар сискәнеп китте.

Тынлык.

Бәлки бу үлемнән качып калуның соңгы юлыдыр?.. Ә бәлки үлемгә туры юлдыр. Ялган барыбер ачыкланыр бер. Малайчактан бирле кулына игәү дә тотып караганы юк лабаса. Алдавыңны белсәләр, ике дә уйламыйча, шундук атып үтерәчәкләр. Җавап булмагач, немец ишеккә борылды.

– Мин! – Сәләй, бар көчен җыеп, яткан җиреннән торып басты. – Мин – слесарь...

***

– Сезнең каныгыз азайган. Менә сугыш бетәр, теләгәнчә шикәр, яшелчә, җиләк-җимеш ашарсыз. Йоклау – кан азлыктан ул...

Йокымсырап утырган балаларга йомшак кына шулай диде Рәмзия һәм, соры тунының җиңеннән кулларын чыгарып, учларына тын өреп алды. Сыйныф бүлмәсе бик салкын. Дәрес биргәндә, тының ак бу булып һавада тирбәлеп тора. Арча педагогика училищесындагы салкын бүлмәләрнең берсендә авыллардан, якын-тирә районнардан җыелган балаларга татар теле грамматикасы укыта ул. Шәкертләр төрле һәм бик охшаш та: әтиләре, абыйлары, туганнары сугышта. Кайсы исән, кайсы юк инде... Бу балалар да нәкъ Рәмзиянең өендәге ике сабые кебек бер телем икмәккә тилмерәләр. Ачлыктан, суыктан дәрестә йоклап та киткәлиләр. Ачуланмый аларны Рәмзия. Йокы кан азлыктан ул.

...1937 елның җәендә, Сәләй белән җитәкләшеп, эшкә кайтып төшкәндә, Арча педагогика училищесы гөрләп торган чаклар иде. Монда күптән түгел генә эшли башлаган дуслары Гали Халит бик мактап чакыргач, ике дә уйламый, Арчага юл тотылар. Бөтен байлыгы бер чемоданга сыеп беткән яшь гаиләгә бәхет өчен күп кирәкме?! Вәгыйзовлар тулай тораклан бирелгән үз куышларында, булганына куанып, булырына ак хыял юллары түшәп, тормыш корып җибәрделәр.

Училищеда студентлар саны күп: татар төркемнәре генә түгел, бер рус һәм бер удмурт группасы да бар иде. Егерме бишләп укытучы, аларның күбесе өлкән яшьтәгеләр, яшьләр сирәк. Шуңадырмы, Сәләй белән Рәмзияне күз карасы кебек кадерләделәр, гел ярдәм итеп, үсендереп тордылар. Ике ятим җанга шуннан артыгы кирәкми дә: үзеңне кадерле итеп тоюга ни җитә бу дөньяда! Очынып, эшкә тотындылар, түгәрәкләр, иҗат берләшмәләре оештырып җибәрделәр. Ничек өлгергәннәрдер: гәҗит-журналларда фәнни мәкаләләре дә чыга торды, методика буенча ярдәмлекләр дә яздылар. И яшьлек, яшьлек... Гомерең генә кыска икән шул синең, хактан да.

Кызлары Римма туар алдыннан Сәләй Арчага әнкәсен дә алып килде. Карчык ялгызы гына яшәп ята, яше дә бар. Бергә торсак, аңа да җайлы булыр диделәр. Бәбидән котылгач, Рәмзия өйдә озак юанмады. Бераз хәл җыйды да эшкә чыкты. Коллегалары, студентлары көтеп тора, эшлисе эшләре, язасы

хезмәтләре, әзерлисе спектакльләре күп – ничек өйдә ятмак кирәк?! Гайшә карчык кына бу хәлгә күнәргә теләмәде. Җай туры килгән саен:

– Һай тиле катын, тиле катын... Балаңны багар идең. Кыйтап язалар, янәмәсе. Нәстәмә кирәк ул сезнең кыйтабыгыз, бер балагызны багарга да вакыт табалмагач, – дип, Самар ягынча кыеп-кыеп сөйләве белән яшьләрне чеметкәләп алырга күп сорамый иде.

Ә Римма төн дими, көн дими елый да елый. Керфек йоммый чыккан төннәре дә булмады түгел Рәмзиянең. Бала буылып-буылып, сыны катып елый-елый да калтыранып йоклап китә. Рәмзия эш өстәле янына ашыга: тикшерәсе дәфтәрләре, язасы планнары җыелган.

Гайшә карчык үгет-нәсыйхәткә тотынды исә, Рәмзиясенең кәгазь-каләмне катырак кыштырдата башлавын сизеп, Сәләй хатынына күз кыса һәм әнкәсенең иңнәреннән барып коча:

– Йә инде, инәй. Йә инде... Бүген әллә нишләп кәефең китек шунда. Замана бит хәзер башка, инәй. Коммунизмга таба юл тотканда, хатын-кыз, бала чүпрәгенә батып, өйдә утырмас лабаса. Заманасы ул түгел. Менә синең киленең, ягъни мәсәлән югары белемле яшь белгеч, киләчәк буынга тәрбия һәм белем бирер урында бала имезеп, биләү юып, өйдә ятсынмы? Бер дә советча түгел инде бу, инәй.

Карчыкның да бирешергә исәбе юк:

– Заманасын-ниен белгән юк, улым. Үзгәргәндер, бардыр. Әмма адәм баласы дөньяга нәкъ элеккечә туа. Орып бирә ул сезнең сәвитегезне. Ашыйсы килсә – күкрәк сөте кирәк, астын юешләсә – биләвен алыштырырга! Инәй кирәк аңа, белдеңме, инәй кирәк... Балаңны күкрәгеңә кысып, тәмле искәйләрен исни-исни, изрәп күкрәк сөте дә имезмәгәч канә. Хөкүмәт эше дип монда, кыйтап язам дигән булып, тфү. Әйттем исә кайттым.

– И инәй, аңламыйсың шул син. Рәмзиянең бит аның өендә бер бала булса, училищеда йөзәрләгән баласы көтеп тора. Драмтүгәрәк җитәкчесе дә ул, сәхнә теленә дә, матур язарга да өйрәтүче...

– Өеңдәгесе генә үзеңнеке аның, саташмагыз. Тегеләре – инәләре менә шулай биерлек, җырларлык, укырлык итеп тупырдатып үстергән балалар. Үз әтәй-инәләре була торып, нишләп сезнеке булсын, ди, алар?! Шуларга бөтен җылыгызны, назыгызны таратып кайтасыз да үз балагызны сөяргә мәхәббәтегез калмый. Бушап кайтасыз сез, бик беләсең килсә. Ә бала кеше барысын да тоя ул. Менәтерә, ник болай үрсәләнеп елый дип беләсең син аны – инәй җылысы кирәк аңа, – дип, Гайшә карчык бала бишегенә иелә дә янә сукрана-сукрана дәвам итә, – Ииии, белмиләр, аңламыйлар, бала бит ул – Раббым Аллаһ биргән нигъмәт. Менә үзеңнекен җырларга өйрәт син, үзеңнекен биергә өйрәт. Күпме хатын бала сөяргә тилмерә бу дөньяда. Аллаһ биргәннең кадерен белмиләр. Әйме, Римма кызыкаем. Йә, йә, син дә алай елак булма, елап кына берни кырып булмый бу дөньякайларда... Исемен дә әллә нindине генә куштылар шунда. Һаман булса телем иямәшәлми...

Рәмзиянең йокысыз төннәрдән күгәргән күз төпләрен күргән күрше-күләннең, хезмәттәш хатыннарның кайсы кызгана, кайсы: «Бала елый-елый үсә инде ул», – дип юата иде. «Менә кырык көне үткәч, тынычланыр», «менә теш чыгып беткәч, туктар», «Тәпи киткәч җайланыр» дигән сүзләргә

юанып, көннәр-айлар үтә торды, тик бала елаудан башканы белмәде. Сөйләшмәде, уйнамады, ялтыравык, шалтыравык уенчыкларны бар дип тә белмәде. Бер ноктага карап сулкылдауда, аннан калтыранып йоклауда булды. Ә ике яше тулганда, Римманың психик авыру икәнлеге ачыкланды...

...Сугышның икенче көнендә үк училищены Арчадан унсигез километр ераклыктагы Үрнәк совхозына, механизаторлар мәктәбе бинасына күчерделәр. Арчадагы бина госпиталь өчен кирәк диделәр. Укучылар кимеде, дәресләр кыскарды. Вәгыйзовларны Субаш Аты авылы мәктәбенә укытырга билгеләделәр. Күченгәндә, Рәмзиянең йөрәк астында фани дөньядагы мәхшәрдән бихәбәр тагын бер нәни җан яралган иде инде. Гайшә карчык хак әйткән: җирдә берни дә үзгәрми, кеше дөньяга елый-елый килә тора, елый-көлә, сугыша-сугыша яши һәм китә тора икән.

Сугышка киткәндә, Сәләй һаман шул бер сүз кабатлады: «Кичер, кичер...»

Бичара Римманың нәүмиз күзләреннән үпте, алты айлык улы Камилнең бәллүенә йөзен терәп торды, Гайшә карчыкның арык иңнәреннән кочты һәм Рәмзиянең күзләренә өздереп-өздереп, озак итеп карап торды.

– Исән кайт. Кайтмасаң, кичермәм, – диде Рәмзия.

***

Кая куалар аларны?..

Төнне ярып, алга – билгесезлеккә үрелгән юл буйлап гәүдәләр бара. Тире дә сөяккә калган шул гәүдәләргә чак эләгеп торган җаннарда өмет дигәнең тыпырчына бит, шайтан алгыры. Югыйсә бу газаплардан котылу өчен бер адым җитә. Колоннадан читкә бер адым каер – һәм вәссәлам... Барлык сызлану-әрнүләр, өметләр һәм өметсезлекләр юкка чыгачак. Бер уйласаң, туу белән үлем арасында әнә шул бер адым гына бар. Адәм заты шул адымны мөмкин кадәр озаккарак сузарга тырышып тыпырчынган була. Тормыш – ике яр арасындагы бер адымлык күперне кичү ул нибары. Бер адым.

...Сәләйнең күз алдында Гришаның сүнгән карашы уйнаклап алгандай булды. Күзләре үле иде инде егетнең. Күзләре – сүнгән, ә иреннәре... елмая иде. Сәләй барысын да аңлады, ләкин туктатырга өлгермәде. Лагерьны тышаулап торган токлы чыбыкка сабый бала әнкәсенең иңнәренә асылынган кебек барып асылынды Гриша... Гәүдәсе, керле кулъяулык төсле, җилдә җилфердәп, берничә көн торды.

Аларны төнлә лагерьдан алып чыктылар да каядыр алып баралар менә. Кая? Крематорийгамы? Як-яклап, «шнель, шнель»ләп конвойлар куалый, арттан – ике-өч машина. Колонна койрыгында ату тавышлары ишетелеп ала: хәлсезләнеп артта калганнарны «чүплиләр». Сәләй башын чайкап алды. Түзәргә, түзәргә кирәк. Фронт сызыгы ерак түгел, ату тавышлары лагерьга кадәр ишетелә иде бит. Артта – үзебезнекеләр, артта – ирек, Рәмзия, балалар... Исән калдырасы булсалар, болар безне лагерьда ташлап китәрләр иде дигән уй баш миен куырып ала. Үлемгә барабыз.

– Качарга кирәк... – Сәләйнең уйларын укый диярсең, Николайның калтыравык тавышы ирнең чигәсенә килеп бәрелде. Уң яктан, колонна читеннән атлый иде ул. – Чамалабрак бар...

Сәләй баш какты.

Юл читендә авып, янып яткан машинаның яктысы ерактан ук шәйләнде. Төтене тоткыннар үтәсе юл өстен ялап тора.

– Хәзер... – Николайның тавышы каты иде. Төтенле урынга җиткәч, ике ир машина артына ташландылар...

...Кача-поса алар килеп егылган шәһәрчек америкалылар кулында иде. Буй-буй зәңгәр сызыклы киемнәреннән, шыр сөяккә калган гәүдәләреннән үк кай җәһәннәмнән качулары күренеп торган бу икәүне хәрби комендатурага алып килделәр. Тәрҗемәче аша, кемлекләрен, кайда кайчан әсир төшүләрен, кай лагерьда булуларын кыскача гына сорашкач, офицер икесенә ике кәгазь язып бирде. Тәрҗемәче боларның ашату өчен карточкалар булуын аңлатты.

– Илегез коммунистлар кулында чакта, демократия булмаячак. Сезне анда үлем яки төрмә көтә. Мин сезгә Америка Кушма Штатларына китәргә тәкъдим итәм, – диде офицер берникадәр тантаналы тавыш белән.

Сатлыкҗаннар, намусы чиста булмаганнар качсын әнә. Ватан алдында Сәләйнең бер гаебе дә юк. Чакыру кәгазе килгәч, кеше рәтеннән сугышка китте. Арчада сәламәтлеген тикшереп, комиссия үткәреп мәшәкатьләнмәгәннәр иде, күзләре начар күрүе, атарга яраксызлыгы фронтка керер алдыннан гына ачыкланды. Кире кайтып китәргә дә мөмкин иде бит ул, андый хакы бар иде. Демобилизация турында карар да килгән иде. «Бөтенесе дә сугышканда, син өйгә таярсыңмыни?» – диде парторг. Ничек кайтып китсен, калды, китмәде, үз теләге белән сугышка керде. Гаеп дип исәпләргә яраса, ирнең бердәнбер ялгышы шушы булгандыр. Тикшерерләр, тикшерми калмаслар...

Җиңү уңаеннан май башында шәһәрчектә Америка гаскәрләре парады узды. Ул вакытка биредә лагерьлардан исән калган төрле милләт тоткыннары бик күп иде инде. Котлаулар, көлү тавышлары һәм күз яшьләре... Җиңү шатлыгы шәһәрчектә гомер кичерүче гади алман кешеләренең күзләрендә дә балкый иде. Сугыш дигән афәтне милләтләр түгел, адәми затлар башлый шул. Ләкин сугыш һәрвакыт милли байракка төрелә. Байракка биләнеп, кешелек бәгыренә ыргытылган бомба ул сугыш...

Көттереп кенә килгән майның ахыргы көннәре иде. Әсирлектән котылган Совет солдатлары лагере янына Америка һәм СССР байраклары белән бизәлгән машиналар килеп туктады. Шәһәрнең берничә җирендә оештырылган бушлай ашату урыннарында тамак туйдырып, шактый көрәйгән, шат чырайлы ирләр машина арбаларына көлешә-көлешә урнаштылар. Илгә, өйгә кайтабыз! Ниһаять! Берәү җыр сузып җибәрде:

«Шёл казак на побывку домой,
Шёл он лесом, дорогой прямой...»

Озак бармадылар, машиналар туктагач, ирләр җиргә сикерде. Американ шофёрлар елмаеп саубуллаштылар да кире кузгалдылар. Тик биредә ирләргә сәлам бирүче булмады. Коры гына рәсми боерыклар белән утызар кешелек төркемнәргә бүлделәр дә кабат машиналарга төяделәр. Тоткыннар кереп урнашкач, кузгалып китәр алдыннан яшь кенә бер солдат кабина эчен

карашы белән айкады һәм теш арасыннан: «Сатлыкҗаннар...» дигән сүз сытып чыгарды. Аннан, шушы гыйбарәнең тешенә сыланып калуыннан шүрләгәндәй, лач итеп җиргә төкерде дә шапылдатып ишекне япты. Машиналар көнчыгышка кузгалып киттеләр...

***

«Бүген үләм. Бүген исән калу юк...»

Тоткыннар, берсе өстенә берсе өелешеп, мөмкин кадәр бергә укмаштылар. Әмма тәрәзләреннән, ишегеннән суык өреп торган баракта алай гына җылынырлык түгел иде. Себер шул бу.

Товар ташый торган вагонда ике ай буе килделәр алар монда. Аңа кадәр СМЕРШ камералары... Тоткыннарның күбесе Сәләй кебек үк җәен кулга алынган – өстә кием-салым җәйгечә. Вагонда тимер мич тора, әмма утынны аз бирәләр. Көн саен, качып китү җаен карамыйлармы дип каккалап-суккалап, вагоннарны тикшергәндә, сакчылар мәхбүсләрне дә кулларында ни бар – шуның белән кыйный иде. Ашарга – бераз икмәк тә тозлы балык. Аны ашагач, кибегәсең, әмма су аз. Печорага килеп җиткәнче үк ачлыктан, суыктан, кыйналудан үлүчеләр шактый булды. Бичараларның фашист концлагерьларын кичкән какча гәүдәләре Совет иле юлларында ятып калды... Эшелоннар белән китереп бушаткач, хәлсез ир-атларны бил тиңентен кар өстеннән шактый кудылар әле һәм менә шушы иләк сыман баракка кертеп яптылар.

«Үзәкөзгеч суык. Бүген исән калу юк. Бүген үләм...»

Утын әрдәнәләре кебек кеше гәүдәләре арасында яткан Сәләйнең аңында шушы сүзләр тыпырчынды. Тыпырчынды-тырнады да тир, кан, ыңгырашу, сүгенү, дога кушылган тоташ гүләүдә юкка чыкты. Ир күзләрен йомды.

...Ул калтыранган куллары белән китапка үрелде дә, чормага сак кына саркылган көн яктысында, «Җәвамигъ әл-каләм шәрехе» дигән сүзләрне искәреп, үрелгән кулы һавада асылынып калды. Бер мәлгә башы әйләнеп, күз аллары караңгыланып китте, чигәсендә нидер сулык-сулык суга башлады, йөзе кызышты. Ул, ярдәм эзләгәндәй, тирә-ягына карады. Торган саен куерган төтен арасыннан иптәшләренең сыннары шәүлә кебек кенә шәйләнә, ул шәүләләр өй кыегыннан чорма түренә, чормадан кабат өй кыегына туктаусыз кымырҗыйлар. Егет китап белән күзгә-күз иде.

Йорт кыегына җитәрәк кенә бәбәкләрен көн яктысына ачарга кыйды ул. Көн каралып, шәфәкъ томаланган, эңгер-меңгер җәелгән. Ихтимал, эңгердән өстәрәк, бик күпкә өстәрәк ай кабынгандыр, әмма егет күккә бакмады.

Китап, саргайган ак канатларын соңгы кат җилпеп, аска очты...

Китап арты китап битләрен ялмап үрсәләнгән учак өстән аермачык күренә, уты йөзне пешерә иде хәтта. Ялкын телләре шашып бииләр. Менә берсе «әлиф» булып күккә үрелде, икенчесе – «ләм», өченчесе «мим» сыман боргаланып сузылды...

Менә учак телләре аның үзенә кадәр үрелделәр, богау булып кулларына, аякларына сарылдылар. «Әлиф»ле ялкын күкрәгенә суга башлады. Ул бу богаудан ычкынырга теләп чәбәләнде, борсаланды, әмма чуала гына барды...

...Күзләрен ачып җибәрсә, күкрәгенә типкәлиләр икән. Сәләй авыртудан

ыңгырашып куйды. Тәне тошаш ут булып яна, кызу, һава җитми. Югыйсә шул ук салкын барак идәнендә ята, ахры. Үтереп су эчәсе килә. «Су» димәкче иде дә, күкрәгеннән аңлаешсыз сызгыру гына чыкты.

– Живой шоли, гнида? Этого к «доходягам». Если дойдет...

Юк, үләргә ярамый!..

Үлем җәза түгел. Кешелекнең коты күтәрә алмас кабахәтлек кылган җинаятьчеләр өчен иң авыр җәза үлем диләр. Ялгышалар. Үлем – җәзадан арындыру, аралау, үлем – ярдәм ул. Сәләй менә хәзер шушында өзелсә, җаны тәннән арынса, кичәргә тиешле җәзаларын кичмичә китәчәк. Юк, үзе кылган гөнаһ өчен үзе җавап бирергә тиеш ул, җәзасы фәкать үзенә генә тиеш. Ә гөнаһы зур, җиде буыныңа җитәрлек... Теге караңгы төннән бирле аның бөтен тормышы – җәза мәйданы. Инде менә әсирлеккә төшеп, лагерьдан-лагерьга тибәрелеп йөри башлаганнан бирле җан газабына тән газаплары да өстәлде. Ни хикмәт, тән газабы җан газабын оныттыра икән. Газабын биргән дөнья дәвасын да бирә, аңласаң. Ир шуңа күрә дә тәне тойган һәр авыртуны, суыкны, карыны тойган һәр мизгел ачлыкны, һәр сугылуны-кагылуны рәхмәтле булып кабул итәргә өйрәнде. Болар барысы да – аның тәкъдиренә тиеш җәза. Фани тормышта михнәтне никадәр күбрәк, кырысрак кичкән саен, җан газабының кими баруын тойды ул. Ул җәзаланырга тиеш: теге төндә утка ташлаган һәр китап, шул китапларның һәр бите, һәр хәреф өчен... Үләргә ярамый...

***

...Мең тугыз йөз кырык өчнең кышыннан бирле, «билгесез югалды» дигән кәгазьдән гайре, Сәләйдән бер хәбәр дә юк. Кеше тиклем кеше ничек югала алсын? Сәләй бит ул! Кем-кем, әмма аның Сәләе югала торган ир түгел. Күңелен чарасызлык корты кимерә башласа, Рәмзия үзен шушы сүзләр белән юата.

Сугыш беткәнгә дә елдан артык. Бәхетле хатыннарның ирләре кайтты әнә, аксап-туксап, аяксыз-кулсыз калып булса да, кайттылар. Ярты гәүдәгә калса да, ир кеше – ир кеше инде, ирле хатынның тавышы бөереннән чыга аның. Әхмәди хатыны Сәкинәне генә күр: кибеткә эшкә, түшен киереп, урамның уртасыннан йөри хәзер. Күрми дә ул сине, сәламеңне дә алмый. Әхмәди Һадиатуллович, сугыштан исән-сау кайтып, кабат укыта башлаганнан бирле, педучилищеның бөтен хатын-кызын күралмас булды Сәкинә. Шул көрән чырай белән күзгә-күз очрашмас өчен генә дә кибеткә кермәссең, валлаһи.

Тиккә генә көнләшмидер анысы, күзеңне ачыбрак карасаң, ир затының ни уйлавы йөзенә язылган була аның. Хатын-кыз шуны аңламаганга салышыр дәрәҗәдә акыллы булсын, йә аңламас дәрәҗәдә җүләр булсын икән. Ә Сәкинә кебекләргә авыр.

– Һай, бу чибәрлекләрең белән әрәмнәр генә булып ятасың инде, Рәмзия Гыйләҗевна. Ялгызыңа гына күңелсездер...

Әхмәди Һадиатулловичның төче тавышынан чирканып куйды хатын. Дәрес конспектлары белән әвәрә килеп сизми дә калган: укытучылар бүлмәсендә икесе генә икән бит. Карашы Әхмәдинең майлы күзләре белән очрашты.

– Нишләп ялгызым булыйм, Әхмәди Һадиатуллович. Ике балам, эшем

бар. Сәгатьләрем күп, шөкер. Өч татар төркеме өстенә бер рус группасы да ачылды бит менә. Моңаеп утырырга һич вакыт юк. – Рәмзия башын җүләргә салды, елмаерга тырышты.

– Шулаен шулай да. Синдәй янып торган хатынга еллар буе ялгыз түшәктә салкындыр диюем инде...

– Җылыткычың кыздымыни?! Сәләем кайтсын гына – бик тиз суытыр ул сине. Оятсыз! – Хатын үз тавышын үзе танымады.

Әхмәди әңгәмәнең мондый юнәлеш алып, юаш кына тоелган Рәмзиянең кызып китүен көтмәгән иде булса кирәк, бер мәлгә югалып калды. Шулай да кәгазь-дәфтәрләрен җыеп, кабинет ишегеннән чыгып баручы хатынга агулы ук атарга өлгерде:

– Сәләй кайтмый ул. Хыялланма.

Көллияттә башка качар урын юк иде: бәдрәф ишегенә сөялеп, түгелеп елады Рәмзия. Кемнәрнедер яңаклый-яңаклый кыйныйсы килде аның. Үксүен ишетмәсеннәр дип, бармакларын тешләп бетерде. Әгәр Әхмәди хаклы булса? Әгәр Сәләй чынлап та кайтмаса? Шулай булу бик ихтимал бит. Исән булса, бер хәбәр салыр иде ичмасам. Билгесезлектән дә авыр нәрсә юктыр бу дөньяда. Юкса, исән дисәләр, гомер буе көтәргә дә әзер лә.

Өйгә кайтышлый, кибеткә кермәде ул бүген. Беркемне дә күрәсе дә, беркем белән сөйләшәсе дә килми иде, Сәкинә белән бигрәк тә. Балалары янына елмаеп кайтып керер өчен, күңелендәгесен аларга сиздермәс өчен көчләр каян аласы? Тын яуган кар бөртекләренә йөзен куеп, урам читендәге сукмактан акрын гына атлады. Кыш кыш инде. Кышын дөнья чуарлыгын качыру җиңелрәк: барысын да кар күмә дә китә. Дөнья аклы-каралы була да кала...

Ишек катыннан ук Гайшә карчыкның агарынган йөзенә сөрлекте.

– Балам, иртәдән бирле сине көтәм. Пучты кызы бер кыягаз китерде. Укып бак әле. Сәләемнән бер-бер хәбәр юкмы... Хәреф танымыйм лабаса...

Карчыкның кулларында конверт калтырый. Күрәсең, ул аны көне буе кулыннан төшермәгәндер, соры конверт кәгазе карчыкның җыерчыклы бармаклары сымангa әйләнгән. Тышындагы «Коми АССР, город Печора», «Газизьян Гатауллин» дигән сүзләрдән бераз каушап калды Рәмзия. Ләкин конверт эчендәге хат язуын шундук танып алды һәм кычкырып җибәрмәс өчен иреннәрен тешләде. Сәләй язуы. Сәләйнеке!..

***

Бу поездның тәгәрмәчләре ник гел бертөсле тыкылдыйлар икән? Тыкы-тыкы, тыкы-тыкы... Әнисе әйтә: «Поездның тәгәрмәче юк. Рельслар буйлап шуып бара ул», – ди. Тыкылдамый ул, Камилне сәламли икән. «Камил-Камил, Камил-Камил» дип әйтә ул», – ди әнисе. Камил игътибар белән тыңлап караган иде, чыннан да, шулай икән шул. Поезд аның исемен кабатлый-кабатлый шуып бара икән. Ура! Камил поездда бара!

Әнисе әйтә: «Тиздән Мәскәүгә җитәбез», – ди. Мәскәү иң зур шәһәр икән. Поезд шуып барган юл читендә җимерек танклар, пушкалар, тагын әллә нәрсәләр күренеп кала. Камил тәрәзә пыяласына беректе. Их, урамдагы малайлар күрсәләрме, көнләшүдән шартларлар иде. Сөйләсәң, ышанмаслар да әле. Римма апасы белән әбисе дә алар белән барса, күңеллерәк булыр иде дә, әнисе: «Дүртебезгә дә билет алырга акча җитми, – диде шул. – Болай

да бурычка баттым». Танклар күренгән саен, малай кулларын чәбәкли-чәбәкли сөенеп кычкыра:

– Әни, кара! Кара! Танк!..

Алар кунакка бара торган шәһәр Мәскәүдән дә арырак икән. Әллә ничә көн бардылар. Ниһаять, төштеләр. Поезд, Камил белән саубуллашып, кычкыртып алды да үз юлы буйлап китеп барды. Шуннан соң машинага утырдылар. Машина йөртүче абыйга әнисе малайга аңлашылмый торган телдә нидер әйтте, аннан акча түләде. Машинадан төшкәч, озак кына тәпи-тәпи атладылар. Камил арып бетте, ләкин, елыйсы килсә дә, түзде. Әнисенә аннан да авыррак, берүзе ничә сумка күтәреп бара әнә. Ул биштәрләрне алар Гайшә әби белән әллә ничә көн җыйдылар.

Тимер капка янына килеп туктагач, Камилнең арулары онытылды. Капка янында автомат тоткан абый басып тора иде. Чып-чын автомат! Камилнең күзе маңгаена менде. Әнисе ул абыйга ниндидер кәгазьләр күрсәтте, ят телдә нидер аңлатты һәм акчалар бирде. Шуннан соң гына автоматлы абый, капканы ачып, аларны эчкә үткәрде.

Тагын әзрәк баргач, аларның каршысына ниндидер бер ямьсез абый йөгереп килде. Йөрегеп килде дә әнисен кочаклап алды. Кара инде, әнисе дә таушалган киемле, сакал-мыек баскан шул килбәтсез абыйны кочаклаган. Әллә Камил турында бөтенләй онытты инде, борылып та карамый, һаман шул абыйны кочаклап тора. Камил түзмәде, кычкырып елап җибәрде. Шунда гына әнисе, теге ямьсез абый кочагыннан чыгып, малайга иелде. Үзе елмая, үзенең күзләреннән яшь ага.

– Улым, кил, таныш. Бу – синең әтиең, – диде әнисе.

«Әти» дигән кеше шушындый була микәнни?!

Абый, елмая-елмая, Камилне күтәреп алды.

– Сәлам, Камил улым! Оһо, син тәмам егет булгансың бит инде!

Абый, сакал-мыеклары белән кытыклый-кытыклый, Камилнең битләреннән үпте. Аннан күккә чөйде. Малай кычкырып көлеп җибәрде. Болытларга башы бәрелер кебек тоелды. Моңарчы әле аны беркемнең дә болай чөйгәне юк иде. Шуннан соң «әти» аны җилкәләренә утыртты да:

– Әйдәгез, өйгә кайтабыз, – диде.

«Землянка» дигән өйдә алар бер атна яшәделәр. Әтисе, Камил уянганда, өйдә булмый, кич караңгы төшкәч кенә кайта. Ул кайтуга әнисе ашарга әзерли, самавыр кайната. Землянка янында биек-биек наратлар үсә. Камил шул наратлардан коелган күркәләрне җыя – самавырга салырга. Монда Камил кебек малайлар бар барын да, ләкин алар татарча белмиләр, русча гына сөйләшәләр. Ә Камил аларча белми. Шуңа да юньле-рәтле уйнап та булмый. Камилгә күңелсез була башлады. Әнисе исә елмаеп кына тора. Әнисенең болай озак елмайганын малайның беркайчан да күргәне юк иде әле. Шулай да берничә тапкыр: «Әни, әйдә кайтыйк инде. Монда кишер дә юк икән...» – дип җайлап кына әйтеп карады. Кишерсез яшәп була димени?

***

Лесокомбинат – Төньяк-Печора тимер юлы төзелешен – НКВД алып бара торган «бөек» төзелешне материал белән тәэмин итә торган төп завод. Юл түшәр өчен шпаллар, баганалар, шулай ук җыелма йортлар өчен борыслар,

җиһазлар, коймалар, мәхбүсләр өчен бараклар, нарлар – болар барысы да шушы заводта һәм тоткыннар хезмәте белән әзерләнә. Язмыш дигәнең бу юлы мәрхәмәтлерәк булдымы, «сатлыкҗаннарны» бригадаларга бүлгән вакытта Сәләй лесокомбинатка эләкте. Ул вакытта, 1946 елны, мәхбүсләр өчен шартлар яхшырган, үлүчеләр саны шактый кимегән иде.

Тимер юл төзелеше башлангач та, монда «халык дошманнары»н китергәннәр. Ачлыкка, авыр хезмәткә, мыскыллауларга түзәлмичә шактый кеше кырылган, алар урынына яңаларын ташый торганнар. Рәсәйдә «дошманнар» җитәрлек ул, эзләргә боерык кына булсын... Миша дәдәй сүзләренә ышансаң, ике ел эчендә меңнән артык кеше җан тәслим кылган монда. Алдамыйдыр, мәетләрне зонадан үзе ташыган кеше ялганламас. НКВД этләре никадәр каты кылансалар да, җитештерү күләме артмаган. Кеше үтереп кенә эш кырып булмаячагы башларына барып җиткәнме, әллә төзелешне өзсәләр, үзләренең дә зона белән «бүләкләнәчәкләре» шүрләткәнме – кырык алтыда дилбегәне бераз бушатканнар.

Сәләйләр колоннасында, нигездә, «илле сигезенче статья»ныкылар. Болар, «уголовник»лардан аермалы буларак, намуслы халык, тырышып эшлиләр. Ә эш авыр. Бүрәнәләр комбинатка тимер юл белән дә, Печора елгасы буйлап су юлыннан да килә. Бозлы суда бата-чума бүрәнә чыгаргач, үпкәсе шешеп, лазаретта дөнья куючылар аз түгел. Кием начар, ашату – ачтан үлмәслек кенә. Ичмаса, баракларда җылы, анысына куанырсың. Мичкә ягарга калдык-постык такта, агач кисәкләрен алып кергәнгә сүз әйтмиләр.

«Гыйлем – беркем дә, беркайчан да талап алалмаслык байлык ул», – ди торган иде Сәләйнең үги әтисе. Үлгәндә дә, хатынына: «Малайны укыт», – дип васыять итеп киткән. Инәсе мәрхүм иренең сүзен аяк астына салып ташламады, башта Богарысланда, аннан Оренбурда укыды Сәләй, аннан, белем эстәп, Казанга юл тотты. Яков Федорович Стрельников белән танышып, якынаеп киткәч, атасының шул сүзләрен күңеленнән җөпләп куйды ул. Яков – утыз сигездә үк кулга алынган кеше. Аңарчы зур гына бер заводның җитәкчесе булган, «корткычлыкта» гаепләп, егерме биш елга Себер сөргәннәр. Бу срокка утыручылар махсус лагерьларга озатыла, ә Яков Федорычны лесокомбинаттан җибәрмәгәннәр. Акыллы, гыйлемле, үзфикерле, эшне дөрес һәм гадел оештыра белүче инженер – завод җитәкчелегенә алыштыргысыз кирәкле кеше. Тоткыннар арасында да хөрмәте зур. Яков Сәләйне башта ук үз итте. Күрәсең, бу икәүнең холкында охшаш сыйфатлар күп булгандыр. Тиң күргән, иш санаган кешеләр сирәк бу дөньяда, мондый тоткынлык шартларында бигрәк тә. Андый кешене очрату – үзеңне табу белән бер. Яков белән Сәләй арасында да әнә шундый җылы, ихлас рухи якынлык бар иде. Бу хис дуслык дип аталадыр, мөгаен.

Комбинатта тоткыннар гына түгел, сәнәгать зонасында гаиләләре белән яшәүче ирекле кешеләр дә эшли. Аларның күбесе элекке мәхбүсләр булып, биредәге шартларны яхшы белгәнгә, тоткын иптәшләренә төрлечә ярдәм итәргә тырышалар иде. Заводта утчы булып эшләүче өлкән яшьтәге Газизҗан абзый белән танышу Сәләйгә язмыш тарафыннан тагын бер бүләк иде. Тумышы белән үзе дә Самара якларыннан, Камышлыдан булган Газизҗан – татарның дөнья буйлап сибелгән бер ярчыгы. Карчыгы белән завод зонасында, ике катлы йорттагы фатирда яшәп яталар. Сәләйне туганы

кебек якын күрде ул. Рәмзия белән Сәләйнең хат алышуы да шушы игелекле кешеләр ярдәме белән мөмкин булды.

Яков Федоровичның яхшы элемтәләре, Газизҗан абзый һәм аның хатынының игелеге аркасында, Сәләйнең гаиләсе бирегә килеп, ир алар белән бер атна яши алу бәхетенә иреште. Кырык җиденең җәендә Печорага Камил белән генә сәяхәт кылса, кырык сигездә Рәмзия ире янына ике баласын да ияртеп килде. Бәхетле сәгатьләр бу юлы унбиш көнгә җыелды. Әмма шушы көннәрнең шатлыгы, рәхәте бәрабәренә айларга, елларга сузылган михнәт көтәсен ул вакытта ир дә, хатын да белмиләр иде әле...

***

Ире янынан кайтканның икенче көнендә Рәмзияне райкомга чакыртып алдылар. Кабинет түрендә techинститутта бергә укыган сабакташы Гафуров Закирны күргәч, Рәмзиянең күңел калтырануы бераз кимегәндәй булды. Гафуров, сугыштан кайткач, райкомның икенче секретаре итеп билгеләнгән иде. Кабинет хуҗасы ни беләндер гаять мәшгуль, күрәсең, Рәмзия ханым кергәч тә, күпмедер вакыт карашын өстәлендәге кәгазьдән аермады. Ханым, килеп керүгә ирештергән сәламенә җавап алмаган хәлдә, ишек төбендә нәүмиз басып тора бирде. Шактый торгач, Гафуров башын күтәрде дә «кеше бар икән» дигән сыман тәкәллефсез караш белән урындыкка ымлады.

– Үтегез.

Рәмзия аркалы авыр утыргычның бер читенә чүмәште. Түшәмгә асылган люстра сыман авыр тынлык дәвам итте. Ул менә-менә Рәмзиянең башына ишелеп төшәр сыман иде.

– Сезне сәяхәттән кайткан, диләр, иптәш Вәгыйзова. Бу дөресме? Кайда булдыгыз?

Кайчандыр бергәләп шау-гөр килеп укып йөргән, яшьлекнең язгы кояш нуры кебек самими якты чорын бер үк сукмакларда уздырган кешенең бүген килеп менә шулай «иптәш Вәгыйзова» дип эндәшүе Рәмзия өчен сәер тоелды. Икенче яктан карасаң, нәрсәсе гайре табигый булсын: ул – гади мөгаллим, ә Гафуров – райкомда, олы кеше...

– Ирем янына бардым.

– Халык дошманы янына йөрисез, димәк?! – Гафуровның тавышыннан люстраның пыяла бизәкләре зеңгелдәп куйды сыман.

– Ул халык дошманы түгел...

Иптәш Гафуров Рәмзиянең зәгыйфь сүзләрен гүя ишетмәде дә, һәр сүзен кадаклап-кадаклап куйгандай коры тавыш белән дәвам итте:

– Сез – укытучы кеше. Халык дошманы хатыны булып, балаларга нинди тәрбия бирә аласыз. Ник бардыгыз анда?!

– Ул халык дошманы түгел, иптәш Гафуров... – Ханымның яңакларыннан хыянәтчел яшь бөртекләре тәгәрәде.

– Бүгеннән сез эшегездән азат ителәсез. Тулай торактагы бүлмәгезне дә бушатырга туры килер.

Рәмзия бу хәтлесен үк көтмәгән иде, шашып калды.

– Балаларым... Минем ике балам, авыру карт каенанам бар. Кая барыйм?! Иптәш Гафуров... Зинһар өчен...

Гафуров кәнәфиеннән торып басты һәм, кулларын як-якка җәеп,

өстәленә таянды. Шулай басып торган хәлдә өстән Рәмзиягә текәлде. Бу урында тынлыкны мөмкин кадәр озаккарак сузарга кирәген ул кәнәфи билгән барлы-юклы берничә ай эчендә интуитив рәвештә чамаларга өйрәнгән иде инде. Әйе, драманың бу өлешендә сүзне көттеребрәк әйтү мәслихәт. Урындыкта шәлперәеп утыручының өмете дә, өметсезлеге дә бер булып төенләнгән мәл бу. Аның язмышы хәзер Гафуров кулында һәм фәкать Гафуров авызыннан чыгачак карарга бәйле. Тынлык тетрәп торган тантаналы мизгелләр! Ниһаять, икенче секретарь, чыраена миһербанлык төсмерләре чыгарып, тамак кырып куйды:

– Эшсез, ашсыз урамда торып каласыгыз килмәсә, бу четерекле ситуациядән бердәнбер чыгу юлы бар, иптәш Вәгыйзова.

Ханым, мөлдерәмә зәңгәр күзләрен тутырып, өмет белән кабинет хуҗасына текәлде. Бәгыре таш түгелдер ләбаса бу бәндәнең дә, бергә укыган сабакташ, Сәләй белән дус-иш булып йөргән кеше бит...

– Әйе, бер юл бар, – дип дәвам итте Гафуров. – Ирегездән аерылыгыз!..

***

Җанына урын табалмаган чакларда, Сәләй Яков Федорович белән сөйләшеп бушана. Акыллы кеше белән гәп кору эсседән әлсерәгән чүлгә коеп яуган яңгырга тиң: дөньяң киңәеп, сулышың иркенәеп кала.

– Бәхетле син, Сәләй, – диде Яков, ни өчендер көрсенеп. – Синең Раечка декабрист хатыннарыннан да болайрак.

Федорыч Рәмзияне шулай үз теленә җайлаштырып «Раечка» дип атый иде.

– Мондый хатының барда, утны да, суны да кичәргә була. Көтәчәк ул сине. Иң мөһиме – көтәр кешең булу, кешене кайда да булса, кем дә булса көтәргә тиеш, аңлыйсыңмы? – Федорыч, кырлы стаканны бугазына бушатты да шапылдатып өстәлгә каплады һәм бушлаты җиңен иснәп алды. Газизҗан абзый көмешкәне шәп куа анысы, ни аз сүзле Яковның да күңелендәгесен теленә чыгарырлык итеп. – Ир-ат өчен иң кирәге ирек, диләр, менә. Воля! Пычагымамыни ул, әгәр кайтып бикләнер ызбаң, шул ызбада сине көтәр кешең булмаса?.. Менә сез – татарлар – ат ияреннән өзелгән кавем. Ат яратасыз. Мин беләм, шалишь! Бик шәп казылык ясый торган мишәр дустым бар иде минем. Әйе, дуслар күп чаклар бар иде... Шәптер ул ат өстендә, әйеме, Сәләй? Ирекнең үзен кочкан кебек, вакытның үзен үткән кебек чабасыңдыр? Чамалыйммы, ә?.. Тик атыңны бәйләр казыгың булмаса, бу ирекнең ни тәме, ни рәхәте... Ирек дигән хисне татыр өчен, иң элек читлек кирәк. Читлек! Читлек булганда гына ирек бар! Ә бит Җир шары – асылда, үзе зур бер читлек. Синең белән мин җан асрый торган менә шушы лагерьның зурайтылган варианты гына ул нибары. Аерма фәкать масштабта... Күк алдында без – читлектәге маймыллар. Без күрсәткән тамашалар, һай, кызыктыр аңа...

– Кешенең асылы шул ук бит, Федорыч. Рефлекслар шул ук. Гасырлар буе бер үк кәмит бара.

– Бөтен хикмәт тә шунда. Ихтыяҗлар шул ук. Җан богау сорый! Тугарып, бәйләп куяр казык кирәк җанга. Бу җирдә һәркемнең үз казыгы, үз күчәре булырга тиеш. Һәрхәлдә үземнеке дип ышанган күчәре. Шунсыз булмый икән... Ә синең Раечка – молодец хатын.

– Без аерылабыз, – Сәләй кырлы стаканны бушатты да йөзен чытты.

– Нәрсә? Раечка дамы?.. Мин дә кешеләрдә ялгышам икән. Гаҗәп. Кызык... – Яковның йөзенә караңгы күләгә йөгерде.

– Аерылырга гариза бир дип үзем хат яздым. Эшеннән куганнар, тулай торактан чыгарганнар. Кабахәтләр... «Халык дошманы» хатыны бит. Безгә генә түгел, аларга да анда бик авыр, Яков. «Миннән аерылсаң, үзеңә дә, балаларга да җиңелрәк булыр», – дидем.

Яков кинәт киң итеп елмайды да кулын дустының иңсәсенә салды.

– Ха! Шул гынамы? – Федорыч шаркылдап көлеп җибәрде. – Шул гынамы? Кәгазь кисәгенә ниндидер бер мөһер сугылганнан Раечка синең хатын булудан туктыймы? Кәгазь ни тора соң ул?! Кәгазьдә син дә, мин дә сатлыкҗан дип, Сталин кеше дип язылган... Кәгазьгә ышанасыңмы, әллә вөҗданыңамы? Раечка сине ташлар дип шикләнәсеңме?

– Ул турыда уйлыйсым да килми... Алты айлык чагымда әнкәем ташлап киткән мине, аңлыйсыңмы? Кадерсез булмадым, ләкин барыбер ташландык мин. Шатлансам да, көлсәм дә, сөйсәм дә, сөелсәм дә, әнә шул «ташландык» дигән күләгәм гел кояшны каплап торды. Дөнья миңа кояшын күрсәтеп, матурлыклары, рәхәтлекләре белән иркәләп алдалыйдыр, болар барысы да вакытлыча гынадыр, берзаман барыбер мине ташларлар кебек тоелды. Бәлки гомер буе ташландык булырга язгандыр миңа? Бу курку бәгыремдә боз булып йөри. Рәмзия дә мине ташласа...

– Ташлыйсы булса, әҗәткә бата-бата, күчтәнәч төяп, балаларыгызны алып, кеше күзеннән кача-поса, җәй саен яныңа килер идеме ул, ә? Көчле кеше ул, хыянәткә бармаячак. Шикләреңнән үзең оялыр идең, җебегән...

Сәләйгә, чынлап та, уңайсыз булып куйды. Рәмзиясе, бөтен дөньяга каршы чыгып, ничек тә гаилә җылысын саклап калырга, бирешмәскә, өметләнергә тырыша, ә ул монда үзен-үзе җәлләп утыра түгелме?

– Дурак син, Саша. Дурак булсаң да, хатын сайлый белгәнсең. Ә мин менә ялгыштым. Чибәр иде минем хатын. Мин сугышка киткәч үк чибәрлеген эшкә җиккән. Җиткерделәр... «Халык дошманы» хатыны дигән исемне иреннәннән помада сөртеп ташлаган кебек кенә ташлады ул... Улым бар, Саша. Моннан чыга алсам, улымны эзләп табасым бар. Мине фанилыкта әнә шул казык кына тотып тора... Ә син бәхетле. Шикләнергә не смей!..

***

Мин бармын – димәк, яшәү бар. Минем күңелем якты икән, дөнья да якты һәм күңелем яктысы мине дә, уйларымны да, тирәлегемне дә яктырта. Өметләнәм икән, өметем кайтаваз булып дөнья, вакыт, заман диварларына бәрелә дә көчәеп, зураеп, яңгырап кире үземә кайта. Калганы – кәлтә койрыгы кебек кенә. Бераздан төшеп калачак, югалачак, онытылачак шикләнүләр, икеләнүләр, хафалар... Дөньяны үзеңә бүләк ит. Дөньяң белән үзеңчә уйнарга, аны үз ихтыярың җаена бөтереп җибәрергә рөхсәт ит. Кешеләр бу хиссиятне, ошбу батырлыкны бәхет-сәгадәт дип атыйлардыр. Үзеңә бәхетле булырга, хөр булырга рөхсәт итсәң, бу югарылыктан сине беркем дә беркайчан да төшерә алмый. Кешене җиңү мөмкин түгел. Кеше үзе җиңелми икән, аны беркем җиңә алмый!..

...Вәгыйзовлар гаиләсе таркалып, Сәләй Вәгыйзов белән Рәмзия

Вәлитованың хәзер бер-берсенә кануни бәйсез булулары турында игълан район гәҗитенең беренче битендә басылып чыкты. Кешелек көтүендә тәртип шулай: кемнең кем белән кавышуыннан, аерылышуыннан җәмгыять бихәбәр калырга тиеш түгел. Бу мәҗбүри ритуалның файдасы булды: берничә көннән Рәмзия ничарадан-бичара вакытлыча урнашкан өй ишеген сабакташы Гали Халит шакыды. Хәлләрне ишеткән икән. Галине кырык өченче елда Казандагы Тел, әдәбият һәм тарих фәнни-тикшеренү институтына эшкә күчергәннәр иде һәм аның урынына татар теле мөгаллиме итеп Арча педучилищесына кабат Рәмзияне чакырганнар иде.

«Мәгариф министрлыгы ишеген шакып карыйм әле» – дип, караңгы чынбарлыкка өмет яктысы салып китте Гали. Сүзендә торды: яңа уку елында көллият шәкертләренә узган елгы Рәмзия Вәгыйзова урынына «өр-яңа» Рәмзия Вәлитова атлы мөгаллим белем бирә башлады.

...Келтер-келтер, келтер-келтер тегү машинасы теркелди. Кич, иртәгәсе сабакка әзерлисен әзерләп бетергәч, Рәмзия ханым тегү машинасы каршына утыра. Детдомда өйрәнгән һөнәре балаларының да, үзенең дә өс-башын бөтәйтер, хәтта күңел юанычына әйләнер дип кем уйлаган. Келтер-келтер, келтер-келтер... Аяк очың белән генә кагылып алуың була, тукыма буенча тыпырдап, инә биеп китә. Киселгән тукыма кисәкләрен, төйнәп-төйнәп, бер итеп тоташтыра, артыннан тип-тигез җеп эзе сызылып кала. Келтер-келтер... Кемдер-кемдер... Өзелмәсен генә.

Келтер-келтер... Көндер-төндер... Урамда көн булса да, төн булса да, шушы көйдән гайре берни ишетелми, гайбәт сүз булып та, әйбәт сүз булып та дөнья шавы колакка сыланмый. Вакыт үзе дә тегү машинасы көенә ага сыман. Вакыт агышын үлчәү мөмкинме икән? Искән җил өчен дә, үскән гөл өчен дә бер тизлектә була алмый лабаса ул! Нәкъ шулай гөл гомере белән кеше гомерен дә бер үк вакыт үлчәме белән исәпләү мөмкин түгел. Вакыт дигәнең эңгер-меңгер пәрдәләре сыман катламлы-катмарлы һәм төрле яссылыктамы әллә? Үскән гөл өчен вакыт – яфракларын иркәләп искән җил исәбендәдер, җил өчен – бөредән гөл ачылу үлчәмендәдер. Келтер-келтер вакыт ага, тукыма буйлап төсле җепләрдән юл салына.

...1953 елның 5 мартында училищеда дәресләр булмады...

Татар хатыннары тыйнак елый ул. Тулгак газапларында да яулык читен чәйнәп түзгән татар хатынына кая инде чәчен-башын туздырып акырып елаулар. Мәскәү тирәсендәрәкләр кинәнеп үкерсен әнә. Элеккеләр мәет өстендә еламаска да куша иде бугай... Алай да хәлдән килгәнчә тырыштылар, педучилищеда валерианка исе аңкып торды. Мышык-мышык борын тарткан, сузып-сузып елаган тавышлардан март җиле дә каушап калды шикелле: кызыл әләмнәрне йолыккалап йөрде-йөрде дә Бирәзә яклап бәрәңге басуларына таба сыпыртты...

***

Можгадан килүче электричканы Арча станциясе төксе йөз белән каршы алды. Кыеклап яуган язгы яңгыр вагон тәрәзәләренә кичке эңгер карасын сыларга ашыкты, станциядә төшеп калучыларга чиркангыч суыгы белән елышты. Әмма кешеләргә тынчу вагоннан төшүгә йөзгә сугылган салкынча саф һава тансык иде.

Ир күкрәк тутырып тирән сулыш алды, биштәрен иңсәсенә салды да берберартлы утлар җемелди башлаган тарафка – өенә таба акрын гына атлап китте. Станциядән Мәктәп урамына кадәр шактый барасы. Бераз атлагач, күшектергеч яңгырдан качарга теләгәндәй, якаларын күтәреп куйды. Ул да булмады, аны урам уртасына җыелган бозлы су белән баштан-аяк коендырып, автомобиль үтеп китте. Ир моңа әһәмият бирмәде шикелле, йөзенә чәчрәгән пычрак тамчыларны кулы белән сыпырып төшерде дә юлын илтифатсыз гына дәвам итте.

«Прәннекләргә су үтмәгән булса ярый инде, – дип уйлады ул. – Балалар куян күчтәнәче көтәдер...» Ләкин, явып торган яңгыр астында биштәр ачып, күчтәнәч барлаудан мәгънә юк иде.

Никадәр мәрхәмәтсез тоелса да, кышны куа торган, җир өстен каракучкыл керле карлардан арындыра торган яңгыр инде бу.

Торган саен куера барган караңгылыкны ярып, янә бер машина үтеп китте. Үтеп китте дә бераз баргач туктады һәм артка чикте. Ярымачылган ишектән берәүнең башы күренде:

– Абзый, утыр, әйдә!

Ир як-ягына каранып алды. Уйларына бирелеп сизми калганмы, арттан атлаучы да бармы әллә? Ләкин, ни гаҗәп, юлда аннан гайре кем дә юк иде.

– Юк, энем, рәхмәт. Кайта тор. Буталдың бугай...

– Сәләй Гататович, утыр, әйдә. Сезнең өй яныннан узам бит барыбер.

Ир гаҗәпләнде, каушады, сискәнде, шикләнде дә... Күңелендә аңлаешсыз тойгылар өермәсе кузгалды. Ул өермә автомобиль салонына, чакырып эндәшүче янәшәсенә кереп утырганда да тынмаган иде әле. Яшь кенә иргегет елмаеп кул сузды:

– Саумы, Сәләй абый! Әллә танымадың инде?

– Саумы, энем! Йөзең таныш кебек тә, исемең генә хәтердән чыккан... – Ни дияргә белмәгәндә әйтелә торганрак җавап әвәләнде.

– Равил мин. Галиәхмәтов. Хәтерләмисеңмени, Сәләй Гататович? Училищеда укыткан идең безне. Сугышка кадәр...

Хәтерләмиме соң? Үзе укыткан Равилнең хәзер район мәгариф бүлеге мөдире Равил Әлмиевич булып китүен дә яхшы белә Сәләй. Хәтта дус-иш саналганнарның да кайберләре «придәтел»не күрмәмешкә салышкан, сәлам дә бирмәгән бер чорда, Равилнең кешелекле мөгамәләсе ирне рәхәт сискәндереп җибәрде. Тик салкынга күнеккән бәгырь җылылыктан курка башлыйдыр...

– Ә-ә-ә, Равил... Равил Әлмиевич, син икәнсең...

– Әткәйне кыстырмый гына сөйләшик әле, Сәләй абзый. Ни хәлләр соң? Каян кайтып килеш болай?

– Әйбәт, шөкер. Яшибез. Кировтан. Урман кисәм бит мин хәзер.

– Ничек?.. – диде дә Равил урынсыз соравына шундук үкенеп куйды.

– Һөнәрне үзгәртергә туры килде шул, энем. Урман һавасы сәламәтлеккә файдалы, диләр... Баш та яхшырак эшли башлый, күрәсең. Әле беркөн чутлап караган идем: баксаң, хезмәт хакын киметеп бирәләр икән безгә. Канторга кердем, исәпләп күрсәттем. Кысып калган акчаларны түләттек тәки. Хәзер егетләр: «Сәләй абзый, син эшләмә, чутлап кына утыр. Норманы үзебез эшлибез», – диләр. – Сәләй көлемсерәп куйды. – Әйбәт, энем, хәлләр, әйбәт... Түзәрлек.

– Алай икән.. – диде Равил сузыбрак.

Равилләр курсын укытканда, Сәләй абзый үзе дә янып торган егет иде бит, ә! Ә ул укыткан дәресләр! Такташ, Тукай шигырьләрен сөйләп җибәрә, шаярта да, теманы да сеңдереп бирә, үзеңне дә сөйләтә. Үсендерә дә, хатаң булса – тәмле итеп, ләкин үтемле итеп күрсәтә дә белә иде. Укытучы абзый буйга озын тоела иде ул вакытта. Иңсәләре төшкән, киң маңгаен буразналар ермачлаган җыйнак кына гәүдәле бу ир белән теге чактагы Сәләй Гататович арасында аерма, һай, зур... Берәр ел элек кайтканын ишеткән иде бит юкса. Янына барасы калган икән лә... Рәмзия Гыйләҗевнаны да җыелышларда, конференцияләрдә күреп торды. Ник бер дә укытучы абыйсының хәлләрен сорашмады соң? Ничек болай килеп чыкты соң әле бу...

– Укытырга алмадылармы?

Сәләй эндәшмәде.

– Әйдә, болай эшлибез, абзый. Министрлыкка барып кайт әле син, укытырга рөхсәт сорап, гариза яз. Мин кайбер иптәшләр белән сөйләшеп куярмын. Сузма.

– Энем, син ут белән уйнавыңны чамалыйсыңдыр бит?

– Аңлыйм, Сәләй Гататович... Борчылма.

Сәләйләр йорты янына килеп җиткәннәр икән инде. Тәмам караңгы төшкән. Яңгырның туктарга исәбе юк, ахры – күк йөзендә ник бер йолдыз төрткесе күренсен. Төн карасын ерып ераклашкан фара утлары артыннан, язгы яңгырга йөз куеп, шактый карап торды әле ир...

***

– Күлмәгеңнең агын киярсеңме, зәңгәрсуынмы?

Хатын ишек катыннан ук сорау ташлады да, җавап көтеп тормастан, тезеп тә китте:

– Зәңгәрлесе сиңа күбрәк килешә инде. Үзем дә зәңгәр күлмәк киярмен дип торам. Пардан киенгәннәр болар дисеннәр әле, әйме? Зәңгәр күлмәгең кечерәймәдеме икән дим менә, әтисе. Күптән кигәнең юк бит. Агы да матур үзе. Зәңгәренә сыймасаң, агын киясең, әйме?

– Әйе.

– Чәчеңне алдырмадың тәки, тыңламадың сүземне. Пөхтәләбрәк алдырасы иде инде. Житү чәч белән, кеше арасында... Яле, яхшылап кырындыңмы? Абау, күзлегеңнең бусын кимә. Пыяласы бигрәк калын. Сукырайган диярләр. Карале, чалбарның сорысын киярсең микән, көрәненме?

– Микән түгел...

– Ни дисең? – Өй буйлап әле анысын, әле монысын барлап, тыр-тыр йөргән ханымның тавышы аш бүлмәсеннән ишетелә иде инде.

– Киярсеңме икән. Татар телендә «микән» дигән сүз юк...

– Әйе, сорысын киярсең. Анысы зәңгәр күлмәк белән килешәрәк сыман. Ай Аллам, галстугыңны барлап куймадым бит... – Түрдәге шифоньерның ярдәм сорагандай чиелдәп ачылганы ишетелде. – Тәки майлап куялмадың инде шушыны! – Тавыш бу юлы шифоньер эчендә үк пырхылдый иде. – Галстугыңның кайсын тагасың? Зәңгәренме, шәмәхәсенме? Җүләр әйткәндәй, галстук тагалармы соң ул бу вакытта? Ә? Бер син генә галстуктан

утырсаң, әллә ничек булыр ул, әйме? Әллә сумкама тыгып кына барыйммы? Кеше таккан булса, сиңа да бәйләп куярмын. Күлмәкнең зәңгәрсуын кисәң, галстукның караңгы зәңгәре матур булыр, әйме?

– Ыхы, – диде ир, алдындагы гәҗиттән башын күтәрми генә.

– Сиңа әйтәм, түфлиең кайда икән? Теге аксыл түфлиең?.. Ә-әй, узган атнада ук барлап кудым бит мин аны. Кая куйдым соң инде. Уф Аллам... – Нидер кыштырдады, нидер шапылдады, ишекләр яшен тизлегендә ачылып ябылды.

Ул да булмады, тавыш гәҗит артында ук яңгырады:

– Кайсын тотыйм?

Ир, гәҗитне бераз төшереп, күзлек астыннан гына дөньяга бакты. «Социалистик Татарстан» аръягында, ике кулына нәрсәләрдер тотып, хатыны басып тора иде. Карашы хәлиткеч имтихан бирүченеке сыман җитди, битләре алсуланган, борын очында тир тамчылары җемелдәшә. Ир, хатын кулында ни-нәрсә икәнен аңлап бетермәсә дә, Аллага тапшырып, берсенә ымлады:

– Бусын.

– И-и-и, зәвыгың яхшы инде синең, этисе. Үзем дә шул сумкамны алырмын дип уйлаган идем!

Ул арада аш бүлмәсендә нидер кайнап түгелде. Хатын шунда очты.

– Хәзер, балаларга ашарга бүлеп калдырам да... Төшке ашлары суыткычта. Киен, әйдә. Юкса, соңга калабыз. Киемнәрең урындык артында әнә. Мин хәзер...

Ир, киенеп, портфелен барлап маташканда, хатын балкып килеп басты.

– Матурмы мин? – дип, балаларча елмаеп, бөтерлеп тә алды.

– Матур, – диде ир, портфеленнән аерылмый гына. Күзлеген кая куйды соң, шайтан алгыры...

Инде чыгып киттек дигәндә, хатын ишек янындагы көзгегә карады да кычкырып җибәрде.

– Абау! Чәчемдәге бигудилар алынмаган бит! Ник шуны да әйтмисең? Баядан бирле лыгырдыйсың лабаса!..

...Алар килеп җиткәндә, кеше шактый җыелган иде. Мәдәният йортына якынлашканда, хатын ирне култыклап алды. Ир, кесәсеннән кульяулык чыгарып, маңгаен сөртте. Көн эссе булмаса да, ничектер бөркү бүген.

Унике елдан соң Сәләй Вәгыйзов янә укытучыларның август конференциясенә бара менә. Кайта.

Өч ел мөгаллим булып эшләдеңме, син инде укытучылыктан китә алмыйсың, диләр. Мәгариф системасының, шәкертләр һәм коллегалар белән эшләүнең ал ягын да, арт ягын да күреп, шул мохиттә үз урыныңны табар өчен өч ел кирәк, янәсе. Бу «сынау срогын» үтә алсаң, кендегең белән берегәсең һәм пенсия яшенә җиткәнче кубарыла алмыйсың инде. Шулайдыр да, әнә бит, мәдәният йорты каршында тәмәке көйрәтеп торучы ирләр барысы да таныш. Сугышка кадәр бер казанда кайнаган, белешеп-күрешеп йөргән кешеләр – педучилище мөгаллимнәре, мәктәп укытучылары...

Мәдәният йорты капкасына җиткәндә, ир хатынының кулларын ычкындырды. Куллар бер-берсеннән аерылыр алдыннан, хатын ирнең

дымлы бармакларын кысып куйды. Искән җилдә көз чалымнары сизелсә дә, көн никтер бөркү бүген.

Ханым ишегалдында гөр килеп торучы хатын-кызларның чуар төркеменә кушылып калды. Сәләй ишек төбендә тәмәке көйрәткән ир-атларга таба атлады.

Бер адым, ике адым, өч адым... Һәр адымың – синеке генә. «Адым» дигән сүзнең әйтелешендә үк үзлек, шәхсилек яңгырап тора. Юнәлешеңне нибары бер адымың, бердәнбер адымың хәл итә кайвакыт. Бер адым читкә атлау хакы гомер белән дә түләнергә мөмкин. Сафтан сыңар адым читкә каерган мәхбүсләрнең үлемнәренә шаһит булды Сәләй. Шунысы тәгаен: адәм баласы дөньяга тәпи басканнан бирле каядыр бара да бара. Атлый, чаба, абына, сөртенә, аннан кабат торып китә. Ничек кенә атласа да, аның һәр адымы үзенеке һәм фәкать аныкы гына. Адым – гомер хәрәкәте ул. Бу хәрәкәт мәңгелек түгел, әмма гомерлек – тукталуга юнәлгән гомерлек хәрәкәт.

Ир төркем тарафына атлады.

Бер адым, ике адым... Әйе, бер адым читкә каерган өчен үлемгә дучар булган мәхбүсләрне күрде Сәләй. Ул алар белән бер төркемдә, бер сафта иде. Алар фашист солдатының күз уңында иделәр. Асылда, кеше үтерү – кешене кеше итеп тану түгелме икән? Үтерергә лаек икән, димәк, ул комачаулый. Комачаулый икән – комачау итәр дәрәҗәдә көчле. Әйе, кешене физик юк итү аның көчен тану, кеше заты итеп, кешедәшең итеп тану билгеседер. Концлагерьда фашистлар аларга арка белән борылмыйлар иде. Мәхбүсләрнең һәрберсе күз уңында иде, чөнки һәр мәхбүс кеше иде.

Ул төркемгә таба атлады.

Төркем аны таныды. Ирләр берәм-берәм Сәләй Вәгыйзовка борылып бастылар...

***

...Ул калтыранган куллары белән китапка үрелде дә, чормага сак кына саркылган көн яктысында «Мөгаллим сәни» дигән сүзләрне искәреп, үрелгән кулы һавада асылып калды. Бер мәлгә башы әйләнеп, күз аллары караңгыланып китте, чигәсендә нидер сулык-сулык суга башлады, йөзе кызышты. Ул, ярдәм эзләгәндәй, тирә-ягына карады. Торган саен куерган төтен арасыннан иптәшләренең сыннары шәүлә кебек кенә шәйләнә, ул шәүләләр өй кыегыннан чорма түренә, чормадан кабат өй кыегына туктаусыз кымырҗыйлар. Ир китап белән күзгә-күз иде.

Күзләрен йомды һәм йорт кыегына җитәрәк кенә бәбәкләрен көн яктысына ачарга кыйды ул. Көн каралып, шәфәкъ томаланган, эңгер-меңгер җәелгән. Ихтимал, эңгердән өстәрәк, бик күпкә өстәрәк ай кабынгандыр, әмма егет күккә бакмады.

Китап, саргайган ак канатларын соңгы кат җилпеп, аска очты...

Китап арты китап битләрен ялмап үрсәләнгән учак өстән аермачык күренә, уты йөзне пешерә иде хәтта. Ялкын телләре шашып биилә. Менә берсе «әлиф» булып күккә үрелде, икенчесе – «ләм», өченчесе «мим» сыман боргаланып сузылды...

...Сәләй шыбыр тиргә батып уянып китте: тагын шул төш – гомерлек бимаза. Арча өстендә таң сызылып килә иде. Ир өстенә бишмәтен элде

дә ишегалдына чыкты. Иртәнге салкынлык, төш сөремен тәмам таратып, умыртка баганасы буйлап кымырҗып узды. Дөнья тын. Дөньялыкның иркәләнеп кенә яңа көн куенына кереп барышы. Төн салкыны белән кояш ялкыны кавышкан ошбу мәлдә күңелдә мәҗүси бер халәт тибенеп куя: чык тамчысы булып салкын йолдызлар чәчрәп узган иртәнге дымсу туфракка тезләнеп, кулларыңны күккә күтәрәсе һәм яңа таңны сәламлисе килә. Табигатьнең иркенлегеннән һәм гаҗәеп күркәмлегеннән күңел тула. Шушы матурлыкны күрә һәм тоя алуың өчен Кемгәдер меңмең рәхмәт укыйсы килә.

Рәхмәтле була белмәгән бәндә бәхетле булалмый.

Кеше итеп яратканың өчен рәхмәт, Тәңрем!

Гамьле итеп яратканың өчен рәхмәт, Раббым!

Күңелемне рәхмәтле хисләр белән тутырганың өчен рәхмәт, Аллам!

Җәзаларың өчен рәхмәт...

Ничәмә еллар саташтырмаган төшне бүген кабат күрде. Тәкъдиренә тиешле җәзалары үтәлеп бетмәгән, димәк. Язмыш аның бурычларын да, гөнаһын да оныттырмый... Соңгы тапкыр кайчан күргән иде соң әле бу төшне шулай да: сугыштамы, фашист концлагерендамы? Печораның салкын барагында, ахры, үлем белән якалашкан чакта... Бәлки бу төш гомеренең хәлиткеч борылышларында яңгырап ала торган кисәтүле кайтаваздыр. Җәза түгелдер ул, бәлки, ярлыкаудыр...

Ир бакчага керде. Бакчаны, яшеллекне, туфрак исен ярата ул. Кара туфракка төртелгән нәни генә орлыктан җир өстенә шытым чыгу, аның үсүе, ныгуы, зураюы һәм җир йөзенең аерылгысыз бер әсәре булып туфракка берегүе могҗизага тиң. Язу эшләре белән өстәл янында утырганнан соң, тән яздырыр өчен дә, җан яздырыр өчен дә бакчасына чыгып китә. Тезләнеп-тезләнеп, түтәлләр утый, чәчәкләренә сулар сибә.

Алмаларны гына күр. Кайчан гына ботагында сандугач тибрәтә-тибрәтә чәчәк аткан алмагач бүген җимешләрен чак тотып тора. Кояш назыннан йөзләре кызарган алмалар тиздән туфракка тәгәрәр. ...Сәләй үскән йорт мәчет янында иде. Мәчет бакчасында зур карт алмагач бар иде. Балачакта Сәләй өчен вакыт әнә шул алмагач мәгыйшәте белән хисапланды: яфрак ярса – яз, чәчәк атса – җәй, алмаларын койса – көз, карлы суыкларда шәрә боткалары белән мәчет тирәсеннән җилләрне куып торса – кыш, димәк. Байтуганнан Гайшә инәкәен Арчага алып килгәндә, ир мәчет алмагачының үсентесен дә биштәренә алды. Ул үсенте бүген Арча туфрагында алма бирә, һәм Гайшә карчык та шушы туфракта инде...

Ир сак кына бер алма өзеп алды, яңагына терәде. Нәкъ теге вакытта Рәмзиясе ул биргән алсу алманы битләренә китергән кебек итеп. Һәм ...тетрәнеп куйды! Алма! Алма... Шушы сүзне эзләп чыккан бит ул бакчага!

Алар язачак Әлифба китабы «алма» сүзе белән башланачак!..

***

Бер ел Мөндеш авылы мәктәбендә рус теле укытканнан соң Сәләйне, һаман да шул Равил Галиәхмәтов ярдәме белән районның мәгариф бүлегенә методист итеп эшкә алдылар. Арча – Мөндеш арасы тугыз километр. Ел әйләнәсе шул араны җәяү йөргән Сәләй район үзәгендә эшкә урнашуына

куанып бетә алмады. Равил Әлмиевичкә исә бу игелеге өчен «выговор» тәтеде...

Рәмзия Вәлитованы районда гына түгел, Татарстанда алдынгы укытучы буларак таныйлар хәзер. Ә яхшы укытучылар ифрат кадерле вакыт. Гасыр башыннан бирле болганган ил үз күчәре тирәсенә оеша башлады кебек, шөкер. Күчәр дигәне – китап һәм икмәк. Тик татарның китабы таланган, ун гасыр буе китапка тупланган гыйлем танымаслык хәлгә килгән. 1928 елдан латин язуына күчү... Инде буразнага кайттык дигәндә, төрки халыкларның берләшүеннән шүрләп, тагын әлифба үзгәртү – утыз тугызынчы елдан хөкүмәт тарафыннан гамәлгә куелган кирилл хәрефләренә каеру сәясәте. Шушы мәгънәсезлеккә каршы булганнарны төрмәләрдә черетү, асу-кисү... Икмәктән аерылса да, китаптан аерылмаган укымышлы татар халкының, ата-баба гыйльми мирасыннан мәхрүм булып, наданлык упкыны алдында басып калуы – нәтиҗә шул иде.

Кирилл язуында дәреслекләр, методик ярдәмлекләр, укыту әсбаплары гаять кирәкле чорда чын мөгаллимнәр алтын бәясенә тиң. Сабыйларга туган телдә белем бирерлек китапны алардан башка кем яза алсын? Мәгариф системасында кайнаган һәм бу кытлыкны үз җилкәләрендә татыган Сәләй белән Рәмзия җиң сызганып эшкә керештеләр. Иң мөһиме: кемдер тарафыннан кушылган «заказ» түгел, ә үз вөҗданнары таләп иткән хезмәт иде бу. Бигрәк тә Сәләй өчен...

***

Ишек тоткасына үрелер алдыннан, ул кулындагы калын папкага күз төшереп алды. Аннан чандыр бармаклары белән чәчен тараштырып куйды, галстугын рәтләде, тамак кырды. Зур имән ишек авырсынып кына ачылды да ирне эчкә этәрде. Бинага кергәч, урам яктысы томаланып, берара күз алдында караңгы шәүләләр биешеп алды кебек. Ул да булмады колагына: «Вам к кому?» дигән тавыш чәчрәннәп килеп бәрелде.

– Кабул итү бүлмәсенә, – дип, кыюсыз гына вахтёрга паспортын сузды ул.

Йөзен ап-ак итеп кершәнләгән олырак яшьтәге ханым документны игътибар белән күздән үткәрде. Аннан, иелгәндә хыянәтчел төстә бүлтәеп чыга торган икенче-өченче иякләрен язып, башын күтәрде дә карашын паспорт иясенә кадады. Шуннан соң гына, маңгай өстендәге кызыл чәч бөдрәләрен селкетә-селкетә, алдындагы журналга нидер сырлады һәм боерык игълан иткәндәй:

– Йөз дә унынчы кабинет, – дип, ТАССР Мәгариф министрлыгы бинасына рәхим итүчеләрне теркәү ритуалын тәмам кылды.

Кабул итү бүлмәсенең ишеген шакыгандай итеп, бусагасыннан атлап керергә өлгермәде, сәркатип кызның салкын тавышы яңгырады:

– Мирза Исмагилович үзендә түгел.

– Гаҗәп... Үзендә булмагач, кемдә соң ул? – Мондый чибәр туташ белән шаян сүз сөйләшү килешле. Елмайсын. Дөньяда иң әрәм матурлык – елмая белмәгән чибәр хатын-кыз.

Әмма чибәркәйнең таш йөзе үзгәрмәде.

– Сез ишетмисезме әллә? – Кыз, ниһаять, карашын өстәлдәге язу машинкасыннан каерып, ишек катындагы адәмгә күчерде. Тиле кешегә

карагандай, баштанаяк күздән кичерде дә һәр сүзен иҗекләргә аера-аера янә кабатлады. – Мирза Исмагилович үзендә түгел!

– Сеңлем, без «Әлифба» әзерләдек. Конкурска. Шуны алып килдем менә, – кулындагы папкасына ымлады ир. – Кемгә тапшырыйм икән?

– Әнә, йөз утыз дүрткә кереп карагыз...

Йөз утыз дүртенче кабинетта уртача яшьләрдәге ир-атка тап булды. Дөресрәге, өстәлгә өелгән папкалар, кәгазьләр арасыннан ялтырап торган күзлеге аша гына шәйләп алды ул кабинет иясен.

– Исәнмесез! Ни йомыш? – диде күзлекле кеше коры гына.

– «Иң яхшы әлифба» конкурсына эшләрне бирәдә калдырасымы?

– Әйе. Сез «Әлифба» яздыгызмыни? – дип, ни өчендер кайтарып сорады күзлекле кеше, иргә текәлебрәк карап. – Мин сезне танымыйм...

– Әйе. Рәмзия Гыйләҗевна белән икәү яздык. Алып килдем менә.

– Яхшы. Утырыгыз. Иң элек кайбер кәгазьләрне тутырырга кирәк булыр.

Кабинет иясе өстәл тартмасыннан берничә кәгазь бите чыгарды. Пөхтәләп, өстәлгә куйды, каләмгә үрелде.

– Исем-фамилиягез, атагызның исеме?

– Сәләй Гататдин улы Вәгыйзов һәм Рәмзия Гыйләҗетдин кызы Вәлитова.

– Туган көннәрегез һәм туу урыннарыгыз?

– Мин 1908 елның 20 октябрендә Самара өлкәсенең Камышлы районы Татар Байтуганы авылында тудым. Иптәш Вәлитова – 1914 елның 29 мартында Башкортстанның Стәрлетамак шәһәрендә.

– Кайда белем алдыгыз?

– Икебез дә Казан дәүләт педагогика институтының филология бүлегендә укыдык.

– Эш урыныгыз һәм вазифагыз?

– Бүгенге көндә Арча педагогика училищесында эшлибез. Татар телен һәм татар әдәбиятын укыту методикасы буенча белем бирәбез. Икебез дә.

– Укытучы, димәк? Училищеда? Хммм... – Күзлекле бәндә Сәләйгә беркавым карап торды. – Дәвам итик. Гыйльми дәрәҗәгез?

– Гыйльми дәрәҗәләребез дә, мактаулы исемнәребез дә юк, энем. Гапгади укытучылар без...

– Сез хәтта кандидат түгелмени?

– Юк...

Кабинет иясе кинәт каләмен ташлады. Күзлеген салып, кәгазь өстенә ыргытты.

– Һәм сез кандидат та булмаган башыгыз белән «Әлифба» яздык димәкче буласызмы?! – Кабинет хуҗасы кәнәфиенә җәелде һәм кычкырып көлеп җибәрде. Шаркылдап көлде-көлде дә күзлек пыяласы өстенә кунган калын кашларын җыерды. – Вакыт үткәреп утырган булам тагын...

Ул яңа гына бик пөхтәлек һәм дикъкать белән язып утырган кәгазь битен erткалап, өстәле янындагы чүп чиләгенә ташлады. Аннан соң аптыраудан сүзсез калган иргә сөзеп карады да:

– Абзый, үзеңнең дә, минем дә вакытымны әрәм итеп йөрмә. Бар, кайтып кит... Әлифбаны академиклар яза аны... – диде һәм алдында торган калын папканы чирканган кыяфәт белән Сәләйгә таба этеп җибәрде. Тышына

«Әлифба. С.Г.Вәгыйзов, Р.Г.Вәлитова» дип язылган ак папка тупас хәрәкәттән идәнгә килеп төште, битләре тузгып чәчелде.

Төрле халыкларның әлифбаларын җентекле өйрәнеп, туган тел хасиятләрен һәм сабыйларга хәреф өйрәтү нечкәлекләрен барлап, икәүнең бер булып, өч ел дәвамында көн-төн язган хезмәте иде бу. Икмәкне идәнгә ташламыйлар... Идәндә сибелеп яткан һәр хәреф Сәләй өчен икмәктән дә, дөньядагы һәммә нәрсәдән дә кадерлерәк. Әлифба – аның аклану мөмкинлеге, йөз аклыгы... Ул бер сүз дә дәшмәде. Кәгазьләрне сабыр гына җыйды да чыгып китте. Әлифбасын җуйган бу илдә аның эшлисе эшләре күп иде әле.

***

Мең тугыз йөз алтмыш тугызынчы елның яз ахырында, каеннар яфрак ярган ямьле көннәрдә Сәләй Рәмзия белән туган авылына юл тотты. Фасылларның иң рәхәт, иң күңелле вакыты – ак каен бөреләре чертләп яшь яфракка ачылган чактыр. Бу яралуда яшәүнең яме дә, фаҗигасе дә бар. Яралган мизгелдән башлап бетүгә юл тоткан матурлык... Сихри яшел яфракларның мәңгелек түгеллеге каенга мәгълүм, әлбәттә, ләкин ул үз сабыйларын яшәү дигән фаҗигадән саклап кала алмый. Кояш нурларына коендыра, шифалы яңгырлар белән туендыра, җилләрдә тибрәтә дә, вакыт җиткәч, туфракка озата.

Сәләйне асрамага алып, тәрбия кылып үстергән әнкәсе Гайшә бакыйлыкка күчкәнгә берничә ел узды. Гайшә карчыкның мәңгелеккә сыенган урыны Арча туфрагында. Аның вафатыннан соң, җәй саен Байтуганга кайтырга талпынса да, Сәләйне гел нидер туктатып торды. Гомер буе күңелендә йөрткән һәм үги анасы бакыйлыкка күчкәч мөмкин булган очрашуны ул гел кичектереп килде.

Үги атасы Гататдин яклап туганнарына кайтып, төн кунгач, ниятен якыннарына җиткерде дә, ат атланып, Яңа Усман авылына юнәлде.

Аның белән көрешкән күпердән акрын гына үтешли, Аның калын кара шәле эчендә, кочагына сыенып басып калган малайчагын исенә төшерде. Яше алтмыштан узган чал чәчле ирнең күзләрен яшь элпәсе каплады. Көткәндерме Ул аны? Көтәдерме? Танырмы? Йөрәктәге җөйләрне кубарып, җәрәхәтләрне ачу гына булмасмы бу очрашу?

Әлифбаның беренче битенә Ана дип язасы килде аның – язалмады.

Әлифбаның икенче битенә Әни, Әнкәй дип язасы килде – язалмады.

«А» хәрефенә – алма, «Ә» хәрефенә әби сурәте Әлифбада...

Атыңны бәйләр казыгың булмаса, ат чабудан ни мәгънә дигән иде кайчандыр бер дусты. Тормыш әнә шул казык-күчәр тирәли әйләнә. Төркиләрнең һәр җыены тиккәме казык, багана тирәли корылган... Тирмәң булсын өчен дә иң әүвәл казык кирәк...

Татар Әлифбасы да казыктай әлифтән башлана...

Казыгын бик яшьли, нарасый чагында ук югалтты ул. Шулай да язмыш мәрхәмәтсез булмады, ныклы тормыш күчәре булырдай хатын белән кавыштырды. Бүген менә, ничә еллар үткәч, балачагында югалткан Ана дигән иң газиз күчәрне бер барып күрергә, теге вакыттагы кебек кочагына сарылып сыенырга, җылынырга дип юл тотышы.

Көтәдерме Ул аны? Теге кыштан соң ник бер тапкыр да күренмәде? Әллә «килеп, баланың күңелен алгысытып йөрмә» дип тыйганнармы? Бәлки Үзе шулай хәл иткәндер? Күрше авылда гына үсеп ятучы улының язмышы белән кызыксындымы икән?.. Ирнең аңында һәм йөрәгендә мең сорау кайный. Яңа Усманга якынлашкан саен бу сораулар чигәне ныграк кыса, йөрәк чыгырыннан чыгар булып ашкына.

Ат Сок елгасы яныннан җай гына юыртып бара. Суларына, елга-күлләренә халык ник сагышлы атамалар бирә икән? Сагышларын елга суына агызып җибәрер өченме? Сок дигән яңгыраштa да никадәр тыенкы сагыш һәм шул сагышка күнү яшерелгән сыман. Ана белән бала, бер елганың икесе ике ярында калып, Сак белән Сок булып кына гомер ителгән шул.

Ничек күрешерләр икән алар? Ниләр сөйләшерләр? Атасы турында сорашыр, билгеле. Әнкәсенең Яңа Усманда үз гаиләсе, балалары бардыр. Алар ничек кабул итәр?

Әнкәсенең кара шәле эченә сыенып, тормыштан качасы килгән вакытлары аз булмады ирнең. Шул җылы кочакның дөньяда барлыгы салкыннардан аралап, җылытып яшәтте. Ни күрсә дә, ни кичерсә дә, шатланса да, көенсә дә, ул бала бит. Уйлап карасаң, заман, ил-көн, дөнья таккан бар ярлыклар бер атама алдында кыйммәтен җуя: җирдә һәркем – ана баласы. Аның да әнкәсе бар, аның да кендек бавы өзелгән газиз кешесе бар бит!..

Кирәкле йорт турына килеп җиткәч, «әллә үтеп кенә китимме» дигән шик ныграк тырнап куйды. Алтмыш ел яшәдең бит инде Ансыз да, калганын ничек тә үтәрсең әле... Ә Аңа ничә яшь икән? Сиксән тирәседер. Беркем дә мәңгелек түгел, менә хәзер бусагасыннан үтми китсә, иртәгә соң булмагае. Күрәсең килә икән – бүген күреш, сүзең булса – бүген әйт. Бүген яшә...

Сәләмә генә йортның ишеге сызланып ачылды, идән сайгаклары бер-бер артлы сыкрап куйдылар. Өй эче караңгы иде. Шул караңгылык арасыннан бер сын шәйләнде. Ак яулыгын иңнәренә салып япкан, җыйнак кына какча гәүдәсенә аксыл күлмәк элгән карчык өйгә кеше керүен ишетмәде, ахры. Ирнең теле аңкавына ябышты, тыны кысылды.

– Исәнме... Инәй...

Карчык, беркавым хәрәкәтсез торгач, акрын гына урыныннан купты. Аякларын идән сайгагыннан шуыштырып, кунак янына якынрак килде. Соргылт күзләренең төсе уңган, иреннәре калтырый иде. Ул берара өрәк күргән кешедәй әсәренеп торды. Аннан калтыранган иреннәре арасыннан карлыккан тонык сүзләр өзелде:

– Ник килдең?..

***

...Рәмзия капка тавышыннан сискәнеп куйды. Кайтты!..

Көтә-көтә көтек булды лабаса. Җанына урын таба алмыйча, әле, тегү машинасын кабызып карады, әле язу өстәле янына утырды, әле аш бүлмәсенә чыгып, нидер юган, җыйган булып йөренде. Нәрсәгә тотынмасын, бер эшкә дә дә кулы ятмады. Кичә кичтән Сәләйгә хәрби комиссариатка чакыру кәгазе калдырганнан бирле картларның тынычлыгы җуелды. «Юк белән башыңны катырма. Картыңны армиягә ала торганнардыр, булмаса, кулъяулык чигә тор», – дип шаяртырга тырышса да, сизде Рәмзия: Сәләй

дә төне буе йокламады. Борсаланып ятты, бакчага да берничә рәт чыгып керде. Көчкә таң аттырдылар.

«Үзең генә йөрмә, мин дә барам», – дип әйтеп-әйтеп карады югыйсә. Кая инде, картайгач та үзенекен итми калмый, киребеткән кемсә... «Хатын-кыз сөйрәп йөри торган җир түгел ул. Өйдә генә утыр. Иптәшкә таягымны алам менә», – дип кеткелдәп чыгып киткән булды. Әнә кайтып җитте, ниһаять. Атлауларын күр, таягына таянырга да оныткан. Ай-һай, капканы каты япты. Болай ипсез кыланмый торган иде. Хәерлегә булсын...

– Чәең әзерме? Кибектем... – Картның коры тавышы ишек артыннан ук яңгырады.

Әзер булмаган кая. Биш кат кайнаткандыр.

– Йә? Ник чакырганнар?

Карт өс киемнәрен каударлана-каударлана элгечкә кундырды. Фуражкасын шапылдатып салды. Куллары калтырый, ачуы йөзенә чыккан.

– Ник чакырганнар, ник чакырганнар... Тик торганчы бер эш булсын дип чакырганнар, мәнсезләр...

– Йә инде, аңлатыбрак сөйлә әле.

– Гариза яз, диләр. Гариза кирәк булган аларга... Ничә ел үткәч, сиксән алты яшьлек карттан гариза яздырмакчылар. Түбәсе кыйшайгандыр инде моның, диләрдер...

– Ниткән гариза? Тынычлан әле. Кан басымың күтәрелә күрмәсен.

– Җиңүнең илле еллыгы җитә, диләр. Гаепсезлегеңне исбат итүләрен сорап үтенеч яз, диләр.

– Син ни дидең? Яздыңмы соң? – дип сораса да, Рәмзия өчен җавап билгеле иде: алтмыш ел бергә гомер иткән картын белмиме соң...

– Язармын мин аларга, язмаган ни... – Сәләй тагын кызып китте. – Ватан алдында минем бер гаебем дә юк, дидем. Теләсәгез үзегез языгыз, дип кайтып киттем.

– И әтисе, әтисе... Карт җүләр син, ачуым килмәгәе. Хөрмәтләп чакырганнар үзеңне, яхшылап аңлатканнар. Язсаң, ни булыр иде соң шул гаризаны? Кулың корыр идеме? Үлгәнче син дә кеше рәтендә йөреп калыр идең. Җиңү бәйрәменә чыгар идек, ичмаса...

– Сиңа сүз сөйләп торам тагын! – Карт ачу белән кул селтәде. – Аңламыйсың икән, дәшмә инде. Туксанга җиткәндә, чуртымамы миңа аларның кәгазьләре, бәйрәм-мазарлары. Гаепле кеше генә акланып йөри ул. Язмыйм да, сорамыйм да, бетте-китте... Бу турыда бүтән сөйләшмибез. Тагын шуныңише кәгазь китерсәләр, миңа күрсәтеп тә торма...

Берәр айдан Арчаның Мәктәп урамында Вәгыйзовлар яши торган йортка хәрби комиссариаттан кызыл тышлы кенәгә алып килделәр. Ялт иткән хәрби киемнән чибәр генә бер кеше ишек шакыды. Кулында күчтәнәчләр тулы пакеты да бар. Сәләй Вәгыйзовны сорады.

– Әтисе, сиңа әйтәм, яныңа килгәннәр. Хәрби комиссариаттан, ди.

Эш бүлмәсеннән Сәләйнең кырыс тавышы яңгырады.

– Эшем күп. Борчып йөрмәсеннәр.

– Йә инде, кәҗәләнмә. Тапшырыр әйберебез бар, диләр. – диде Рәмзия, эш өстәле янында кәгазьгә күмелеп утырган картына иелеп үк. – Яхшы түгел, әтисе. Чык инде.

– Бирәсе нәрсәләре булса, ишек катында калдырсыннар. Чыкмыйм дигәч чыкмыйм...

– Сәләй Гататович авырыбрак тора шул әле. Көйсезрәк чагы. Гаеп итмәгез инде, зинһар. Карт кешенең хәлләре шулайрак шул... – дип читенсенеп өтәләнде Рәмзия, кунакны озата чыкканда.

Өйгә кергәч, кызыл кенәгәне ачып карады да, тиз-тиз атлап, Сәләй янына керде. Кенәгәне карты алдына өстәлгә бик кадерләп, сак кына куйды. Сәләйнең иңнәреннән нәкъ бала сөйгән кебек йомшак кына сыйпап алды һәм бер сүз дә әйтмичә бүлмәдән чыгып китте.

Карт беркавым кенәгәне кулына алырга кыймый торды. Игътибар бирмәскә тырышып карады, ләкин язасы сүзен онытты, фикере чуалды. Ниһаять, ул кенәгәгә үрелде. Кытыршы какча бармаклары кызыл күн тукыма өстеннән сак кына сыпырып уздылар. Берара тотып торганнан соң гына ачарга кыйды. Бу Сәләй Гататдин улы Вәгыйзовның Бөек Ватан сугышы ветераны булуын раслый торган таныклык иде. Сиксән алты яшьлек карт, таныклыгын күкрәгенә куеп, тын гына, сабый бала сыман сулык-сулык елый иде...

***

Училищеда ел саен тугызынчы май көнне ветераннарны хөрмәтлиләр: концерт куялар, табын хәзерлиләр. Елдан-ел кимеп барган ветеран мөгаллимнәрне котлап, матур сүзләр әйтәләр, сугыш чорында фронтта һәм тылда күрсәткән батырлыклары өчен рәхмәтләр укыйлар. Җиңүнең илле еллыгын каршылаганда, бу бәйрәмгә көллияттә мөгаллимлек итеп, лаеклы ялга чыккан Сәләй Вәгыйзовны беренче тапкыр чакырдылар...

Алтмыш тугызынчы елны ук пенсиягә чыкса да, карт укытучы көллият сукмагына тузан кундырмый, көн саен диярлек килә. Лекцияләр укырга да, яшь мөгаллимнәрнең укыту методикасын ныгытырга да чакыралар, болай гына хәл-әхвәл белешеп булса да урап китә. Ләкин бүген бу бинага бик дулкынланып килде ул. Сер бирмәскә тырышса да, тез буыннары калтырый, башы әйләнеп, күз аллары караңгыланып куя. Артык сөенергә дә ярамыйдыр, күрәсең, бу яшьтә. Ярый әле, таянырга уң ягында Рәмзиясе, сул ягында таягы бар дигәндәй.

Тантаналы музыка яңгырап торган, шарлар белән бизәлгән бинага үткәч тә тынычлана алмады карт. Гардероб янына җиткәч, кулы калтырап, плащының сәдәфләрен ычкындыра алмый изаланып бетте. Әлеге дә баягы, ярый Рәмзиясе янда. Бу мәшәкатьтән мең бәла белән котылып, матур гына үз урыннарына таба атлап барышлары иде, шулвакыт – кирәк бит! – ишектән Әхмәди Һадиатуллович күренде.

Теге вакытны укытучылар бүлмәсендә Рәмзия белән «уңышсыз» әңгәмәгә илле ел узган. Ул көннәр әллә кайчан караган аклы-каралы кинофильм кадрлары сыман гына хәтердә, онытырга күптән вакыт. Әмма Әхмәди онытмый. Дөресрәге, гафу итә алмый иде. Рәмзияне түгел, Сәләйне гафу итә алмады ул: кеше булып калуын, көчле булуын, алай гына да түгел, хөрмәтле укытучы, бихисап дәреслекләр авторы булып танылуын кичерә алмады.

Вәгыйзовлар Әхмәди белән көрешмәскә тырышалар. Күрүеңнән

күрмәвең мең артык та, әмма бер урамда гомер иткәч, күрешми дә калып булмый. Бар бит шундый кешеләр: тимисең, өлешенә кермисең, һичбер алыр-бүләр уртак нәрсәгез юк, әмма син аңа никтер гел комачаулыйсың. Һәм, җай туры килгән саен, үзенең «матур» мөнәсәбәтен сиздерми калмый ул. Бу юлы да шулай булды. Керә-керешкә Әхмәди Сәләйгә таба ымлап һәм бөтен кеше ишетерлек итеп ярып салды:

– Бу монда нишләп йөри?..

Болай да бәйрәмгә килгән һәммә кеше аны күзли кебек тоела иде Сәләйгә. Бу сүзләрдән соң бөтенләй коелып төште. Рәмзиянең дә кулы калтырап куйды, аңа да авырдыр. Йа Хода, ник килде ул монда? Моңарчы чакыручы булмады, бәйрәмнәрдә йөрмәде, купшы сүзләр ишетмәде – яшәде бит әле. Җаны тыныч булмаса да, колагы тыныч иде ичмаса... Инде картаймыш көнендә никләргә кирәк булды бу матавык?..

Шулвакыт арттан училище директоры Илдус Габрахмановичның яңгыравык тавышы ишетелде:

– Исәнмесез, Сәләй Гатовович! Рәмзия Гыйләҗевна! Иминлекме, саулыкмы? Килүегезгә рәхмәт! Әйдәгез, рәхим итегез, сезгә урын түрдән, Сәләй абзый!..

...Бәйрәм тәмамлангач, Вәгыйзовларны Илдус үз машинасы белән кайтарып куйды. Карт белән карчык чәйгә чакыргач баш тартуны яхшысынмады, өйгә үттеләр. Җыйнак кына, тыйнак кына йорт: бәләкәй генә аш бүлмәсе, йокы бүлмәсе һәм ике якта ике өстәл куелган зал – ирлехатынлы мөгаллимнәрнең эш урыны. Ике өстәлдә ике язу машинкасы, шкафлар, киштәләр тулы китаплар, кәгазьләр.

Сул якта Сәләйнең эш өстәле өстендәге киштәдә үзләре язган хезмәтләр тезелеп киткән. Җәмгысе кырыкка якын китап: «Дәрестән тыш уку өчен методик материаллар» (1962), «Грамотага өйрәтү буенча тартмадагы кисмә хәрефләр» (1965), «Рәсемле әлифба» (1965), «Әлифбага методик кулланма» (1966), «Кызыклы грамматика (башлангыч класслар өчен)» (1970), «Башлангыч сыйныфларда татар теленә өйрәтү методикасы» (1970), «Язарга өйрәтү дәфтәрләренә методик кулланма» (1976), «Кызыклы грамматика (башлангыч сыйныфлар өчен)» (1980), «Татар теле дәреслеге. 1 класслар өчен» (1982), «Әлифбага методик кулланма» (1982), «Уку китабына методик кулланма» (1982), «Татар теленә методик кулланма» (1982), «Татар теле буенча дидактик материаллар» (1982), «Татар теленнән таблицалар» (1982), «Татар теле буенча дидактик материаллар» (1986), «Татар әлифбасы (6 яшьлек балалар өчен)» (1986), «Уку китабы (2 класс)» (1988), «Татар теле (2 класс)» (1988), «Методик кулланма (2 класс татар теле дәреслеге өчен)» (1988), «Туган тел (7 яшьлекләр өчен)» (1994), «Татар теле (7 яшьлекләр өчен)» (1994) һәм башкалар, һәм башкалар...

Иң түрдә «Әлифба» тора. Мең тугыз йөз алтмыш дүртенче елның беренче сентябреннән алып, Ватандагы бөтен татар баласына туган телдә укырга, язарга өйрәткән зәңгәр тышлы «Әлифба» – туган телнең Коръәненә тиң газиз «Әлифба»...

Ул арада Рәмзия ханым ялт кына чәй өстәле хәстәрләгән икән, аш бүлмәсенә чакырды. Бераз утыргач, үзе «эшләрем бар» дигән булып, чыгып та китте. Илдус портфеленнән күчтәнәч чыгарды, чәркәләргә бүлде.

Иңсәләргә баса торган әллә нинди авыр көн булды бүген. Илдус барысын да аңлый, билгеле: Әхмәди Һадиатулловичның ни әйткәнен дә ишетте ул, Сәләй Гататовичның агарынган йөзен дә күрде. Абзыйны уйлары белән ялгызын калдырып чыгып китү ярамас. Бәйрәм бит бүген, бәйрәм, шайтан алгыры... Ул бит бүген беренче тапкыр бәйрәмдә катнашты. Әнә, берни булмагандай елмаеп утыра. Шулкадәр кыерсытулар, нахак ялалар, тибәрүләр кичереп, ничек елмая ул? Ничек елмая ала? Каян бу көч?

– Сере гади аның, – диде карт, шактый дәшми торганнан соң. – Мин гомерем буе таш атканнарга аш атып яшәдем...

– Юк, ничек инде... Мин ышанмыйм, абзый. Сине күпме изгән, сыткан бу Ватанга күңелеңдә тамчы да үпкә юкмыни?

– Ватан – әнкәй ул, энем. Әнкәйгә үпкәлиләрмени?!.

***


...Ул калтыранган куллары белән китапка үрелде дә, чормага сак кына саркылган көн яктысында «Әлифба» дигән сүзләрне искәреп, кулы һавада асылып калды. Бер мәлгә башы әйләнеп, күз аллары караңгыланып китте, чигәсендә нидер сулык-сулык суга башлады, йөзе кызышты. Ярдәм эзләгәндәй, тирә-ягына карады. Торган саен куерган төтен арасыннан кемнәрнеңдер сыннары шәүлә кебек кенә шәйләнә, ул шәүләләр өй кыегыннан чорма түгенә, чормадан кабат өй кыегына туктаусыз кымырҗыйлар. Егет китап белән күзгә-күз иде.

...Сәләй шыбыр тиргә батып уянып китте. Куркынган күзләре өй эчен айкады. Йортта ялгызлыктан гайре кем дә юк, дөнья тын һәм салкын иде. Ул кабаланып урыныннан торды һәм язу өстәленә ыргылды. Өлгерергә, өлгерергә кирәк...

Киштә түреннән зәңгәр тышлы китап алды. Тәрәзләрдән чак сирпелгән көн яктысында китап тышындагы «Әлифба» сүзе балкып күренә иде. Һич искәрмәстән, бик газиз бер нәрсәсенә юлыккандай нәүмиз халәттә карап торганнан соң китапның беренче битен ачты. Калтыранган карт куллары өстәлдән каләм эзләп капшанды. Өлгерергә, ничек тә өлгерергә кирәк! Ул кабалана, әмма җаны давылдан соң изрәп калган диңгез төсле ифрат тын һәм тыныч иде.

Әлифбаның беренче битенә кара каләмнән мөгаллимнең соңгы сүзләре сибелде:

«Дорогому сыну Камилю на долгую и вечную память от родителей...»



Мөнир
Вафин

# МИҢА ТАУЛАР – ЯСТЫК УРЫНЫНА...[*]

***

Миңа таулар – ястык урынына,
Кыяларга башны салып ятам.
Тузан булып күзгә кермәсен дип,
Йолдызларны күктән сибереп атам.

Мин кояшка бик еш арка терим,
Үзе чөнки сорап җиңнән ала.
Тик кояштан мин җылылык алмыйм,
Киресенчә, кояш миннән ала.

Мин төкерсәм, океаннар бата,
Җиргә тибү – туплы уйнау гына.
Кодрәтемә киртә булып баса
Тик таяныр нокта булмау гына.

Тузан булып туза бар кешелек,
Бармак арасыннан гасыр җилә.
Мин тауларга барып вакланмыймын,
Чөнки таулар миңа үзе килә.

***

Ак яулыгын ак чәченә салып,
Ап-ак кышның ак бер таңында,
Әниемнең таба ашы пешереп
Йөргән чагы күзем алдында.

[*] Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе тарафыннан оештырылган II әдәби бәйгедә шигырьләр номинациясендә өченче урынга лаек булды.

Мөнир ВАФИН (1961) – *шагыйрь, публицист; «Сүзләр чәчтем», «Дөнья – куласа», «Йөрәгем пәрәләре» исемле китаплар авторы. Уфада яши.*

Коймак, тәбикмәкләр, кыстыбыйлар,
Көлчә, гөбәдия, бөккәннәр,
Күзикмәкләр, кабартма һәм бәлеш
Минем авыз аша үткәннәр.

Бала чагым, әти-әниле чак –
Уйласам да, күңел пакьләнә.
Гомеремнең ак көннәре булып,
Күңелемдә мәңге саклана.

***

Төн килде дә... Кире китмәде.
Караңгылык басты дөньяны.
Күңелләре сукыр булганнар
Сизмәделәр ләкин һич аны.

Бугазлардан алды каралык,
Әллә дөнья бара таралып?!
Әмма ләкин, берни булмагандай
Ашап-эчеп ята бар халык.

Гавам өчен төн ни, көн ни ул? –
Утырганда шашып сыйланып.
Газизләре шәмдәй янганнар
Алалардыр бәлки уйланып...

Караңгылык йотты кемнедер,
Дәррәү сизмәгәнгә салыштык.
Мизгел тынычлыкта калу өчен
Туар таңны төнгә алыштык.

Караңгылык кемгә җитмәде,
Күзләрен дә кысып бәйләде.
Түрдәгеләр шәрә икәнен
Күңел күзе булган шәйләде.

Төн килде дә... Кире китмәде.
Төн артыннан төннәр актылар.
Соңгы йолдыз булып атыла
Күңелдәге соңгы яктылар...

## Алмагачлар

Агачларның кыз чаклары,
Сылулар, бер дигәннәр!
Алмагачлар кемузардан
Туй күлмәге кигәннәр.

Күп тә узмас көмән-көмән
Алмага төйнәлерләр.
Җилдән алмага узган дип
Кемнәрдер сөйләнерләр.

Ак күлмәкләр алышыныр
Яшькелт халатлар белән.
Үзләре дә килешерләр
Мондый халәтләр белән.

Җимешләре дә өлгереп
Коелыр берәм-берәм.
Саргаеп беткән халатны
Тарткалар давыл, буран.

Ачы җилләр, зәһәр суык...
Ботакларын иярләр.
Алмагачлар кемузардан
Ап-ак кәфен киярләр...

***

«Торыйк-торыйк», – тагын кошлар китте,
Тавышлары керде җан ярып.
Җанымның да нәни бер өлеше
Алар белән китте ияреп.

«Торыйк-торыйк», – диеп алар тагын
Тезелешеп кайтыр, яз җиткәч.
Йөрәгемнең кыйпылчыгы гына
Кире кайтмас инде бер киткәч.

Минем йөрәк коштай булган икән!
Аңламадым шуны – әй, надан...
Күзләр саен кечерәя барам,
Китә барам шулай дөньядан.

Җан авазым васыять булып яңгырар
«Торыйк-торыйк» дигән кошларда.
Йөрәгемнең соңгы кыйпылчыгы
Мәңгелеккә китәр кышларга.

## Тукай белән сөйләшү

Төн уртасы. Кемдер ишек какты,
Декабрьнең салкын челләсе.
Тукай тора, үзе яланаяк,
Өстә тузып беткән хөлләсе.

Өйгә узды. Оек, кием суздым.
Ул аларны кабул итмәде.
«Киемсезлек түгел, ә мәнсезлек
Йөрәгемә, – диде, – үткәне».

Чәйләп-мәйләп шуннан фикер сүттек,
Ютәлләп тә алды буылып.
Без ютәлсез килеш буылганны
Ул тыңлады миннән шым булып?!

«Икебез дә бума, – диде Тукай, –
Безне буганнардан юк дару.
Иң мөһиме – фани дөньяларда
Тапталмаган намус калдыру».

«Сине бүген бар да сөя, – дидем, –
Синең алда безнең юк гаеп.
Милләт кенә хаста сәясәттән
Елдан-елга бара азаеп.

Күп җирләрдә синең сыннарың бар,
Исемеңне урам, чат алган.
Дәүләт бүләге дә, Тукай дустым,
Синең исем белән аталган».

Теплоходлар, мәйдан, клубларны да
Санап киттем – бармак җитмәде.
Үз исемен мәңгеләштерүгә
Тик Тукайның исе китмәде.

Пушкинны да шуннан искә алдык,
Фикерләр бер икән ләбаса!
Пушкин бит ул – Пушкин булмас иде,
Патшаларга әгәр яраса!

Синең чорда, Тукай, күпме халуй,
Күпме булган сарай шагыйре.
Һәм бүген дә хакимиятчеләр
Арабызда йөри бик эре.

Шифаханә аңа тәкъдим иттем,
«Кымыз тулы, – дидем, – киштәләр».
«Бүген түгел, чирне вакытында
Дәваласын иде иптәшләр...»

Шулай диеп Тукай чыгып китте,
Сузылып ятты ишек келәсе.
Аяк эзләреннән тирләп калды
Декабрьнең салкын челләсе.

## Мескенлек

*Узган җанисәп уңаеннан*

Бүре булып улыйсылар килә,
Хыялларда ята бүрелек,
Юкка гына ул хис сиздермидер,
Бүре булганбыздыр без элек.

Бүре булып улыйсылар килә,
Тик бәэлдәү чыга калтырап.
Минем көчәнүне күреп калган
Кавемдәшләр тора аптырап.

«Болай да бит безгә әйбәт, – диләр, –
Дөнья иркенлеген күр сәнә.
Иртәгәсе көнне уйлыйсы юк,
Көтүчеләр юлны күрсәтә».

Без күмәкбез, безнең тояклардан
Барча җирләр тора селкенеп.
Күмәклекне тоеп, бүрелегем
Күңелләрдә куя җилкенеп.

Бер көн килеп, күңелләрне ертып,
Бүрелекләр чыгу – икеле.
Сафлар кими, халәтебез булгач
Корбан сарыклары шикелле...

* * *

*Татар акылы төштән соң.*
Әйтем

Төш вакыты күптән узды.
Һич уянмый, каһәрең.
Баш очында: «Не будить!» – дип,
Кемдер чәчә зәһәрен.

«Татар – хәтәр»не аңладым –
Йокычылыгың хәтәр.
Уян! Борылып ятарга
Вакытың җиткән, татар...

***

Йолдызлар утлары беткәч,
Җан бирәләр атылып.
Мин дә яндым йолдызлардай
Янып һәм яратылып.

Мин сүнгәндә күзләреңә
Карармын бер йотылып,
Шуннан башны салачакмын,
Кочагыңа атылып...

***

Бала чакта саф, самими
Булгангамы уйларым,
Иң ак карлар бездә генә
Ява диеп уйладым.

Алар, чыннан да, ак иде,
Өрфия мамык кына.
Сокланып карап торырлык
Кулларга алып кына.

Карлар яву – күңел баю,
Тиң иде алар җырга.
Вәкарь белән генә карлар
Төшәләр иде җиргә.

Шәһәр карлары ак түгел,
Вәкарь дә түгел, җебек.
...Үзем дә үзгәрә барам
Шәһәр карлары кебек.

## Без «булдырабыз»

Без биесәк – җир селкенә,
Табаннан ут оча.
Тик хөррият сорар өчен,
Әлбәттә, кот оча.

Без җырласак – моңнарыбыз
Бар дөньяга тула.

Бәйрәм арты бәйрәм булгач,
Гамьнәр дә онытыла.

Җырлау гына, бию генә
Дөнья барышында.
...Ә телебез бер почмакта –
Соңгы сулышында...

## Чыпчыклык

Илдә чыпчык үлми диләр,
Шуңа яшибез әле.
Телләребез дә йолкынган,
Шуңа дәшмибез әле.

Ә без кайчандыр бервакыт
Бөркетләр булганбыз бит.
Көч-куәт белән дөньяны
Селкетеп торганбыз бит.

Безне дошманнар кыргачтын,
Бер мәлдә вакланганбыз,
Чыпчык рәвешенә кереп,
Вакланып саклангaнбыз.

Ә күкрәктәге йөрәкчек
Дертләп һәм дулап ала.
Кайчандыр бөркет булганын,
Ахрысы, уйлап ала.

Илдә чыпчык үлми диләр,
Шуңа торабыз артып.
Бу илдә чыпчык булганчы,
Үлүең күпкә артык.

...Илсез калган бабамнарның
Тетмәсен тетеп ятам.
Чыпчык бөркеткә әйләнер
Чакларны көтеп ятам.

## Җәйдә калам

Җәйләр җитсә, хатын-кызлар
Кием салып ташлый.
Кем күбрәк чишенә ала
Дигән ярыш башлый.

Чишендерүчеләр өчен
Эшләр күпкә кими.
Иренемдә – иреннәре,
Кулларымда – ими.

Чишенсә дә, итагатьле:
«Абый, мин оялам».
...Мин күзләргә күчеп тормыйм,
Мин – җәйләрдә калам.

## Кайтты...

Кайчан гына киткән иде,
Озатты авыл зурлап.
Әти-әнисе, туганнар,
Сөйгәне калды елап.

Нигәдер моңсу иде ул,
Күңеле ташып-ташты.
Барча халыкны кочаклап,
Яратып саубуллашты.

Тәки кайтты. Кайгы, елаш
Салып халык бәг(ы)ренә.
Барча авыл чират торып
Балчык салды каберенә...

***

Алпан-тилпән атлаганда,
Бераз чайкалып алам.
Арттан көлеп калган була
Җыен алам-салам.

Ертык тишектән көлә, ди,
Эчкәен уа-уа.
Әмма ләкин мин басканга
Дөнья чайкалып куя.

***

Мин китмәмен якты дөньялардан,
Дөнья китәр мине калдырып.
Ятар ләхет, өстә кәфен булгач,
Һич кенә дә тормам калтырап.

Барлык уем синең хакта булыр,
Мин анда да зарыгып көтәрмен.
Бакыйлыкта җан сөйгәнем белән
Очрашулар өмет итәрмен.

Синең урын Оҗмахларда булыр,
Ә минеке инде... билгеле.
Әмма ләкин чын сөюләр өчен
Чикләр булу миңа көлкеле.

Бакыйлыкта очрашулар өчен
Сәкарьләрдән сәхрә ясармын.
Ратканнар бергә була диеп,
Коръәннәргә өстәп язармын!

Син көт мине!



Фәтхулла
Абдуллин

# ЧӘЧКӘ ИДЕК ИЛЛӘРДӘ...

ПОВЕСТЬ*

Бәхет эзләп юлга чыккан Гөлфияне Бөгелмәдә үк якташларыннан аердылар. Кемнедер – урман кисәргә Урал якларына, кайберләрен тагын да ераккарак, ташкүмер чабарга Кузбасс шахталарына озаттылар. Таза гәүдәле, илле яшьләр тирәсендәге вербовщик, япа-ялгыз калган, борчылуы йөзенә чыккан Гөлфиянең күңелен күтәрергә теләпме, елмайгандай итеп, аңа дәште:

– Шатлан, кызый, сиңа бәхет елмайды. Сине җылы якка – Үзбәкстанга җибәрәбез. Син анда алма җыючы комбайнда утырып кына йөрерсең, – дип, кулына Договор кәгазе һәм, кул куйдырып, билет алырга акча тоттырды. Аннары: – Ташкентта менә шушы Килешү кәгазендә күрсәтелгән оешмада сиңа подъёмный бирерләр, эшкә дә урнаштырырлар, – диде.

Ул тагын нидер әйтте.

Гөлфия, иптәшләреннән аерылып, ялгыз калуына көенсә дә, вербовщик агайның, «алма җыючы комбайнда утырып кына йөрерсең» дигән сүзләре аның күңелен җылытып җибәрде. Ни дисәң дә, урман кисү, караңгы җир астына төшеп, ташкүмер чабу кебек авыр эш түгел бит әле дип тынычлангандай булды. «Подъёмный» гыйбарәсенең ни аңлатканын белмәсә дә, нәрсәгәдер өметләндерә торган сүз икәнен чамалады.

Чишмә, Кинәле кебек юллар тармакланган станцияләрдә поезддан-поездга күчеп утыру русчасы такы-токы булган кызга җиңел булмады. Ярый әле, миһербанлы бәндәләр булышты. Ниһаять, Куйбышевта (Самараның ул чактагы атамасы) «Мәскәү – Ташкент» поезды аны, җилдереп, күз күрмәгән якларга алып китте. Сугыштан соңгы елларда «җилдереп» сүзен шул көлеп әйтсәң генә инде. Паровозлар, станция саен туктап, чаннарына су тутыралар, ташкүмер төйиләр. Семафорлар кузгалырга рөхсәт биргәч тә әле,

* 2021 елда «Аһ, туган каумем газиз!» әдәби конкурсында кызыксындыру премиясенә лаек булган әсәр.

Фәтхулла АБДУЛЛИН (1937) – *язучы; Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе. «Еракка китеп кара», «Тормышка юл ярганда», «Чүл бүресе» һ.б. күпсанлы китаплар авторы. Түбән Кама шәһәрендә яши.*

«пуф-пуф!», «уф-уф!» килеп, зарлана-зарлана гына кыймшаналар. Кызып киткәч кенә, зарлы «уф-уф!»лар «пуф-пуф!»ка әйләнә. Паровозларның тавышы вагон тәгәрмәчләренең текелдәгәне белән бер ритмга көйләнә.

Ырынбур каласын үтеп, Казакъстан җиренә чыккач, хәтфә үлән каплаган болыннарда тәгәрәп үскән Гөлфиягә күз күреме җиргә сузылган дала шыксыз күренде. Җире дә әллә нинди, көлсыман соры туфрак. Бер карыш чамасы гына үскән үләннәр дә соргылт төскә кергән. Кайсы гына якка карасаң да, күңелгә моңсулык өсти торган шул ук соры төс! Әллә нигә бер күзгә чалынган кыйшык өйле казакъ авылларын да соргылт төс сарып алган. Сәмән кирпечтән әвәләнгән, кашагасыз тәрәзәле ул алачык кебек йортларда ничек көн күрә торганнардыр, шайтан белсен!

Күзләрне иркәли торган яшеллек үзәнлекләрдә генә шәйләнә. Тик алар биредә күп түгел. Очсыз-кырыйсыз дала белән чагыштырганда, кулъяулык кадәр генә.

«Мәскәү – Ташкент» пассажир поезды менә ничә тәүлек инде уфылдый-уфылдый юлын дәвам итә.

Гөлфия Актүбә станциясендә беренче мәртәбә тире капчык-бурдюкка тутырган кымыз сатучы казакъларны күрде. Алар кымызларын «җаксы кымыз!» дип мактый-мактый тәкъдим итә. Бәләкәй генә пиалага салып «дәмләп карарга» – авыз итәргә дә бирәләр иде. Марҗа түтиләр, кысык күзле казакъ әкәләренең кыяфәтләренә карап, чырайларын сытсалар да, ир-атларда кызыксыну көчле. Бер җамаякны каплап куйгач, тагын сорап алалар. Казакъ агайларының кайберләре тире чалбар кигәннәр иде. Җәйге челләдә нигә шулай пышлыгып йөри торганнардыр? (Аларның малбагар-көтүчеләр икәнен, төнге далага салкын төшкәнен татар кызы каян белсен инде?)

Поезд Арал диңгезе буйлап барганда, Гөлфия өнсез калды. Диңгез өстендә давыл купкан иде. Эскерт кебек дулкыннар бер-бер артлы ярга килеп бәреләләр, әйтерсең пассажир вагоннарын юып алып китәргә телиләр. Кызның күңелен курку басты. Берөзлексез такылдаган марҗа түтиләр дә «телләрен тешләп» шомланып калдылар. Поезд юлын нишләп шулай диңгезгә якын салганнардыр? Аңламассың! Ул берара күрмәгән, белмәгән чит җирләргә чыгып китүенә үкенеп тә куйды. Бик китмәс иде, ике аягының берсен дә атламас иде. Әгәр колхозда иртә таң белән кояш батканчы эшләгәненә адәм рәтле түләсәләр. Юк бит, юк! Коры таякка эшләп мантый алмыйсың шул инде. Сугыштан агач аяк белән кайткан, шулай булса да, колхозда хисапчы эшен тел-теш тидермәслек төгәл башкарган әтисен дә эшеннән алдылар. Райком җибәргән председательнең хатынына урын кирәк булды. Өйдә берсеннән-берсе бәләкәй дүрт бала. Өстәвенә, яңарак кына унсигез яше тулган Гөлфиядән «бездетность» дигән салым түләтә башладылар. Унсигез яше тулганда, кыз баланың кулында каян килеп сабые булсын инде? Закон буенча унсигезе тулмаган кызларга кияүгә чыгарга рөхсәт тә юк бит әле! Бик чыгар иде дә, егетләрнең күбесе яу кырында ятып калды. Исән кайтканнарның да кайсы аяксыз, кайсы кулсыз...

Гөлфия менә шулай, ничарадан бичара, гаиләдә бер кашык булса да кимрәк булыр дип, туган-үскән иленнән китеп бара...

Диңгез буендагы станциядә перрон тулы кысык күзле, карсак буйлы,

төптән юан чыккан казакълар, кычкыра-кычкыра, ысланган эре-эре балыклар сатып утыралар иде. Станция буе ысланган балык исе белән тулган. Тәмле ис юлаучыларны ихтыярсыз үзенә тартып тора. Сатучыларның тәвәккәлләре бер вагоннан икенчесенә күчеп сәүдә итә. Проводницаларның сукрануларына исләре дә китми. Поезд кузгалгач кына сикереп төшеп кала. Төшә алмасалар да, кайгырмыйлар. Аларга каршы яктан килгән поездга утырып кайту берни түгел! Балыклары гына сатылсын.

* * *

Ташкентка сәфәр озын да, озак та, ялыктыргыч бертөрле дә иде. Кая карама, һаман шул очсыз-кырыйсыз дала... Тәрәзәләре кашагасыз булгач, кашсыз-керфексез күзләр шикелле тәрәзәле шыксыз йортлар...

Тынга каплана торган эссе һава вагон эченә дә үтеп керә. Авызны киптерә. Проводницаларның биргән чәе генә җитми. Ир-атлар, тәҗрибәле пассажирлар зуррак станцияләрдә поезд туктау белән чәйнек, бидоннар күтәреп, «кипяток» дип язылган краннан кайнаган су алырга йөгерә.

Гөлфиянең урыны плацкарт вагонның өске сәндерәсендә иде. Өйдә калган әти-әнисен, сеңелләрен, энеләрен уйлап алды. Ул аларны сагына башлаган иде инде. Стена ягына борылып ятты да, башкаларга сиздермәскә тырышып, «балавыз сыгып» алды. Саубуллашканда, дүрт яшьлек Шамилнең:

– Апа, миңа пәке алып кайт! Ялыймы? – дип «заказ» биргәнен исенә төшереп, үзалдына елмаеп куйды.

Гөлфия үзе дә аңа «заказ» бирергә онытмады.

– «Р» хәрефен әйтергә өйрәнсәң, алып кайтырмын, ярыймы? – дип, яратып кына башыннан сыйпап алды.

Сабый, башын ия-ия, берничә мәртәбә:

– Ялал! Ялал! – дип кабатлады.

Туганнары исенә төшкәч, юк, мин анда озак тора алмам, юллык акча эшләсәм, алма сезоны беткәч тә кайтырмын дип, күңеленә беркетеп куйды.

Гөлфия алма җыя торган комбайнны күз алдына китерергә тырышты. Ул «НАТИ» тракторына тагып иген ура торган «коммунар» комбайнына охшаган микән? Алмагачлар анда Сәет урманындагы агачлар кебек тоташ үсәләр микән дип баш ватты. Юктыр! Алай булса, анда комбайн ничек керсен? Мөгаен, аларны рәт-рәт итеп утыртканнардыр дип фаразлады.

* * *

Очсыз-кырыйсыз дисәләр дә, шыксыз даланың да чиге бар икән. Ничәдер тәүлектән соң, юллар тармакланып төрле юнәлешкә китә торган Арысь станциясен үтеп, күпмедер баргач, табигать алыштырып куйгандай үзгәрде. Яшеллеккә төренгән кышлаклар, кипарислар кебек биеккә үрләгән тупыллар күренә башлады. Пассажирлар арасында җанлану башланды. Телләренә «Ташкент» сүзе килеп керде.

Гөлфиянең йөрәге дөп-дөп тибә башлады, урыныннан купты! Ходаем! Ничек кабул итәрләр? Буең бәләкәй дип кире бормасалар гына ярар иде дип борчылды. Поезд, «гыжт»[1] кирпечтән салынган, алардан соң калыккан

[1] Гыжт – үзбәкчә үзле балчыкка салам кушып болгаткан измәдән сугылган кирпеч.

дүртәр-бишәр катлы йортларны «ерып», сигналын сызгырта-сызгырта барды да вокзал каршына килеп туктады. Пассажирлар арасында ашыгу, кабалану, ыгы-зыгы башланды. Кемнәрдер туганнарын каршы ала, шундук чупылдатып үбеп ала. Пырдымсызлары, каударланып, чемоданы белән кемнеңдер аягына бәрелеп үтә. Авырткан тезен угалап калганы артыннан куа китмәсә дә:

– Итәгеңә ут каптымы әллә? Кая ашыгасың! – дип ачуын баса. Тегесе борылып та карамый. Ишетсә дә, ишетмәмешкә салыша. Аңа тизрәк вокзал каршына килеп туктаган троллейбуска өлгерергә кирәк. Адәм баласы һәрчак каядыр ашыга, кабалана... Бала чакта тизрәк үсәсе, юлга чыкса, тизрәк барып җитәсе килә... Мөгаен, ул аның канына сеңгәндер... Ашыгуларның ялгышуга китерү ихтималын ул уйлап та карамый...

Гөлфия, җыйнак кына фанер чемоданын тотып, перронга төште. Кайсы якка китәргә белмичә, тирә-якка күз төшереп алды. Вагоннар сөйрәп килгән паровоз тынычланып калган. Юлаучыларын исән-имин китереп җиткергәненә сөенгәндәй, җиңелчә генә пар чыгарып, «пошкырып» тора иде.

Вокзал түбәсенә ат башы кадәр хәрефләр белән «Тошкент» дип язганнар. Бина, бер катлы гына булса да, үзбәкләрнең милли бизәкләре белән бизәлгән иде. Янәшәдә генә ачык һавада яшеллеккә төренгән «Шестой зал» дигәне дә бар. Биредә, кая карама, яшеллек. Киң ябалдашлы агачлар асфальт юл буенда да үсәләр, йортлар тирәсендә дә күләгә ясап утыралар иде. Гөлфия урам тулы халык йөргәнгә гаҗәпсенеп калды. Көпә-көндез нишләп шулай эшсез йөриләр болар? Үзләре бертуктаусыз сөйләшәләр, көлешеп тә алалар әле, җитмәсә!

Бәхетенә, аңа кирәк оешма вокзал янында гына булып чыкты. Гөлфия курка-курка гына аның ишеген ачты. Кулына килешү кәгазе тотып, коридор буйлап тезелгән ишекләрнең кайсына керергә белми аптырап торган кызны:

– Вам кого? – дип айныттылар.

Ул:

– Мне… комбайн… яблоко… – дип, үзенең хәлен, кем икәнен аңлатырга тырышкан иде, кырыс тавыш аны ярты сүздә бүлде:

– Откуда приехала?

– Тарлаудан, – диде ул татарча. Аннары рәсми кәгазьләрдәгечә, – Дөмәй Тарлау, – дип «төзәтте».

Кызга туган авылы җирнең кендеге сыман булса да, Ташкент кешесе Дөмәй Тарлауны каян белсен инде.

– А где это находится?

– Татарстанда!

Юан гәүдәле ханым, Татарстан сүзен ишеткәч, Гөлфиянең кем икәнен чамалап алды.

– Пошли со мной! – Һәм үзенә иярергә кирәген аңлатып, җиңелчә генә кул изәп алды. Ханым коридор буйлап тезелгән ишекләрнең «Отдел кадров» дигән язулысын ачып:

– Исламия Каримовна, принимайте! Вам пополнение! – дип китеп барды.

Өстәл янында нииндидер кәгазьләр актарып утырган урта яшьләрдәге ханым, башын күтәреп, кызны күздән кичереп алды. Аннары:

– Керегез, кер! – диде ул Гөлфиягә саф татарча.

Үзбәкстан булгач, гел үзбәкләр генә яши торгандыр дип уйлаган кыз, ялгыш ишетмәдемме дигәндәй, бер мәлгә югалып калды. Ханым каушап калган, чемодан күтәргән килеш ишек катында басып торган кызга тагын:

– Курыкмагыз, сеңлем! Керегез, кер! – дип кабатлады.

Гөлфия, ханымның ярыйсы гына ягымлы тавышын ишеткәч, тынычлангандай булды. Ул күрсәткән урынга барып утырды.

Ханым алдында яткан кәгазьләрен өстәлнең бер читенә этәреп куйды. Тагын бер кат кызны күздән кичерде.

– Йә, сөйләп җибәр, сеңлем. Ничек килеп җиттең? Юл газабы – гүр газабы дигәннәр бит борынгылар.

Ханымның үз итеп сөйләшүе кызга кыюлык өстәде.

– Әйбәт, – диде ул. – Тәгәрмәчләр текелдәгән тавыш кына әле һаман колак төбендә тора.

Ханым җиңелчә генә елмаеп куйды.

– Сеңлем, монда сиңа ул тәгәрмәчләр тавышына күнегергә туры килер инде, – диде ул тыныч кына. – Кая, кәгазьләреңне бир әле! Карыйк!

Гөлфия кулындагы кәгазьләрен аңа сузды. Ханым сүзсез генә кызның документларын тикшерә башлады.

Юл буе алма җыючы комбайн башыннан чыкмаган кыз тәвәккәлләп сорарга булды.

– Апа, ул алма җыючы комбайнның утыргычы кайда була? Алдамы, арттамы?

Сүзсез генә кызның документлары белән танышкан ханым башын күтәрде.

– Аңламадым. Нинди комбайн турында сорыйсың син, сеңлем?

– Алма җыючы комбайн турында, – диде кыз, шуны да белмисезмени дигән кыяфәттә гаҗәпсенеп. – Миңа вербовщик абзый: «Алма җыючы комбайнда утырып кына йөрерсең», – диде бит.

Һәм ул ихлас күзләре белән ыспай киемле ханымга текәлде.

Ханым җиңелчә генә башын селкеп алды.

– И беркатлы бала! Син бу килешү кәгазьләренә кул куйганда укымадыңмыни? Сине таныштырмадылармыни? – Ул бармагы белән кәгазь битенә төртеп күрсәтте. – Менә бит монда акка кара белән «путевая рабочая сроком на два года» дип язылган. Тимер юлда эшләячәксең. Монда мамык җыючы комбайннар гына бар. Алма җыючы комбайнны конструкторлар уйлап тапмаган әле.

Әйтерсең, көтмәгәндә Гөлфиянең башына күсәк белән ордылар. Күз аллары караңгыланып киткәндәй булды. Чалт аяз күкне гүя болытлар каплады. Кыз, ни әйтергә белмичә, телсез калды. Ул бит вербовщик абыйның сүзенә ышанып юлга чыкты. Өлкәннәр дә шулай алдакчы булалар микәнни? Олы кеше – солы төше дигән булалар тагын. Алай булгач, бу дөньяда кемгә ышанырга соң? Кемгә?! Анда җылы... Йөзем җимешләре бушлай... Алмалар җирдә тәгәрәп ята... Тик менә шуларны җыеп кына өлгерә алмыйлар, имеш. Тасма тел тагын әллә нәрсәләр әйтеп кызыктырды...

Гөлфия берара, бүлмәдән чыгып, кире вокзалга йөгермәкче дә булган иде. Әмма «кара сакалы» аны чабудан тартып туктатты. Хәзер бит аның

кулында юллык акчасы да юк! Ярдәм кулын сузарлык кешесе дә юк! Хәзер аңа нишләргә? Кая барырга? Кемгә ялынырга? Кызның йөрәген үкенечле уйлар ташкыны чеметтереп алды. Тыны кысылгандай булды. Эх!.. Э-эх!.. Ташкын күкрәк читлегеннән чәчрәп чыкты да күз яшьләре булып тәгәрәде... Кыз үкереп еларга тотынды... Кулъяулыгы күз яшьләреннән сыгып алырлык булды...

Кабинет хуҗасы, әкрен генә урыныннан торып, кызның иңбашына кулын куйды. Тынычландырырга теләп, җиңелчә генә аркасыннан кагып, «бәпләп» алды.

– Сеңлем, тормышта гел генә ал да гөл булмый. Гомер иткәндә, әллә нинди көтелмәгән хәлләргә дучар буласың. Яшәү белән үлем арасында калган чаклар була. Тынычлан. Үзеңне кулга ал. Син яшь бит әле. Сиңа яшисе дә яшисе. Ә яшәр өчен кайда булса да эшләргә кирәк.

Ниһаять, Гөлфия, күз яшьләрен сөртә-сөртә, башын күтәрде. Янында басып торган ханымга төбәлде.

– Ике ел дидегез. Апа, мин монда шулай ике ел буе тоткын кебек беркая да китә алмыйча яшәргә тиеш буламмыни инде?

– Юк, сеңлем, юк! Син – ирекле кеше. Эштән соң, ял көннәрендә теләсәң кая бара аласың. Унбер ай эшләгәч без сиңа отпуск бирербез. Советлар Союзының теләсә кайсы төбәгенә бушлай барырга билет бирербез.

– Бөгелмәгә кадәр дә бушлай кайтып буламы?

– Була, була! Әйтәм бит, СССРның любой точкасына. Хет Мәскәүгә, хет Владивостокка! Мондый мөмкинлек тимер юлда эшләгән кешеләргә генә бирелә. Бүтән җирдә андый өлгүтә юк әле ул.

Гөлфия, ниһаять, елавыннан туктады. Күңеленнән генә, күрәсеңне күрми гүргә кереп булмый дигәннәре хак икән дип куйды.

Ханым үз урынына барып утырды. Кызның кәгазьләрен кулына алды.

– Сеңлем, мин бүген үк синең кәгазьләреңнең эшен бетереп, бухгалтериягә тапшырырга тырышырмын. Сиңа йөз илле сум подъёмный акча бирерләр. Ул сиңа получка алганчы җитәргә тиеш. Саграк тотсаң, калыр да әле. Кассир бүлмәсеннән чыккач, кабат минем янга кер. Безнең эшчеләр әлегә Мирзачүл станциясендә эшлиләр. Шунда вагоннарда яшиләр. Әлегә дим, чөнки анда эшләре төгәлләнсә, икенче станциягә күчәләр. Шуңа бәйле оешманың исеме дә «күчмә колонна» дип атала.

Балтасы суга төшкән кешедәй пошаманда утырган Гөлфия аның әйткәннәрен дәшми генә тыңлады. Ханымның сүзләренә шатланырга да, хафаланырга да белмәде. Ул инде чарасыз, язмышы белән килешергә мәҗбүр. Бүгенге көндә сайланып торырга бүтән юл юк. Кайда булса да эшләргә кирәк. «Чегән тормышы икән» дип кенә уйлап куйды.

Гөлфия кадрлар бүлегенә кабат кергәч, ханым аңа берьюлы берничә кәгазь сузды.

– Менә бу кәгазь белән вокзалда сиңа Мирза-чүл станциясенә барырга билет бирерләр. Акча түлисе түгел. Бушлай. Аңладыңмы? Син инде безнең штаттагы кеше саналасың. Менә монысы завхоз Николай Недоедкога. Ул сине урнаштырыр, урын-җир бирер. Ә менә монысын колонна начальнигы Василий Таракановка күрсәтерсең. Ул сине бригадага билгеләр. Аңладыңмы?

Гөлфия «таракан» сүзен ишеткәч, ихтыярсыз, чирканып куйды. Начальник кеше оялмыйча ничек хәшәрәт исемен фамилия итеп йөртә икән? Сорокин, Зайцев булса, бер хәл иде әле.

Ханым ике сүзнең берендә «аңладыңмы?» дия-дия, имән бармагын селки-селки дәвам итте.

– Аю баласын да циркта биергә өйрәтәләр. Син дә юл эшенә өйрәнерсең. Борчылма, сеңлем! Барысы да җайланыр. Бездә эшләүчеләрнең күбесе оргнабор белән килгән татарлар, башкортлар. Бәлки әле якташларыңны да очратырсың...

* * *

Гөлфия, Мирза-чүл станциясенең бер читендәге тупикка ике рәт булып тезелгән торак вагоннарны күргәч, гаҗәпсенеп калды. Болар ул утырып килгән пассажир вагоны шикелле дүрт күчәрле дә, озынча да түгел, ат арбасы кебек көтек, ике күчәрле генә такта вагоннар иде. Шулай да арада яшелгә буялган, дүрт күчәрле берничә вагон башкаларыннан аерылып тора. Якынлашкач, аларның берсе – «столовая», икенчесе – «клуб», өченчесе «душевая» икәне ачыкланды. Ә «магазин», «начальник участка» дигән язуларны ике күчәрле вагоннарга «чәпәгәннәр». Күрәсең, аларга шулар да җиткәндер.

Көн кичкә авышып барганда, Гөлфиягә, беренче чиратта, урын-җирне кайгыртырга кирәк иде.

Аның каршына, нәрсә турындадыр бәхәсләшә-бәхәсләшә, бер хатын-кыз белән бер ир-ат килгәне күренде. Ир-ат, бер кулын үзенең башы биеклеге күтәреп селки-селки, нәрсәдер исбатламакчы иде бугай. Ә хатын-кыз «сөйләмә юкны!» дигән шикелле ир-атка таба кулын селтәп-селтәп ала иде.

– Миңа Николай Недоедко дигән кеше кирәк иде, – диде кыз гаепле кеше сыман әкрен генә.

– Ә-ә, «камбала»мы? – диде ир-ат хатыны белән бәхәсләшкәндәге кайнарлык белән. – Әле генә шушы тирәдә йөри иде. Кибеттә түгел микән?

Завхоз Недоедко, чыннан да, кибеттә булып чыкты. Ул берничә хатын-кызны авызына караткан да, артистларча кыланып, нәрсәдер сөйли иде. Тегеләре дә мөкиббән китеп, аның авызына карап «катканнар»: дөньяларын онытып, аның «әкият»ен тыңлыйлар иде. Бер күзен фронтта югалткан «камбала», сыңар күзле генә булса да, яңа килгән яшь кызларны бик тиз күреп ала икән. Ул, күзләрен майландырып, Гөлфиянең кәгазен озак кына кулында әйләндергәләп торды. Ниндидер мактау сүзләре әйтте. Кыз тулысынча аңламаса да, «шундый чибәр кызны иң әйбәт, иң йомшак вагонга урнаштырмасаң, гөнаһ булыр» кебек сүзләр икәнен чамалады. Спецовка сайлаганда, ул тагын да әрсезрәк кыланды.

– Монысы сиңа зуррак икән. Монысы сиңа таррак икән, – дигән булып, Гөлфиянең әле бер егет тә кул тидерергә базмаган күкрәкләренә «ялгыш кына» кулларын тидереп-тидереп алды. Кыз, ояла-ояла, читтә тайпылды.

Хуҗалык мөдире аны патша заманыннан калган, искергән ике күчәрле вагонның бер як яртысына өч кыз янына урнаштырды. Вагонның икенче яртысында да кызлар яши иде булса кирәк, бүленгән такта аша аларның

көлешкән тывышлары ишетелде. Ярый әле, вагонның баш-башларында аерым ишекләре бар иде. Гөлфия, завхоз абзыйның «иң шәп, иң әйбәт вагон» дигәне шушы микәнни дип, үзалдына көлемсерәп куйды.

* * *

Гөлфия икенче көнне, энәдән-җептән төшкән өр-яңа спецовка киеп, эшкә барырга чыкты. Хәзер аңа колонна начальнигын күрәсе генә калган иде. Ул кая җибәрер? Иртәнге сәгать белән ике рәт итеп тезелгән торак вагоннар арасы умарта күче кебек «гөжләп» тора. Ул, кабалана-кабалана, кешеләр төркеменә таба йөгерде. Аңа кигән кителенең җиңнәренә дә, якаларына да ачкыч-чүкеч төшкән, янәшәсенә бәләкәй генә өч йолдыз «кунаклаган» эмблемалы кешене күрсәттеләр. Ни хикмәттер, җирән чәчле ул кешенең бите-күзе дә, муены да, хәтта китель җиңеннән чыгып торган куллары да кызгылт иде. Юк, бу кояшта «пешкән» тән төсендәге кызыллык түгел, гайре табигый кызыллык иде. Шулай булса да, якаларында берәр йолдызлы мастерлар да, шпаллар төшкән бригадирлар да аның авызына карап торалар, әйткәннәренә баш иеп ризалашалар иде.

Гөлфия, тәвәккәлләп, аңа кадрлар бүлегеннән биргән кәгазьне сузды.

– Дядя Вася... вәт... менә...

Тараканов каушавыннан ык-мык килеп торган кызга төксе генә:

– Дядя Вася на базаре семечками торгует, – дип кырт кисте дә, сүзем бетте дигәндәй борылып, кемгәдер дәште. Кызып-кызып нәрсәдер аңлатырга кереште.

Гөлфия кәгазен тоткан килеш тораташ катып калды. Нәрсә бу? Аны кабул итмәделәрме? Кире бордыларны? Абый дип зурлап мөрәҗәгать итте бит югыйсә...

Кемдер, бияләен учына кысып, нишләргә белми торган кызның иңбашына җиңелчә генә кагылып алды.

– Сеңлем, чүтеки ул начальник кеше бит. Аңа Василий Степанович дип мөрәҗәгать итәргә кирәк. Гомумән, руслар әтисенең исемен кушып әйткәнне яраталар. Аңладыңмы?

Гөлфия «аңладыңмы?» сүзен биредә еш ишетергә туры киләчәген аңлаган иде инде. Тел белмәүнең кыенлыгын поезддан-поездга күчеп утырганда ук кичергән иде.

Ниһаять, барысы да җайланды шикелле. Аны Җәүдәт Галимуллин бригадасына билгеләделәр. Җәүдәт Гөлфиядән күп булса өч-дүрт яшькә өлкәнрәк булгандыр, баскан җирендә ут чыгара торган егеткә охшаган иде. Ул шундук аңа инструментлар алып, вокзал каршына килергә кушты. Кыз:

– Инструментлар... – дип авыз ачкан иде, Җәүдәт аның сүзләрен ахырынача тыңлап тормады, маңгаена «инструментальная» дип язылган вагонга төртеп күрсәтте дә:

– Әнә, күрәсеңме? Кирка белән көрәк ал! – дип, җәһәт кенә китеп тә барды.

Инструмент алуның да тәртибе бар икән. Кызга, фамилиясен журналга теркәп, калай номер бирделәр. Син, көн саен иртән номерыңны биреп, кирәкле инструмент аласың һәм, эштән соң чистартып, кире тапшырырга тиеш буласың икән.

* * *

Дрезина ачык платформага төялгән эшчеләрне күпмедер баргач төшереп калдырды да үз юлына китеп барды.

Бүген бригадага поезд юлының ничәнчедер километрында черегән, ярылган шпалларны яңасына алыштыру бурычы йөкләнгән иде. Мастерлары Сәүбәнов – илле яшьләр тирәсендәге агай – яраксызга әйләнгән шпалларга акбур белән тамга салып бара. Эшчеләр шуларны алып ташларга, алар урынына яңаларын урнаштырырга тиеш. «Тиеш» сүзен әйтү генә җиңел. Вагон күчәрләрен майлаган мазут, дистә еллар буе тама-тама, шпал өстенә дә, шпаллар тирәсендә дә сыланып каткан. Ян-якларындагы мазутлы комташны кәйләң белән чокып чистартмасаң, рельс астындагы шпалны, никадәр генә көчәнсәң дә, тартып ала торган түгел.

Яңасын урнаштыргач та, рельска беркеттең дә киттең түгел әле. Шпал астын буш калдырырга ярамый. Ком-таш салып, ян-якларыннан төяргә кирәк. Әйтәсе дә юк, авыр хезмәт. Кояш кыздырганга чыдар әмәл юк. Тәннән бөрөзлексез тир ага. Тамак кибә. Инструктаж үткәргәндә үк кайнамаган су эчмәскә дип кисәттеләр. Гөлфия күңелленнән генә «И-их, үзебезнең «Шифа чишмәсе» булса!» дип уйлап алды. Аның тау башыннан агып төшкән суы, тешеңне сындырырдай салкын булса да, тамакны да авырттырмый, сусауны да баса.

Ашханә дигәннәре иртәле-кичле генә эшли икән. Төшке ашка куенына кем нәрсә кыстырып килә – шуның белән тамак ялгый. Зур титан белән чәй кайнаталар. Анысы бушлай. Күпме кирәк – эч!

Юлның бер ягында мамык плантациясе. Сабаклары биек түгел – билдән генә. Яфраклары тач бәрәңге яфрагы инде. Юл буенда үскән тут агачлары да элмә биеклеге генә. Ефәк корты, шуның яфракларын ашап, ефәк җебе үрә.

Поезд килә башласа, сары фуражка кигән сигналчы кызлар быргы кычкырта башлый. Алар «сөрән салмасалар» да, паровозның ухылдавы әллә каян, ерактан ук ишетелә. Эшчеләр поезд якынлаша башласа, тизрәк юл өеменнән төшәләр дә күләгә эзли башлыйлар. Әз булса да, ял итеп алырга форсат туа.

Эшчеләрнең дә, бригадирларның да күбесе – татарлар. Берән-сәрән генә чувашлар, марилар да бар. Барысы да теттереп татарча сөйләшә. Кайбер сүзләрне әйткәндә генә, телләре «салулап» киткәли иде.

Бригадада чылгый мыеклы Киртай исемле казакъ әкәсе дә бар. Ул тәнәфес вакытында башкалар шикелле агач күләгәсенә барырга уйламый да, бияләен астына салып, кояшта кызган рельска утыра да «насвай» тарта. Тарта дигәч тә, аның тәмәкесе авыл абзыйларныкы шикелле түгел, үзгәрәк. Нindидер үләнне киптереп, он кебек төелгән ямь-яшел төстәге порошок. Ул шуны, ярым түгәрәк савытының бөкесен ачып, бер чеметем генә учына агыза да башын артка ташлап тел астына сала. Пенсия яшенә җитеп килсә дә, өйләнмәгән. Бик өйләнер иде дә, фашист ядрәсе ул мескеннең... җан җирен өзеп алып киткән, каһәр. Шуңа күрә, кешеләрдән уңайсызланып, бүлмәсендә генә юына. Бу кадәресен Гөлфия түгел, күпләр белмәгәндер дә әле.

Эшчеләр арасында тагын бер сәеррәк, нәрсәсе беләндер башкалардан аерылып тора торган үсмер егет тә бар. Нишләптер аңа гел «шагыйрь» дип эндәшәләр. Гөлфия баштарак ул аның исеме дип уйлаган иде дә,

соңрак кушаматы икәненә төшенде (шагыйрь кеше черегән шпал сөйрәп йөрмәс бит инде!). Бүген аның кәефе юк идеме, үзе башлап сүз кушмый, эндәшсәләр, «әйе», «юк», «ярар» дип җавап бирә дә тынып кала иде.

«Шагыйрь» төш вакытында да үзалдына бикләнеп утыра бирде. Сохари кимергәне дә күренмәде, хатын-кызлар тәкъдим иткән ипи кыерчыгына да үрелмәде. Ахыр чиктә егетнең күңел түрендә кайнаган хисләре ташкын булып урылды. Ул, уфтанып, кискен генә тезенә сугып алды:

– И-их! Булмады, егетләр, булмады!

Эшчеләр аның сәерлегенә күнеккәннәр иде, игътибар итмәделәр.

Башкалар ял итү ягын караса, Зиннур хатын-кызлар тирәсендә кайнаша. Нәрсәдер сөйләп көлдереп ала. Ахыр чиктә ул, ашъяулык җәеп, үзенә аерым табын ясап утырган Сания янында тукталды. Яңарак кына утыз яшен тутырган тол хатын чәен туган Туймазы якларында – Ык буенда үсә торган үләннәр салып пешерә. Исе дә, тәме дә үзгәрәк була.

Зиннур – тел бистәсе – тота-каба гына сүз башламады.

Сания апа суга бара –
Алма-алма чиләге.
Чиләгенә караганда
Үзе – кура җиләге, –

дип такмаклап алды. Шуннан соң гына, анда да әле йомшак кына итеп сүз кушты:

– Сания апа, җаным, тамагым кипте. Зинһар, бер генә чәшке чәй бир әле.

– Әле генә Җәмилә кайнаткан чәйне эчтең бит.

– Һи-и, Сезнең чәйгә җитәме соң, Сания апа, җаным! Тәме, валлаһи менә, бер атнага җитә!

Бу кадәр мактагач, ничек күңеле эремәсен инде? Ханым мизгел эчендә балкып ала.

– И шушы Казан татарлары хәтле хәйләкәр дөньяда юктыр. Җаныем, җаныем дип кенә торалар. Авызыңны ачыбрак торсаң, сум итеңне кисеп алып китәрләр, билләһи! Мә инде. Эч! Суынгандыр түлке.

Зиннур биргән чәйне тәмләп кенә бер йотып куйды да сүзен ялгап китте.

– Хәйләкәрлеккә Уфа татарлары да калышмый, җаным. Норлатка кайтканда, Уфага да барып җитә алмадым. Чишмәдә үк чемоданымны чәлделәр.

Аларның әңгәмәсенә агач күләгәсендә утырганнар да кушылды.

– Әйтәм җирле бик тиз әйләнеп килде.

– Рәмзияне сагынудан саргая башладым да сарыга сабышканчы тизрәк килдем ди бит әле.

– Һе, Зиннур әйтер ул. Сандугач тел дип юкка гына даны чыкмаган инде аның.

– Менә, ышан син аңа, ышан.

Хатын-кызлар җиңелчә генә көлешеп алдылар.

Гөлфия эченнән генә татарларны Татарстаннан гына түгел, Башкортстаннан да чүпләгәннәр икән дип уйлап алды.

Хыял диңгезендә йөзгән «Шагыйрь» тагын уфтанып куйды.

– И-их, булмады, егетләр, булмады! Үкенечкә калды.

Чәйләп алганнар иде инде. Бу юлы берән-сәрән генә кызыксынучылар табылды.

– Нәрсә булды?

– Нәрсә үкенечкә калды?

«Шагыйрь» кабат телгә килде.

– Тагын бер ел көтәргә кирәк бит әле! Бер ел!

Җәүдәт, бригадир буларак, эшчеләрнең барысын да бертигез күрергә тиеш булса да, моннан бер ел элек үз теләге белән килеп урнашкан Таһирны ни өчендер якын күрә иде. Оялчан, гәүдәсе дә кәтүк буе гына, тәне дә кояшта янмаган Таһирга «ак малай» кушаматы тактылар. Тиресен текмәгәннәр, бер ел эчендә ул гәүдәгә калкынды. Аяусыз кыздырган кояш астында эшләгәч, тәне дә туткылга әйләнде. Кызыксынучан егет үзбәкчә дә ярыйсы «чәперә» башлады. Шигырь язарга маһирлыгын күреп аңа «Шагыйрь» кушаматы тактылар. «Ак малай» дигәне үзеннән-үзе онытылды.

Җәүдәт әле һаман пошаманда утырган егет янына килде.

– Таһир, син, нәрсә, иртәдән бирле сөмсерең коелган килеш йөрисең? Авырыйсыңмы? Бер-бер хәл булдымы?

– Юк әле, булмады. Менә бүген була!

– Нәрсә була?

– Сабантуй була!

«Сабантуй була» сүзе колакларына кергәч, тәмәке пыскытып утырган татарлар, ялгыш ишетмәдемме дигәндәй, бер-берсенә карашып алдылар. Хатын-кызлар арасында да кызыксынучылар табылды.

– Кайда була?

– Кайчан була?

– Безнең авылда! – диде Таһир горур гына. Аннары үкенгән кыяфәттә җиңелчә генә башын селкеп алды. – Кайтып булмады... Үкенечкә калды...

Таһир башына төшкән хәсрәт: аның отпуск сорап язган гаризасына җитәкчеләр кул куймаганнар. Ял вакытын көзгә күчергәннәр иде.

«Сабантуй була» сүзе колакларына кергәч, дәррәү купканнарның «авылда» сүзен ишетүгә (җете кызыл тиз уңа) «кикрикләре» бик тиз шиңде.

– Һи-и, монда буламы әллә дип торам тагын...

– Каян булсын инде ул монда?

– Аны кем оештырсын?..

Кайберләре, кул селтәп, читкә үк китеп утырды. Җәүдәт, ризасызлыгын белдереп, башын чайкап алды.

– Егетләр, кул селтәп китү җиңел ул. Үзебез тотынмасак, аны безгә кем оештырсын? Әйдәгез, быел башлыйбыз! Көрәшкә чыгарсыңмы, Таһир?

«Шагыйрь»не әйтерсең алыштырып куйдылар. Көлсәң көл! Ул урыныннан сикереп тә торды.

– Кирәк булса, хәзер үк чыгам!

Ул, көндәш эзләп, як-ягына каранып алды.

– Зиннур абый, әйдә, көрәшәбез!

Зиннур Таһирга карап көлемсерәп торды да кискен генә кулын селтәп куйды.

– Мин синең ише малай-шалай белән вакланып тормыйм инде. Батырга гына чыгам!

Аның сүзләре утка керосин сипкәндәй тәэсир итте. Таһир инде аның кулларына барып тотынды.

– Әйдә әле, әйдә! Көрәшеп карыйк әле! – диде ул, кызып.

Башкалар да җанланып киттеләр. Көтмәгәндә булачак тамаша битарафларның да «казанын кайнатып» җибәрде.

– Зиннур, әйдә, чык инде! Чык!

– Куркып калдыңмы әллә?

Җәүдәт сәгатенә карап алды. Вакыт бар иде әле.

– Әйдә, Зиннур, осталыгыңны күрсәт инде, алайса, яшьләргә, – диде ул, елмаеп.

Зиннурны төрле яктан төрткәли үк башлаганнар иде инде. Ул теләмичәрәк кенә уртага чыгып басты.

– Сөлге бирегез! Сөлге! – диде ул вәкарь генә.

Чәйханщик Җәмилә шундук икесенә ике сөлге тоттырды. Эшчеләр, ярымтүгәрәк ясап, уйламаганда-көтмәгәндә башланган көрәшне дөньяларын онытып тамаша кыла башладылар. Бил алышкан егетләрне дәртләндереп кычкырдылар, киңәшләр бирделәр. Әйтерсең туган авылларында Сабантуй карап утыралар иде.

– Бирешмә, Таһир, бирешмә!

– Һе, Зиннур, сазаган егет, остарак шул.

– Яшь булса да, Таһир да төшеп калганнардан түгел. Әнә, күрәсеңме...

Зиннур Таһирны бик җиңел генә чөеп ыргытмакчы булган иде дә, ел буе рельслар, шпаллар сөйрәп, сеңерләре ныгыган егетнең дә тиз генә бирешәсе килмәде. Зиннурның, уйлаганы барып чыкмагач, егетнең аягын чалып булса да, җиңү иде исәбе. Бу юлы да егет сизгерлек күрсәтеп өлгерде. Аның хәйләсен башкалар да күреп алганнар икән, таләпчән хөкемдарлар шикелле, аңа шундук кисәтү ясадылар.

– Зиннур, хәрәмләшә! Күтәреп ал!

Бил алышкан егетләрнең берсенең дә җиңеләсе, бригада алдында хур буласы килми иде, байтак кына тартыштылар. Ахыр чиктә Таһир Зиннурны, күтәреп, сыртына салды! Эшчеләр күңелле генә шаулап алдылар. Тормышның борчу-мәшәкатьләре, авыр хезмәт беразга онытылды. Әйтерсең, алар туган якларына кайтып килделәр.

– Һе, менә сиңа мә!

– Уйламаган идем...

– Карама беләккә, кара йөрәккә ди!

– Молодец, энем, егет икәнсең!

Зиннурның аркасыннан тузаннарын кагып торган хатын гына зарланып алды.

– Ә-әй, Сабантуй дигән булып... Имгәнмәдегезме? Безнең энебез, үткән ел көрәшеп, умрау сөяген сындырган әле. Бик кирәге барые...

Хатынның зарын тыңлаучы да, хуплаучы да күренмәде.

Сания урыныннан кузгалган Җәүдәтне җиңеннән тартып туктатты.

– Сабантуй Сабантуй инде ул. Елына бер килә дә үтә. Җәүдәт, син, чүтеки ФЗУ бетергән кеше, язып җибәр әле. Зифа Басыйрова җә Рәшит Ваһапов килсен әле бер. Үлеп яратам шуларның җырлаганнарын.

– Язгач-язгач, күмәк хат итеп, тимер юлда эшләүче татарлар исеменнән икесен дә чакырып язарга кирәк инде, Сания апа.

– И, баш та бар инде үзеңдә, ә!

Сания тагын нидер әйтмәкче иде, Җәмилә килеп кысылды:

– Карале, Сания, теге Әюпов бригадасында эшләгән Зәлифә апаның хәле ничек микән анда?

– Әлмира белән Мәэнүнә барып кайтканнар. Хәле начар ди, «Ык буенда үскән үләннәрнең шифасы тияр иде, кайтарып куймаслар микән?» – дип әйтә ди.

– Вербовщикларның тасма теленә алданып килгән кеше гомерлек гарип булып калды инде, мескенкәй.

– Поезд кадәр поезд китереп бәрсен дә сиңа. Ярый әле, исән калды.

– Һи-и, ярты ягың йөрмәгәч, исән калуда ни мәгънә?

– Әйт әле, ахирәт, син ул алтын таулары вәгъдә иткән вербовщикны очратсаң, чыраена төкерер идеңме, нишләтер идең?

– Нишләтер идемме? ...тешләтер идем! Йә, ... өзеп авызына каптырыр идем!

Әңгәмәдәш хатыннар бер-берсенең беләкләренә сарылып көлешеп алдылар.

Көрәшкәндә сулуы капкан Зиннур үз хәленә кайткан иде. Ул, Гөлфиягә ымлап, егетләргә сүз катты.

– Егетләр, үпкәләштән булмасын, яңа килгән чибәркәйне яңа җирләр, бу якларның әрәмә-тугайлары белән таныштыруны мин үз өстемә алам.

– Рәмзияң ишетмәсен. Башыңда бер бөртек чәчең калмас.

– Рәмзия ялгызы йөрергә өйрәнде инде ул. Татарга тылмач кирәкми дип кенә җибәрә. Ә менә бу чибәр кызга минем кебек тел белгече кирәк. Мин үзбәкчәсен дә, казакъчасын да...

Сания аңа җәелеп китәргә ирек бирмәде.

– И мактанмасана ла. Үзбәк теленең нәрсәсе бар соң аның? Сүз саен бер иҗек өстисең дә куясың инде. Була диясе урынга булады дисең. Булды урынына булыпты дисең.

Аларның әңгәмәсен сигналын сызгырта-сызгырта якынлашкан составның гөрелтесе күмеп китте.

Поездан коелып калганнар диярсең, көтмәгәндә каяндыр дүрт почмаклы кәләпүшләренә зур гына өтер төшкән, буй-буй сырган чапан кигән ике үзбәк егете пәйда булды. Нәрсә кыдырып йөргәннәрдер, шайтан белсен! Алар, әрсезләнеп, ял итеп утырган эшчеләр янына якын ук килделәр. Игътибар белән тыңласаң, аларның үзара сөйләшкәннәрен аңларга була иде.

– И-ия, нугай кызлары килепте – ю! – диде берсе, икенчесенә карап. – Эргәш әнә, әнә, кара кызны күрәсеңме? Җөдә һәм чырайлы икән, ә!

Һәм ул тартынусыз-нисез Гөлфиягә төртеп күрсәтте.

Икенчесе, иптәше белән килешкәнен белдереп, баш какты.

– Һә-ә расгәперәсән. – Аннары Гөлфиягә дәште.

– Һай, күзеңдән... Атың ни? Әлфияме, Зөлфияме?

Төшке аш вакыты тәгәлләнеп килә иде. Җәүдәт, ике телне кушып, егетләрне куарга тотынды.

– Һәй, сез, әкәләр, үкәләр! Комачаулап йөрмәгез монда! Барыгыз, бар!

Җәүдәтнең вазифасы буенча өлкән икәнен чамалап алган үзбәк егетләре аңа сырпаланырга тотындылар.

– Яхшы егет, безләргә биттә кыз табып бирсәңче...

– Һә-ә, таныштырсаңчы, бездә кәттә миһман булырсың.

Үзбәк егетләренең бездә кадерле кунак булырсың дигәннәренә Җәүдәтнең исе китмәде.

– Тимер юл буенда буталып йөрергә ярамый. Күрәсезме, поездлар йөреп тора. Барыгыз, бар! – дип куып җибәрде.

Алар ризасызлыкларын белдереп:

– И-и, и-я! Бу ни бу? – дия-дия, күздән югалдылар.

Гөлфиянең биленә кадәр төшкән толымнарын күргәч тә, Зиннурның күңелендә вәсвәсәле уйлар туган иде. Бүтәннәр күз салганчы кызның кылларын тартып карарга кирәк.Ниндирәк кош икән, янәсе.

– Чибәрләр чибәре Гөлфия туташ, бүген безнең вагон-клубта индийский кино күрсәтәләр. Кил! Курыкма! Үзем озатып куярмын. Юкса, күрдең бит, үзбәк егетләре татар кызларына бәйләнергә генә торалар.

– Мин клубыгызны күрдем инде, – диде Гөлфия тыйнак кына. – Барасым килсә, үзем дә юлны табармын. Рәхмәт!

– Әттә-тә, әйттеме үзеңә. Урал яклары шулай алар. Җырлаганда да безнең сыман: «саргаям синең өчен... оныта алмасам нишләрмен...» дип, балавыз сыкмыйлар. «Агыйдел, Чәрмәсән, исемем Бибкәй булмасын, шул егеткә бармасам», – дип кенә җибәрәләр.

– Юк, апа, мин Сарман якларыннан, – диде Гөлфия тыныч кына.

Җәмилә ихтыярсыз куллары белән үзенең янбашларына шапылдатып алды.

– Шулаймыни? Ә мин сине Урал якларыннан дип торам тагын.

Кызның кире җавабы Зиннурның «казанын кайнатып» җибәргән иде. Ул хатын-кызларның холкын белә. Сүзгә дә кесәгә кереп тормый. «Сандугач тел» кушаматы аңа юкка гына бирелмәгән. Ул бу кызны барыбер «сындырачак». Башкалар кул сузганчы кисәтеп куярга кирәк.

– Егетләр! Шушы кызны үземә каратмасам, исемем Зиннур булмасын!

Ул, кызып китеп, хәтта баш киемен җиргә бәрде.

– Булдыра алмасаң, Зиннур түгел, Синбур диярбез инде, алайса.

– Һәй, егет, фуражкаңны ки, башыңа эссе капмасын. Кояш иңкүллеккә төшмәгән бит әле.

Зиннурның кыланышына баядан бирле саруы кайнаган Сания түзмәде:

– Очраган бер хатын-кызга сикерергә, син, нәрсә, нәсел айгырымы әллә? Алай бик азынсаң, хәзер печтерербез без сине!

Эшчеләр рәхәтләнеп көләргә тотындылар.

– Ну, малакаем, синең телең, ә! Пычаксыз суясың, билләһи!

– Бәй, артыгын кыланмасын. Кайтып, авылда калган баласын карасын. Шулай бит, Җәүдәт?

Ул аны, култыклап, читкәрәк алып китте. Бая әйтергә кыжраган, Җәмилә аркасында бүленгән сүзе бар иде.

– Бригадир булсаң, бригадир бул инде син, Җәүдәт. Атнага бер булса да кереп, «хәл белеп» чык инде. – Ул, кыбырсып, Җәүдәтнең култыклаган кулын әкрен генә кысып-кысып алды. – Нәрсә, кызлар клубка киткәч, киләсеңме? Берәр кызылны да әзерләп куярмын.

Тол хатын бер күзен мут кына кысып елмайды. Күзләре көйдереп алырдай булып яна. Ә иреннәре... иреннәре... пешкән чия төсле ымсындырып

торалар. Сугыштан соң килгән кырыс еллар да аның яшьлек гүзәллеген юып китмәгән иде.

Җәүдәт Саниянең култыгыннан кулын алды.

– Сиңа бирәр үзбәк табып бирмичә булмый инде, Сания апа.

– Үзбәк?! Гомергә ир чырае күрмәсәм дә, чыкмыйм мин аңа!

– Ник алай дисең? Әнә бит әле генә ике егет килгән иде.

Димәк, татар кызлары монда да почётта.

– Беләм мин аларны, беләм. Калым түләргә акчасы юкка килгәннәр алар.

– Ну елгыр да инде, син, Сания апа! Барысын да беләсең!

– И-и, «апа» дигән булып, картайтма әле син мине. Әнә, Мөхәммәд пәйгамбәрнең дә беренче хатыны Хәдичә үзеннән унбиш яшькә өлкән булган. Мин дә бит әле кырыкка җитмәгән. Синең белән нибары сигез яшь аерма.

Сания ялгыз калган минутларда яу кырында ятып калган Сәетҗанны искә ала. Өзелеп сагына. Юксына. Гитлерны каһәрли. Аның сөеклесе дә Җәүдәт кебек тәвәккәл иде. Сугышта да шулай, тәвәккәләп, ут эченә барып кергәндер. Алай дисәң, «хәбәрсез югалды» дигән хәбәр җибәрмәсләр, «батырларча һәлак булды» дип язарлар иде. Аяксыз-кулсыз кайтса да, ул аны читкә типмәс иде. Сәетҗанкае исән булса, ул, болай мәсхәрәгә калып, кулдан кулга да йөрмәс иде... И-их, гомерләр, гомерләр... Кайчан да булса аңа тугыз ай карынында йөрткән сабыеның исенә исереп, күкрәгенә кысып сөюләр насыйп булыр микән?

* * *

Гөлфия өчен монда барысы да үзгә иде. Еракта-еракта Ходаның бирмеш һәр көнендә кояш яктысында утырса да, түбәсен эремәс кар каплаган мәгърур таулар тезмәсе! Тау буенда гомер сөргән адәм баласына, мөгаен, шул таулар горурлыгы сеңә торгандыр. Ә безнең Каравыл тавы дип йөргәнебез дә гап-гади бер калкулык кына.

Ял көнне, кызларга ияреп, базарга баргач, мондагы муллыкка аның исе китте. Безнең якта мескен авыл кешесе печәнен-саламын аннан-моннан көчкә юнәтеп асраган малының түшкәсе бихисап салымнар түләргә китә. Ә үзе эче-башы белән генә юана. Ә монда җаның нинди ит тели – барысы да бар. Бәяләре дә тешли торган түгел, арзан гына.

Кызлар Гөлфияне үзләреннән аерылып калмаска кисәттеләр. Ир-атлар белән дә сөйләшеп торырга ярамый икән. Кызның битен-күзен пәрәнҗә белән каплаган хатын-кызны да беренче күрүе. Үзе борчак чүмәләсе кебек юан хатын (көмәнле булса кирәк), юеш борынлы ике баласын җитәкләп, аларның каршысына килә иде. Кигән күлмәге үзеннән дә озын. Аягындагы башмаклары хатын атлаганда гына яртылаш күренеп-күренеп ала иде. Пәрәнҗәне ат кылыннан киндер суккан кебек сугалар икән. Җәйге челләдә пәрәнҗә бөркәнеп йөрү рәхәт түгелдер. Күрәсең, биредә гореф-гадәтләр законнан өстенрәк.

Гөлфиягә чәйханә дигәннәре дә кызык тоелды. Учак өстенә көйләнгән зур казанда пылау пешерәләр. Авыздан су китерерлек тәмле ис тирә-якка таралган. Аш-су тирәсендә хатын-кыз затын күреп күнеккән кыз, казан янында кайнашкан ир-атны күргәч, гаҗәпсенеп калды. Ул көрәк кадәрле

агач калак белән мамык маенда чыжлап утырган кишер, дөге, ит кисәкләрен әледән-әле болгатып тора. Клиентларга чәй «дәмләп» торучы да башына дүрт почмаклы кәләпүш чәпәгән үсмер егет иде.

Җиләк-җимешләр рәтендә дә ир-атлар сәүдә итә.

– Падхади, народ! Свой огород. Палавинә – сахар, палавинә – мёд! – дип, такмаклый-такмаклый, ничек тә товарын сатарга тырыша.

* * *

Күчмә колонна булгач, эшчеләрне ике станция арасындагы юлда ремонт эшләрен бетергәч, торак вагоннары белән бергә икенче урынга күчерәләр. Почтальоннар аларны Үзбәкстан буйлап эзләп йөрмиләр. Килгән хатлар, салган посылкалар турыдан-туры Ташкенттагы юл идарәсенә килә. Атнасына ике мәртәбә аларны почтальон Хәмидә алып кайта. Аны пәйгамбәр кунагы кебек перронда көтеп торалар, сырып алалар.

– Хәмидә апа, миңа хат юкмы?

– Хәмидә апа... миңа...

– Хәмидә апа...

Кулларына конверт эләккән бәхетлеләр, шундук читкәрәк китеп, түземсезләнеп, каударлана-каударлана, аны ачалар, дөньяларын онытып (Хет сум итен кисеп ал! Сизмәячәкләр!) укырга тотыналар.

Өйдә ниләр бар икән? Әти-әниләр, туган-тумачалар исән-сау микән?.. Аларның хат укыгандагы кичерешләре йөзләренә дә күчә. Кемдер кояш кебек балкып-балкып ала, кемдер, сагышланып, уйга кала...

* * *

Почтальон хатыннан Ташкентта Зифа Басыйрова гастрольләре буласын ишеткәч, Таһирның йокысы качты. Аның ничек кенә булса да җырчыны күрәсе килә, тамашачыларны әсир иткән җырларын үз авызыннан ишетәсе килә иде. Бу хәбәр аңа, ятса да, торса да, тынгылык бирмәде, күңелен кытыклап, бимазалап торды. Нишләтәсең, адәм баласы һәрчак матди һәм рухи ихтыяҗларга бердәй мохтаҗ. Булачак концертның ял көненә туры килүе дә аны канатландырып җибәрде. Зифа Басыйрованың концерты эче дә, тышы да күркәм Свердлов исемендәге Концертлар залына билгеләнгән иде. Тамашага билетлар күптән сатылып беткән. Шулай булса да, урам тулы халык! Сабантуй диярсең! Әйтерсең ярты Ташкент җыелган! Концертка агылган халыкны троллейбустан төшүгә уратып алалар. Телләрендә фәкать бер сүз:

– Артык билетыгыз юкмы?

– Артык билетыгыз...

Барысының да халык мәхәббәтен яулаган җырчыны күрәселәре килә. Сагыну хисләрен басасылары килә.

Яхшы булса да торган як,
Сагындыра туган як...

Әйе, җырда барысы да төгәл әйтелгән.

Таһирны кадрлар бүлеге җитәкчесе Исламия Кәримовна күреп алмаса,

бәлки ул борынын салындырып кайтып киткән дә булыр иде. Ханым, билет эзләп, әрле-бирле йөренгән егетне танып алды.

– Таһир энем, син түгелме соң бу?

– Исәнмесез, Исламия Кәримовна!

– Нәрсә, Мирзачүлдән килдеңме? Әллә Ташкентта танышларың бармы?

Таһирның монда каян танышлары булсын инде. Ул боек кына:

– Мирзачүлдән килдем. Билетлар юк икән, – дияргә мәҗбүр булды.

Ханым, елмаеп, иренә нидер әйтте дә:

– Әйдәле, энем, минем белән! Әйдә! – дип, Таһирны ияртеп алып китте.

Ул, күзенә керердәй булып: «Артык билетыгыз юкмы?» – дип йөргән кешеләрне аралап, туп-туры ишеккә юнәлде. Ишек янында хуҗаларча басып торган контролёр белән үзбәкчә сөйләшә башлады. Таһирга ым кагып ала-ала нәрсәдер сөйләде. Бераздан үзбәк:

– Җай йук! – дип, җиңелчә генә башын чайкап алды.

Үзбәкнең «урын юк» дигәненә ханымның исе китмәде. Ташкентта күптән «тамыр җибәргән», үзбәкләрнең гадәтен яхшы белгән Исламия Кәримовна, «миһман егет» сүзен кыстыра-кыстыра дәлилләп, сүзен дәвам итте. «Кунак егет» сүзен ишеткәч, үзбәкнең күңеле эри башлады бугай. Ханым ахыр чиктә: «Чүнтәгең ачылган кү», – дия-дия, контролёрның кесәсен төзәткәләгән булып, акча сонды. Шуны гына көткәндәй, контролёр үзбәк ишеккә арты белән борылды. Ханым шундук Таһирны аркасыннан этеп, эчкә кертеп җибәрде. Колагына:

– Арттагы рәттән басып карарсың, – дип пышылдады.

Таһир бу кадәресенә дә чиксез шат. Ул Зифа Басыйрова концертын басып түгел, ятып карарга да риза иде.

* * *

Таһир концерттан соң вокзалга килгәндә, Мирзачүл ягына барасы пассажир поездлары китеп беткән. Ә аңа, таш яуса да, кайтып өлгерергә кирәк.Ул кузгалырга торган товар поездының тамбурына сикерде. Ике ягына да баскычлар көйләнгән тамбурның күтәртеп, стенага беркетелгән бер кешелек кенә такта утыргычы да бар. Кирәк чакта төшерәсең дә утырасың. Менә сиңа бер кешелек купе! Вагоннар текелдәгән тавышка кушылып җырлый-җырлый кайтасың. Кичке җиләс җил синең җырыңны еракларга алып китә.

Тамбурлы вагоннар составта берничә. Кесәләрендә җилләр уйнап торган куяннарга менә дигән бушлай транспорт! Билет тикшерүче кырыс контролёрлар да юк. Дөрес, ул куяннар өчен дип эшләнмәгән, составны озата баручы хезмәткәрләр өчен көйләнгән. Әгәр кыйммәтле товар төялгән булса, «койрык»тагы вагонның тамбурында мылтыклы сакчы составны саклап бара. Якын да килә алмыйсың.

Таһир кунаклаган өсте ачык вагонга ташкүмер төялгән иде. Җиләс җил, поезд җиле белән кушылып, ташкүмер тузанын җилгәрә – тирә-якка очыра. Тузан тамбурга да керә, колак яфракларына, керфекләргә куна, күлмәк якаларына, борынга тула, күзләрне әчеттерә.

Үч иткәндәй, ни сәбәптәндер, Янги-юл станциясендә составны озак

кына тоткарладылар. Поезд күчмә колонна урнашкан Мирзачүлгә таң беленгәндә генә якынлашты. Таһир эшкә барганчы бер-ике сәгать булса да черем итеп алырмын дип уйлаган иде. Әмма станциянең ике башындагы семафорларның икесе дә «борыннарын күккә чөйгән» – күтәрелгән иде. Димәк, поезд станциядә туктап тормаячак. Сикереп калмасаң, әллә кайларга алып китүе бар. Бетон перронга сикерергә ярамый да ярамый инде. Сынмаган сөягең калмас!

Кырыклап вагонны сөйрәп барган паровоз кызыл фуражкалы, төрелгән сары төстәге флажок-әләмчеген күкрәге биеклеге күтәргән дежурныйга (станция нәүбәтчесенә) «барысы да тәртиптә!» дигән шикелле сигналын кычкыртып сәлам бирде дә дөбердәп үтеп китте. Киләсе станция унсигез чакрымда. Анда да туктамаса, бетте баш! Эшкә соңга калырга да ярамый. Тимер юлда тәртипләр кырыс! Һәр җирдә төгәллек! Ике рельс арасы да миллиметрлар белән үлчәнә.

Таһирның бар өмете: җиде чакрым үткәч, поезд тизлеген киметергә тиеш. Ул участокта алар шпал араларын иске балласттан чистарттылар – шпаллар ялангач калды. Андый участок хәвефле санала. Аны үткәндә товар поездлары гына түгел, «скорый» поездлар да тизлеген киметә. Эшкә килгән машинистларга, «Маршрут кәгазе» белән бергә чакрымнарын күрсәтеп, «Предупреждение!» дип язылган кисәтү кәгазе дә бирәләр.

Зифа Басыйрова концертын карап кайткан егеткә җиде чакрымны тәпиләп кайту пүчтәк кенә инде!

Таһир торак вагоннарына кайтып җиткәндә, егетләр татлы таң йокысы белән изрәп йоклыйлар иде. Ул бүлмәдәшләрен юынгычны шалтыр-шолтыр китереп уятмас өчен аннан-моннан гына юынды да мендәренә ауды. Ташкүмер тузаны иртән юынганда да бетмәгән иде. Кешенең юк кына кимчелегеннән дә көләргә яраткан Зиннурга шул җитә калды. Ул астыртын гына елмаеп:

– Син, Таһир, төнлә шахтага шабашкага төштеңме әллә? – дип ихахайлады.

Эшчеләрнең кайберләре генә Таһирга карап елмаешып алдылар да өзелгән әңгәмәләренә «чумдылар».

Җәүдәт егетнең кыяфәтенә карап алды да:

– Дрезина килгәнче, бар, тиз генә чумып чык! – дип, аны станция янындагы арыкка җибәрде.

Таһир ничаклы гына тырышып ышкыса да, майлы ташкүмер тузанын арыкның салкын суы ала алмады.

* * *

Искергән балласттан арындырганнан соң бушап калган шпал араларына салыр өчен бортлары ике якка да ачыла торган платформаларда эре ком белән аралашкан чуерташ-гравий китерәләр. Ул бер состав комташны поездлар йөрешен туктатып бирелә торган «окно» вакытында бушатып бетерергә кирәк. Платформа саен икешәр эшче генә куялар. Ике сәгать буе алсыз-ялсыз эшләргә мәҗбүр булган кешеләрнең маңгайларыннан аккан тирләрен сөртеп алырга да аралары юк. Борын буйлап агып төшкәннәрен дә тыннары белән генә өреп җибәрәләр.

Җәмилә, капкачлы эмаль чиләген күтәреп, бер платформадан икенчесенә күчә-күчә, чәй өләшеп йөри. Аңа әле тегеннән, әле моннан «Чайханщик!» дип кычкырып кына торалар. Пассажир поездларында вагоннар тоташкан буферлар өсте табаклы калай белән капланган. Ян-якларына ныклы материалдан саклану пәрдәләре корылган. Ә йөк вагоннарында алар юк. Берөзлексез шыгырдап, күңелгә шом салып торган буферлар аша үткәндә, Җәмиләнең йөрәге урыныннан куба: кылдан нечкә, кылычтан үткен сират күперен кичкәндәй була! Комташ тигез төшсен өчен состав бер алга, бер артка йөреп тора. Аягың таеп, ике платформа арасына егылсаң, исән калырмын димә!

Бригадир Җәүдәт беркемне дә аралап та, аяп та тормый. Гөлфиягә кулдаш итеп бер чуваш кызын билгеләде. Алар, бригадирлары өйрәткәнчә, платформаның икесе ике башына кара-каршы басып чүмәләм өелгән комташны бушатырга тотындылар. Кулларында як-яклары калкып торган колаша (совковый) көрәк. Аңа, ким дигәндә, бер пот сыя торгандыр! Гөлфия, авылда кая кушсалар, шунда эшләп үскән кыз, кешеләрдән калышмаска тырыша. Кулдашы Ольга да тырыша тырышуын. Киемнәре тиргә батып, тәненә ябышып беткән. Елгыр егетләр платформаларын чистартып, дөбершатыр бортларын яба башлады. Ә аларның платформасында әле һаман чүмәлә кадәр бер өем чуерташ сераеп тора. Аны ничек «окно» вакыты беткәнче бушатып бетерергә? Белгән юк! Көтмәгәндә буферлар аша аларның платформасына Таһир сикерде. Сүзсез генә чуерташ чүмәләсенең өстенә менеп басты.

...Эштән кайтканда, Гөлфиянең куллары кабарып чыккан иде. Йа Раббым! Көн саен мондый эш булса, нишләрсең? Ике ел буе кәтер хезмәтенә ничекләр түзәрсең?..

* * *

Гөлфия Таһирны беренче күрүендә сәеррәк егет дип уйлаган иде. Әмма беренче тәэсирләр алдаучан булганын тора-бара аңлады. Ташкүмер тузаннарына бата-чума концерт карап кайткан егет кемнәрдер өчен сәеррәктер дә. Гөлфия үзе туган авылын, якыннарын төшләрендә күрә башлагач, аның хәлен аңлады. Дәртләнеп көрәшеп тә алгач, өстәвенә Зифа Басыйрова концертын да тамаша кылып кайткач, Таһирның күңеле бераз тынычланып калгандай булды.

Гөлфия егетне жәлләп куйды. Аның ташкүмер тузаннарына баткан киемнәрен юып, үтүкләп бирде.

– Керләнгән киемнәрең булса, китер. Юып бирермен.

– Рәхмәт! Монысы өчен дә рәхмәт әле!

– Икенче мәртәбә ташкүмер төялгән составка утырма инде.

– Карап торып булды, ди, сиңа! Миңа бит ничек тә эшкә кайтып җитешергә кирәк иде.

– Ничек, концерт әйбәт булдымы соң? Ошадымы?

– Концерт ошады. Тамашачылар ошамады.

– Нишләп?

– Үзләре татар концертына килгәннәр, ә үзләре...

Ул сүзләрен әйтеп бетермәде, кулын гына селтәп куйды.

– Сине шагыйрь диләр бит. Концерттан алган тәэсирләрең турында берәр нәрсә язмадыңмы соң?

Таһир әйтерсең шуны гына көтеп торган иде.

– Яздым! Укып күрсәтимме?

– Әйдә, укы!

– Көлмәссеңме соң?

– Юк.

Таһир куенынннан дүрткә бөкләнгән кәгазь кисәге тартып чыгарды, дәртләнеп, артистларга охшатырга тырышып укырга тотынды. Шигырь концертка килгән тамашачыларның ярым татарча, ярым үзбәкчә сөйләшүләрен тәнкыйтьләп язылган иде. Гөлфиягә аеруча шигырьнең:

Кем кушты сиңа, милләттәш,
Туган телең онытырга?
Анаң телен салып таптап,
Башка телне йолкырга?

Өйрән син башка телне дә,
Без моңа каршы түгел.
Ләкин инде үз телеңне
Онытырга ярамый гел, –

дигән соңгы куплетлары ошады. Ул ихластан сокланып, кулларын чәбәкләп алды.

– Әйбә-әт! Син чын шагыйрь икәнсең бит, Таһир!

Егет ризалашмыйча башын чайкап алды.

– Юк, әллә ни түгел инде. Болар ачу килгәндә генә сырлаган шигырьләр шунда.

– Эчтәлеге әйбәт бит. Тагын ни кирәк?

– Эчтәлеге әйбәттер, килешәм. Тик аны барыбер, чын шагыйрьләрчә, бер укуда кешенең күңеленә сеңәрлек итеп, Тукайлар, Такташлар кебек итеп язарга кирәк.

– Өйрәнерсең. Киләчәктә син дә алар кебек яза башларсың.

Күчмә колоннада Тараканов шикелле чегән тормышына күнеккән, тора-бара үз иткән берничә гаилә бар-барын. Шулай да эшчеләрнең күбесе – вербовщикларның тасма телләренә алданып, кармакка эләккән кешеләр. Үз ихтыяры белән килгәннәр бармак белән генә санарлык. Таһир да шул «ала каргалар» рәтендә. Гөлфия күптән бу турыда сорарга кыймый йөри иде, бүген тәвәккәлләргә булды.

– Таһир, әйт әле, нишләп син монда үз ихтыярың белән килеп, рельслар, шпаллар сөйрәп йөрисең?

Егетнең бу турыда сөйлисе килми идеме, бер тын сүзсез торганнан соң гына телгә килде.

– Мин детдом баласы бит, – диде ул, карашын ерактагы тау тезмәләренә төбәп. – Дөнья күрәсем килде. Әтием фронтта һәлак булган. Әнием сугыш чорындагы ачлыктан вафат булды. Шуннан соң мине ятимнәр йортына урнаштырдылар. Хәзер минем авылда әбием белән бабаем гына бар.

– Шулай да син ятимнәр йорты турында түгел, күбрәк авыл турында, Сабантуйлар турында сөйлисең.

– Ятимнәр йорты дигән сүз үзе үк кыерсытылган язмышлар йорты дигән сүз бит инде ул, Гөлфия. Аның нәрсәсен искә аласың? Ә авыл кешеләренең, әбекәй белән бабакайның эчкерсез, ихлас мөнәсәбәте хәтергә күбрәк сеңеп калган инде. Хәзер отпускыга кадәр түзәм дә... аннан күз күрер. Хәйрулла Усманович көз көне диде бит.

Каяндыр килеп чыккан Зиннур аларның әңгәмәсенә килеп тыгылды.

– Нигә, көз әйбәт инде. Каз-үрдәкләрнең симереп җиткән чагы була.

– Зиннур абый, синең бар хыялың симез үрдәк, симез каз да чибәр кыз бугай инде.

– Ә нигә? Кеше ашар өчен, яхшы киенер өчен яши. Аннары... аннары... Кызларны яратыр өчен яши. Шулай бит, Гөлфия?!

Кыз тел бистәсе ир-атларны гомергә өнәмәде. Әтисе дә андыйларны «бушбугаз» ди торган иде. Әнисе дә аны озатканда, кызым, берүк бушбугазларның тасма телләренә ышанып, алдана күрмә дип кисәтте. Ул Зиннур өметләнгәнчә җилбәзәк түгел, авыз ачмады.

Таһирның тормышка, яшәешкә карата үз фәлсәфәсе.

– Алай гына түгел! Кеше кешеләргә яхшылык эшләр өчен яши. Җәмгыятькә, әз булса да, файда китерер өчен, дөньяны агартыр өчен яши... Балалар үстерер өчен...

– Йә, әйт әле, көз көне анда кайтып, нәрсә эшләмәкче буласың инде? Ул чакта синең хыялланган Сабан туеңнан җилләр искән була бит.

– Минме?... Андамы?... Мин...

Таһир, бертын башын иеп, уйланып торды. Бераздан горур башын югары күтәрде, уң кулын алга сузды. Бу минутларда ул очып китәргә әзерләнгән бөркетне хәтерләтә иде.

– Үз илемә кайтып, җиргә ятып,

Әрләннәргә шигырь сөйләрмен! Белдеңме?

– Син, хыялый, гомердә булмаган нәрсәләр сөйләргә оста инде.

Зиннур кулын селтәп китеп барды. Ә эчендә кайнаган ачуы басылмады.

Гөлфияне күргәч, килеп сүз каткан иде. Кызның кылларын тартып карамакчы булган иде. Күр инде син ул кызыйны, ә! Шул хыялыйның авызына караган да каткан. Дөньясын онытып, шуның әкиятен тыңлап тора. Тьфу!

***

Эшчеләр көн туды исә станция алдындагы перронга җыелалар. Аларны кирәкле километрга илтә торган дрезина, чакыру сигналын көтеп, тупикта тора. Машинист инде моторын кабызган. Бәләкәй генә үзйөрешле платформа күшеккән кәҗә бәтиедәй җиңелчә генә дерелдәп утыра. Эшчеләрне төяп китәргә диспетчерның рөхсәте кирәк. Станция начальнигы, Ташкентта утырган диспетчерның рөхсәтен көтеп, ярты сәгать инде телефон трубкасын кулыннан төшерми утыра.

Эшчеләр, форсаттан файдаланып, перрон буендагы, биеклеге билдән артмаган тимер-бетон коймага эш коралларын сөяп, гәп коралар, яңалыклар белән уртаклашалар. Ир-атлар тәмәке пыскыта. Хатын-кызларның үз гаме.

– Фатыйма, синең вербовка срогың кайчан тула?

– И-и, тагын ярты ел бар шул әле.

– Минеке ике айдан тула, Алла боерса!

– Карале, ахирәт, үзбәкләрне әйтәм, җиләк-җимешне үстерәләр, нишләп тимер юлда үзләре эшләмиләр икән? Акча яраталар югыйсә.

– Акча яратсалар да, эше авыр шул.

– Акча дип, бу кәтер хезмәтенә кем чыдасын?

Аларның кәтер дигәннәре каторга сүзенең татарча әйтелеше инде.

– Кызлар, ишеттегезме, Зәлифә апагызның хәле начарланган, ди, бит әле.

– Шулаймыни? Ишетмәгән идем.

– Төне буе ыңгырашып чыга, ди, мескенкәй.

– Кит инде! Тәки мантый алмас микәнни инде?

– Таракановка әйтергә кирәк. Бүлнискә салсыннар.

– Аның артыннан кем йөрсен инде?

– Бәй, бригадирлары бар бит. Әйтсен!

– Әнә теге... завхозның буш вакыты дачурта! Илтсен!

– Әйе шул! Гел хатын-кыз итәген күзәтеп йөрмәсен, тоз күз!

– Әйтерең бармы? Фашист! Камбала!

– Беркөнне сабын алырга кергән бригадир Әюповның хатынын кочакларга маташа, ди, оятсыз!

– Равил ишетсә, икенче күзен дә төртеп тишә инде.

– Безнең кебек көне буе перегонда шпал сөйрәп, мазутка каткан чуерташ чокып йөрсә, хатын-кыз кайгысы булмас иде. Хөрәсән ялкавы!

***

Безнең татар эшчән, тырыш (кирәк булса, ком чүлен гөлбакчага әйләндерә), җырга-биюгә һәвәс булуы өстенә шагыйрь дә әле ул! Кайда яшәсә, шул төбәк атамаларын кертеп, үзенең язмышын чагылдырган җырлар чыгарган. Шахта, Уфа-Чиләбе, Порт-Артур, Герман көе һәм башкалар – моның ачык мисалы. Хәтта кул сузымындагы Самара да татар җырына кереп киткән.

Әйдә, барыйк Самарга –
Җәйли печән чабарга;
Печән чапкан акча җитмәс
Тишек-тошык ямарга.

Ә гармун – аның мәңгелек юлдашы. Ул аны, яу кырында үлем белән күзгә-күз очрашканда да, үзеннән калдырмаган. Ә Ташкент якларында гомер сөргән татарларның үз фольклоры. Җирле халык белән аралашып яшәү дәверендә барлыкка килгән «Ярамаган тагын татарга каз ите, ашасын үзбәкләр дөя ите» кебек шаян гыйбарәләр.

Вербовка белән бу якларга килеп чыккан апалар вагон-клубны дер селкетеп биегәндә әйтә торган:

Тыпыр-тыпыр, тыпыр-тыпыр
Тыпырдатабыз гына,
Көн ярымга мең ярымны
Шапылдатабыз гына, –

кебек такмаклар;

Яратам Ташкент каласын,
Үз итәм үзбәкләрен.
Килгән якларыма карап,
Өзелә үзәкләрем, –

кебек җырлар чыгарган.

Поездлар төрле тарафларга йөреп тора. Утыр да кит югыйсә! Ә юк... Утырып кайтып китәр иде, койрыгы бозга каткан. Договор белән беркетелгән вербовка срогы бар. Шуны тутырмыйча беркая китә алмыйсың.

Җырларның мондыйраклары да бар:

Үзбәкстан – мамык иле,
Ташкент – таш арасында.
Бу дөньяның бар рәхәте
Якташлар арасында.

Бу һич арттырусыз шулай. Татарча сөйләшкән кешене күрсәң, туганыңны очраткандай буласың. Сөйләшер сүзләр бетми.

Бүген вагон-клубка Җәүдәт тимер юл буеннан куып җибәргән үзбәк егетләре дә килгән иде. Алар мотлак кемнедер көтәләр иде булса кирәк, вагон-клубка кермичә, бер як читтә басып тора бирделәр. Шулай булып чыкты да. Вагон-клубка якынлашкан Зиннурны күргәч, алар бердәй җанланып киттеләр, бер-берсенә карашып «Эш пешә!» дигән төсле канәгать кенә елмаешып алдылар. Зиннур кызмача иде бугай, борын эченнән генә яраткан җырын сузып килә иде:

Зимагурны шуннан таныйм,
Каеш буа биленә.
Ашый калҗа, коча марҗа,
Ник кайтсын ул иленә!

Ул егетләр белән (кайчан танышып өлгергән!) якын дуслары кебек колачын җәеп күреште, үзбәкчә дә сукаларга тырышты.

– Хуш келипсез, егетләр! Сезне күрүемә мән шатмән!

– Сәламалейкум, Зиннур әкә!

– Һә-ә, яхшымысыз, Зиннур әкә!

– Яхшы, яхшы! Сезнең әхвәлләр кандай?

– Мәнеке унча яман имәс, – диде гәүдәгә калкурагы. – Мәнә Ишмәт үкәгәкәмпер кирәк. Сән кайчан биттә кыз табып бирәсән?

Янында басып торган карсак буйлысы, кабаланып, аның сүзен җөпләде.

– Һә-ә, сән әйтепсән кү!

– Әйткән идем әйтүен дә. Сезнең өчен бер дә яхшы кыз юк бит әле. Һәммәсе дә теге... ни...

Ул ни әйтергә белми торганнан соң үзбәк егетләренең колакларына нидер пышылдады. Аның сүзе егетләрнең күңеленә хуш килде, ахры, күмәкләшеп көлеп алдылар.

– Яхшысы кайчан булады?

– Скоро Башкортстаннан йаш кызлар киләде. Шуларның биттәсе обязательно сезнеке булады.

Зиннурның сүзләренә ихластан ышанган карсак буйлысы, хәзер үк кәләш куенына керергә әзерләнгәндәй түземсезләнеп, тагын телгә килде.

– Скоромы? Расмы?

– Рас, рас! Скоро киләчәкләр.

Ант иткән кебек кулын йөрәге турысына куеп сөйләгән кешенең сүзенә ничек ышанмыйсың инде. Кәләш кыдырып йөргән егетләрнең карсак буйлысы аягы янында торган ярыйсы гына зур төенчекне Зиннурга сузды.

– Мәнә бу сезгә, Зиннур әкә!

– Һо-о! Рәхмәт!

– Көтәмез, Зиннур әкә!

– Көтегез, көт! Обязательно биттә кыз сезнеке булады.

Юллары уңганына ихластан ышанган үзбәк егетләре кулларын күкрәкләренә кушырып саубуллаштылар.

Зиннурның кәефе болай да күтәренке иде. Үзалдына әкрен генә әйтеп куйды.

– Обещанное три года ждут. Көтегез, көт. Скоро минем вербовка срогы тула. Аннан соң тотарсыз минем койрыкны.

Ул, өзелгән җырын көйли-көйли, үзбәк егетләре калдырган төенчекне чишә башлады.

– Ашый кал-җа-а, коча-а мар-җа-а... Һо-о! Монда-а! Йөзем, шәфталу... Нәрсә генә юк! Базарга барып йөрисе дә калмады.

***

Эшчеләр төшке ашка туктаганнар гына иде, алар янына үзбәкчә озын күлмәк кигән бер әби килде. Сәлам бирде. Өлкән кешене иске шпаллардан кораштырып, өстенә клеенка япкан өстәл янына утырттылар.

– Оланнар, күңелем кипте. Суыгыз юкмы? – диде ул дога кылганнан соң.

– Хәзер безнең Җәмилә апабыз сезне чәй белән сыйлар.

– Мингә кайнамаган болак суы кирәк. Карагай чишмәсенең бер колтым суы кирәк.

– И, апа җан, монда каян килеп Карагай чишмәсенең суы булсын инде.

Әбекәй күңеле белән Карагай чишмәсенең суы булмасын белсә дә, көн саен диярлек кичке һавада станция ягыннан яңгыраган татар моңнары аның яшьлек елларын исенә төшерде... күңелен айкады... Шуннан соң түзмәде, якташлары очрамасмы дигән өмет белән килгән иде.

– Улым, сән Карагай адәме имәсме?

– Юк, ул Норлат мишәре.

Әбекәй өмет белән икенче егеткә сүз кушты.

– Улым, сез кайсы як баласы?

Егет икеләнеп торган арада Зиннур өлгерлек күрсәтте.

– Улмы? Ул – Азнакайдан җәяүләп качкан типтәр.

Әбекәй, көткән җавап ишетмәгәч, чарасыз калган кыяфәттә бер тын башын иеп, җиңелчә генә селкеп торды.

– Һи-и, шунча татар арасында да Карагай адәмнәре юк икән, ә?! Минем бит әле сеңелләрем калган иде анда. Ничекләр белергә соң аларның хәлен, кемнән сорарга?

Тимер юлчылар арасында бу татар карчыгына ярдәм итәрлек кеше юк иде.

– Сез, әбекәй, бу якларга ничек килеп чыктыгыз соң?

Чәчләре чаларган карчык җавап бирергә ашыкмады. Бәлки, аның үткәннәрне исенә төшерәсе килмәгәндер. Бәлки, сер итеп саклый торган сәбәбе булгандыр. Каян беләсең? Кеше күңеле – кара урман...

Ул алдына куйган чәйне йотып куйды.

– Мән үз ихтыярым белән килмәдем ку. Егерме беренче елгы ачлыкта мине Уфа якларына килгән бер сарт[2] сәүдәгәренә сатып җибәрделәр.

– Уһу! Утыз елдан артык вакыт үткән бит инде! Шул гомердән бирле Карагай авылын онытмадыгызмы?

Әбекәй бу юлы горур гына башын күтәреп тибрәтеп алды. Әйтерсең бу минутларда аның күз алдына бар хозурлыгы белән туган як табигате килеп басты.

– Һи-и, онытып буламы! Ул безнең яктагы җиләкле болыннар... ул карагайлы урманнар... ул тау астындагы җырлап... э-э, челтерәп аккан салкын сулы чишмәләр... Бер йотым суы алтын бәһасенә торадыр!

Гомерен чит мохиттә үткәргән әбекәйнең туган як чишмәсенең бер йотым суы алтын бәһасенә тора дигән сүзләре күпләрнең күңелен айкап узгандыр. Туган-үскән җирләрен, бер кайгысыз сабый чакларын хәтерендә яңарткандыр...

– Хәзер нишлисез, апа җан? Мамык үстерәсезме? Оныклар карыйсызмы?

– Пахтаны колхоз үстерәде. Оныклар кәттә егетләр булыпты.. Куй багамыз, сыгыр...

– Ничә баш сарык асрыйсыз соң? Икеме, өчме?

– Ходага шөкер, йөз баш куемыз бар.

Зиннур башын чайкап, тел шартлатып алды.

– Йөз баш? Булмас! Йөз баш сарык асрарга кем сезгә рөхсәт бирсен!

Әбекәй исе китмәгән кыяфәттә җиңелчә генә кул селтәп алды.

– И-и, рөхсәт-прөхсәт сорап торадымы Хода бәндәсе. Безнең кышлак сәвите Баһадур үкәнең Чимган тауларында биш йөз куе бар. Малбагар тота.

– Да-а, бер Советлар Союзы югыйсә?!

– Мәскәү безгә генә ул бер сыер, бер бозау асрарга рөхсәт итә. Үзебез бозау булгач...

– Бездә бит җелегеңне суыралар.

– Шулай шул. Бирәнгә биргәнең генә җитми.

Таулар арасындагы үзәнлекләрдә бишәр мең куй асраган байлар яшәгәнен, бүлмәләрендә әле дә Николай патшаның портреты эленеп торганын ялланып килгән татарлар каян белсеннәр инде?! Йөз баш дигәнгә дә исләре китте.

* * *

Сәгать телләре аяусыз. Берөзлексез текелдәп, минутларны, секундларны санап кына тора. Гөлфиянең Үзбәкстанга килгәненә дә өч айдан артты. Кыз, әкренләп, эшкә дә, мондагы тормышка да күнегә башлады. Ял көннәрендә кызларга ияреп, кышлактагы базарга барды. Вагон-клуб дигәннәре яшьләр

[2] Сарт – үзбәк.

өчен күңел ачу урыны булса, өлкәннәр өчен яшьлек хатирәләрен искә алу, туган илен сагыну, җирсү хисләрен басу урыны да иде.

Гармунчы кешене әллә каян эзләп торасы да юк. Гармун уйный белмәгән татар, булса да, сирәктер. Егетләрнең шпал сөйрәп тупасланып, бирчәеп беткән бармаклары гармун телләрендә күз иярмәс тизлек белән биегәненә шаккатасың.

Гөлфия бүгенге ялда беркая да бармады. Мендәр тышларын, эш киемнәрен юды. Тумбочкасын актарганда, бер кочак хатлар килеп чыкты. Туган яктан килгән хатларны ул кат-кат укый, ятлап бетерә. Үзе дә көнаралаш диярлек хатлар яза.

Почтальон Хәмидә апалары көлеп:

– Ташкентка барганда да, кайтканда да букчамның яртысы синең хатлар инде, сеңлем. Язучы булып китәсең бугай инде, – ди.

Гөлфия, чыннан да, хат язарга һәвәсләнеп китте. Яраткан кешеңә хат язганда, әйтәсе сүзләр, ихлас теләкләр үзеннән-үзе моң булып кәгазьгә түгелә. Дүрт яшьлек Шамилгә аерым яза. Аңа дигәне өйгә язган хат эчендәге хат була инде. Шулай булса да, яраткан энесенең «шәхсән» аңа атап язган хатны укыганда, ничек авызын ачып тыңлап торачагын күзалдына китереп, елмаеп ала. Килгән хатны укыганда да шулай – сиңа хат язган кешене каршыңда утырган кебек хис итәсең.

Гөлфия тумбочка тартмасыннан ишелеп төшкән хатларны кочагына алды, иснәп карады. Әйтерсең ул хатлар туганнарының сәламен генә түгел, туган як һавасын да алып килгәннәр иде. Ул, үзе өчен кадерле хатларның берничәсен алып, вагон баскычына чыгып утырды, бирелеп укырга тотынды.

Аның кулына әле яңарак кына килгән хатларның берсе туры килде. Анда «көз җитте, агач яфраклары саргая башлады» дигән сүзләр бар иде. Кыз агач яфракларын алтынсу төскә манган көз фасылын күз алдына китерде. Иң беренче чаган яфраклары төсен үзгәртә. Алар сеңлесе белән коелган яфракларның иң матурларын җыеп, китап арасына кыстыра торганнар иде. Бүген үк Гөлназга хат язарга кирәк. Хат эченә бер генә булса да чаган яфрагы салып җибәрсен әле. Исән-сау килеп җитсә, кызык булыр иде! Ул, күңеленә килгән уена сөенеп, елмаеп куйды. Кемнеңдер аяк тавышлары татлы хыял канатларында гизгән кызны җиргә төшерде.

Аларның вагонына Таһир якынлашып килә иде. Кызның балкыган йөзен күргәч, ул да елмайды.

– Гөлфия, Сез кайдадыр күкләрнең җиденче катында йөзә идегез бугай. Комачауладым, ахры?

Кыз, киресенчә, егетне күрүенә шат иде:

– Юк, юк! Ул кадәр биеккә менеп җитмәгән идем әле. Вагон баскычының өченче аратасында гына утыра идем.

– Биеккә омтылуның беренче адымы инде.

– Канатларым булса, мин әллә кайдагы күк түбәсенә менмәс идем, ял саен әти-әниләрем, туганнарым янына кайтып килер идем.

– Сагынасыңмы? – диде Таһир, «син»гә күчеп.

– Минем туганнан бирле район үзәгеннән ары киткәнем юк иде бит әле.

– Кыз бала ата йортында кунак кына диләр. Кайчан да булса, ул барыбер туган йортыннан китәргә, мөстәкыйль оя корырга мәҗбүр була.

– Миңа ул турыда уйларга иртәрәк әле. Авыл тормышыннан башка берни дә белмим.

– Әйдә, беренче эш итеп, мамык плантациясен карап кайтабыз.

– Аның нәрсәсен карыйсың. Бәрәңге сабакларына охшаган инде.

– Ә сугару системасын күрдеңме?

– Юк. Нәрсә, аңа су сибеп йөриләрмени?

Таһир кычкырып көлеп җибәрде.

– Әйе. Лейка күтәреп, төбе саен су сибеп йөриләр. – Аннан соң җитди генә дәвам итте. – Монда бит җәй буе тамчы да яңгыр төшмәгән еллар була. Ә үсемлекләргә барыбер дым кирәк. Рәт араларына арыклардан су җибәрәләр. Әйдә, күрсәтәм!

Алар, кышлакны үтеп, күз күреме җиргә сузылган мамык плантациясенә юнәлделәр. Ә еракта-еракта, офыкның аргы башында Чимган таулары... Аннан да ары кайдадыр күксел томаннар артында түбәсен мәңге эремәс кар каплаган Тянь-Шань таулары…

Гөлфия оялчан сабый сыман кыюсыз гына Таһир белән янәшә атлады. Юк, янәшә дип әйтү дөрес булмас, егет белән кыз арасыннан җигүле ат үтәрлек ара бар иде. Көтмәгәндә, сукмак читеннән атлаган кызның итәген чәнечкеле дөя үләне эләктереп алды. Ул, аннан котылмакчы булып, кискен генә селтәнгән иде, чәнечкеләре бармагына кадалды.

– Уф, әнекәй генәм!

Кызның бармагыннан чәчрәп кан чыкты.

– Гөлфия, сукмактан гына бар дидем бит мин сиңа.

– Кара син аны, камырлык энәсе кебек икән. – Ул авыртуын басарга теләп, канаган бармагына тынын өрергә тотынды.

– Менә шуны дөя яратып ашый инде.

– Әстәгъфирулла! Аны ничек чәйнәргә кирәк! Теленә кадалмый микәнни ул мескеннең?

– Күнеккән инде.

Гөлфия кульяулыгы белән канаган бармагын бәйләде. Аның кәефе кырыла башлады. Нәрсәгә кирәк булды инде аңа мамык басуы?

– Әйдә, кайтабыз.

– Күп калмады бит инде. Арыкны чыгасы гына калды.

Җәйге чилләдә, көн сүрелгәч, рәт араларына арыктан су җибәрәләр. Арык аша йөрергә тар гына тактадан басма салганнар. Ул суга тияр-тимәс кенә тора. Көннәр инде көзгә авышкан. Мамык җыяр вакыт җитеп килә. Басу да ап-акка әйләнгән. Әйтерсең ябалак-ябалак кар яуган да тавык йомыркасы зурлыгындагы мамык капларына кунган. Бу әле комбайн керергә әзер дигән сүз түгел. Мамык сабагының ян-якларындагы каплары әле һаман яшел килеш тора. Хәзер, мөгаен, аларны сугарудан туктаганнардыр. Шулай да басма такталары исән иде әле.

Гөлфиянең бу сират күперенә тиң басмага керәсе килми иде.

– Тактасы муртаеп беткән бит моның! Куркам.

Таһир Гөлфиянең кулына үрелде.

– Әйдә, җитәкләп алып чыгам.

Кыз кулларын артына яшерде.

– Юк. Күрәләтә суга чумасым килми әле. Тактасы да юка гына. Көчлерәк җил иссә, сынарга тора.

Басма тактасы, чыннан да, юка иде.

– Тикшереп карыйк әле.

Егет саклык белән генә басмага керде. Такта нык агачтан булгандыр, сыгылса да, сынмады. Таһир атлаган саен суга тиеп-тиеп, чупылдап алды. Егеткә бу кызык тоелды. Ул басманың уртасына басып, тирбәлергә тотынды.

Гөлфия, авырткан бармагы турында онытып, егеткә кычкырды:

– Хәзер тактаң сына да суга чумасың бит инде! Чык!

Егет тагын берничә мәртәбә басманы чупылдатып алды да икенче ярга чыкты, кызга кул изәде.

– Әйдә, син дә бу якка чык инде.

– Юк. Мин куркам. Суга карасам, башым әйләнә. Йөзә дә белмим.

Кыз йөзү турында шыттырды, билгеле. Ындыр артындагы буа буенда үс тә ничек йөзә белмисең инде.

Таһир, килгән якка чыкканда, сыгылмалы басма тактасын тагын берничә мәртәбә чупылдатып алды. Бу минутларда аның авызы колагына җиткән, ул сабый бала шикелле ихластан шатлыклы мизгелләр кичерә иде.

– Беләсеңме, Гөлфия, бу манзараны төнлә яисә таң атканда күрсәң, кызык булыр иде, ә!

– Хыялый син, хыялый! Кайчан күрсәң дә, шул басма бит инде ул.

Егет хисләреннән арына алмаган иде, кайтыр юлга чыккач та, башын иеп, бераз уйланып барганнан соң, бер кулын югары күтәрде.

– Суга ятып, таң йокысын йоклый,

Төн инешен имгән басмалар...

Шәп бит, ә?

– Нинди инеш булсын, арык кына бит бу!

– Арык сүзе сарык, ярык шикелле сүзләр белән генә рифмалаша. Мин бу шигырь юлларында туган яктагы инешне күз алдыма китердем. Минем өчен туган як табигате якынрак.

Гөлфия көлемсерәп куйды.

– Ә-ә, әйе, синең бит әле илгә кайтып, җиргә ятып, әрләннәргә шигырь сөйлисең бар.

* * *

Тимер юлда көтмәгәндә бер-бер хәл килеп чыкса, күчмә колонна эшчеләрен, тәүлекнең кайсы вакыты булуына карамастан, шунда җибәрәләр.

«Новосибирск – Ташкент» пассажир поездының авариягә юлыгуы турындагы хәбәр Мирзачүл станциясенә сәгате-минуты белән төн уртасында килеп ирешә. Югарыдагылар кичекмәстән бер бригада эшчеләр җибәрүне таләп иткәннәр. Колонна башлыгы Тараканов Җәүдәткә бригадасындагы ир-атларны җыярга биш минут вакыт бирде. Чәйләр эчү кая, хәтта юынырга да ирек юк. Дрезина станция каршына килеп баскан, семафор ачык, эшчеләрнең җыелып бетүен генә көтеп тора. Юл идарәсендә утырган диспетчерлар,

Мирзачүл белән Ташкент арасында товар поездларын гына түгел, хәтта «скорый» поездларны да туктатып, аларга юл ачканнар иде.

...Эшчеләр утырган килеш бер-берсенә сөялеп черем итәләр. Мастерлары Сәүбәнов агай да чүмәшкән урынында «сүнгән».

Җәүдәтне, нишләптер, йокы алмады. Нинди каһәрләнгән маршрут булды соң бу? Өч ай элек кенә Ташкентка туксан чакрым кала шушы маршрутта фаҗига булган иде. Әйтергә чиркангыч... мәетләрне әрдәнәләп өйделәр... Инде тагын... Бу юлы Ташкентка килеп кергәндә генә, пассажирлар, шатланышып, якыннары белән очрашу минутларын көткәндә генә, тагы шул ук хәл...

Алар фаҗига урынына барып җиткәндә, мәетләрне, имгәнгән, җәрәхәтләнгән бичараларны каядыр алып киткәннәр иде инде. Авариянең шаһиты булып, ныклы корычтан коелган рельслар бөгәрләнеп беткән, күчәреннән чыгып очкан вагоннар юл өеменнән аска янтаеп авып яталар иде. Җәүдәтләргә канга баткан, чәрдәкләнеп беткән вагоннарны өеп яндырырга куштылар. Җимерелгән юлны торгызу да аларга йөкләнде.

Монда эшнең авырлыгыннан бигрәк фаҗигале хәлгә тарыган кешеләр турында уйлау авыр. Алар арасында сугыш афәте кичереп исән калганнар да, якты дөньяга яңарак кына аваз салган нарасыйлар да булгандыр... Хатын-кызларның илереп елаган, кемнеңдер җан ачысы белән ярдәм сорап кычкырган тавышлары турында уйласаң, акылдан шашарсың! Ярый әле, Җәүдәткә ир-атларны гына алырга куштылар. Алар тешләрен кысып булса да түзәргә күнеккән. Артыгын сөйләшмиләр, төпченмиләр. Тәнәфес вакытында да сүзсез генә тәмәке пыскытып алалар да эшкә тотыналар.

Көтмәгәндә, яннарына икесе дә бертөрле киенгән әзмәвердәй ике егет килеп басты. Алар исәнлек-саулык сорап тормадылар, Җәүдәткә хәзер үк эшчеләрен бер урынга җыярга боердылар. Боларның кыяфәтләрендә миһербанлыкның әсәре дә юк. Шулкадәр тәкәллефсез, төксе кыланалар, әйтерсең, җир йөзен яулаган җиһангирлар! Таһир берсенең, макинтошын ычкындырып, китель кесәсеннән ручка алганда, погоннарын һәм бил каешына кидергән пистолет кобурасын абайлап өлгерде. Иң гаҗәбе: әзмәвернең погонында йолдызлар урынына яшен уклары төшерелгән иде. Алар, сәбәбен аңлатып тормастан, эшчеләрнең исем-фамилияләрен язып алдылар. Таләпчән һәм кырыс тавыш икеләнеп торырга урын калдырмады.

– Сез күргәннәрегезне беркемгә дә сөйләмәскә, хатка язмаска тиеш! Әгәр авария турында сүз ычкындырасыз икән, Совет дәүләтенең серен ачкан җинаятьче буларак, хөкемгә тартылачаксыз! Аңладыгызмы?

Шомланып калган кешеләр аңына килгәнче, бөердән чыккан тавыш тагын һаваны ярып узды:

– Нәрсә карап каттыгыз?! Кулларыгызны куегыз!

Төксе «кунаклар» күздән югалгач, Таһир түзмәде, ярым пышылдап кына сорап куйды:

– Җәүдәт абый, болар нинди кешеләр? Бигрәк тупас кыланалар.

– Күпне күрсәң – тиз картаерсың дигәнне ишеткәнең бармы?

Һәм ул аңлатып торуны кирәк тапмады, җиңелчә генә кулын селтәп алды.

Таһир үзеннән өч яшькә өлкән Җәүдәтне бертуган абыйсы кебек якын күрә, бригадирлары да аны чит итми иде.

Җәүдәт як-ягына күз төшереп алганнан соң, Таһирның колагына пышылдады:

– Болар, энем... палачлар... Белдеңме?

– Палачлар дип кеше үтерүчеләрне әйтәләр бит. Нүжәли?!.

– Болар нәкъ шулар инде. Авария булган җиргә беренче булып шулар килә. Алар бит, энем, алар... авария турында хәбәр читкә таралмасын өчен имгәнгәннәрне, ярдәм сорап ялварганнарны атып йөриләр.

Таһир үз колакларына үзе ышанмагандай өнсез калды. Ниләр генә юк икән бу дөньяда...

– Энем, мин әйткәннәрне син, ялгышып, Гөлфиягә ычкындыра күрмә! Ату икебезне дә алып китәрләр.

Җәүдәт аларның очрашып йөрүләрен белә иде.

* * *

Пассажир поездының һәлакәтендә югалтулар күпме булгандыр – билгесез. Җәүдәтләр Мирзачүлгә кайтканда, күчмә колонна да югалту кичергән иде. Хатыннарның юраганы юш килгән – никахлашу көннәре килеп җиткәндә генә сугыш афәте сөеклесеннән аерган Зәлифә вафат булган. Аны кышлактагы мөселман зиратына җирләгәннәр. Васыятен үтәп, киелмичә калган туй күлмәген кәфен итеп, ләхеткә иңдергәннәр иде.

Бәхет эзләп, читкә киткәннәрне адым саен хәвеф сагалап кына тора. Күпме яшь гомерләр җир куенында ятып кала... Бу турыда беркем дә, хәтта дала җиле дә хәбәр китерми. Ул фәкать тимер чардуганга барып орына да кабер өстендәге кылганнарның ак чәчләрен тарый...

* * *

Җәүдәт кибеткә дип чыккан иде (сагалап торган диярсең!), Сания очрады. Бер казанда кайнагач, күрмәмешкә салышып китеп булмый. Сүзгә оста хатыннан тиз генә котыла да алмыйсың. Сорауларына да җавап табып кына өлгер.

– Авариядә кем, стрелочник гаепледер инде? Барыгыз да исән-сау кайттыгызмы? Ташкент ничек анда?

– Аварияне сәбәпләрен белмибез. Ташкент үз урынында калды. Үзебез, Аллага шөкер, исән-сау кайттык, Сания апа, рәхмәт.

– Тәки апа диюеңне ташламыйсың, ә?

– Татар булып туганмын бит, Сания апа, нишләтәсең. Бездә үзеңнән өлкән хатын-кызга апа диләр шул.

– Теге вакытта да килмәдең. Мул итеп табын әзерләп көткән идем югыйсә. Шул апа дигән булып, тәки миңа өйләнмәдең инде. Соңыннан аерып җибәрсәң дә, үпкәләмәс идем. Хет, ичмаса, Җәүдәткә кияүгә чыкты, дигән даны калыр иде.

– Ә минем хатын аерган кеше дигән даным чыкса да ярый, ә?

– Алдагысын Алла белә ди. Әле кем белгән... Тормыш колагыңны бормыш ул.

– Сания апа, зинһар, үпкәләмә инде. Мин ФЗУ белеме белән генә калырга теләмим. Быел соңга калдым инде. Киләсе елда техникумга булса да керергә исәп.

– Картаеп беткәчме?

– Соң булса да уң булсын дигәннәр бит борынгылар.

Сания үкенгән кыяфәттә җиңелчә генә башын селкеп алды.

– Һи-и! Хатын-кыз кочаклыйсы урында китаплар кочаклап йөрмәкче буласың инде, алайса.

Болай да терәлеп диярлек баскан хатын Җәүдәткә тагын да якынайды.

Күзләренә текәлде. Хисләрнең ялкыны – аяусыз. Хатынның кайнар сулышы егетнең керфекләрен өтеп алгандай булды.

– Мин сине бит Сәетҗанкаема охшаткан идем. Бер төн булса да, синең кочаккаеңа чумып ятасым килгән иде. – Ул ни өчендер үзенең күкрәгенә сугып алды. – И-их! И-их! Насыйп булмаган икән!.. – Бер мизгелгә тынып, тамагына килеп утырган төердән котылмакчы иде. Булмады. Күз яшьләренә тыгылып, Җәүдәтнең күкрәгенә капланды, үксергә тотынды...

Җәүдәт ихтыярсыз аны кочаклап алды. Күкрәгенә кысты. Тынычландырырга теләп, иңбашларын, чәчләрен сыйпады.

– Сания апа, Сез – уңган, булган хатын! Нинди генә эшкә тотынсагыз да, пөхтә итеп, җиренә җиткереп башкарасыз. Борчылмагыз! Ходай кушса, насыйбыгыз табылыр. Өметсез шайтан гына диләр.

* * *

Шуннан соң ике атна үтте микән, Сания эзсез югалды. Колонна халкы өчен бу көтелмәгән хәл иде. Аның вербовка срогы туларга да өч ай гына калган булган икән инде. Һәркем үзенчә фаразлады, киңәш итте.

– Ишеттеңме, ахирәт, безнең Сания югалган бит әле.

– Ишетмичә. Бергә торучы кызлары да: «Кичтән барыбыз бергә йокларга яттык, иртән торуга урынында юк иде», – дип әйтәләр ди.

– Үзбәкләр урлаганнардыр инде. Бүтән кем булсын. Безнең эшләгән җиргә ике тоз күз килеп йөрде бит. Милициягә хәбәр итәргә кирәк. Якынтирәдәге кышлактан эзләсеннәр.

– Һәй, эзләп табарлар дисеңме? Үзбәк милициясе үзбәкне яклый ул. Синең белән мине түгел.

Ахирәте бертын сүзсез торганнан соң өстәп куя:

– Шулай шул. Кыерсытсалар да, беркая бара алмыйсың. Әле үткән ел гына зур-зур чемоданнар күтәреп, Ташкент вокзалына килеп төшкән яшь кенә ике татар кызын бер үзбәк яхшатланып, әйдәгез, бездә кунып чыгарсыз дигән булып, өенә алып кайтканын күргәннәр. Ә шул кызларның үзбәк ихатасыннан чыгып киткәнен күрүче булмаган.

– Һи, явыз! Әйберләренә кызыгып, яшь кенә кызларның башын ашаган инде, тәмуг кисәве! Ходаем, безнең Сания белән шулай була күрмәсен тагы!

– Сания ул кадәр беркатлы түгел лә инде. Төп башына үзе утырта торган хатын!

– Алла сакласын инде, малакаем, Алла сакласын! Кая барсаң да, үзбәкләр: «Мән хуҗәин!» – дип кенә торалар!

* * *

Ул көнне кичке уеннарның да рәте-чираты булмады. Саниянең югалуы монда да йогынты ясады. Кая инде ул уен-көлке, вагон-клубны дер селкетеп биюләр! Җырлаган җырларның да күбесе:

Чит, чит, дидем – читкә киттем.  
Чит иде теләкләрем.  
Хәзер инде чит җирләрдә  
Өзелә үзәкләрем.  
Чәчкә идек илләрдә,  
Чәчелдек чит җирләргә.  
Тагы да чәчкә булыр идек,  
Кайтсак туган илләргә –

кебек үкенү, сагыну-сыктау хисләрен чагылдыра иде. Виртуоз гармунчы Фәниснең уйнавы да күңелдәге кайгы юшкынын юып төшерә алмады. Таралыштылар.

* * *

Югалтулар моның белән генә бетмәгән икән. Атна-ун көн үтмәгәндер, тел бистәсе Зиннур да югалды. Аның югалуы үзбәк егетләре өчен әллә ни зур кайгы булмаса да, Зиннурның тасма теленә ихластан ышанган Рәмзиягә аяз көнне яшен суккандай булды. Чөнки ул бичара... балага узган иде.

Зиннур – хәйләкәр төлке, барысын да алдан уйлап эш йөрткән. «Камбала»ны сыйлап, обходной кәгазьләренә кул куйдырып, эшен бетереп киткән. Вербовка срогы тулган, кәгазьләрендә завхозның да кулы булган кешегә юл идарәсендәге бухгалтерлар көнендә үк исәп-хисап ясаганнар. Шуннан соң «тәти егет» кай тарафка юл тоткан? Шайтан белсен!

* * *

Зиннурның югалуы тиз арада ачыкланса да, Саниянең суга төшкән кебек эзсез югалуы эшчеләр өчен генә түгел, җитәкчеләр өчен дә табышмак булып кала бирде. Бу – җиң эченә яшереп калдыра торган хәл түгел. Юл идарәсеннән кадрлар бүлеге башлыгы Исламия Кәримовна Мирзачүлгә килеп төшүгә үк бригадирларны, мастерларны җыйды. Станция начальнигын чакыртып алды. Бүген ул тимер юлчылар формасында. Петлицасындагы йолдызлары да эре һәм саллы гына. Болар ханымның дәрәҗәсе югары булуын күрсәтеп тора иде.

Җыелышта күсәкнең юан башы колонна начальнигы Таракановка төште.

– Тимер юл транспорты – ул илнең кан тамыры. Без, оргнабор аркылы Идел буе халыкларын чакырып, ничек тә Үзбәкстандагы юлны тәртиптә тотарга тырышабыз. Алар турында кайгырту – сезнең өстә. Кемнеңдер нахакка бер бөртек чәче коелса да, сез җаваплы! Сез шул турыда уйларга тиеш идегез! Ә сез!.. Кызганычка каршы...

Ханым кискен генә тавышын үзгәртте.

– Ә сез беләсезме, илдәге йөк әйләнешенең ничә проценты тимер юл транспортына туры килгәнен?

Болай да кысла кебек кызыл чырайлы Тараканов комач кебек кызарган иде. Ул:

– Күп инде, күп, – дип, җиңел генә котылмакчы булган иде. Бу аның наданлыгын гына күрсәтте.

– Белмисез. Бүгенге көндә Советлар Союзындагы йөк әйләнешенең сиксән дүрт проценты тимер юл җилкәсендә! Безнең бурыч...

Исламия Кәримовна сүзен йомгаклар алдыннан папкасыннан бер бит кәгазь тартып чыгарды. Таракановка карап укырга кереште.

– Ташкент юл идарәсенең приказы белән күчмә колонна начальнигы буларак вазифаларын тиешенчә үтәмәве сәбәпле, Тараканов Василий Степанович колонна начальнигы вазифасыннан бушатыла! Вакытлыча бу вазифага өлкән мастер Сыртланов Сәит Садыйкович билгеләнә. Приказ белән таныштым дип кул куегыз!

Ир уртасындагы Сыртланов сүз сорагандай кулын күтәрде.

– Исламия Кәримовна, минем грамота юк бит!

Ханым шундук аның авызын каплады.

– Ә сез Василий Степанович академия тәмамлаган дисезме? Ул да сезнең шикелле түбәннән күтәрелгән кеше. Өйрәнерсез!

Тараканов Некрасов заманнарыннан калган такта вагонда үзе шикелле җирән чәчле марҗасы белән сугыш чорыннан бирле гомер кичерә иде. Ул сугышта катнашмаган. Тимер юл мастеры буларак, аңа бронь биргәннәр. Алтмышка якынлашкан Тараканов алга бөкрәебрәк йөри. Үзеннән алда очлы борыны күренә. Шуннан соң гына фуражка козырёгы пәйда була. Ә җиңнәренә бәләкәй генә өч йолдыз тегелгән кителе, кайчан күрсәң дә, өстендә. Ул аны кырык биш градус эсседә дә салмый. Йоклаганда сала микән әле? Аның айга бер, кайда бер дигәндәй, көлемсерәп алган чаклары да була. Таракановның көлүе дә үзенчә. Кая инде ул аңа ихластан шаркылдап көлү яисә җиңелчә генә кеткелдәп алу. Ул көләргә тырышканда, тамак төбеннән чыккан авазлары (ни галәмәт!) үпкәсе чирле кешенеке шикелле гыжылдап чыга һәм... кинәт кенә өзелә дә куя.

Аның карбыз ашаганда сөйли торган сүзе дә бар әле.

– Вот я на Урале ел! Вот где настоящие арбузы! Прямо в зубах хрустит! Не то что, это! – дип, әллә булган, әллә булмаган, әллә төшендә генә күргән карбыз турында сөйләргә ярата. Ә үзе шул мактаган карбызлары белән сыйланырга бер дә Уралга атлыгып тормый, Үзбәкстанда үскәнен сыпырта гына. Балалары булгандырмы, юкмы, белгән кеше юк. Мәгәр хатыны холыксызланып тавыш куптарса, «сасысы» тирә-якка тарала. Әрепләшкәндә әйткән җөмләләре бер вагон аша яшәгән Җәүдәткә өтеренә кадәр аермачык ишетелә. Күршеләре, мескеннәр, бу мәхшәргә ничек түзә торганнардыр?

Жыелыш нәтиҗәсен ишетсә, бүген Тараканов кына түгел, күршеләре дә йокы күрмәячәк инде...

* * *

Исламия Кәримовна җыелыштан соң торак вагоннарын йөреп чыкты. Сораулар, тәкъдимнәр булса, язып алды. Гөлфияне күргәч, алма җыючы комбайн турында исенә төшереп, шаяртып та алды.

– Күнектем инде, – диде Гөлфия дә, елмаеп.

Ханым Рәмзияне озак кына юатып торды.

– Борчылма, сеңлем, без ул «ата казны» җир астыннан булса да эзләп табарбыз. Советлар Союзыннан беркая да чыгып китә алмый ул. Берүк аборт ясата күрмә.

Ул Таһир турында да онытмаган икән.

– Энем, синең отпуск вакытың җитте бит. Ял вакытында кая барасыңны әйт. Мин сиңа кая кирәк, шунда барырга бушлай билетка заявка бирермен.

Таһир Гөлфия белән танышканнан соң ялы турында уйламый башлаган иде.

– Эш белән мавыгып, аннан соң авария... Ял турында онытканмын икән бит, – диде егет гаепле кеше сыман.

– Карале, энем, син шигырьләр язасың бит әле. Казанга барасың бардыр.

– Казанга булса да ярый инде. Аннан соң бабайларга автобус белән дә кайтырга була.

Ханым, нәрсәнедер хәтеренә төшергәндәй, имән бармагын югары күтәреп алды.

– Туктале, синең Мәскәүне күргәнең бармы?

– Юк.

– Әйдә, алайса, мин сиңа «Ташкент – Казань через Москву» дип язам. Берочтан Мәскәүне дә күрерсең.

Көтелмәгән тәкъдимнән егетнең башы күккә тигәндәй булды.

– Рәхмәт, Исламия Кәримовна, рәхмәт! Ы-ы, ни... – Ул башын кашып алгандай итте. Әйтерсең бүреге белән киңәшә. – Ни... Мөмкин булса, отпуск турында мин сезгә киләсе атнада әйтермен.

Ханым:

– Озакка сузма! – дип китеп барды.

Таһир тәгаен бер карарга килгәнче, Гөлфия белән киңәшеп алырга уйлады. Ике йөрәк арасындагы эчкерсез мөнәсәбәтләр тамыр җибәрә башлаган. Егетнең күңел түрендә мәхәббәт бөреләре шыта башлаган иде. Ә бәлки бер аның күңелендә генә дә түгелдер...

Түбәсе күккә тигәндәй «очкан» егетне Җәүдәт туктатты. Ул бер кулын шлагбаум тәртәсе шикелле Таһирның юлына аркылы сузды.

– Тукта! Тукта! Тормозга бас! Кая шулчаклы кабаланасың? Гөлфия өйдә юк. Әле генә кибеткә кереп китте.

Яшьләрнең очрашып йөрүләре колонна халкы өчен сер түгел иде. Җәүдәт Таһирны торак вагоннары арасындагы сукмактан берничә адым читкәрәк алып китте.

– Энем, беләсеңме, минем башка бер уй төште бит әле. Өйләнгәч, әллә укып була, әллә юк. Сиңа да гомер буе шпал сөйрәп йөрергә димәгән. Егетлек түгел. Нинди дә булса һөнәр, төпле белем алырга кирәк. Әйдә, икәүләп техникумга керергә әзерләнәбез. Мин белештем. Эш стажы булганнарны, имтиханнарын «өчле»гә бирсәләр дә, алалар, ди.

* * *

Исламия Кәримовна тол хатын Сания яшәгән вагонга да кереп чыгарга булды. Бәлки нәрсә дә булса ачыклар? Бүлмәдә чуваш кызы Ольга ялгызы гына иде. Ул кадрлар бүлеге җитәкчесен күрү белән сикереп торды. Гаепле кеше сыман каушап калды.

Сизгер ханым шундук биредә ниндидер яшерен сер барын шәйләп өлгерде. Ничек бу кызның телен чишәргә дигән уй яшен тизлеге белән күңелен айкап узды. Вазифасыннан файдаланып, «Кая куйдыгыз Сания Сахапованы?» дисә, кыз баланың эченә бикләнүе бар. Ул, үз итеп, салмак, сабыр гына ерактан башларга булды.

– Сания апагыз турында ниләр беләсез, сеңлем? Әйбәт кеше идеме?

– Айбәт, айбәт! – диде кыз ихластан. – Ул строгий булса да, честный иде. Безгә әниебез кебек булды.

– Алай әниегез кебек якын булгач, аның кая югалганын беләсездер бит инде.

Ольга, бүлмәдә икәүдән-икәү генә булсалар да, як-ягына каранып алды.

– Ул, каяндыр хат алгач, алмашынган кебек булды. Хатны күкрәгенә кысып, нишләргә белми, әрле-бирле йөрергә тотынды. Безне кочаклап үбә башлады. Без бу точно ычкынган дип уйлыйбыз инде. «Нәрсә булды сиңа, Сания апа?» дигәнгә дә җавап бирми. Кулындагы хатны үбеп ала-ала да: «Сәетҗанкаем исән икән бит! Исән икән! Кайткан икән бит! Кайткан икән!» – дип бертуктаусыз сөйләнә дә сөйләнә!

Ханым Саниянең сугышта хәбәрсез югалган ире кайтканын аңлап алган иде инде.

– Кайтып киткәнен белә торып, ник әйтмәдегез?

– Һе, Сания апа әйтмәскә кушты бит. Ике атнасыз әйтмәскә кушты. Белсәләр, телеграмма сугып, поезддан төшерерләр, диде.

Исламия Кәримовна, кадрлар бүлеге башлыгы буларак, Договор срогын бозды дип, Саниягә карата хөкем органнарына шикаять язарга тиеш булса да, бер кәгазь дә язмады.

Фәкать өч айдан соң «уволена по окончанию Трудового Договора по собственнному желанию» дигән сүзләрдән соң кул куеп, мөһер сукты да Саниянең «Хезмәт кенәгә»сен конвертка салып, Туймазыга җибәрде.

* * *

Таһир, кайтышлый Мәскәүне тамаша кылганнан соң, авылда бабасына кышлык утын әзерләште дә китү турында сүз кузгатты. Әбисе:

– И-и, улыкаем, сине күреп тә туймадык бит әле. Тагын әзрәк тор инде. Рәтләп кунак итеп тә булмады, – дип өтәләнде. – Гүәрдин кебек булгансың бит, улыкаем! Күз тия күрмәсен берүк, – дия-дия аркасыннан сөйде.

Егет Гөлфия турында өлкәннәргә бер сүз дә әйтмәде. Китәргә ашыгуының сәбәбен:

– Имтиханнарга әзерләнәсем бар, – дип аклады.

Өлкәннәр оныкларының уку ниятен бишкуллап хупласалар да, тиз генә җибәрәселәре килми иде. Икесе дә җитмешнең өске ягында. Оныкларын тагын кайчан күрергә насыйп булыр? Алдагысы Алла кулында...

Ахыр чиктә алар:

– Укырга ниятләгәнсең икән, улым, бик әйбәт. Раббым сиңа максатыңа ирешергә насыйп итсен! Пәйгамбәребез дә үзенең өммәттәшләренә: «Укыгыз! Укыгыз! Кирәк булса, Кытайга барып белем алыгыз!» – дигән. Йа Раббым, оныгыбызга зирәк зиһен, камил гакыл, күркәм холык бир... Сәфәрләрендә хәвеф-хәтәрсез йөрергә насыйп әйлә... – дия-дия, Таһир гомердә ишетмәгән, төшенә дә кермәгән теләкләр тели-тели, фатихаларын

биреп озатып калдылар. Ярыйсы ук өшәнгән карт белән карчык, егет автобуска утырып киткәч тә әле, күзгә ачы җилдән бер-берсенә ышыкланып, озак кына кул болгап тордылар... Әйтерсең мәңгегә хушлаштылар...

## Эпилог

Дәрт иткән – морадына җиткән, ди. Җәүдәт белән Таһир имтиханнарын уңышлы гына тапшырып укырга керделәр. Техникумның тулай торагында аларның икесен дә бер бүлмәгә урнаштырдылар. Тәрәзәләре кояшка караган иркен бүлмә биш кешегә исәпләнгән. Караватлар әлегә буш. Теләгәнен сайлап ал!

Укытучыларның күбесе – пенсия яшенә якынлашкан өлкәннәр. Тимер юлда, төзелештә, заводларда эшләп тәҗрибә туплаган педагоглар. Укыткан фәннәрен, тормыштан мисаллар китерә-китерә, миеңә сеңәрлек итеп аңлаталар.

Җәүдәтнең оештыру эшләренә сәләтен сизеп алган курс җитәкчесе аны староста итеп билгеләде. Таһирның тарих, әдәбият фәннәренә хирыслыгын күрү белән стена газетасы редакторы вазифасын йөкләде. Укырга да, җәмәгать эшләренә дә – барысына да өлгерергә кирәк. Көннең үткәне сизелми дә кала.

Бүлмәдәш казакъ студентларына түшкәсе белән итен, маен китереп торалар. Стипендия акчасына көн күргән Җәүдәт белән Таһирга үзләренә каяндыр акча табарга кала.

Ташкент – миллионга якын кеше яшәгән зур шәһәр. Предприятиеләрнең күбесе төбәкләр белән алыш-биреш итә. Үзбәкстанга бүрәнә, такта, цемент, Кузбасстан ташкүмер килә. Товар алган оешма, сәгате-минуты белән килгән йөкне бушатып, вагоннарны чистартып, тимер юлчыларга акт белән тапшырырга тиеш. Юк икән, вагонның тик торганы – «простое» өчен зур күләмдә штраф түләтәләр. Товар алган оешманың тәэминатчы-снабженецлары тулай торакка килеп, ишек шакый-шакый, вагон бушатырга – «шабашка»га кыстап йөриләр. Эш бетүгә исәп-хисап та ясыйлар. Татар егетләрен шул коткара.

Ә теге... бер семестр укып, кечкә-көчкә плюс белән минусны аера башлаган наданнарны сарык түшкәләре дә коткарып кала алмады.

* * *

Тормыш бер урында гына тормый – ташбака адымы белән булса да, алга бара. Соңгы елларда тимер юлда да уңай якка үзгәрешләр күренә башлады. Хәзер чуерташны ачык платформаларда түгел, ян-якларына люклар көйләнгән хоппер-дозаторлар белән китерәләр. Люк капкачын чамалап кына ачасың да машинистка сигнал бирәсең. Чуерташ әкрен генә барган уңайга ике рельс арасына түшәлә бара.

Гөлфия, килешү срогын тәмамлап, Ташкенттагы тукыма комбинатына эшкә урнашты. Биредә эшләүче үзбәк кызлары белән аралаша торгач, үзбәкчә дә өйрәнде. Иң мөһиме: Таһир белән көн дә очрашу мөмкинлеге туды!

Әмма тормыш майлаган арба шикелле шома гына бармый. Чыгымчы ат кебек бер урында таптанып торырга да мөмкин. Язмышның дуамал җилләре

көтмәгәндә сине ерып чыга алмаслык чытырманлык каплаган сукмакларга да алып кереп китә...

Таһир техникумның соңгы курсында укыганда, сөеклесе белән, гаилә корып, матур гына яши башлаганнар иде... Үзбәкстанда милләтара чуалышлар башланды. Моңа кадәр үзбәкләр «Мән-хуҗәин!» дип күкрәк сугып кына йөрсәләр, тора-бора ачыктан-ачык:

– Русские – в Рязань! Татары – в Казань! – кебек шомландыра торган сүзләр ишетелә башлады.

Монда кемнедер гаепләү – бик җиңел. Бар гаепне бер якка гына аударып калдыру да хилафлык. Исәпләсәң-уйласаң, гаеп атта да, тәртәдә дә булгандыр. Үзбәкләрнең дә колагына чүбек тыкмаган. Бер сынык ипигә тилмереп килгән килмешәкләр ачка әлсерәп йөргәндә, үзбәкләрнең риясыз ярдәме турында онытып, «чурка» дип кимсетүләре, ике кыллы музыка коралы дутарны «одна палка, два струна – я хозяин страна» дип мыскыл итүләре дә үзбәкләрнең мин-минлегенә тигәндер...

Әмма дә ләкин... Әмма... югарыда телгә алынган шомландыргыч сүзләрнең татарларга карата әйтелгән өлеше белән һич кенә дә килешеп булмый. Ул ак эт бәласе кара эткә кебегрәк килеп чыккан. Инкыйлабка кадәр дә, аннан соң да казакъ авылларындагы, үзбәк кышлакларындагы мәктәп-мәдрәсәләрдә мәгърифәт таратучы мөгаллимнәрнең күбесе татарлар булганын онытмаска иде!

Үзбәкстанда вазгыять үзгәрәсен сизенгәннәр, алдан ук хәстәрен күреп, кендек каннары тамган туган туфракларына кайтып сыенды. Ул чорда башланган гигант төзелешләр эшчеләргә кытлык кичерә иде. Куллары ни тотса, шуны чәчкә итә белгән кайтучыларны бишкуллап кабул иттеләр.

Ә бер болганмай су да тынмай диләр. Бу болгавыр заманнар үтәр, дөньялар тынычланыр әле дип икеләнеп калганнарның өмете акланмады. Ташкентның үзендә төпләнгәннәр арасында да тәвәккәлләр табылды. Йорт-җирләрен юк кына бәягә сатып (яисә бушка калдырып), өй җиһазларын контейнерларга тутырып кайтучылар күбәйде...

...Алар арасында тупырдап торган ике малай җитәкләгән Таһир белән Гөлфия дә бар иде...

Ватаның булу – олы бәхет! Таһир өчен кайту – икеләтә бәхет! Татарстан китап нәшриятында аның «Йөрәгемә чәчәк җыям» дигән беренче шигырьләр җыентыгы чыгып килә иде...

...Ул, һичшиксез, күңел чәчәкләрен кешеләргә өләшер, орлыкларын туган туфрагына сибәр...



Фәнил
Гыйләҗев

# КҮҢЕЛЛӘРДӘ УТЛАР ДӨРЛИ, ТЫНМЫЙ...

## Шигырь яктысы

Кешелеккә аваз сала шагыйрь.
Кыйтгаларга шигъри сүз оча.
Аһәңеннән мең хис кайный җанда,
Йә яктылык иңә мең кочак.

Кочак-кочак җылы өләшә ул,
Эремәсме диеп күңелләр.
Кальбе тулы бәйләм-бәйләм гөлләр,
Кальбе тулы утлы күмерләр...

Вулкан да ул, шаулы гөлбакча да,
Ургып, кайнап чыга хисләре.
Җан кыллары белән тоеп яши
Кай тарафтан җилләр искәнне.

Тоеп яши җиһан гамен, зарын,
Хәятнең мең кылын сиземләп.
Һәр җөмләсе – хисси чәчкә тажы,
Һәр шигыре – милли бер гөләп.

Китаплары – күңел гөлбакчасы,
Уй-хисләре – шытар бөреләр.
Җир йөзендә үз дөньясын төзеп,
Ул – хыялда йөзгән бер юләр...

Җандашларын барлап исәрләнә,
Шигъри утта янып, мең шаша.
Һәм өр-яңа ысул, алым эзләп,
Үз урынын даулый, фал ача!

Фәнил ГЫЙЛӘҖЕВ (1987) – *шагыйрь; Ш.Маннур исемендәге әдәби премия лауреаты. «Ризасызлык», «Кирмән нигезе» исемле шигырь китаплары авторы. Казанда яши.*

## Ленин өндәмәсе

Ерактан ук кулын изәп өндәр,
Ансыз булмас район үзәге.
Пеләшеннән буй-буй агып төшәр
Ирек кошларының тизәге.

Бакыр сакалыннан үбәр кояш,
Җиң очларын җилләр селкетмәс,
Урыныннан кузгатмас, җил-давыллар,
Гарасатлар аны өркетмәс.

Басып торыр юллар чатында ул,
Һәр силсәвит ишегалдында.
Узган дәвер карачкысы булып,
Кулын изәп өндәр тагын да.

Алгысытыр алга, киләчәккә,
Игелекле ирек юлына.
Инкыйлабка өндәр халыкларны,
Әйләнмәскә патша колына.

Ә патшалар алмашына торыр,
Тик ирәймәс ирке колларның.
Күңелләрне басар азан моңы,
Йә чаң кагар колоколлары.

Дин өйрәтер халык лаек диеп
Үзе сайлап куйган хакимгә.
Таянырга өндәр бер Илаһка,
Разый булып бирмеш һәр көнгә.

Үз тиранын буар башкисәрен,
Үз Ленинын күтәр туар таң.
Мәңге шулай булган һәм булачак –
Җирне ашлап ургый кара кан.

## Чынлыкта...

*Әкиятне башлыйк яңабаштан.*
Г. Морат

Нигезеңә синең эт күмгәннәр,
И Казаным минем, Казаным!
Чукмарның гел юан башы төште,
Мулдан эчтең җамын җәзаның.

«Свинью подложили» гыйбарәсе,
Кайда бакма, аша чынлыкка.
Хәтта зиратта да тынычлык юк
Халкың яшәгәндә коллыкта.

Бал мичкәсен дегет кашыгыннан
Боздыргандай этлек кылалар.
Тәре баганасы булып калка
Сөлге җыйган имле колгалар.

Хөрлегеңне синең Былтыр кыскан,
И Шүрәлем минем, Шүрәлем!
Кәҗә белән Сарык халәтендә
Калгансың син, арык җүләрем.

Ашар боткаң – Бүре казаныннан,
Тарагыңны угры малайлар
Талап алган синең, Су гүзәле...
Шулар эттән-эткә салганнар...

Эт типкесе булып яшәр хәлгә
Калгансың бит, изге Ак Бүре.
Урманыңда улар урының тар,
Тирә-юнең – тавык тәпиле.

Убырлының өе таптап узган,
Таплап, тамга салып ызанга.
Биләмәңдә тугры көчек булып,
Борынчактан чәңче шулай да...

Ике башлы Сәмруг канатлары
Күк Тәңренең күген каплаган.
Мәшрикләрдән алып Мәгрибкәчә
Бар да тигез (тирес!)... Тап-таман...

Ханлыкларны чабаталы изгән,
Онытылган хаклык бизмәне.
Тирә-юньне шомлы томан сарган,
Җанга үткән коллык бизгәге.

Хөрлек төсе уңган күк астында
Бәргәләнә маңкорт мордарлар.
Әкияти яңа кара көчләр –
Волдемортлар, Саурон, Мордорлар

Җанны бимазалый, җелекләргә
Үтеп тамырыңны корыта.
Әкиятне яңабаштан башлау
Мөмкин микән соң ул чынлыкта?!

## Шаһгалилек хакында

Шаһгали дә котсыз булмагандыр.
Гамәлләре котсыз ясаган.
Юкса ул да Җангалигә кардәш,
Туган алар уртак атадан.

Сөембикә Җангалине сөйгән,
Шаһгалигә күңеле ятмаган,
Иле белән бергә җанкисәге
Сафагәрәй ханны мактаган.

Ил-йорт белән бергә Сөембикә
Йөргән алмаш тиен урынына.
Йөри торгач җуелгандыр хәтта
Каберенең төгәл урыны да.

Уен барган. Шахматтагы сыман
Фигуралар торган алмашып.
Бизмәнгә ил хакы салынганда
Мөһим түгел кемгә кем гашыйк.

Бирнә булып йөргән Сөембикә –
Ил-йорт белән бергә өстәмә.
Чибәр хатын булган буйга-сынга,
Матур булган биткә-төскә дә.

Уфтанабыз, сукранабыз нидән?
Хәл мөшкеллек нигә гаҗәп соң?
Ханбикәсе белән сату иткән
Милләт үзе кемгә хаҗәт соң?

Ханбикәсен җуйган кавемебез
Җуйган шулай ил-йорт котын да...
Әйтерсең үз Шаһгалие яткан
Һәр татарның фигыль-холкында.

## Дәүләт һәм Ватан

Дәүләт вә Ватанны бутама!
Бутама намус вә бурычны!
Иленә гражданин дигән ат
Тәңгәлме? Мәҗбүри булмышмы?

Дарылы мичкәдә утыру
Өлешен алмадык теләп без.
Ватансыз итсә дә дәүләтең,
Туфракны ашларга кирәкбез.

Гражданин идек бит элек тә,
Ни өчен бүлделәр төрләргә?
Берәүләр «дәүләтне төзүче»,
Калганнар – хезмәтче берләргә...

Күперләр яндыру эш түгел,
Үз җирең калдыру түгел эш!
Һиҗрәткә юл тотсак, сөенер
Ташландык мөлкәткә мең өлеш.

Безләрне асканда, кискәндә,
Сөргенгә сөргәндә шатланган.
Ватаннан качмамын, шулай да
Сез сызган сукмактан атламам!

Сез корган уенда катнашу
Килешмәс вөҗүдем, холкыма.
Үз куллап каберен үзенә
Казырга язмасын халкыма!

Вөҗданы ятсынган максатка
Кем хезмәт итәр соң ихластан?
Үз халкын кыйнамас, керләтмәс,
Аермас һәм бүлмәс хак Ватан.

## Нурихан Фәттахка мәрсия

Итил суы һаман ага әле,
Ярларына дулкын кага әле.
Халкым сагына җуйган үз Акланын,
Күңеле тулы тоташ яра әле.

Оча дәвер, гүя очар уклар,
Сызгырыплар уза, җанда утлар.
Күңелләрдә утлар дөрли, тынмый.
Итил шавын, йөрәк чаңын тыңлый.

Дулкын кага, яу чапкандай атлар.
Үткәннәрдән иңә шанлы хатлар.
Чал тарихның өнен туз көленнән
Өр-яңадан иләп җыя татар.

Ача серен Итил суларының,
Юа керен милләт узганының,
Милләт узганына юлын сабып,
Барлый чиген ил-йорт ызанының.

Ул – дастанын язган милләтемнең
Өр-яңадан, елъязмачы гүя.
Милли әдәбият атавына
Әсәр арты әсәр өя-өя.

Итил суы һаман ага торыр,
Ярларына дулкын кага торыр.
Нурихан күк әдипләре белән,
Үткәннәре белән халкым горур!

## Бабам мирасы

Лермонтовны, Пушкин шигырьләрен
Һәм Такташны сөйли иде яттан.
Ул һәр эшнең белә иде ибен,
Уңа иде мал-туардан, аттан.

Ул – җәйләрен арба җигеп йөрде,
Малга кышлык ризык – печән чапты.
Ә кышларын толып кигән картны
Җиккән аты чана тагып тартты.

Сәүдә итте, йөрде балыгына
Һәм эстәде гомер бакый белем.
Әби казан асса, ул ит бүлде,
Калҗа кисте безгә телем-телем.

Тапкырлады, бүлде, алды, кушты –
Маһир иде санау дәресенә.
Шахмат уйный идек кара-каршы
Озын кышкы кичтә, җәй – эсседә.

Белә иде балта-чүкеч эшен,
Чалгы чүки иде ләззәт белән...
Авыл тулы иде шундый картлар.
Бар да китеп бетте берәм-берәм...

Хәтеремдә бабам дәресләре,
Өйрәнгәнем генә ярты-йорты...
Арба тимерләре – кара металл,
Дирбиясен күптән мунча йотты...

Калды бары тонык хатирәләр
Тапкыр, зирәк, сабыр картларымнан.
Әйтер иде алар: «Тыңла, өйрән!
Сезгә калачак бит дөнья, олан!»

Алар да юк, тормышлар да үзгә...
Мең сипләнгән лапас-каралтылар
Ядкарь булып озак сакланмады,
Бар да тузып, череп таралдылар...

Колхоз да юк күптән, хуҗалык та,
Мал да бетте, тел дә бара китеп,
Без укыган дәреслекләр дә юк –
Сабак бирде тәкъдир, җанны өтеп...

Лаек варис була алмадык без,
Чоры белән үлде күпме һөнәр...
Мирас булып калды хатирәләр,
Һәм без – ярык тагараклы юләр...

## Луизага

Шигырьләрең синең ярату һәм
Сагыш кына бары, бары әрнү.
Юатмакчы бугай син Җир шарын,
Диеп: «Бәллү, бәллү!..»

Ярату һәм чарасызлык зары –
Тәкъдирләргә тәтегәне безнең...
Безгә тышау, авызлык вә тезген
Кидергәннәр йөз мең...

Ә шулай да җан тугайда ауный,
Җан тургайдай сайрый... Атыла да
Кабат канат кайрый, көен ялгый,
Салам өен ямый...

Юатмачы, зинһар, син Җир йөзен!
Юанырдай түгел хәл-әхвәлләр...
«Ни язган дип, ник язган дип, юләр!..»
Кем соң укыр безне?!

Кем соң безне әрләр? Шундый мәлләр,
Шундый көннәр якынайды сыман:
Белми берсен-берсе дусны дус дип,
Туганы дип туган...

Күршеләре белми күрше хакын,
Хатын белми хакын үз иренең...
Тешләп канат та син үз иренең...
Сүз дәшмәвең – алтын...

Шигыреңнән таныйм җан әрнүең,
Җан әрнүем диеп, шундый охшаш.
Тоташ әрнү Җирдә, әрнү тоташ...
Шундый хәлләр бүген...

«Җаным!» дисең, җанга җылы өстәп,
Җансызлардан гүя аралыйсың.
«Яра» дисең, җаннар тоташ яра...
Кайнар каннар ага...

Кайнар каннар ага, гүя хәмер,
Кешелеккә кими хөрмәт-кадер...
Адәмнәргә җир җитми йә кабер...
Бу соңгымы дәвер?!

Без бу чорның гүя аһы, зары...
Язабыз да бушанабыз бары...
Йолып, тыеп булмас языкларны...
Чыгып сазлыкларны...

Кыямәтнең авызына атлый
Ул яралткан Адәм балалары.
Бетәр берчак әрнү, сагыш, моң-зар...
Һәм кешелек бары...

Ә әлегә түзик, бәхет төзик,
Өзик зынҗырларны рухны изгән!
Һәммәбезгә Күктә әзер бизмән!
Сизәм: вакыт тиздән...

Булмасакчы өмет җуйганнардан,
Томанадан, дөм сукырдан, надан!
Дөньясыннан, кешелектән бизгән!
Вакыт бик аз. Сизәм...

«Җаным!» дисең, җанга җылы өстәп...
Җансызлардан аралыйсың гүя.
Яна-көя төти гомер-кисәү,
Бары яна-көя...

## Озатышу

Сары яфрак сона нәни кызчык
Әткәсенең кайнар учларына.
Кичә генә әле назланды ул,
Сырпаланып аның кочагында.


Сары, юеш яфрак. Кызчыгыннан
Олы бүләк – Ватанының төсе.
Шул яфракка сеңгән Кояш нуры,
Яңгыр суы, газиз туфрак исе.

Шул яфракка сеңгән нәниенең
Ихласлыгы, назлы бармак эзе.
Сары яфрак суза нәни кызчык –
Бөре әле, нәни бөре үзе.

Күзләр җиткәч, җирне яфрак түши,
Коелмасын иде яшелләре,
Өзелмәсен Ватан кәүсәсеннән!
Сез ямь-яшел әле, иртә әле!

Күз алдыннан китми нәни кызчык,
Яфрак кыскан нәни учларына.
Әткәсенә нәрсә бүләк итсен?
Кипкән сары сыңар яфрак сона!

Чак өзелми үзәк яфрак булып,
Шушы манзарадан таша күңел.
Әткәсенә бүләк – сары яфрак!
Күз алдында шул мәл, шушы мизгел.



Солтан
Шәмси

# МИЛӘШ

ХИКӘЯ

I

Утыз еллар элек бу агачны бакча түренә ызан буена ук утыртканда, Сәлим аның язмышы мондый аяныч рәвештә төкәнер дип күз алдына да китермәгән иде. Кухня тәрәзәсеннән һәрвакыт күренеп торган миләшне ул бик ярата иде. Бу теләсә кайда үсә торган ачы җимешле миләш түгел, ә питомниктан кайтарылган, сортлы, тәлгәшләре эре тәмле-татлы агач иде. Сәлимгә аны питомникта эшләгән бер танышы мактый-мактый бүләк итте. Мондый сортлы миләшнең көтмәгәндә кулына килеп керүе һәм бакчада үз урынын алуы аны нык сөендерде. Ул бу вакытта үз авылларында хуҗалары ташлап киткән бер өйне сатып алып, аны үзенә яраклаштырып төзәтә, үзгәртә, әйләнә-тирәсенә җимеш һәм башка төрле агачлар утырта иде. Сәлим, күптән инде Казанда яшәсә дә, авылда туып үскән егет буларак, анда дача сыман бер нәрсә оештыру теләгән бик бирелеп тормышка ашыру белән шөгыльләнде. Ә миләшне ул махсус кухня тәрәзәсе каршына утыртты. Болай үзе дә, өйдәгеләр дә аны күреп торалар. Язларын аның актан киенгән затлы кәләш кебек ак чәчәкләргә төренүе үзе бер ямь булса, көз җитәрәк агачның өлгергән кызгылт тәлгәшләре күз явын алырлык хозурлык белән игътибарны гел үзенә җәлеп итеп тора иде.

Үткән утыз ел вакыт эчендә миләш кечкенә генә үсентедән биек, киң ябалдашлы, көчле һәм сәламәт агачка әверелде. Сәлим бәрәңге, суган, чөгендер, борыч үскән янбакчага чыккан чакта ызан буенда яшьнәп утырган миләшкә күз салмыйча кала алмый, аның мәһабәт, горур кыяфәт белән як-якка канатларын җәеп басып торуы сокландыра, бу миләш булмаса, бакчага нәрсәдер җитмәс кебек тоела иде. Ара-тирә Сәлим миләш янына ук килә, аның шактый юан кәүсәсенә кулларын куеп тыңлап тора. Шунда миләшнең аны яратуын сизгән кебек була. Чыннан да, агачлар, үсемлекләр, чәчәкләр

Солтан ШӘМСИ (1946) – *прозаик, тәрҗемәче; Ф.Хөсни, А.Алиш исемендәге әдәби премияләр лауреаты. «Еллар эзе», «Идел Болгарстаны», «Низаглы йортта», «Күк капусы ачылса» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

тере нәрсәләр бит, алар яннарына килеп баскан адәмнең мөнәсәбәтен сизәләр икән, бу хакта соңгы вакытта галимнәр дә яза башлады. Көннәр корыга киткәч, миләш төбенә чиләкләп су сипкәннән соң, икенче көнне аңа якын килеп бассаң, агачтан ниндидер күңел генә сизә торган ягымлылык килгәнен тоя иде ул.   Сәлим моны агачның рәхмәт әйтүедер, ахры, дип кабул итә иде.

Миләшнең тәмле-татлы җимешләр бирә торган сортлы агач икәнлеген хәзер тирә-юньдәге күршеләр дә белә. Аның «Сәлим миләше» дигән атамасы күрше-күләннең теленә үк кереп китте. Җимешләр өлгереп җиткәч, шушы урам малайлары Сәлим абыйларының тәмле миләш тәлгәшләрен зур поднос белән капка төбенә алып чыгуын, аларга өләшүен өмет итеп килгәлиләр иде. Шушы урамда торучы Нәгыйм дә сортлы миләшнең өлгерүен көтеп ала. Ул бу миләштән үзенә менә дигән исерткеч төнәтмә ясарга өйрәнеп китте, кайвакытта, рәхмәт әйтә-әйтә, Сәлимне дә сыйлый.

Әмма миләш җимешләре тәмам өлгереп җиткәч, ел саен бер кыенлык килеп чыга. Миләшне бер төрле кошлар бик ярата икән. Шуңа күрә аларга миләш чыпчыгы дигән исем дә тагылган. Аларны күзәтә торгач, Сәлим бу кошларның гадәтләрен тәмам белеп бетерде. Эш болайрак тора иде: миләш тәлгәшләре кызгылт төскә кереп өлгереп җитәр алдыннан агач тирәсендә ике-өч миләш чыпчыгы күренгәли. Болар җимешләрнең ни хәлдә икәнен белү өчен килгән разведчик кошлар була. Алар шулай миләшне даими күзәтеп, тикшереп торалар. Ниһаять, миләш тәмам өлгереп җитә, һәм шул вакыт бер төркем булып тупланган утыз-кырыклап миләш чыпчыгы агачка һөҗүм итә. Алар, самолётлар эскадрильясы дошман өстенә ташлангандай, миләшкә шундый дәрт белән ябырылалар һәм, күз алдына китерүе кыен булган комсызлыкка бирелеп, өлгергән миләш тәлгәшләрен ботарларга тотыналар. Мондый вакытта бакча кошларның ямьсез чыркылдавына күмелә, җиргә бертуктаусыз миләш коела. Әгәр дә бу вакытта өйдә кошларны куркытып куып җибәрердәй берәр кеше булмаса, ярты сәгать эчендә миләш, көчле давылдан зыян күргәндәй, бөтен матурлыгын югалтып басып кала. Андый чакта Сәлим, кулына буш чиләк тотып, аңа таяк белән суккалый-суккалый, кошларның көтеп алган мәҗлесенә чик куя, шулай миләш тәлгәшләрен саклап калырга тырыша иде. Шунысы кызык: урамдагы икенче бер йортның капка төбендә дә зур миләш үсә, җимешләре дә була, тик кошлар нигәдер ул миләшкә һөҗүм итмиләр. Күрәсең, алар татлы миләшне күбрәк яраталардыр.

## II

Күп еллар элек бу йортны сатып алгач, Сәлимгә бакча әйләнәсендәге коймаларны яңабаштан корып чыгарга туры килде. Дөресен генә әйткәндә, анда койма диярлек нәрсә калмаган да иде. Сул яктагы күршесе белән ике арада буш йорт урыны сузылып ятканга ул якны да капларга, койма корырга кирәк булды. Аның малай чагы шушы авылда үтте, ул әлеге бушап калган урында элек кемнәр торганын яхшы хәтерли. Элекке хуҗаларның искергән йортны ташлап, Казан янындагы Залесный бистәсенә күчеп китүләрен дә аның ишеткәне бар. Алар киткәч, ташландык йортны, лапасны, капка-

коймаларны кемнәрдер сүтеп, утынга ярарлык бөтен нәрсәне алып киткән, бу җир суырып алынган теш урыны сыман бушап калган иде.

Сәлим бирдә тормыш кора башлаганда, буш җирнең әле хуҗасы юк, анда хәтта бәрәңге дә утыртмыйлар иде. Әмма бу җир гел буш тормады. Сул як күршеләрнең Борһан атлы кияве, пенсиягә чыкканнан соң, Казандагы фатирын кызына калдырып, хатыны Кәүсәрия туып-үскән йортка кайтып яши башлады. Күрәсең, шәһәр тормышына караганда, авылда яшәүне яратарак күргәндер, шуңа күрә карты вафат булганнан соң ялгыз калган Мәйсәрә карчык янына кайтып төпләнделәр. Сәлимгә дә аралашырга кеше булды.

Бу аралашу, Борһан буш җирне үзенекенә кушып, бакчасын зурайтканнан соң, дөресен генә әйткәндә, шыпырт кына җирне басып алганнан соң, тагын да ешайды. Шулай аның җире күршесе коймасына, миләш янына ук килеп җитте. Сәлим кереп-чыгып йөрер өчен койманың бер урынын кисеп, анда капка да ясап куйды. Икесе дә бакчада чакта күршеләр очрашкалап, Борһан бакчасындагы озын урындыкка утырып гәпләшәләр, хәл-әхвәл сорашалар, дөнья хәлләре турында сөйләшәләр иде.

Борһан уртача буйлы, түгәрәк йөзле, алга бүселеп чыккан корсаклы, чәче кырылган ялтырап торган башлы, төймә сыман кечкенә борыны астында дага рәвешендә салынып төшкән мыеклы, шикәр авыруы белән азапланганга көн саен үзенә укол ясап көн күрүче бер адәм иде. Аның гомере заводта эшләп үткән, пенсиягә цех мастеры булып хезмәт иткәндә чыккан. Заводта эшләгән кеше буларак, аның сараенда нәрсә генә юк; кайвакытта Сәлим берәр нәрсә әмәлләгәндә, аннан эш коралларын алып торгалый иде. Борһанның хатыны Кәүсәрия чәчәкләр үстерергә бик ярата, аларны тәрбияләүнең серләрен белә. Сәлимнең хатыны Саниягә дә ара-тирә берәр чәчәк үсентесе кертеп бирә, алар аны бергәләп утыртып та куялар иде.

### III

Еллар үтә торды, Сәлимнең ызан буена утырткан миләше ел саен биегәя, ботакларын як-якка җәелдереп, ябалдашын һаман киңәйтә, шулай матур агачка әверелә бара иде. Күршесе Борһан агачның киләчәктә тагын да зураясын, ябалдашының киңәя төшәсен исәпкә алмыйча, аның янына ук төрле агачлар, кура җиләге куаклары утыртып чыкты. Бервакыт Сәлимне сагаерга мәҗбүр иткән вакыйга булып алды. Ул көнне кичен бик көчле җил исә башлады да давыл купты. Давыл капка төбендәге өянкенең шактый юан ботагын каерып төшерде, ботак электр чыбыгы өстенә төште, аны өзеп ташлады, өйдә ут бетте. Бу хәл кичен караңгы төшкәч булды. Ул кичне давылдан тагын нинди зыян килгәнен ачыклап булмады. Иртәгесен Сәлим янбакчага чыгып караса, Борһан белән ике арадагы койманың ауган килеш җирдә ятуын күреп алды. Якынрак килгәч, баганалар черегән икән шул, җилгә каршы тора алмаганнар дигән нәтиҗә ясады.

Ул ике көн ауган койманы сүтү, араталарындагы кадакларны суыру белән шөгыльләнде. Аннан такталарны циркулярка да турады, шулай мунчага ягарлык шактый утын килеп чыкты. Ул ауган койманы сүтеп ятканда, янына Борһан килеп туктады. Кичәге давыл турында сөйләшеп алдылар. Давыл аларның да түбә калаен бер җирдән кубарган икән, күршесе яңгыр

килгәнче шуны төзәтәсе бар әле дип зарланып алды. Аннан аунап яткан коймага күрсәтеп:

– Сиңа эш чыкты, малай, яңа койма корасың бар, – дип кеткелдәп көлеп куйды.

Бу сүз Сәлимгә бер дә ошамады, ул:

– Юк инде. Минем койма унбиш еллап торды. Ул уртак койма иде. Хәзер синең чират, кирәк булса, үзең корырсың, – дип, ачулы итеп җавап бирде.

Борһан беравык аңа текәлеп карап торды да сүз әйтмичә борылып китеп барды. Ул ике бакча арасында койма корырга алынмады. Сәлим дә койма корып маташмады. Шулай ике бакча бергә кушылгандай, аралары ачык калды. Хәзер ике арадагы ызанны Сәлимнең яраткан миләше генә билгеләп тора иде.

Тора-бара ике бакча арасында койма булмау табигый хәлгә әверелде. Бу бигрәк тә хатыннарга аралашу өчен җайлы булып чыкты. Бакчага чыкканда, Кәүсәрия белән Сания бер-берсен күреп алалар да, ызан буендагы миләш янында очрашып, туйганчы сөйләшәләр. Борһан гына Сәлим янына килми башлады. Берәр йомышы чыкса, күршесенә хатынын кертә, аның аша эш йөртә. Ә Сәлим аның бу гадәтен күрмәмешкә салышты, күршесен бакчада күрсә, кулын изәп сәлам бирә, кайвакытта янына ук килеп, хәлләрен сораша. Гадәттә, аларның аралашуы бер яклы гына бара иде. Сәлим күбрәк аны тыңлый, ә тегесе тыңлаучы булгач, рәхәтләнеп авыруы турында сөйли, дөньяны сүгә. Сәлим аның мондый гадәтен авыру кеше психологиясе дип кабул итә иде. Бервакыт Борһан:

– Дөньяның бер кызыгы да калмады, малай... Хатын пешергән тәмле ризыклар гына бераз күңелне күтәрә, – дип әйтеп салды. Сәлим аңа каршы сүз әйтми, каршы килсәң, Борһанның бәхәсләшә башлавын яхшы белә.

Берзаман Сәлимнең Татарстан педагоглары турындагы очерклар китабы басылып чыкты. Ул, кайчандыр Казан университетының журналистика факультетын тәмамлап, гомерен татар газета-журналларында эшләп уздырды, аны журналистлар белән язучылар, татар зыялылары яхшы белә иде. Басылып чыккан китабына күп еллар дәвамында төрле басмаларда дөнья күргән очерклары кергән иде. Сәлим өчен бу бик куанычлы вакыйга булды. Ул берничә китапны авылга да алып кайтты. Берсен китапханәгә тапшырды. Саниясе түзмәгән, китапны ишегалдына кергән Кәүсәриягә дә күрсәткән, ул бу хакта иренә дә әйткән. Борһан исә бу вакыйганы бик нык аптырап һәм үчегеп кабул иткән булса кирәк. Ул күршесенең элек ниндидер газетада эшләвен ишетсә дә, аның турында бик аз белә иде. Ничек инде үзе шикелле җәйләр буе авылдагы дачасында ятучы, аның шикелле помидор, кыяр, борыч, кишер һәм тагын әллә нәрсәләр үстерү белән шөгыльләнүче кешенең китабы басылып чыксын ди?! Була торган хәлмени бу? Аның бит эшләргә рәтле кораллары да юк, миннән алып тора...

Борһан бу мәсьәләне ачыклау өчен бер көнне махсус Сәлим янына керде. Күршесе бу вакытта ишегалдында, шланг сузып, мичкәгә су тутыра иде. Борһанны күргәч, каршына барып, кул биреп исәнләштеләр. Сәлим, утырып торыйк дигәндәй, тирбәлмә-урындыкка күрсәтте. Килеп утырып, беравык дәшми торганнан соң, Борһан:

– Ниндидер китабың чыккан икән. Күрсәт әле шуны, – диде.

– Хәзер алып чыгам, – дип, Сәлим урыныннан купты да өйгә кереп китабын алып чыкты, аны Борһанга сузды. Күршесе, китапны кулына алып, бераз аның тышлыгына карап торды; анда зур хәрефләр белән: «Сәлим Газиз. Татарстан педагоглары» дип язылган иде. Китап тышлыгында күршесенең зур хәрефләр белән язылган исемен күрү Борһанның күңелендә көнләшү кебегрәк хис уятса да, ул аны сиздермәскә тырышты. Китапны урта бер җиреннән ачып карады. Анда олырак яшьтәге бер хатын-кыз фотосы урнаштырылган иде. Ул китапны тагын берничә җиреннән ачкалады да кире Сәлимгә бирде. Аннан:

– Китап өчен сиңа күпме түләделәр соң? – дип, үзен кызыксындырган төп сорауны бирде.

– Мин аны акча эшләү өчен язмадым.

– Нәрсә өчен яздың?

– Татарстандагы атаклы педагогларның зур хезмәтен халыкка күрсәтәсем килде, шуңа яздым.

Борһан, авызын кыеклап, башын чайкап куйды:

– Хәзер китап бастыру кыйммәткә төшә дип ишеткәнем бар. Нинди акчага чыгардың? Синдә андый акчалар юктыр...

– Педагоглар спонсорлар тапты. Миңа да өлеш чыкты.

Ул бераз дәшми торгач:

– Ярый, яхшы булган, – дигән булды. – Китапны бүләк итмәсәң дә ярый. Мин бөтенләй китап укымыйм, болай да эш муеннан...

Шушының белән сүзе бетте дә шикелле. Борһан урыныннан торды да китәргә җыенды. Шунда суы тулып агып утырган мичкәне күреп алды:

– Әнә бочкаң агып ята... Синдә су исәпсез шул... – дип, дорфа кыяфәт белән ишегалдыннан чыгып китте. Сәлим, барып, тиз генә кранны япты, күршесе турында: «Моңа нәрсә булган?» дип уйлап куйды.

Быел җәй бик коры килде. Бер ай тирәсе яңгыр яумады. Яшелчәләргә даими су сибеп торырга кирәк иде. Бу яктан Сәлимнәр күршеләре сыман суга тилмереп яшәмиләр, суны тирәннән, җир астыннан алалар. Җәй көннәрендә авылда суга кытлык үзен нык сиздерә. Алар яшәгән урам авыл читендә урнашканга, монда торучыларга су ялындырып кына килә. Шул сәбәпле Борһан бакчадагы мичкәләрен кешеләр йоклап беткәч кенә тутырып куйгалый. Бөтенләй килмәгән вакытта ул су сорарга аларга хатынын кертә. Андый чакта Сәлим озын шлангны миләш янына ук сузып куя да тегеләр аңа үзләренекен тоташтыра, шулай мәсьәлә тиз хәл ителә.

Борһанның Кәүсәриясе аларга еш керә, Сания белән даими аралаша, аның аркылы Борһан да Сәлимнәрнең тормышын, хәл-әхвәлләрен белеп тора. Ул бигрәк тә Сәлимнәрнең кияве авылга кайткан чакта бабасына гел булышып торуын бик көнләшеп кабул итә. Ә Борһанга ярдәм итүче юк. Бөтен эшен авыру килеш үзенә башкарырга туры килә. Җитмәсә, Казандагы кызы да, кияүгә чыгып, ире белән ун ел яшәгәннән соң, ялгызы торып калган. Бала таба алмаганга ире ташлап киткән. Шуңа күрә Борһанның тормышында күңелен күтәрердәй хәлләр бөтенләй юк дәрәҗәсендә иде. Сәлимнең һәр яктан җайлы тормышына ул кызыгып һәм көнләшеп карый. Җитмәсә, һич уйламаганда, күршесенең шактый калын китабы басылып

чыккан. Ул Сәлимнең андый дәрәҗәле кеше икәнен бөтенләй белми йөргән икән. Бу вакыйга аның күңелендә күршесен өнәмәү хисен тагын да тирәнәйтә төште.

**IV**

Сәлимнең бакча күрке булган миләше ел саен биеккәрәк күтәрелә, ябалдашы һаман киңәя, матурая барды. Игътибарны даими үзенә тартып торган бу агачтан башка бакчаны хәзер күз алдына да китереп булмый иде. Ул Сәлимнең горурлыгына әверелде, чөнки башка берәүдә дә авыл халкының теленә керердәй андый татлы җимешле, мәһабәт сынлы миләш юк иде. Бервакыт миләшнең ызан буенда киң ябалдашын як-якка җәеп үсеп утыруы күршесе Борһанның эчен пошыра башлады. Моның сәбәбе дә бар: миләшнең зур күләгәсе аларның бакчасына төшә, утырткан нәрсәләре көннең бер вакытында кояш күрмичә калалар, тиешенчә үсә алмыйлар иде. Борһан бер көнне, күршесе белән бакчада очрашкач, бу мәсьәләне кабыргасы белән куйды:

– Сәлим, кис син бу миләшеңне, – диде.

Сәлим, гаҗәпләнеп, аңа карап торды:

– Кисәргә?! Сиңа ни зыяны тиде?

– Күләгәсе ярты бакчаны каплый. Әнә утырткан әйберләр үсә алмыйча утыра...

– Монда миләшнең бер гаебе дә юк. Аны утыз ел элек утыртканда, бу җир синеке түгел иде. Бакчаңны соңыннан зурайттың...

– Анысы – икенче мәсьәлә. Мин хәзерге көн турында сөйлим. Кис син аны, нигә кирәк булды сиңа бу миләш?

– Ул бакчабызны бизәп тора, җимешләре тәмле. Мин аны кисәр өчен утыртмадым...

– Алайса, кисмисең?

– Юк, кисмим... Уйлама да ул турыда.

Борһан ачу белән беравык күршесенә карап торды, аннан:

– Ярар, үзеңә кара, – дип китеп барды.

Күршесенең пырдымсыз сөйләшүе, тупас таләбе Сәлимне гаҗәпкә калдырды. Борһанның аннан көнләшеп яшәвен даими сизеп торса да, эш аларның яраткан миләшен кисүгә үк барып җитәр дип ул башына да китереп карамады. Бу сөйләшү Борһанны яңа яктан ачып җибәрде шикелле. Менә нинди уйлар белән яши икән аның ян күршесе. Рәсмиләштермичә буш бакчаны басып алуы гына җитмәгән, хәзер инде аңа миләшне кистереп, аннан котылу да кирәк икән. Агач күләгәсе аның бакчасына бераз төшә төшүен дә, тик ярты бакчаны һич капламый, Борһан анысын арттырып җибәрде. Барысы да аны өнәп бетермәү галәмәте инде. Ни генә булмасын, Сәлим аны кисмәячәк, миләш шул килеш бөтен бакчага ямь биреп торачак.

Кәүсәрия чәй әзерләп кенә бетергәндә, өйгә Борһан килеп керде, өстәл янына кереп утырды. Хатыны аның йөзе кызарганны күреп алды:

– Йөзең кызарган, әллә кәефең юкмы? – дип сорады.

– Әле Сәлим белән сөйләшкәнием. Ачуымны китерде.

– Нәрсә сөйләштегез алай ачу килерлек?

Борһан бераз дәшми торды, аннан, башын күтәреп, хатынына карады:

– Миләшеңне кис дигәнием. Кисмим дип кырт кисеп әйтте.

– Кисмәс шул, матур агач бит.

Хатынының сүзләре иренең болай да кырылган кәефен тагын да боза төште:

– Син дә Сәлим җырын җырлый башладың. Әллә күрмисеңме, миләш күләгәсе ярты бакчаны каплап тора.

Кәүсәрия каршы сүз әйтмәде, иренең дулап китүчән холкын белә иде. Борһан алдындагы чәйне уртлап куйды да:

– Миләшне ул барыбер кисәчәк, мин әйтте диярсең...

Хатыны бу юлы җавапсыз калмады:

– Кисмәс ул, кисмим дигән бит.

Борһанның йөзендә мыскыллы көлемсерәү чагылып узды:

– Кисәчәк, менә күрерсең...

Шушының белән бу хакта сүз бетте.

**V**

Июль уртасында Сәлим белән Саниянең кызлары кырык яшь тулу уңаеннан зурдан кубып туган көн бәйрәме уздырырга булганнар. Әтисе белән әнисен шунда катнашу өчен Казанга чакырдылар. Олылар, бер уңайдан оныкларны да күрербез дип, шәһәргә киттеләр. Китәр алдыннан Кәүсәриянең парниктагы кыярга су сипкәләп торуын үтенделәр, ул берсүзсез риза булды. Борһан да күршеләренең Казанга китүен белде һәм тегеләр өйдә юк чакта ниятләгән эшен башкарырга уйлады.

Атна саен чәршәмбе көнне авыл уртасындагы мәйданда базар була. Авыл халкы Казанга барып йөрми, үзенә кирәк азык-төлекне, башка төрле кирәк-яракны шуннан гына ала. Кәүсәрия дә, кешелеккә кия торган күлмәген киеп, атнага бер тапкыр базарга бара, анда таныш хатыннар белән аралаша, яңалыклар ишетеп кайта, өйгә кайткач, Борһан белән сөйләшергә сүзләр дә була. Бүген чәршәмбе көн, Кәүсәрия, гадәттәгечә, ике тәгәрмәчле кечкенә арбасын тартып, базарга чыгып китте, ул анда берәр сәгать торачак.

Борһан хатыны өйдән чыгып китү белән алдан уйлап куйган эшенә кереште. Башта мунча алдына керде, әзерләп куйган электр шнурын розеткага тоташтырды, күршеләргә карап торган кечкенә тәрәзә аша шнур бәйләмен тышка ыргытты, аны Сәлим миләшенә кадәр сузды. Аннан соң, сарайга кереп, дрель алды, аңа бармак юанлыгындагы борау беркетелгән иде. Ул дрель белән миләш янына килде. Агач кәүсәсен кайсы җирдәнрәк тишәргә икән дип чамалап, бераз уйланып торды. Тишекне төптән ярты метр биеклектә ясарга булды, һәм аска таба кыйгачлап, дрель белән миләш кәүсәсен тишәргә кереште. Эш тиз барды, дүрт-биш минутта тишек әзер иде инде. Тишкәндә, Борһан боравын агачның үзәгенә җитәрлек итеп батырды. Моны ул кичә үк уйлап куйды, шулай иткәндә эш барып чыгачак иде. Эшен тәмамлагач, чәнти бармагын тишеккә тыгып карады, миләш төбенә коелган дрель йомычкаларын җыеп, читкә ташлады. Инде җирдә сузылып яткан шнурны җыясы һәм соңгы эшне башкарасы гына калды. Анысы иң мөһиме, төптән уйланган эш иде.

Бакчада эшен бетергәч, кабат сарайга керде. Андагы буяу банкалары, химик сыекчалы шешәләр, пластмасса савытлар тезелгән шүрлектән нечкә

авызлы берсен алды да бакчага чыкты. Миләш янына килде, чүгәләп утырган килеш үзе ясаган тишеккә савытның нечкә авызын тыкты һәм аңа сыекча коя башлады. Тишек аска таба авыш ясалганга сыекча кире агып чыкмый иде. Ул тулар-тулмас дәрәҗәгә җиткәч, савытны тишектән алды да, «Булды бу!» дигәндәй, ниндидер азарт белән миләш кәүсәсенә шап итеп сугып алды. Аннан борау тишеген балчык белән томалап куйды. Ул эшеннән бик канәгать калды, җиңүче рәвешендә зур-зур атлап, өенә таба китте. Сарайга кергәч, кулындагы савытны урынына куйды. Шулвакыт капка тавышы ишетелде. Борһан Кәүсәрияне каршылап, аның кулыннан шактый авырайган арбаны алды, болдырга җиткәч, хатыны алып кайткан азык-төлекне бушатырга тотынды. Шулай Кәүсәрия аның кыңгыр эшен күрми калды.

Август урталарында Сәлим миләш яфракларының ни сәбәптәндер саргая башлавына игътибар итте. Ул моның серенә төшенә алмады. «Башка агачлар әле ямь-яшел килеш утыра, нигә миләш яфраклары төсен югалта соң, әле бит сентябрьгә дә кермәгән. Дөрес, быел җәй коры булды, яңгырлар да ялындырып кына яуды. Бәлки миләшкә дым җитмидер», – дип, ул аның төбенә су сипкәләде. Әмма су сибү ярдәм итмәде, миләш башка агачлардан иртәрәк саргая иде. «Әллә инде Борһан агач төбенә берәр ярамаган нәрсә сипте микән? Алай дисәң, миләш төбендәге үләннәр саргайган булыр иде. Юктыр, күршесе аны сөймәсә дә, андый ук эшкә бармас, бу бит башка сыймый торган нәрсә». Сәлим шундый уйлар белән ара-тирә миләш янына килә, аптыраган хәлдә аның саргая башлаган яфракларына карап торгалый иде. Ул нишләргә дә белмәде, өч дистә ел буе карап үстергән, күптән бакча күркенә әверелгән миләшен ничек тә коткарып каласы килде аның. Әмма ничек коткарырга? Уйлый торгач, ул киләсе язны көтәргә булды. Яз көне бөтен табигать уяна, бәлки әле аның миләше дә бу сырхаудан арыныр, элеккечә яшьнәп утырган агачка әверелер. Ул шулай үз-үзен тынычландырырга тырыша иде.

## VI

Карлы-буранлы кыш узды. Кабат яз килде. Сәлим белән Санияне кияүләре Рәхим май башындагы озын ялда авылга кайтарып куйды. Бу аларның җәй буе торырга кайтулары иде. Дача сезоны башланганда, хуҗалыкта эш күп була. Кышка каршы сарайга кертелгән тирбәлмә-урындыкны, су мичкәләрен, арбаны, үлән әчетү өчен файдаланылган чуен казаннарны һәм тагын шуның ише бик күп нәрсәләрнең барысын да бакчага чыгарып куярга туры килә. Базны да ачасы бар. Көз көне коелып, бөтен җирне каплаган агач яфракларын да җыеп алырга кирәк. Ә өйдәге бетмәс-төкәнмәс эшнең күпме икәнен Сания генә белә. Сәлим дача сезоны ачылган вакыттагы мәшәкатьләрдән аеруча яфрак җыюны ярата иде. Тырмаланган җир чәче кырылган баш сыман чип-чиста булып калса, башкарылган эшеңнән зур ләззәт аласың. Бу эшләрнең иң мөһиме – кышка ябылган артезиан суын көйләп җибәрү. Моның белән һәрвакыт кияүләре шөгыльләнә: ул андый нәрсәләрнең җаен белә, бабасын су фильтрын чистарту өчен кое төбенә төшерми.

Кайтып кергәч, Сәлим, бу эшләргә тотынганчы, иң элек бакчага чыкты,

миләше янына килде, сәлам биргәндәй, кулын аның шадра кәүсәсенә куеп торды. Аннан соң агачның бер ботагын тартып китерде дә бөреләрне тикшерә башлады – бүртәләрме, юкмы? Бөреләрдә уяну сизелми диярлек иде. Ул янәшәдәге алмагач янына килде, анықылар шактый бүрткәннәр, яз фасылының илаһи көче тәэсирендә уяна ук башлаганнар. Сәлимнең хәтерендә «Алмагачлар чәчәк ата майның унбишләрендә» дигән җыр сүзләре калыкты. «Әйе, унбиш көннән алмагач бөреләре бәлки ачылырлар, ә миләшнекеләр ни хәлдә булыр?» дип уйлап куйды ул. Бу уй аны бер дә сөендермәде. Шулвакыт ул бакчага чыккан Борһанның аңа таба килүен күреп алды. Күршесе белән алар кул биреп күрештеләр. Хәл-әхвәл сораштылар. Сәлим:

– Кышны ничек чыктың, бик күңелсез булмадымы? – дип сорады.

Борһан бу сүзне елмаеп кабул итте:

– И-и, малай, киләсе кышка Казанга китәргә кирәк дип торам әле.

– Ник алай?

– Кыш буе дворник булып эшләдем...

Сәлим шаркылдап көлеп җибәрде:

– Кар күп яуды шул, хәлеңне аңлыйм, – диде.

– Алайса, бөтенләйгә кайттыгыз...

– Әйе, җәй буе монда торырга исәп.

Сәлим өйдә эшләр көтеп торганны искәреп алды:

– Ярый, бүген эшләр күп, Кәүсәриягә сәлам әйт, – дип китеп барды.

Борһан миләш кәүсәсендәге балчык белән томаланган тишек урынына күз салды, йөзендә канәгать көлемсерәү чагылып узды, һәм ул өенә таба атлады.

Җәй буе миләш Сәлимнең күз алдында әкренләп корый барды. Яфраклары элеккечә тармакланып үсә алмады, җәй уртасында алар саргая башлады. Сәлим бу юлы да миләш төбенә чиләкләп су сипте, тик бу чара да ярдәм итмәде, август урталарында корыган яфраклар коелырга тотынды. Шулай агач торган саен шәрәләнә бара иде. Сәлим аңлады – ул миләшне коткарып кала алмаячак, аның өмете өзелде. Агачның корыганын Борһан да күреп торды, эчтән сөенсә дә, күршесе белән миләш турында сүз кузгатмады. Ул Сәлимнең агачны иртәме-соңмы кисәчәген белә иде. Хәзер бакча түрендә утырган миләш, давыл җимергән иске йорт кебек, кыяфәте белән Сәлим күңелендә авыр хисләр уята иде. Сентябрь урталарында Сәлим миләшне кисү турында уйлана башлады, тик бу эшкә керешүне тарта-суза килде, кулы бармый иде.

Онықларның укулары башланганда, Сәлим белән Саниянең Казанда булуы кирәк. Гадәттә, балалар дәресләрдән соң туп-туры аларга кайталар, монда тамакларын туйдыралар. Шуннан соң җиденче класста укучы Әмир өенә кайтып китә, икенче класска барган төпчек кыз Мәдинә олылар янында кала. Монда ул дәресләрен дә карый, тиешле сәгатьтә аны дәү әтисе яки дәү әнисе Абдулла Алиш исемендәге балалар иҗат сараена хореография, рәсем ясау яки театр түгәрәгенә илтәләр. Әти-әниләре эштән шактый соң кайтканга, балалар карауны олылар үз өстенә алдылар. Тормышлары шулай көйләнгән. Шуңа күрә авылдагы сезонны иртәрәк ябарга туры килә. Укулар башлангач, алар авылга ял көннәрендә генә кайтып йөриләр.

Сәлим миләшне кисүне кияве Рәхим белән башкарырга булды. Кияве ял көнне кайтачак, ул аны көтте. Рәхим әле аның миләшне кисәргә җыенуын белми иде. Сәлимне корыган агачны икенче елга калдырасы килмәде. Аны кухня тәрәзәсеннән күрсә дә, бакчага чыгып, карашы аңа төшсә дә, күңелендә авыр хис уяна. Кисеп эшне бетерергә кирәк дигән карарга килде ул.

Рәхим шимбә көнне кайтты. Чәйләп алгач, алар ишегалдына чыктылар. Гадәттәгечә, кияве:

– Бүген нишлибез соң, нинди эш бар? – дип кызыксынды. Атна буе офиста утырганга, ял көннәрен ул бирәр эш белән үткәрергә тырыша, авылның саф һавасында эшләү аның өчен иң яхшы ял иде.

Бабасы аңа:

– Бакча түрендәге миләшне кисәсе иде, – дип җавап бирде.

Рәхим, гаҗәпсенеп, аңа карап куйды:

– Ничек шулай тик торганда корыды соң ул?

– Нәрсә уйларга да белмим.

– Бәлки картайгандыр?

– Юк, узган ел кинәт корый башлады.

– Алайса, кисәргә булдың...

– Әйе, кисәргә кирәк. Күз алдында корып утыруын күрә алмыйм...

Алар эшкә керештеләр. Рәхим машина багажнигыннан озын бау алды, бабасы сарайдан бензин пычкысын күтәреп чыкты, һәм икесе дә миләш янына килделәр. Кискән вакытта төшкән ботаклар карлыганнарны сындырмасын өчен, һәрберсенә бау бәйләп, читкә тартып торырга булдылар. Рәхим юан ботакларны кисәргә тотынды. Эшли торгач, миләшнең урта кәүсәсе генә тырпаеп калды. Анысын бүлгәләп кисеп төшерү өчен баскыч кирәк булды. Сәлим сарайдан озын баскыч алып чыкты, кияве баскычка менеп, агачның очын кыеп төшерде. Кисә торгач, Рәхим агач төбенә якынайды. Сәлим кәүсәнең киселгән бер өлешен читкә алып ташлый торды. Ниһаять, төпкә үк җиттеләр. Тагын берне киссәң, ярты метрлык бүкән генә утырып калачак. Кияве анысын да кисте, Сәлим өзелеп төшкән өлешне алып ташлыйм дип иелгәндә, бүкән кисешендә ниндидер кара тишек күреп алды. «Бу нинди тишек, ничек барлыкка килгән?» – дип уйлап алды. Ишарә ясап, киявенә пычкысын сүндерергә кушты:

– Карале, монда ниндидер тишек бар, – дип, киселгән урынга күрсәтте. Икәүләшеп кәүсәдәге сәер тишекне тикшерә башладылар. Рәхим тишеккә бармагын тыгып карады:

– Бу табигый тишек түгел, борау тишеге.

– Шулай дисеңме? – дип сорады Сәлим.

– Тишекнең башы тегесендә булырга тиеш, – дип, ул әле генә кисеп төшерелгән бүкәнне күтәреп алды, анысында да тишек күреп:

– Әйтәм бит, башы монда, – диде.

Сәлим аунап яткан ботактан нәзек чыбык сындырып алды, аны тишеккә тыгып карады:

– Әйе, ясалма тишек бу, борау белән тишелгән, – диде.

– Кем эше дип уйлыйсың?

– Борһан тишкәндер... Былтыр кис миләшеңне, күләгәсе бакчаны каплый дип әйткәләгән иде.

– Алайса, аның эше. Сезнең бакчага аннан башка кереп йөрүче юк.

– Тишеккә нәрсә салды икән?

Кияве бераз уйланып торды да:

– Берәр төрле гербицид булырга тиеш. Үсемлекләрне корыта торган агу инде. Андый нәрсәләр хәзер кибеттә сатыла.

– Алайса, миләш үзәгенә агу салган.

Шул вакыт икесе дә бакчада Борһанны күреп алдылар, ул аларга таба килә иде. Якынлашу белән киң итеп елмайды, кулын исәнләшергә сузды, тик аңа кул бирүче булмады. Күршеләрнең үзләрен сәер тотуы аны бераз сагайтса да, ул сер бирмәскә тырышты:

– Кисәсезмени миләшне?.. Яхшы булган, барыбер корыган иде, – диде.

Сәлим белән Рәхим үзара карашып алдылар. Сәлим:

– Корыган дисеңме?.. Аның нигә корыганын син яхшы беләсеңдер. Кил әле бире, бер нәрсә күрсәтәм. – Ул Борһанны киселеп бетмәгән бүкән янына чакырды. Тегесе теләр-теләмәс кенә миләш төбенә килде. Сәлим кулы белән миләшкә күрсәтте:

– Күрәсеңме мондагы тишекне?

Күршесе каушап калды, әмма дәшмәде. Сәлим:

– Бу – борау тишеге. Аны кем тишкән дип уйлыйсың?

– Мин каян белим... Миләш синеке, үзең беләсеңдер...

– Мин беләм. Без кияү белән барысын да ачыкладык.

Борһан курка калды, йөзе агарынып китте:

– Такмагыз миңа нахак бәла. Миләшегез янына килгәнем дә юк. Картайды ул, шуңа корыды...

Сәлимнең бик нык ачуы чыкты, ул:

– Син чын дошман икәнсең... Агачны тишеп агу салгансың. Ул шуңа корыды. Миләшне син агуладың, син генә бетердең. Моннан соң күземә күренәсе булма... Борылып та карамаячакмын... – диде.

Шушы сүзне ишеткәч, Борһан артка чигенде, сөртенә язып, кырт борылды да тиз-тиз өенә таба атлады. Сәлим белән Рәхим аның кыяфәтсез гәүдәсенә карап калдылар.

* * *

Бер атнадан Сәлимнәр дачасына койма коручы ике егет килде. Кирәкле бөтен нәрсәне алар машина белән китергәннәр иде. Ике көндә Сәлимнәрнең ызаны буенда калай койма барлыкка килде. Алар хәзер күршеләрне күрмиләр, ишетмиләр иде. Шулай да Сәлим коймада капка ясатты. «Хатынының ни гаебе бар, Сания белән аралашып яшәсен» дигән фикергә килгән иде ул.



Галия
Гайнетдинова

# МӘХӘББӘТНЕҢ ИКЕ КОЛЫ БЕЗ...

## Алмагач бакчасында

Ак карлар яуган диярсең
Алмагач бакчасына.
Парлылар йөри бакчада
Сокланып барчасына.

Алмагачлар чәчәк аткан,
Күрсәң, китәр исләрең.
Күзләр чагыла аклыктан,
Әй исләре, исләре!..

Бик иртәләгәннәр быел,
Гадәттәгечә түгел.
Шушы могҗизаны күреп,
Сокланып туймый күңел.

Алмагачларның һәрберсен
Назлап, май җиле исә.
Җыр тумый калмас, бу ямьне
Шагыйрь күзләре күрсә.

Килә шул пакьлек, сафлыкны
Күңелләргә саласы.
Елга бер килгән мизгелгә
Ләззәтләнеп каласы.

Язгы хисләр дулкынында
Башкача тибә йөрәк.
Гыйшык тоткан гашыйкларга
Сөю-сөелү кирәк.

---

Галия ГАЙНЕТДИНОВА (1960) – *шагыйрә; С.Сөләйманова исемендәге кызыксындыру премиясе иясе.«Күңелем язлар көтә», «Ашыкма син, гомер!», «Яратам!» дип язып куйдым» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

Парлылар йөри бакчада
Мәхәббәттән исереп.
Рәссам булса, ак киндергә
Шул яшьлекне һич үзгәртми
Куяр иде күчереп.

## Яшьлегем учагы

Толымнарын чайкый суда таллар,
Җилләр килеп тарый чукларын.
Тыңлыйм чишмә җырын,
Күрәм, әнә, моннан ерак түгел,
Без кабызган учак утларын.

Хәтер күрә, очкын чәчә-чәчә
Уйнап янган яшьлек учагын.
Эх, кайтарып булса икән кабат
Гомерләрнең җанга җылы биргән
Мәңге онытылмас шул чагын.

## Дуслар белән

Якын дуслар күп булмый ул диләр,
Бер булырга мөмкин, йә ике.
Санаган юк, минем дус-ишләрнең
Саны булыр, бәлки, унике.

Бәлки әле аннан күбрәктер дә –
Ерак төбәкләрдә күпмесе.
Дуслык кадерен белеп яши алар,
Юк арада көнче, үчлесе.

Җәен таралышсак төрле җиргә,
Очрашабыз тагын көзләрен.
Кич утырып, шигырь укый-укый,
Бушатабыз йөрәк серләрен.

Аулак өйләр үткәрәбез бергә,
Гармун моңнарына күмелеп.
Шигъри җанлы дус-ишләрем белән
Кичләр үтә җырга үрелеп.

## «Балам» диеп әнкәм дәшкәндә...

Әлегәчә бала булып яшим,
«Балам», – диеп әнкәм дәшкәндә.
Шундый рәхәт әнкәй яннарында,
Икәү бергә чәйләр эчкәндә.

Арыдым дими, уфтанып та ятмый,
Карыйм кайчак аңа сокланып.
Бутаса да безнең исемнәрне,
Аркабыздан сөя ул танып.

Үзем дә бит инде дәү әни мин,
Оныкларны сөям куанып.
Тик әлегә картлык читтә йөрсен,
Кәкре таягына таянып.

Аермасын язмыш көтмәгәндә
Баласыннан газиз анасын.
Хәер, белеп буламыни аның
Кайда абындырып егасын.

Булсын иде дә соң бераз гына
Шул вакытны сатып алырга.
Өлгерәсем килә, әнкәм исән чакта
Игелекләр эшләп калырга.

Әнкәемә түләр бурычым зур,
Кайтарырга гомерем җитәрме?
Тау кадәрле бурычымны түләп
Бетергәнне әнкәм көтәрме?

## Көнбагышлар

Сары диңгез сыман еракларга
Көнбагышлар кыры сузылган.
Санаган юк, кайткан-киткән чакта
Бу юллардан күпме узылган.

Көнбагышлар биючеләр сыман
Юл буена тезелеп басканнар.
Барысы да, кояш назын сизеп,
Сары керфекләрен ачканнар.

Әйтерсең лә август кояшының
Нурларыннан алар яралган.
Итәк очларына бер ямь биреп,
Күкчәчәкләр килеп сарылган.

Менә-менә биеп китәр төсле
Көнбагышлар, чыгып юлларга.
Охшаганнар алар, күрегезче,
Сары калфак кигән кызларга.

Көнбагышлар арасына кереп,
Түрләренә килә узасым.
Алар белән бергә җитәкләшеп,
Бер биисем йә җыр сузасым.

## Аймылышлар

Югалма син кереп томаннарга,
Юллар очрашырга торганда.
Ялгыз җаным күрешүләр көтеп,
Ярты гомер инде узган ла...

Син эзлисең мине, ә мин сине,
Юкса, ерак түгел аралар.
Аймылышлы юллар безне һаман
Сары сагышларга салалар.

Тәкъдир сынавымы икәү бергә
Туры килмәү бер үк урында?!
Очрашулар көтеп тилмерәбез
Өмет белән сөю барында?

Ике ярда калган ике йөрәк –
Мәхәббәтнең ике колы без.
Гомер юлларында Сак-Сок булып,
Аймылышлар булып йөрибез.

Тапкан кебек Йосыф Зөләйхасын,
Мәҗнүн тапкан кебек Ләйләсен.
Бер кавышыр безнең йөрәкләр дә
Язлар җиткәч, бәлки, белмәссең.

## Син әзерме?

Күрәм, сизәм, гашыйк булгансың син –
Әйтеп тора шомырт күзләрең.
Кош тоткандай ихлас куанасың,
Балдан татлы әйткән сүзләрең.

Шушы халәт минем үземдә дә,
Кыймыйм гына аны әйтергә.
Тик нишләрсең, сиңа бүген ошап,
Шигырь җене ияләшкән җаным
Ошамаса әгәр иртәгә?..

Син әзерме шагыйрь йөрәгенең
Ялкынында янып яшәргә.
Син әзерме, әгәр кирәк булса,
Аның белән бергә яшьнәргә?

Бер дулкында дәрья кичәр өчен,
Көч-куәтең синең җитәрме?
Озакласам юлда, йөрәккәең
Кайтуымны сагынып көтәрме?

Нечкә күңелемне юатырга
Табарсыңмы сүзнең кирәген?
Аңлый алырсыңмы кирәк чакта
Шул катлаулы шагыйрь йөрәген?

Агымнарга каршы йөзгән чакта,
Булырсыңмы ныклы терәгем?
Яши алырсыңмы, сүндермичә
Шигырь тулы шагыйрь йөрәген?

Ярсу йөрәгемнең уты хәтәр,
Утлы дәрткә җаның түзәрме?
Син әзерме мәхәббәтең белән
Яз итәргә сары көзләрне?



Рөстәм
Галиуллин

ХИКӘЯЛӘР

# БӘЛЛҮР

Гүяки сагыштан саргайган сары диварлы, кызыл түбәле һәм әйтерсең лә кан тамчыларын хәтерләткән хәрефләре чекрәеп торган тимер юл вокзалы бинасы күз уңыннан югалды – поезд Воркута шәһәреннән төньякка таба кузгалды. Берара рельслар кысасында ирегe җуелганга ризасызлык белдергәндәй, тәгәрмәчләрен ыңгыраштырып барды да, язмышына күнеп, бер көйгә тизлеген арттыра төште. Безне тизрәк озатырга теләгәндәй, иртәдән бирле Төньяк Боз океаны ягыннан салкын җил исә; көндез ул җәяүле буранга әйләнде, кичкә таба, менә, күзгә күренеп көчәйгәннән-көчәя бара. Поезд тәрәзәсеннән төньяк сазлыгында сызланып үскән нечкә, тәбәнәк каеннарның, бездәге мәгърур абый-апаларына сәламнәрен җиткерергә теләгән сыман, шәрә ботакларын селки-селки йөгерешүе күзгә чалынып кала.

Без поездга аздан гына соңга калмадык. Без дигәнем – Воркута шәһәрендә яшәүче милләттәшләребез белән очрашуга килүчеләр. Дүрт кеше без. Юлбашчыбыз – күренекле җырчыбыз Миңлегали агай. Мондагы татарлар өчен нәкъ менә ул иң кадерле, хөрмәтле кунак иде. Үз күзләренә ышанмагандай, тотып-тотып карадылар аны. Берсенә дә каршы килмәде, ничек түземлеге җиткәндер: сәгатьләр буе һәркайсы белән фотога төште, сөйләште, киңәште. Очрашуларда, концертларда да сәхнә күрке ул иде: елмайтты, җырлатты, елатты... Поездга да нәкъ менә Миңлегали агайның шул киң күңеллелеге аркасында көчкә өлгердек.

– Ярар инде, егетләр, бу якларга гомер эченә бер киләбез, – диде ул, безнең күзләрдә пәйда булган ризасызлык очкыннарын тоеп. – Болай да нинди кырыс шартларда нужа күреп яшиләр мескенкәйләрем. Шахталарда хезмәт хакы ташка үлчим, ничә дистә еллар тир түгеп тапкан фатирларының бәясе бер дә юк, сатып алучы да күренми – туган якларга кабат күченеп

---

Рөстәм ГАЛИУЛЛИН (1987) – *язучы, филология фәннәре кандидаты; ТРның Муса Җәлил исемендәге премиясе лауреаты. «Биш «ике»ле», «Юлларда җил ак иде...», «Васыять» һ.б. китаплар авторы. Казанда яши.*

кайтыр идек дип хыялланалар бит. Шушы ике көн гомеребезнең бизәге булды дигән сүзләрен ишетмәдегезмени? Күзгә күренеп карашлары яктырды. Сизмәдегезмени соң шуны?..

Миңлегали агай хаклы, барыбыз да аны хуплый, ләкин ул тагын биш минутка тоткарланса, без бүген кояшлы, алтын көзгә кергән Казаныбызга кайтып китә алмыйча, карлы-буранлы кыш хөкем сөргән Воркутада калырга мәҗбүр булыр идек.

Вагоннар төньякның рәхимсез җиленнән яргаланган кырыс йөзле ирләр белән тулы. Барысы да диярлек җылы свитерлардан, алар янында безнең кәчтүм-күлмәкле дүрт кешелек төркемебез кара каргалар янындагы чәүкәләр кебек күренә иде. Паспорт-билетларны тикшерү, урнашу, табын көйләү мәшәкатьләренә бәйле тынгысызлык артта калды, вагонда ирләрнең үзара гәпләшүеннән, ара-тирә шаркылдап көлүеннән ниндидер бер ләззәтле халәт барлыкка килде.

– Гасыйм, ал әле баяныңны, – диде кинәт Миңлегали агай.

Шуны гына көткәндәй, Гасыйм баян япкычын ача башлады. Ул – Миңлегали агайның талантлы шәкерте, көне-төне гармунда уйнарга әзер егет. Баянын бик кадерли:

– Бөтен булган акчамны кырып-себереп алдым, бик кыйммәтле, – ди.

Гасыйм Воркутадагы милләттәшләребезне әле танышканчы ук шаккатырды. Перронга аяк басуга, бозда таеп егылды ул. Баш сөягенең «чеңк» иткәнен барыбыз да ишеттек. Баянын күкрәгенә кыскан килеш аркасына ятып тын калган Гасыймны күргәч, каршы алучылар бөтенләй коелып төште. Тиз арада Гасыйм тирәли кеше җыелды.

– Әрәмнәр генә булды егет! – диде кайсыдыр.

– Бигрәк яшьли килеш...

– Врач чакырыгыз!

Гасыйм башын җирдән калкыткач, барыбыз да җиңел сулап куйдык. Миңлегали агай аның баш артыннан сыйпап, хәлнең ни дәрәҗәдә җитдилеген чамаларга тырышты.

– Баянга зыян килмәдеме, Миңлегали агай? Яхшылап карале...

– Менә бу яшьлек дип атала инде, – диде Миңлегали агай. – Баяны башыннан кадерлерәк әлегә. Ярар, барысы да тормыш тәҗрибәсе белән килә, башының да кадерен белергә өйрәнер, исән генә булсын...

...Гасыйм баянны шыгырдатып алды да, әмер көткәндәй, Миңлегали агайга текәлеп, тын калды.

Бездә биек таулар бар ла,
Тау астында таллар бар;
Талда яфрак, миндә сагыну,
Сездә нинди хәлләр бар?

Миңлегали агай салмак кына башлады. Аңа без дә кушылдык.

Тау астында салкын чишмә
Агып төшә улакка;
Сагынуымны әйтер идем,
Җил дә исми ул якка.

Бу җырны Воркутада да кат-кат җырлаттылар Миңлегали агайдан. Нигәдер нәкъ менә шушы җырны башкарганда, аның күзе яшьләнә, тавышы нечкәрә төшә. Бу юлы да шулай булды. Керфекләре арасыннан тәгәрәп төшкән ике эре тамчыны сизмичә дә җыр суза Миңлегали агай.

Алмалар өзәр идем лә,
Бауларга тезәр идем;
Янмаса бу йөрәккәем,
Сагынуга түзәр идем.

Безнең янга берәм-берәм ирләр җыела башлады. Җырның ахырында бөтен вагон бергә җырлагандай кебек тоелды миңа.

Салкын чишмә буйларында
Атлар эчерсәң иде;
Туган-үскән илләреңдә
Гомер кичерсәң иде.

– Афәрин! – дип, безнең кулны кысты яныбызда торганнары.

– Зинһар, тагын, тагын җырлыйкчы шуны, канәт!

– Миңлегали агаем, бәгърем, үзәгемне өзәсең бит!

Без шаккаттык: әле бая гына үзара русча әңгәмә корып барган вагон татарлашты да куйды. Без ул җырны кат-кат җырладык. Алай гына түгел, кич буе, төн буе – Мәскәүгә җиткәнче татарча җырлап кайттык. Вахта ысулы белән төньяк котыпта эшләүче ирләрнең кырыслыгыннан берни калмады, җилкәдән кага-кага, елый-елый рәхмәт укыды күбесе. Татар ир-егетләрен күпләп күрәсең килсә, өшеткеч төньякка, сазлыклы Себер якларына бар икән. Бүген дә шахталарга татар егетләре төшә, рудаларны татар егетләре казып чыгара...

Мәскәү вокзалларында безнең юллар аерылды. Казан вокзалына безнең белән бер-икесе генә күчте.

– Татарстанга сәлам җиткерегез!

– Безне онытмагыз!

Бик җылы саубуллаштык без. Якын туганнан, җан дустан аерылган кебек булды.

Мәскәү – Казан поездында без инде җырламадык. Мөгаен, җырласак та, безгә кушылучы табылмас иде. Миңлегали агай да никтер, уйларына чумып, тын гына бара. Поезд Гусь Хрустальный станциясендә туктады.

– Аякларны язып керикме соң? – диде Гасыйм.

– Әйдә соң. – Без икәү чыгарга кузгалдык.

– Миңлегали агай, син дә безнең белән һава сулап кермисеңме? – дидем мин.

– Юк, егетләр, тәрәзәдән генә карап торам. Нәрсә генә сатмыйлар монда, шаккатарсың...

Без Гасыйм белән перронга чыктык. Шундук, урап алып, яше-карты пыяла-бәллүр эшләнмәләрне тәкъдим итә башладылар. Без, корт чаккандай кулларыбызны бутап, алардан чак котылып, кире вагонга кердек. Миңлегали агай урынында юк иде.

– Абзый кайда? – дип сорады Гасыйм тагын бер юлдашыбыз – яшь җырчы Мараттан.

– Сезнең арттан чыкты бит. Тәрәзәдән карап-карап утырды да кинәт атылды. Акча да алды ул. Нәрсәгәдер күзе төшкәндер...

Поезд кузгалып китәргә җыенганын кисәтеп кычкыртты. Без пошаманга төштек. Инде кузгалып китә башлагач кына, кулына бәллүр люстра тоткан Миңлегали агай килеп керде. Никтер күзе кызарган иде аның.

– Менә, егетләр, бәллүр люстра алдым әле. Ошыймы?

– Әйбәт булган, – диештек без Гасыйм белән.

Маратның уйлаганын эчендә калдырмый торган егет икәнлеген без бу сәфәрдә аңлаган идек инде, бу очракта да ул үзенә тугрылыклы калды:

– Фиии, Миңлегали агай, нәрсәгә алдың моны? Бу бит инде модада түгел, андыйны авылларда да күптән чыгарып ташладылар.

– Ярар инде, егетләр, ошатып алдым бит.

– Фатирыңда элә күрмә, кеше көләр! – Марат безнең «кирәкми, дәшмә» дигән ишарәне аңламый, үзенекен тукыды.

– Дачага булса да ярап куяр әле...

– Моны лапаска да элмиләр хәзер. Бәясе бардыр әле үзенең?

Миңлегали агай җавабыннан Марат сикереп үк торды:

– Шул бәягә алдыңмы? Алдаганнар бит сине, Миңлегали агай! Эх, ник үзем дә ияреп чыкмадым икән соң?

Дөресен әйтим, бу бәллүр люстраны мин дә ошатмадым. Кыйммәтле икәнен дә белгәч, Миңлегали агайга карап, шулай ук аптырашта калдым. Марат исә үзе алдангандай угаланды.

– Вәт кабахәтләр, ә? Өлкән кешене алдамасалар! Чегән-мазар идеме соң әллә?

– Юк...

Шулчак Миңлегали агайның яңаклары буйлап яшь тамчылары тәгәрәде. Бу күренештән Марат тораташтай катып калды хәтта. Миңлегали агай тәрәзәгә таба борылды. Авыр тынлык иде бу. Бераздан ул, тәрәзәдән карашын аермаган килеш, телгә килде:

– Эх, егетләр, минем кызымның исеме Бәллүр... иде бит... Бер ай элек вафат булды, бәгырькәем. Шул кайгыларым бераз таралмасмы дип чыктым бу сәфәргә дә.

Миңлегали агай, кесәсеннән кульяулыгын чыгарып, күз яшен сөртеп алды. Сабырсыз Марат түзмәде:

– Бу бәллүр люстра аны хәтерләтәме? – дип сорады.

– Юк, егетләр. Сатучы кыз минем Бәллүремә шулкадәр, шулкадәр... охшаган иде...

Миңлегали агайның сагышы безгә дә күчте. Авыр уйларыбызны куарга ашыккандай, поезд алга ыргылды, тизлеген арттырды, рельслар ыңгырашуына кушылып, Миңлегали агай кулындагы бәллүр люстра чыңлады...

# РӘФИДӘ

Өч көн дәвам иткән халыкара чарадагы очрашулар, чыгыш ясаулар алҗыткан иде. Соңгы көнне безне тарлавыкка алып бардылар. Кавказ тауларының серпантин юлларыннан күккә ашкан тау түбәләренә, кан тамырларын чымырдатып алырдай упкыннарына сокланып, шушы гүзәл тарлавыкка килеп җиттек. Бүген – хушлашу көне, саубуллашу мәҗлесе.

Ташларга бәрелә-бәрелә, тау сулары челтерәп ага. Алар берничә – кайсыларыдыр мул сулы, кайберләре үзән буйлап түбәнлеккә юл тоткан инешкә оялып кына кушыла. Берсе исә, тау-кыяның үзеннән тибеп чыгып, бөтенләй тамчылап кына тора. Ул мине шундук үзенә җәлеп итте, ташлардан ташларга күчеп, янына ук килеп утырдым.

– Әйтерсең лә күз яше тама. – Якындагы тавышка сискәнеп борылдым. Мари халкының вәкиле Рафидов фамилияле агай икән.

– Чынлап та охшаган шул, – дидем, аның белән килешеп.

– Ирләрнеке булырга тиеш бу. Бигрәк саф.

Әлеге чагыштыру икебезгә дә кызык тоелды. Безнең көлү авазларын тарлавык та кайтаваз булып яңгыратты.

Ни гаҗәптер, чыгыш ясаганда, Рафидов агайга гел миннән соң сүз бирделәр. Ул инде өлкән яшьтә, салмак итеп, сүзнең тәмен белеп сөйләшүе, уйчан карашы, сирәгәя төшкән ак чәчләре аны чын мәгънәсендә зирәк аксакал итеп күрсәтә иде. Рафидов агай һәр сүзен татар халкын мактаудан башлап китә дә халыкара җыенны татарныкына әйләндерә дә куя. Аннан соң чыгыш ясаган төрки кардәшләребез дә, халкыбызга мәдхия укып, безнең мөгаллимнәрне, шәхесләребезне җылы итеп искә алалар. Үземне мактаганга күптән инде кылым да селкенми, әмма читтә, башка милләт кешесе татар турында шулай яратып, мактау-соклану сүзләре ирештерә башласа, авызым колакка җитәрдәй булып ерыла, бу йомшаклыгымнан котылыр әмәлне әлегәчә таба алганым юк.

– Сез бик төпле чыгышлар ясадыгыз, – дидем, әнә шул мизгелләрне кабат күз алдымнан кичереп. – Безнең милләт турында әйтелгән сүзләрегез өчен тагын бер кат рәхмәт!

Шартына туры китереп, мин дә мари халкын мактадым. Мондый халыкара җыеннарда мактау сүзләренә саран булмаска кирәклегенә төшенеп, бу җәһәттән шактый гына шомарып килә идем инде. Тырыш-уңган булулары, гореф-гадәтләрне саклаулары, табигать белән бер сулышта яшәп, күркәм холыкка ия икәнлекләрен тезеп чыккач, Рафидов агайның үзенә дә чират җитте. Иң ахырдан:

– Сезнең бит фамилиягезгә кадәр шулкадәр үзенчәлекле! Ра-фи-дов! Безнең татарда Рәфидә исеме шактый таралган, хәтта шуны да хәтерләтә!

– Ну, татарлар, сизгер дә халык соң үзегез! Чамаларсыңмы дип көтеп йөргән идем.

– Әллә кыек атып, туры тидердемме?

– Өстенә бастың! Фамилиям Рәфидә исемле татар кызы белән бәйле дә инде!

Мин, ялганын тотарга теләгәндәй, Рафидов агайның күзенә туры

карадым. Аның күзе яшьле иде. Әле генә таш арасыннан тибеп чыккан тау суыдай, ике бөртек күз яше керфекләреннән тамды. Гаебем бар кешедәй, карашымны читкә бордым.

– Әйе, Рәфидәгә бәйле фамилиям, – диде Рафинов агай. – Тарихын сөйлимме?

Минем сабырлыгым тәмам төкәнгән, әдәп саклап кына түзеп, дәшми торам.

– Сөйләргә теләгегез булса, рәхәтләнеп тыңлар идем.

Рафидов агай без яңа гына ирләрнең күз яшенә охшаткан тау чишмәсенә карап, салмак кына, бер көйгә сөйләп китте.

...Рәфидә – күрше авыл кызы. Татар авылыннан ул. Безнең Марида алар шактый бит, беләсеңдер, булганың да бардыр. Без алар белән аралашмадык, алар безнең белән дигәндәй. Сугышып яшәгән авылларны беләм, ләкин без алай булмадык. Бәхетемә димме, бәхетсезлегемә димме – аларның мәктәбен тугыз еллыкка калдырдылар, унынчыга безгә килделәр. Күрдем дә гашыйк булдым шул Рәфидәгә. Бер күрүдә! Ләкин мәхәббәтемне ничек аңлатырга? Аңа хатлар язар өчен татарчаны тырышып өйрәндем. Ул башта миннән көлеп кенә йөрде. Аннан ничектер үз итә башлады. Баштарак беркем дә сүз әйтми иде. Аңа язган мәхәббәт хатларын әнисе күргәч башланды хәлләр. Рәфидәне өендә орышканнар, минем белән сөйләшми башлады. Мәктәптә янына килергә оялам, бөтен батырлыгымны җыеп, татар авылына киттем. Яз иде ул, март ае иде. Кояш күзне чагылдыра – инде көннәр озынаюга бара. Кар өстенә күзгә күренеп, нindидер бер каракучкыл зәңгәр төс йөгерә, кыш аклыгын мизгелләп җуя бара.

Урамда әрле-бирле йөренүдән мәгънә юк, татар авылын беләм, озаграк таптансаң, хәзер йортлардан иң әүвәл бабайлар, аннан апалар чыгып, кемлекне, җиде бабаны төпченә башлаячаклар. Туп-туры яшел йорт ишегалдына уздым, тәвәккәлләп, ян тәрәзәне кактым.

Ян тәрәзәдә пәрдә ачылып-ябылды, аяк тавышлары өйалдында ишетелде дә кинәт ишек ачылды. Ике калын толымын ике якка үргән түгәрәк йөзле, миңа көлемсерәп караган кызны күрүгә мин бермәлгә телсез түгел, тынсыз калдым. Гәүдәм буйлап нindидер калтырану узды, әллә ниткән дулкыннар кубып-кабарып, аяк астын чайката башлады. Кыз мәхәббәт чокырын балкытып, туры карап тора. Моңарчы мин мондый халәт кичергән кеше түгел.

– Рәфидә ... – дидем үземә хас булмаган чит бер тавыш белән.

– Әйе, тыңлыйм...

Телем көрмәкләнде. Юл буе, алай гына түгел, инде ничә көннәр, төннәр әйтергә теләгән, күпме әзерләнгән, ятлаган сүзләрем онытылды да куйды. Бер-беребезгә карашып, тик басып тордык шулай. Тамырлар буйлап нindидер ләззәтле хис таралды.

– Рәфидә... Мин... мин...

– Кирәкми... – диде ул пышылдап һәм нindидер бер шомлану белән ян тәрәзәгә карап алды.

Өйалдының идән такталары шыгырдады. Кайдандыр яз җиле ишегалдына үтеп кереп, йөземне җиңелчә сыйпап үтте. Рәфидәнең:

– Абыйлар! – диюеннән айнып киттем. – Кит, зинһар! Бүтән килмә!

Баш өстендә кояш көлә, аяк астында кар сулары ерганак булып ага, кыр ягыннан салкынча җил исә. Аякларымны кадаклаганнармыни – кузгала алмый торам. Юк, минем бу яшел йорт яныннан китәсем килми. Шулчак пәрдә тартылып куйды: үткен күзләрем Рәфидәнең карашын тотып алырга өлгерде. Ниндидер бер билгесез хистән дөньясын тетрәтеп, бер аваз саласым килде.

Юл буе үземне куркаклыкта гаепләп, пешмәгәнлектә битәрләп, сүгеп кайттым. Абыйларыннан куркып качуыма гарьләндем. Икенче көнне дә киттем татар авылына. Капкадан узуга, ике абыйсы ике яктан эләктереп алды:

– Син начар малай түгел. Әмма да ләкин безнең марига бирә торган сеңлебез юк. Бер әйтүдән аңларсың дип ышанабыз. Тагын безнең өй каршында күренсәң, бездән яхшылык көтмә, – диделәр.

Шуннан минем өчен иң кара көннәр башланды: Рәфидә бүтән безнең мәктәптә күренмәде. Ябыктым-киптем. Түзә алмадым: тагын киттем. Ахырын сөйләп тормыйм: абыйлары сүз тота торган егетләр булып чыкты...

...Рафидов агай, сөйләвеннән бүленеп, сагышлы күзе белән тутырып карады. Аның карашында сукмагын җуйган юлчы билгесезлеге белән беррәттән, ихлас яктылык чагылды. Сабырлык җепселләрем соң чиккәчә киерелеп тартылган иде:

– Шуннан, ничек бетте соң бу хәлләр?

– Берничек тә, – диде ул тыныч кына. – Рәфидәне үз гомеремдә бүтәнчә күрмәдем мин. Ләкин менә шул татар авылыннан тукмалып кайткан көннән соң шигырь яза башладым.

– Ә фамилия? Рафидовның Рәфидәгә ни катнашы бар?

– Шигырьләрне мин Рафидов тәхәллүсе белән яздым. Унсигезем тулгач, фамилияне дә Рафидовка үзгәрттем.

Мин Рафидов агай хикәятенең шулай тәмамлануыннан шулкадәр канәгатьсез идем ки, чыраема ук язылды, ахрысы:

– Ошап бетмәде бугай бәяным?

– Аннары оныттыгызмы Рәфидәне?

– Юк. Беркайчан да! – Рафидов агай моңсу елмайды. – Вакыт барысына да дәва диләр. Әйе, дәвалый, әмма йөрәктән алып ташлап булмый. Минем барлык шигырьләрем дә, җырларым да Рәфидәгә багышланган.

– Гаҗәп кеше сез, – дидем башка сүз таба алмаудан. – Шулай татар кызын сагынып, ялгызыгыз гомер кичердегезме?

– Ник ялгызым? Арняшам белән чөкердәшеп яшәдек, дүрт бала үстердек, оныклар санында буталам инде хәзер.

– Ә Рәфидә?

– Ул да әби инде хәзер. Шул авылда яши.

– Чынлап та башка күрешмәдегезме?

– Юк. Бер күрәсем килгән иде дә, тәнкыйтьче дустым туктатып калды. «Күңелеңдә шулай яшь, чибәр килеш сакланып калсын, югыйсә бүтән шигырь яза алмаячаксың», – диде.

...Мәҗлес халкы безне эзли чыккан иде. Рафидов агай, ташлардан

ташларга җитез генә күчеп атлады. Ничектер җиңеләеп калган, яшәреп киткән кебек иде ул. Тагын бер кат сокланыр өчен тау-кыядан бәреп чыккан чишмәгә борылып карадым. Шулчак эре генә саф тамчы тәгәрәде. Ул, ни өчендер, мин белгән дә, белмәгән дә Рәфидәнең күз яше сыман тоелды...

# ҮЗЕМНЕҢ ӘТИ

Әтиемнең үземнеке булмавын мин инде ике ел беләм.

– Син бит үги малай! – дип кычкырды күрше Даниял.

Без аның белән яңа гына сугышып, алышта мин өстен чыккан идем. Еламсырап, үртәлеп, борынын тарта-тарта тагын кабатлады:

– Ууу, үги малай!..

Ул сүзнең ни аңлатканын белми идем. Әнидән сорагач, имәнеп китте, кулымнан алып, ишегалдына алып чыкты. Әйтерсең лә ниндидер хәрби сере белән уртаклашкандай, пышылдап сорады:

– Кем әйтте?

– Даниял.

– Юньсез! – Әни нигәдер бик ачулы иде. Ул күрше ихатага нәфрәтле карашын текәде. Аның күзе яшьләнде. Әнине борчыганга үзем дә пошаманга төштем. Гаепсездән гаепле икәнлегемне тоеп, башымны ия биреп, сулыш алырга да куркып басып тордым. Бу сәер тынлык күпме дәвам иткән булыр иде икән, әтинең эштән кайтып керүе икебезгә дә җан кертте.

– Нишлисез сез икәүләшеп? – диде ул, аптырап. – Әллә Азат улым тәртип боздымы?

– Юк ла... – Әни кирәкле сүзен таба алмый изаланды. – Өйгә керәсеңме әллә, улым? Энекәшләреңә күз сал...

Әти ишегалдындагы бүкәнгә утырып, әни коймага сөялгән килеш озатып калдылар.

Ул чакта миңа унбер яшь иде, сигез һәм алты яшьлек энекәшләрем – Мансур белән Илсур идәндә машина узыштыралар. Алар уенына мин дә кушылдым.

Бераздан әти белән әни ишектә күренде.

– Әти!

– Әти кайткан!

Энекәшләрем, агачка үрмәләгәндәй, әтинең ике ягына сарылдылар. Берберсен төрткәләп, әти кочагында ялгызы гына калу өчен көрәш башланды. Әти икесен дә идәнгә бастырды:

– Тәртипле булдылармы кечкенәләр? – Ул, тавышын юри кырыслатып, усал итеп сорап куйды.

– Тәртипле, бик тәртипле!

– Мин тәртиплерәк!

– Мин тагын да тәртиплерәк! – диеште энекәшләр, берсен-берсе уздырып.

– Маладислар! – Әти икесенең дә аркасыннан какты, аннары мине алдына утыртты.

– Йә, олы улым, сөйлә, нинди яхшы гамәлләр кылдыгыз бүген?

Ул гел шулай: эшкә китәме, башка җиргәме: «Өйдә минем урынга Азат улым баш булып кала, аны тыңлагыз, сүзеннән чыкмагыз», – ди. Кайткач, менә шулай – алдына утыртып, хисап ала.

– Икесенә дә «бишле», – дидем. – Кушканны үтәделәр, еламадылар, ашадылар, урамда уйнадылар, әнине тыңладылар.

– Син аларны яклап әйтмисеңме? – Әти ачык күк төсендәге карашын миңа төбәде.

– Юк, дөресен сөйлим, әти.

– Маладислар! – дип кабатлады. – Мондый акыллы улларың булганда, дөньясын гөрләтәчәкбез әле.

Әти мине кочып утыра бирде. Тәбәнәк буйлы булса да, бик көчле ул: кулы каты, мускуллары кабарып тора, өчебезне берьюлы «эһ» тә итмичә күтәрә.

– Барыгыз әле, ишегалдында йөреп керегез, юкса өйне кузгатасыз, – дип эндәште әти. – Ә без Азат улым белән сөйләшеп алыйк.

Безнең өйдә ике тапкыр кабатлату юк: энекәшләр мизгел эчендә күз уңыннан юк булды. Аш бүлмәсеннән әни чыкты, әти аңа кырын карап алды:

– Әллә ашарга әзер дәме инде?

– Юк, юк...

– Безнең сүз бар, – диде әти, миңа күз кысып. – Азат улым белән генә сөйләшә торган.

Без бер-беребезгә туры карадык. Әти кытыршы, каты кулы белән яңагымнан сыйпады, чәчтән сыпырды, аркадан сөйде. Ул – тракторчы, көне буе рульдә, өйгә соң гына, арып кайта. Әни белән икәү аңа өйдәге эшләрне калдырмаска тырышабыз.

– Хәзер без бик җитди сөйләшәбез, улым. Мине бүлдермичә, күземә туры карап тыңла. Килештекме?

– Килештек, әти... – Тамырларымнан эсселе-суыклы бер дулкын кагып узды, калтырануымны сиздермәскә тырыштым.

Без кул бирештек.

– Әниең әйтте... – Әти ни өчендер сүзләрне сайлап, ашыкмыйча сөйли иде кебек. – ...Даниял белән сугышканыңны.

– Мин җиңдем аны, әти!

– Кемнәндер ишеткәнче, үзем сөйлим. – Әтигә җиңүем мөһим тоелмады, ул үз сүзен дәвам итте. – Мин... мин синең әтиең... үз әтиең түгел, улым...

Җир чайкалдымы, әти урыныннан кузгалдымы – башым әйләнеп китте. Нидер әйтергә теләдем – тавышым чыкмады.

– Син – олы улым. Яраткан улым... – Әти туктаусыз башымнан сыйпады. – Ләкин синең үз әтиең бар.

Бугазыма ниндидер төер тыгылды да ни сүз әйтергә, ни еларга бирми, әтигә карап, тораташтай тын калдым.

– Дөньяда төрле хәлләр була, улым. Әтиең безнең авылда яшәми инде. Ул башка җиргә киткән. Әниеңә өйләнгәндә, сине үз улым кебек күрәчәгемне әйттем. Үз улым кебек яратам да. Шуны бел...

– Ә Мансур белән Илсур? – дия алдым, ниһаять.

– Алар синең энекәшләрең...

– Аларның да әтисе башкамы?

– Юк...

Кинәт, әллә кайдан – күңел төпкеленнән ярсу давыл купты, үз-үземне белештерми, урамга атылдым.

– Артыннан йөрмә! – Әтинең әнигә әйткән сүзләре генә колагыма эленеп калды.

Бик озак яттым мин печәнлектә. Башымнан нинди генә уйлар кичмәде. Әнигә дә ачуландым, әтигә дә, кайчандыр мине ташлап киткән үз әтиемә дә... Аларга начарлык теләдем, үсеп җиткәч, ничек итеп газаплар китерүемне күз алдыма китердем. Шул уйларымнан күңелемә авыр булып, сулкылдап еладым.

Тынычланган кебек идем инде, печәнлек баскычының араталары шыгырдавы ишетелде.

– Азат улым, әйдә, өйгә керәбез.

Әти тавышын ишетеп, тагын күңелем тулды. Бик озак утырдык без печәнлектә. Ул көнне әти белән икәү кочаклашып йокладык.

Әтинең үги малае икәнлегемне белү һичкайчан исемнән чыкмаса да, башкача еламадым, печәнлеккә качмадым. Әмма шул көннән соң, әти мине тагын да үз итә башлады, еш кына үзе белән эшкә ала, алдына утыртып, трактор рулен ышанып тапшыра иде.

Шулай да үз әтием хакында беләсе килү, аны күрү теләге беркайчан сүрелмәде. Икәү генә калган чакларда, әнине үз әтием турында сорашып бимазаладым.

Мин тууга ташлап киткән икән безне. Себер якларында яши, ди. Безнең авылга шул китүдән бүтән аяк басмаган. Аннан әни әтигә кияүгә чыккан, Мансур белән Илсур туган. Менә шул.

Шул җәйдән соң ике ел узгач, әти беркөнне каршына утыртты:

– Азат улым, үз әтиең авылга кайткан. Сине күрергә тели.

Күңелемдә тагын өермә кузгалды: үч, нәфрәт, ачу хисләре кызыксыну, билгесезлектән котылу теләге белән бергә буталды.

Ахыр чиктә әти күндерде:

– Үзең белән иптәшкә Мансурны да ал, әгәр теләсәң, – диде ул.

Мансур белән үз әтием яшәгән урамга киттек. Мөнәвәрә әбинең улы икән ул. Капкадан уздык, ишегалдында шортыдан, майкадан ябык, озын буйлы бер абый каен себеркесе бәйләп утыра. Ул, эшеннән бүленеп, безгә текәлде. Карашлар очрашты.

– Улым... Азат!

Мин Мансурның кулын чытырдатып кыстым, авыртудан ул урынында таптанып алды хәтта. Бер адым артка чигендек.

– Кил, әтиең белән күреш!

Кул кысыштык.

– Егет булып беткәнсең икән инде. – Таныш чалымнар эзләгәндәй, карашын гәүдәм буйлап йөгертте. – Мин сиңа шәп бер костюм алып кайттым. Киеп кара әле. – Ул, болдыр баскычында торган сумканы алып, аннан костюм-чалбар тартып чыгарды.

– Йәле, сиңа таман булырга тиеш бу.

– Хәзер үк кииммени? – дидем, аптырап.

– Әйе, ничек икән, күрик.

Мин карышмадым, костюм-чалбар, чыннан да, матур иде. Беркөнне кич әти белән әнинең сөйләшкәне колагыма чалынган иде.

– Бу малайлар ай үсәсен көн үсә, быел өчесенең дә кәчтүм-чалбары кечерәеп калган, – диде әни.

– Яңаны алырга кирәк, – дип җавап бирде әти.

– Акча ягы такыррак бит әле, әллә ничек тә искеләр белән чыксыннармы соң быел? Бераз кечкенәрәк инде дә...

– Акча була да бетә ул. Кәчтүмлек кенә бардыр. Өчесенә дә алабыз!

Шул сөйләшүне исемә төшереп, икене генә аласы була дип уйлап куйдым.

Костюм-чалбар миңа кечкенә иде. Мансур энекәшкә менә таман гына булыр кебек.

– Мда... Кечкенә булып чыкты бит әле бу. Нишләтәсең...

Мансур энекәш тә, мин дә костюм-чалбардан күзне алмадык. Абый кеше – үз әтием инде – аны төреп, сумкага кире тыкты.

– Ярар, синең размер булмаган бу, кире кайтарырмын. Бәясе хәйран иде. Әйдә, өйгә керик, чәй эчәбез.

– Кайтабыз! – дидем мин, Мансурның кулыннан алып.

– Туктале, улым... Азат!

Өйгә кайтып кергәнче, бер авыз сүз сөйләшмәдек. Әти белән әни безне сагаеп каршы алды.

– Минем бер генә әтием бар – үз әтием генә. Башка әти турында миңа бүтән әйтмәгез! – Әтине кочакладым да, – Бер генә әтием бар, – дип кабатладым. – Үз әтием генә – син генә!..



*Гөлүсә Мортазина (1998) – Арча районының Сеҗе авылы кызы. Ул башлангыч сыйныфлардан ук каләм тибрәтә башлый, ике мәртәбә Г.Тукай һәм Г.Ахунов исемендәге район җирлеге премияләренең лауреаты була. Өлкән сыйныфларда тележурналистика белән кызыксына, Арча «Нур» балалар телестудиясенә йөри, яшь журналистларның «Алтын каләм» фестивальләрендә катнаша. Иҗади кыз табиб һөнәрен сайларга була – Казан дәүләт медицина университетының ординатура бүлегенә «лор» юнәлеше буенча укырга керә. Шулай да шигырь язуын ташламый. «Балачагым Кесмәс елгасы буенда үтте. Бөдрә таллар, чишмә чыңы, су агышы мине кечкенәдән илһамландыра һәм иҗатка өнди», – ди яшь авторыбыз.*

Гөлүсә
Мортазина

# ЫШАН МИҢА, ЫШАН ТЫЛСЫМГА!

## Хыяллан!

Хыяллан! Бу гомер бик кыска, бик татлы.
Хыялы булганнар булалар канатлы!

Хыяллан! Күрерсең – ачылыр күзләрең.
Ә синнән көлгәннәр белсеннәр үзләрен!

Хыяллан! Курыкма беркемнән, бернидән.
Уйлап тап үзеңә хыялны бер дигән.

Ул яшәр йә ун көн, йә ун ел ул яшәр.
Һичшиксез, хыялың тормышка бер ашар!

## Әти белән

Кырын салып куйган ак кепкасын,
Маңгаеннан сөртә тирләрен.
Туры басып, «чаж-чож» итеп кенә
Печән чаба әти кичләрен.

Эшләп аргач, бераз туктап тора,
Күз карашын төбәп еракка:
«Кайтыйк, балам, хәйран булды, – ди ул, –
Озакламый батар кояш та».

Әти белән иркен болыннарда
Үтә минем җәйге кичләрем.
Рәхәтләнеп тыңлыйм чалгы җырын,
Тәмләп сулыйм печән исләрен.

***

Мин – табиб, баш тарткан
Уколдан, дарудан...
Син – минем чын дәвам
Мең төрле арудан.

Мин – шагыйрь, яшердем
Шигырьләр дәфтәрем.
Син белсәң, шул җитә
Күңелем серләрен.

Мин – рәссам, ясаучы
Һаман бер рәсемне.
«Нинди?» – дип сорасаң,
Ул – синең исемле.

Мин – җырчы, белмәүче
«До»ны да, «фа»ны да.
Тормышым – үзе җыр,
Син булсаң янымда!

***

Син бәхеткә лаек, әйе, чып-чын,
Ышан миңа, ышан үзеңә.
Әйдә, килешәбез: бүгенгедән
Тик бәхетле яшьләр күзеңдә.

Син сөюгә лаек, изрәп яткан
Сабый кебек ап-ак бишектә
Мәхәббәтнең иң сафына лаек,
Каршыла, ул – инде ишектә!

Син дуслыкка лаек, үзең кебек
Ышанычлы, яхшы иптәшкә.
Ярдәм кулы суза торганына
Каршылыклар белән көрәштә;

Матурлыкка лаек, төнге күктә
Энҗе йолдызларны күрергә.
Үзең генә түгел, башкаларның
Сөенечен бүлә белергә.

Син ирекkә лаек, биеклектә
Хуҗа булып очкан бөркеттәй.
Чит сүзләрдән, кеше фикереннән
Бүгеннән син инде ирекtә.

Син өметкә лаек, киләчәгең
Үзең теләгәнчә булсынга.
Күңелеңне генә төшерә күрмә –
Ышан миңа, ышан тылсымга!

***

Хатын-кызга җан биргәндә Хак Тәгалә
Бүләк иткән гүзәллеген бар җиһанның.
Кулын – нәфис, буен – зифа, ә йөзләрен
Яз гөледәй нурлы итеп сөйгән аның.

Хатын-кызга биргән Раббым күңелләрнең
Иң нечкәсен, күркәм, хәлгә керердәен.
Сабырлыкны сынмас ныклы корыч иткән,
Толым биргән, гомере итеп үрердәен.

Һәммәбезгә биргән тәмле туган телне,
Сихерләрдәй назлы аһәң-тавышларны.
Яшик, кызлар, кадер белеп үзебезгә!
Сәламләп һәр туар таңны, танышларны!

## Хатлар

Ишеп-ишеп ап-ак карлар яуды –
Урам, йортлар, шәһәр күмелде.
Таң калырлык матур… тик бер сорау
Борчып тора һаман күңелне.

Бу карларны күкләр җибәргәнме,
Сабырлыгы тәмам калмагач?
Кешеләрнең җирдә яхшылыкны
Күптән онытуын аңлагач?

Әллә һәрбер яуган кар бөртеге
Ак конвертта безгә хатлармы?
Җир йөзенең бөтен каралыгын
Бу конвертлар гына капламы?

Укыр микән аны, аңлар микән
Бик акыллы адәм баласы?
Өзгәләнеп-өзгәләнеп күкнең
Ниләр килде икән язасы?

«Тукта, – диде микән, – кеше, тукта!
Ашыгасың болай кайларга?
Юк, карышма, син сокланып кара
Ишеп-ишеп яуган карларга!»

***

Тәрәзәмә яз шакыды – керттем.
Хуш киләсең, мин бит сине
Узган яздан бирле көттем!

Уз, оялма, синең урын түрдә.
Эхх... яраса иде җибәрмәскә
Сине бер дә!

Кышның салкын җилләрендә
Туңмас иде йөрәк.
Кеше җаны шундый инде,
Аңа җылы кирәк.

Шатлык булып, синең, язым,
Чәчкәләрең атсын.
Тынычлык һәм саулык булып
Ташуларың аксын.

Һәркемгә дә тамсын иде
Бәхет тамчыларың.
Хәбәрләрнең китер безгә
Бары яхшыларын!

## Табибка

Җилкәсенә нинди йөк төшсә дә,
Ул тайпылмас барыр юлыннан:
Өмет тулы күпме караш үтә,
Күпме язмыш табиб кулыннан.

Саф күңеле, яшь йөрәге белән
Ул сайлады шушы сукмакны.
Антын бирде таптан саклыйм диеп,
Иңендәге ап-ак халатны.

Кеше гомере өчен көрәшкәнче,
Көрәште ул озак үзе дә.
Эзен салып узган, әнә күпме
Йокысыз төн аның күзенә.

Юк, зарланмас, рәхмәт сүзләреннән
Канатланыр табиб янәдән.
Көнме, төнме – ярдәм кулы сузып,
Ул коткарыр сине бәладән.

Тәүге аваз салып, дөньяларга
Килгән чакта каршы алучы.
Сүнгән йолдызларны кабызырга
Дөрес юлын эзләп табучы.

Ул дәвалар бәлки күңелеңне,
Шифа бирер сүзләр табып кына.
Фәрештә дә түгел, тылсымчы да,
Ул бары тик гади табиб кына!..

***

Йөрәк асларында саклап йөрткән,
Безгә якты дөнья бүләк иткән;
Тәүге адым, безнең тәүге «ы-гы»ларны
Көннәр санап, барысыннан да ныграк көткән;
Безнең өчен төн йокысын җәлләмәгән,
Ару-талу, авыртуны да белмәгән,
Безгә ап-ак бәхет сорап дога кылган,
Кирәк чакта укытучы, табиб булган;
Безнең өчен күпме хыял-теләгеннән
Башын тарткан һәм һич үкенмәгән;
Без китергән борчуларны кабул итеп,
Күрсәтмичә генә эчтән көйгән;
Иң кайнар аш, тәмле чәен куеп,
Безне һәрчак якты өйдә көткән;
Ялгышсак та, безнең яклы була белгән
Газиз кешем, әни бәгърем, ул син икән!



Әлфирә
Галиева

# БИЗМӘННӘР НИ ДИЛӘР?

хикәя

Бусаганы атлап керүчеләр икесе бер кеше булып күренде: озын буйлы ябык егет артында буе-сыны бер карыш шәүлә чагылып кына китте. Гүя анда бушлык, беркем юк...

– Нихәл, улым Пётр? Кайттыңмы?

– Кайттым, мама. Әй-й... Кайттык... Икәү...

Егет, артына карамый гына, кызны капшап эзләп тапты да җайсыз гына янәшәсенә тартып китерде.

– Бу – Мәрвия, минем булачак хатыным!

– Кем-м-м?

– Мәр... Мәрвия... Без өйләнешергә уйлыйбыз.

– Кая, кая, карыйм әле ныклап! Кулбашларыңны турайтып бас. Боже, абруеңны төшереп, нинди сәләмә тотып кайттың син?! Ни исеме, ни буе, ни төсе, ни киеме! Талган канатын сөйрәгән карга кыяфәтләре бар бу карачкыда. Алгарак чык, кем...

– Татар кызы ул, Мәрвия исемле!

– Мондый сирәк исемне әйтергә телем әйләнми минем. Каян таптың бу орчыкны? Теге хатыныңның гәүдәсе шәп – симергән дуңгызныкы хәтле иде, исеме дә безнеңчә – Зоя, ат хәтле ашый, сыер кебек мышный иде. Сине санга сукмыйча, дөньяга сыймаган кебек йөргәнгә, сүзләреңне танавына да элмәгәнгә күрә генә артына типтең. Эш эшләмичә, таганда атынып ятты. Монысы – элеп киптергән балык. Вак-төяк йомышка ярап торыр, дисеңме? Синең кебек олпат ирне бәхетле итәрлекме соң ул? Сиңа кул-канат була аламы? Бу шул ашарга пешерергә дә төнге эшкә генә ярап торыр кебек. Авыз алдарга ярап торыр, дисеңме? Әллә теле дә юкмы, исәнләшә белми! Кара инде, чаука кебек авызын ачып басып тора.

– Исәнмесез, ә-ә-әни!

– Нинди әни булыйм мин сиңа, мама диген! Бүгеннән исемең – Мария! Атаңның исеме ничек?

– Сәмигулла... Әни...

Ана кеше дары кебек кабынып китте:

– Мама диген! Никакой әни! Әни дип авыз чайкап торма монда! Тамчы

да шикләнмим, керәшенгә чыкканыңны белгәнсеңдер?! Әни дисәң, азаккы исәптә, бусагадан да уздырмыйм. Дүрт малайны башлы-күзле иттем, бу эштә минем бөкрем чыккан, әнә, барысы да киң тамыр җәйде. Синең кебекләрне күрә-күрә күз күгәргән. Кабатла, син – Мария Сергеевна!

– Ничек инде?

Мәрвия Пётрга карады...

– Мин... Мин... Минем Мария буласым килми!

Мәрвия, авызын каплап, тыенкы гына елап җибәрде... Назлы гына башыңнан сыйпап, аркаңа пычак кадаганчы, күсәк белән орсалар, җиңелрәк булыр иде!

Пётр, Мәрвияне авыр хәлгә куйганын аңласа да, ваемга да алмады: буе бер карыш кызны язмышның салкын кочагына ташлады да тизрәк йортка чыгып китте. Баш калкытып маташкан вөҗдан дигән нәрсәне, әле генә таулар күчерерлек булган мәхәббәт хисләрен тиз генә кире урынына төртеп утыртты. Тс-с-с! Дәшмәгез, каерылып сүз әйтмәгез! Тиз һәм шыпырт шылыйм...

Пётрның әнисе авызыннан агу чәчкән кебек тоелды...

Мәрвия һаман елады да елады... Пётр йорттан һаман кермәде дә кермәде...

Әй, кул тимәгән кыз бала, Мария дигән ат биргәч, кинәт авызың кибеп китте... Курку катыш аптыраулы кыяфәттә чит дөньяга кереп барасың. Каршы сүз әйтә алмаслык халәттә почмактагы иконага баккансың... Беренче кат күрәсең шул! Үзең эссе далалар кичкән дәрвиш кебек сусагансың... Еш-еш сулыйсың, йөрәгең күкрәк читлегеңне ватып чыгам дип тибә... Синең хәлеңне аңлаучы юк монда, чөнки ошбу йортта син килгәннән берни дә үзгәрми. Ә менә син... Син үзгәрдең... Дөресрәге, сине үзгәрттеләр... Юк, юк, син үзең үзгәрдең... Сине беркем көчләмәде бит... Пётрның бусагасыннан үзең белеп, үзең теләп, үз акылыңда атлап кердең... Бер диңгездән икенче диңгезгә сикергәндә, бер җирең дә канамас дип уйладыңмы?

Шул мизгелдән син үз асылыңны югалттың... Кызлыгыңны югалтканчы, асылыңны югалттың! Пётр, ярты төн уртасында, почмактагы иконага карый-карый, Мәрвиянекен түгел, Марияның кызлыгын алды...

Биштәрең буш түгел иде, бала. Анда тамырларың, нәселең, динең, денең, телең, җыруларың, биюләрең, шигырьләрең, тарихың, иманың, моңың, кендек каны тамган җирең, кавемең, дәрәҗәң һәм инсан булып яшәр өчен тагын күпме кыйммәтләр иде. Ошбу догалар умыртка сөягеңне яндырып алмадымы? Яки куыклар чыгарырлык пешермәдеме?

Дога көче иңдерелгән су эчтең, дога көче иңдерелгән тәгам авыз иттең. Әбиең ялгыз үстерсә дә, бу биштәреңә татар гаиләсенең яшәү рәвеше, тәрбия алымнары, шөгыльләрен салып җибәрде. Алар кая китте?

Әбиеңнең кәҗәсен сауганда, мөгезен тотып торган кыска буйлы, ябык Гали исемле саф күңелле малай кая адашып калды? Сөю тулы күзләре белән Гали бер елмаеп караса, ятимлек ачылары кул белән сыпырып ташлагандай була иде ләбаса... Һәр таңда сиңа болын чәчкәләре бүләк итте буе бер карыш, борын астына мыек төрткән малай. Гәүдәсе орчык кадәр малай янында үзеңне көяз сандугачтай хис иттең, Мәрвия! Яклаучың булырга тиешле ике метр буйлы Пётр кулында көзге яфрак кебек калтырап торасың әнә...

Буй-сыннарыгыз бер иде! Теләк-хыялларыгыз бер иде! Сукмакларыгыз бер иде! Кулыңны сорап өлгермәде шул Гали, артык кыюсыз булды. Кер тимәгән пакь хисләре кыюлыгын юып алгандай итте... Ә тәҗрибәле Пётр эшне кызу тотты, беркатлы ятим кыз баланы үзенә каратуы авыр булмады аңа...

Алга китеп булса да әйтим, ни кызганыч, файдасы булмады төс үзгәртүнең, асыл югалтуның, кулы-кулга йокмыйча тырышуның... Саф кыз килеш хатын аерган кешегә кияүгә чыгуның. Алар көенә биесә дә, яратмадылар Мәрвия-Машаны.

Кем кулында уенчык син, кыз бала?! Нигә син очып-очып түгел, ә арка бөгеп, алпан-тилпән йөрисең? Аннан-моннан бәхет тажы өзгәләп...

Мулла кушкан исемең гомер буе җил булып чорналып йөрде... Көчкә атлап йөргән әбиең өчен һәм гомере буе яшерен сөю белән янган Гали өчен син Мәрвия булып калдың...

– Алланың һәр бирмеш көнендә толымыма уралма сана, җил, койрык булып та тагылма, акырып та елама! Мария мин, Мария Сергеевна... Пётр Пермь өлкәсеннән килгән Мәрвияне түгел, Марияны ярата...

Яшьләр якындагы шәһәргә урнашырга уйладылар. Ике кулны ике кесәгә тыгып, сапсыз чемоданга ике пар чалбар салып чыгып киттеләр. Тишекле сеткада ярты ипи, ун күкәй, кечкенә банкада кәҗә сөте.

– Мин сезгә бөтен әйберне биреп чыгардым...

Тормышны юктан башладылар...

Туган тиешле кешеләргә өч төнгә генә сыйдылар. Зина түтәй:

– Оланнар, күреп торасыз, миңа күптән кеше аягы басканы юк, ялгызак мин, боже! Кеше белән тора алмыйм икән, күзне йомганчы дилбегәне бирәсем килми! Торак эзләгез инде сез! Гомер бакый ялгыз гомер иткән карчыкка чит-ятның көен көйләү авыр. Маша бөтен эшне кырып эшли, кулы теләсә кайсы эшкә ятып тора, ләкин мин үземчә каркылдыйм. Аңардан соң тагын бер кат юып алам. Лакированный өстәлемдә бармак эзләрегез калган, бармак эзләрен төкерек белән ышкып бетереп китегез. Юарга су бирмим, су кыйммәт хәзер...

Кыш уртасында кем безне кунарга кертер икән дип, сукбайлар кебек йөрделәр. Тәмам караңгы төшкәч кенә, чираттагы тәрәзәне чиерттеләр. Изге сәгатькә эләксә, башларын ястыкка төрттеләр, эләкмәсә, арырак атладылар. Ике аягыбызның берсен дә атламабыз дигән тупсага да орынырга туры килде. Кемнең генә тәрәзәсенә шакымадылар алар, кулларында гел шул сапсыз чемодан булыр иде үзләренең...

Кышлакта яшәргә дә риза дип йөргән бер вакытта тулай торак бүлмәсе алуга ирештеләр... Бәхетләренең иге-чиге булмады. Дөнья гел елмаеп-көлеп карый төсле тоелды... Чемодан өстенә чиратлап утырып, килькадан пешергән аш ашадылар, шикәрсез чәй эчтеләр. Авылга киткәндә, кечкенә тартма хәтле генә буш туңдыргычны сүндереп калдыралар иде: анда барыбер ризык юк...

Һәр атна ахырында корсагы борынына тигән килен авылда, көл сибә-сибә, каткан идәнне юды, урын-җирне тазарттты, чүп җыйды, терлек асты чистартты, бакча казыды, печән чапты, утын кисте, бүкән ярды, су ташыды, бозлы бәкедә кер чайкады. Уфалланы Мәрвия алдан тартты, Пётр арттан төртте...

– Каенатаңның кулыннан чалгысын ал – печән чап, көрәген ал – бакча казы, балтасын ал – утын яр, сәнәген ал – салам өй, пычкысын ал – утын кис!

Игезәкләр туачак, диделәр... Пётр шатланып бетә алмый: берьюлы ике малай йөгереп йөрсен әле йортында...

Язгы суык ял иртәсендә тулгак уятты Мәрвияне. Кичтән этисе белән яхшы гына салган, дию йокысы белән йоклаган Пётр башы чатнап ярылган көенчә уянып китте.

– Мама, Машук чирли башлаган, нишләргә инде?

– Бар, икеле-микеле сөйләп торма, Зубр исемле атны җик, ул ат үзе юлны белә! Күперне чыккач та, теге як ярда ук бүлнис урнашкан! Кантурга барып, врачның өенә шалтыратам хәзер, ял көне булса да, бүлнискә килсен, сезне каршы алсын! Тирә-якка бер врач!

«Тапкан инде бала табар вакыт! Чөй өстенә тукмак!» – диеп сукрана-сукрана, хатынны күрше авылның кечкенә хастаханәсенә илтергә китте Пётр. Ат җиккән вакытта тамагын чылатып алырга да өлгерде, башын артка борып-борып косты. Моны күреп торган Мәрвия дә укшырга тотынды, тау кадәр корсагының асты өскә әйләнде...

Биш чакрым араны йөз ел үткән кебек тоелды хатынга. Әллә ат поезд вагоны кебек өстерәлеп барды инде? Тулгак ачысына иренең арбаны дер селкетеп укшуы, кикереп-какырып баруы да өстәлде. Әллә үлемем шул микән?!

Киерелеп ачылган борынга, ниһаять, су исе, елга исе, яңа кузгалган иләмсез калын бозлар исе килеп бәрелде... Үпкәсен тутырып сулады хатын. Инде менә якын офыкта соры хастаханәнең каралган шифер түбәсе күренде...

– Тизрәк, тизрәк, бахбай Зубр! Дөм караңгыда да адашмый диделәр сине!

Хатын дилбегәне үз кулына алып селтәнгәндәй итте, ләкин чалгы белән кисеп еккандай сыгылып төште...

– Петя! Булыш миңа, Пет-я-я-я! Тизрәк!

Әй адәми зат, Раббыбызга ярдәм сорап мөрәҗәгать ит! Аллаһыга таян! Әбиеңә хәлеңне белгерт, намаз карчыгының догалары кабул булучан!

Бер бәхетсез, гел бәхетсез дигәндәй, инде менә килеп җиттек дигәндә, ир белән хатынны коточкыч хәл аяктан екты, хәтта Зубрны сагаеп калырлык итте. Күпер култыксасына кунган чыпчык ук кебек атылып атның күзенә туп-туры килеп керде. Күпергә керергә җыенган ат, куркып, читкә сикерде. Шул мизгелдә күпер ямьсез тавышлар чыгарып җимерелде, бозлар белән кочаклашып йөзеп тә китте. Кул сузымы ара кала!

– Ах-х-х!

– Рәхмәт, кошчык, ничә җанны әҗәлдән коткарып калдың!

Ат, ялларын җилкетеп, Пётр белән Мәрвиядән гафу үтенде: тояк астында чыпчыкның җансыз гәүдәсе аунап ята иде...

Инде Мәрвия үзен түгел, чыпчыкны кызганып елап җибәрде.

– Нишлибез? Аяз күктән яңгыр көтеп ятып булмый, аргы якка чыгарга кирәк!

Пётр авызында ботка пешерде. Ә, юк, дөньядагы әшәке сүзне әйтеп иске күперне, корсагы җиргә тигән Мәрвияне, дөньяга аваз салырга ашыккан сабыйларны, үлгән чыпчыкны тирги иде. Теге як ярга врач йөгереп килгән, әнә, Мәрвияне чакырып кул изи, корсагына ишарәли. Янәсе, корсагың

аска ук төшкән, хәзер табасың! Бик авыр хәлгә дучар ителгәнсең, ничек тә булса бу якка чык! Көймә яки сал фәлән юк, йөзеп чык! Пётр ат булсын – җилкәсенә атландырсын, Пётр көймә булсын – аркасына утыртсын! Аркан белән тарттырсын яки җилкәсе белән ышыкласын!

– Хатыныңның кулыннан ныклап тот, төенчеген үзең күтәр! Монда су чыпчык тезеннән түгел, тирән! Хатыныңның чыдар әмәле калмаган, тиз булыгыз!

Пётр миннән булмый дип баш селкеде, нишлим дигән сораулы кыяфәте белән ары-бире чабулап йөргән врачка акаеп карады. Ул арада чырае качкан Мәрвиянең итәгенә саркып чыгарлык итеп суы китте. Хатын кычкырып җибәрде дә җиргә чүкте. Куркудан авып ук китте.

Теге як ярдан врач ярылып акыра, бу якта тулгак ачысыннан – Мәрвия. Авыр хәлдә калган Пётр нишләргә дә белми аптырап калды: анда барып басты, монда килеп сөялде. Үзе ярдан ары китмәде...

– Боже, бу тормышта адәм ышанмаслык, тиз генә ерып чыга алмаслык хәлләр дә була икән! Фәләнен фәлән итим!

Хәтсез вакыт үтте. Җан алып, җан биреп торган Мәрвия, гамендә дә булмаган кебек басып торган Пётрга карап торды-торды да берүзе суга кереп китте. Җан тырмашып, төенчеген авызына капты, аяк астыннан алып, ике кулына ике кәкре таяк тотты. Каршы яктан врач суга керде:

– Ярдәмеңнән ташлама, бер Аллаһым!

– Боже, Маша, боже!

Алдан су ерып, Пётр барырга яки, хатынның артыннан тотып, суга керергә тиеш иде... Ә ул яр буенда басып калды... Җаны юктыр аның! Исең китмәсен, хатын, мондый гамәле беренче генә түгел, Мәрвияне Марияга әйләндергән көнне дә бернинди гамәл кылмыйча чыгып качкан иде ләбаса. Менә бүген дә эх тә димичә өч язмышны җил кочагына ташлады, асты өскә килгән дөньясын җайларга тырышмады.

Ошбу гамәле белән җанны тирән җәрәхәтләде. Мәрвия белән Пётр арасында икенче тапкыр ватып булмаслык дивар үсте, бавырына боз урнашты... Эремәс ул боз, эремәс...

Билдән су ерып барган Мәрвияне теге як ярдан врач тартып чыгара алмыйча йөдәп бетте, чөнки гөжләп аккан ташу икесен бергә кочагына алмакчы булып котырды.

– А-а-а, коткарыгыз!

Үтеп баручы сирәк сакаллы карт чыбыркы ташламаган булса, бәлки, икәү бергә су төбенә китәрләр иде. Җиргә аяклары тиюгә, ерак булмаган бүлнискә җитәкләшеп киттеләр: Мәрвия егылмас өчен врачка чытырдатып ябышты. Хатынның да, врачның да аяклары атламас булып калтырый, өсләреннән боз кебек салкын су ага. Мәрвиянең үзәге өзелеп, биле авырта. Олы корсагы җирдән ышкылып барган, балалары берәм-берәм бот арасыннан төшеп калган кебек тоелды... Чабуын җыйнабрак тотты, төшсәләр, күлмәк чабуына төшсеннәр, бозлы җиргә түгел...

– А-а-а!

Алай да хатын, көче җитеп, теге ярга борылып карады: кәттә киенгән Пётр дыңгычлап тутырган йомшак печәнгә чумып утырган, елмаеп китеп бара иде...

– Боже, җен алгыры хатын, тәки язгы ташу суларын ялгыз кичте. Бусы

да, врач та батып үлмәделәр, агып китмәделәр, боже! Коточкыч ташуны ефәк юлын кичкән кебек кичтеләр! Вәт хатын! Вәт врач!

Шул мизгелдән хатынның күкрәгенә тагын бер кат тау кадәр үпкә утырды, үпкә зур төен булып оешты. Янәшә атлаган врач та, ярдәм кирәксә, булышырмын дип ияреп барган сирәк сакаллы карт та хатынның күкрәгендәге төерен йотканын ишеттеләр бугай, җайсыз гына тамак кырып куйдылар...

Йөрәкне канатып, күзенә генә карап торган Гали исенә килеп төште... Үзенең суга кереп барган ярты сынын да күзаллады хатын... Гали Мәрвияне күтәреп чыгар иде... Мәрвиянең бармак очын да бозлы суга тидермәс иде, «шалкан бәясе торган» Гали...

Җир читеннән килеп, чит дин кешесенә кияүгә чыгуына үкенеп тә куйды бугай. Юк, юк, тәүбә, тәүбә, ни сөйлим мин, тфү, пар малайлар алып кайтсын әле, Пётр кулларында гына күтәреп йөртер... Өчесен дә... Аракы шаукымы гына комачаулады бүген...

Бүлнис ишегеннән керүгә врач хатынның өстен салдырды, кып-кызыл куллары калтыраган килеш, калай кружканы тутырып, спирт салды:

– Эч шул спиртны! – диде, шәрран ярып врач.

– М-м-м... Юк, юк! Мин аракы эчмим!

– Эч диләр сиңа! Эчмим дип барабан сукма! Эчәргәме-юкмы дип җирәбә саласы юк! Эч! Спирт эчеңдәге салкынны куып чыгара. Каты өшегәнсең, салкын җелегеңне куырган. Терелә алмыйсың, үзең дә җан тәслим кыласың, балаларны да үтерәсең!

Врач, башын селки-селки, катлы-катлы итеп сүгенде...

– Мин дә өшедем, шакырдап каттым! Ләкин мин эчмим, миңа сине игә китерергә кирәк! Башым белән җавап бирәм ләбаса! Питләгә менимме?!

Тирә-якка бердәнбер врач! Ул сүгенә белә икән... Ләкин сүгенгән вакытта да йөзе кояш кебек якты, күңеле шыр ачык үзенең...

Эчте Мәрвия... Гомеренә авызына алмаган нәрсә булса да, калай кружка төбенә хәтле төшеп, йөзен дә чытмыйча эчеп бетерде. Бер мизгелдән коточкыч ташу да, ыржайган Пётр да, өзгәләнеп чапкан кояш йөзле врач та, ыгы-зыгы да эреп юкка чыктылар...

– Тәүлек ярым йокладың, тор, Мәрвия, тау хәтле корсагың белән җәйрәп ятма!

Врач тагын бәйнә-бәйнә нидер сөйләде...

– Хәлеңне бәяләп бетермисең! Йөрәгең уйный әле монда, учтан сикереп чыга, минутына – 146 тапкыр тибә!

Спирт эчкән хатын, исереп, тәүлек ярым йоклаган икән. Эчендәге балаларның тереме-юкмы икәнен дә белмичә! Бер сүз белән әйткәндә, йөзендә кан әсәре калмаган, битләре, иреннәре шешенгән, корсагында үле тынлык, әз генә дә җан әсәре сизелми...

– Ай Аллаһым, балаларым, нигә селкенмисез сез, нигә тибенмисез? Әллә сез дә исерекме? Бил тиңентен бозлы суны кичкәндә әллә үлдегезме? Әллә минем кебек аяктан егылдыгызмы?

Йөрәге атылып чыгардай булып типкән Мәрвия еларга тотынды. Аңа тулгак яңарта торган укол кададылар.

– Аналыгыңдагы суың ташу суларына кушылып агып беткән, аналыгың коры килеш балалар табасың, авыр булыр!

– А-а-а!

– Дөрес көчән, алар икәү, берсе икенчесен кыскан... Берсенең кендеге муенына чорналган!

Мәрвия җан ачысы белән кычкырып җибәрде:

– Әбием, догада тор! А-а-а!

...Ике зәңгәр түмгәкнең берсе сулый, берсе суламый иде. Җеп бөртеге дә калмый тирләгән врач Евгений Сергеевич җан-фәрманга йөгерде. «Үле зәңгәр түмгәк» янында әвәрә килде дә, өмет булмагач, кырыйгарак алып куйды. Әҗәл белән тартышкан Мәрвияне аңга китерергә кереште.

– Әй син хатын, сула, язгы ташулар кичкән хатын мондый гына авыртудан үләргә тиеш түгел! Бүрек эчендә үсмәгәнсеңдер! Сула димен, күзләреңне ач!

Врач Евгений Сергеевич шәфкать туташларын да мәш китерде:

– Гадәттән тыш хәл! Гакылдан сабам хәзер сезнең белән! Әйләнгәләп йөрмәгез, уколны туры йөрәккә бәрегез! Давай, Мәрвия, йөрәк парәм, давай, уян! Әйткән иде диярсең, үлсәң, җелегемне суыралар минем!

Сабыйларның сулый торганы гөр килеп елап җибәрде. Шул тавышка гүр газабын кичкән Мәрвия күзләрен ачты. Зәңгәр иреннәрен селкетеп, хәлсез тавыш белән:

– Пётр, Пётр, малай туды...

Хатын саташа иде...

– Күзләреңне ачтыңмы, Мәрвия! Авызыңны ачып сула! Битләреңә алсу төс кунмый һаман, кислород җитмидер. Ну, куркытып та куйдың! Җәһәннәм аша уздың бит! Өч гомер өчен җавап бирергә туры килә иде! Малай түгел, ике кыз, бик матур кызлар туды! Берсе...

– Кыз?

Мәрвия елмаерга теләгән иде, авызы чалшаеп китте.

– Икенчесе малайдыр бит?

– Юк. Икенче кызың авыр хәлдә. Аналыкта ике тәүлек сусыз торганнар бит оланнар.

Дилбегәне бушаткан врач шелтәле караш белән Мәрвиягә карады...

– Пётр ике малай дип хыялланган иде...

– Ә-ә-ә, җан кердеме әзрәк, исән калганыгызга шатлан! Өч җеназа укыйсы була иде! Җир куенына керә яздыгыз бит! Пётр да Пётр дисең һаман! Малайга тагын килерсез, юлы ачылды! Әмәлен табарсыз!

– Сез, Евгений Сергеевич, врач кына түгел, изге җан!

Икенче «зәңгәр түмгәк» тә күзләрен ача, ләкин гомерлеккә гарип булып кала...

Нәкъ шул сәгатьтә Мәрвиянең әбисе – бердәнбер якын кешесе – бакыйлыкка күчә. Үз җанын туасы оныкларына бирә диярсең! Ястүдән соң...

Өчәү бүлнистән тернәкләнеп чыкканда, яңа агач күпер салынган, җир кабара башлаган, җылы яктан кошлар кайткан иде. Үзен коткарган врачка гына рәхмәт әйтә, кадер-хөрмәт күрсәтә алмады Мәрвия: язгы ташуда өч гомерне коткарганда нык салкын тидергән врач Евгений Сергеевич, кала бүлнисендә дә рәткә килә алмыйча, мәңгелеккә күзләрен йомган иде. Үпкәләрен суык куырган килеш тагын ике тәүлек өч гомер өчен көрәште

бит! И-и-и-х! Гиппократ анты биргән чын врач башкача булдыра алмый ла ул! Булдыра алмый!

Кабыгына сыя алмыйча йөргән Пётр ат арбасындагы кызларга әйләнеп тә карамады...

– Миңа малайлар кирәк иде! Кызлар икәнен белсәм, ике аягымның берсен дә атламый идем...

– Ни сөйлисең син, Пётр?

– Сиңа әбиеңнән телеграмма килгән иде...

Пётр, җан биздергеч караш белән карап, бөкләнеп беткән кәгазь кисәген арбадагы печән өстенә ыргытты.

– А-а-а, әбием үлгән бит, әбием! Ул бит мине тәрәзә төбендә үсеп утырган тамчы гөлгә охшата иде! Син үзең тамчы гөл, әбием! Кая, кара әле, Пётр, телеграмма бер ай элек килгән бит!

Мәрвия кәгазьне тотып, Пётрның каршысында селкеде.

– Нигә, язгы ташуларны кичеп, миңа телеграмманы китереп китмәдең? Әбием үлгән минутта оныклары туган! А-а-а!

Шулай көннәр, айлар үтте. Гарип кыз Катерина сөйләшмәде, үрмәләмәде, ашамады, күрмәде, ишетмәде. Врач хөрмәтенә Евгения исеме кушылган икенче кыз (пәрдә белән туган) вакытында тәпи китте, туктаусыз тәтелдәде, чырык-чырык көлде...

Пётр иртән чыгып китә, төн җитеп, ай чыккач кына кайта. Дилбегә тотучымы соң Пётр, әллә янда гына утырып баручы булдымы?

Хәзер алар авылга әле ул вакытта беркемдә дә булмаган, нәчәлникләр генә йөри торган бишекле мотоциклда кайталар.

– Әштер-өштер генә ясалган чирле баланы, авылга алып кайтып, кеше күзенә күрсәтеп йөрмәгез. Кеше инәне бүрәнә итеп сөйли. Икмәк йөзен күрмим, затлы нәселле җитәкче кешегә чирле бала белән йөрү килешми! Поты бер тиен андый баланың! Безнең нәселдә кучән башлар юк, сезнең ыру пыскак яңгыр кебек ярты-йорты бугай! – диде күзен дә йоммыйча каенана...

Пычаксыз суйды, үз оныгын рисвай итте...

Каенана төрле сабаклар биреп, Мәрвиянең бавырына төшсә дә, авылдашы Лев Илларионовичның (Мәскәү врачы) адресын Мәрвиягә тоттырды:

– Теге чирләшкә нәрсәгезне Мәскәүгә алып барып кара! «Анда аны иләк аша үткәрәләр», – диде Лев Илларионович. Рәтләнерлек булмаса, җир өстеннән себереп түгегез... Саварга сөте, йолкырга йоны булмаган хатыннан нинди исән бала тусын инде?! Сазаган кыз булып калсаң, җир йөзендә бер имгәккә кимрәк булыр иде! Зина түтәй заман ахыры җиткән диде! Мондый чирле балалар заман ахырында гына туа, боже!

Бу сүзләргә үпкәләргәме, сүз хуҗасын каргаргамы, чәч йолкып еларгамы, кулга элмәк алыргамы, ике баланы ике кулга, төенчекне авызга кабып, билгесезлеккә, әбисе үлгәч, ишегенә йозак салынган, яртылаш җиргә чумган туган нигезенә чыгып китәргәме?!

Пётр эштән кайткач, аңа туйганчы елап, эчен бушатты...

– Әйдә, Пётр, Катеринаны Мәскәүгә алып барыйк, бәлки, файдасы булыр, чыннан да...

– Ярар, саескан шикелле кабатлап торма! Әйдә, барыйк. Поезд тәүлек ярым бара. Вокзалдан билет алырмын. Акча бир.

– Миндә нинди акча булсын инде, мин өйдә утырам лабаса. Эш хакыңны өйгә алып кайтмыйсың, ипи-тозлык кына бирәсең. Кичә дә күрше хатыннан сөт алып чыктым оланнарга. Акча синең кулда, Пётр...

Ир, салкын канлылык саклап, авыз эчендә ботка пешерде...

– Җан көеге булып, балавыз сыгып утырма, берәр нәрсә уйлап табарбыз. Пермьгә барып, әбиеңнең йортын сатып кайт. Бер саплам җеп тә биргәне булмады. Түшәк астында пенсиясе дә калгандыр, ил өстендә көн күрмәде бит...

Җан өшеткеч сүзләрдән соң ничек гомер итәргә?

Шулай... Ир белән хатын арасында күзгә күренми торган диварлар үсә торды...

– Син зур урында эшлисең, акчаң бар. Евгенияне мамаларга кайтарып калдырыйк. Тәүлек ярым поездда бер бала белән дә бик авыр булачак.

– Ярар... Акча бирәм, ләкин кайтарып бирү шарты белән. Юк-барга сарыф итмә, ашханәдә ашап йөрмә, юлга ипи белән суган, йомырка ал. Оланга шешәдә су ал! Поездда чәй кыйммәт. Пермьгә барып, әбиең йортын саткач, кайтарып бирерсең...

Евгенияне мамаларында калдырып торырга киткән Пётр икенче көнне иртүк Евгения белән кире килеп җитте:

– Мама алып калмады: «Евгенияне үзегез белән Мәскәүгә алып барыгыз, минем аны карарга рәтем юк, – диде. – Без дә җәннәт түрендә яшәмибез», – диде...

Ниндидер гаебе булса, Пётр янга карап сөйләшә иде...

– Хе... Ярар инде, алай булгач. Синең белән икәү баргач, әйбәт әле, берсен – син, берсен мин карармын.

Сөйләнә-сөйләнә ишеккә талпынган Пётр, тагын янга карап:

– Машук, мин дә Мәскәүгә барырга кыҗрап тормыйм. Эштән дә җибәрмәсләр. Мин бит ирекле кош түгел! Үзең генә бар ике бала белән!

– Ничек инде?! Мин ничек итеп үзем генә ике сабый белән ерак юлга чыгып китим? Берсе гел чаба, берсе гел ыңгырашып ята.

Мәрвия озак кына зиһенен туплый алмыйча торды... Тегенең үз сүзе сүз...

– Ана кеше карарга тиеш, диде мама. Үзе тапкан үзе баксын, диде... Калганнар карый бит әле. Икебезгә кыйбатка төшә. Бу айда драп пәлтә сатып аласы бар. Карт кеше җилгә сүз сөйләми ул...

Җепнең очы күренми... И Аллаһым, бир сабырлык!

– Юк, юк, мин үзем генә ерак юлга ничек чыгып китим?

– Син турсаеп торма! Сүзне зурга җибәрмә! Язгы ерганакларны ерып чыккан җен хатын Мәскәүне генә гизеп кайтырсың! Биергә өйрәнгәндә егылсаң да ярый...

– Егылганда торгызучы булса, тулы бәхет лә ул... Ә җиде ямаулы сыңар канат белән җилкәнеңне киерә алмыйсың! Гомер буе җиңел якка ятып йөзәсең инде син! Өй почмагына ут капса да, кайгырмыйсың!

Китте Мәрвия-Машук. Мең газаплар белән Мәскәүләрдә йөреп кайтты. Бер роман язарлык юл булды ул. Ләкин китапка кертелми торган, искә-акылга килмәгән өзекләр дә була икән! Була икән шул...

Барса, исе китте: Катерина кебек чирле балалар белән кала хастаханәләре тулган! Инә төртер урын юк! Гыйбрәт аласың килсә, кала больнисенә бар икән!

Әнә чиратта как сөяккә калган бер хатын балалар арбасындагы баласын ак җәймә белән томалап куйган.

– Нигә баланы томалап торасың?

– Кеше куркып китәр димен. Менә, кара, алайса!

Хатын ишарә бармак белән җәймә читен күтәреп күрсәтте: дүрт яшьлек баланың теле тезенә хәтле салынып төшкән...

– Йа Аллаһым, күрсәтмә!

– Җир упсын, әгәр алдасам, әле һаман теле үсә...

Әнә чираттагы икенче хатын инәдән җепкә киендергән биш яшьлек кызының ыштан төбенә ак чүпрәк бөкләп тутыра, сәгать саен ыштанын алыштырып тора...

– Биш яшьлек кызымның күреме башланды...

– Йа Аллаһым, күрсәтмә!

Халык бар да чиратта... Акча юк, ризык юк, дару юк, кием юк заманнар. Өмет шәме сүнеп бетмәгәннәр килгәннәр...

– Юлым хата вә сынаулардан торса да, мондый ачы сынаулар читләтеп үтәр дип уйладым... Ереваннан килдем, касә хәтле кара күзле ике багалмадай баланы күрәсеңме, алар – минекеләр. Икесендә дә шикәр чире, икесе дә инсулин кадап торалар. Шикәр чире берсенең күзләрен бетерде, берсенең – бөерләрен... Җир упсын, берсе күрми, берсе йөри алмый...

– Йа Аллаһым, күрсәтмә!

– Эшем җимерелеп уңды, шәригатьчә яшәүче кешене очраттым. Хозурланып яши башладык. Озак уйлап тормыйча илле ике яшемдә бала таптым. Брачлар, бүлнистә калдыр, бу бала түгел, бу – могҗиза диделәр, калдырмадым. Дога кылып, намаз укый торган хак мөселман ирем итек табанына да торырлык түгел икән! Таң сызылганда чемоданын җыйды да йомыркадан җөй эзли-эзли чыгып тайды. Киткән җирендә таш булып батты тәмуг кисәве. Орлыктан кибәкне аера белмәгәнмен. Өйсәң – ишелә, тотсаң – тишелә, тартсаң – сүтелә! Менә, кара бу могҗизага! – диде чиратта торучы ап-ак чәчле хатын.

Арбасына караганда ике тапкыр зур, нәкъ бүрттергән аю хәтле бала карап ята. Үзенә өч яшь, гәүдәсе әнисенеке хәтле, шырылдап су белән тулган... Водянка димедер... Үлә дигәннәр...

– Тау менгәч, акыл керә дигән булалар бит әле... Миңа иллегә җитеп тә кермәде! Теш кайрап кына, тәртәне кире борып булмый икән!

Гомумән, кала бүлнисләренә өлкәләрдә дәвалап булмый дип исәпләнгәннәрне генә – гайре табигый хәллеләрне генә озаталар шул...

Калада үз адресына да җанны өшетерлек кыйсса ишетте болай да врачка өне кысылып кергән Мәрвия.

– Иң әүвәл шуны әйтәм: өмет юк, бер игезәк сыңары яралгы чагыннан икенчесен кысып яткан. Катеринаның гәүдәсе бар кадәренчә кала, мие сүнеп бара, балык кебек телсез булыр, авызы кыек, камыт аяклы, селәгәе гел ага. Иң яхшы дигәндә, ике-өч ел яшәр. Ләкин шигем дә зур. Нигә дисәң, һәр адәмнең гомер озынлыгы зур сорау астында, беркем дә кайчан үзен зиярәт кыласыларын белми. Кала врачлары да пәйгамбәр түгел! Очып барган шәпкә мәтәлә адәм. Җиң сызганып, үзегез карасагыз гына, бөтен авырлык үз җилкәгезгә төшә, хөкүмәт ярдәм итәрлек түгел. Тик торганда өянәге кузгалса, 4 сәдәф дару бирегез...

– Барыбер өметемне өзмим!

– Өзмәгез, апа, дөрес эшлисез! Моннан ун еллар элек өч яшьлек малайны

төн уртасында алып килделәр. Әнисе бөтен Мәскәүне кузгаткан булып чыкты. Зур урыннардан шалтыраттылар! Күрсәң, егылып та китәсең: малайның бер күзе битенә хәтле салынып төшкән, сыңар кан тамырында эленеп тора. Сирәк күренеш! Ничек алай булган дисезме, башындагы шеше кинәт үсеп киткән дә күзен бәреп чыгарган. Өметсез дип кайтарып җибәрдек. Елап утырган киленнең кулыннан явыз каенанасы баланы йолкып алган да өшкерүче әбиләргә чыгып чапкан! Ышанасызмы-юкмы, дәвалауның алтынчы көнендә күз үз урынына кереп утырган. Бер елдан соң күзе күрә башлаган! Хәзер мәктәптә «бишле»гә генә укый, ди. Бер генә фәнни китапта да өшкереп, кешене үз-үзенә ышандырып дәвалап була дигән җөмлә юк! Без, врачлар, фән кушканча эшлибез...

Поезддан каршы алучы булмады. Берсен итәгенә бәйләде, берсен аркасына бәйләп күтәрде, ике кулга дүрт сумка күтәреп кайтып керде хатын. Кайтса, исерек Пётр гырлап йоклап ята.

– Елама, солы камыры, бигрәк серкәң су күтәрми инде! Иргә тавыш күтәрергә ярамый! Малай алып кайтырсың, токымың корымас! Ачуыңны эчкә йот!

Шул сүзләре белән сөмсере коелган ир соңгы ноктаны куйды, Мәрвиянең сөяленә басты...

Гомер азагына хәтле үз аршыны белән үлчәде ир: исерде дә йоклады, исерде дә, төкердем башына дип, бар нәрсәгә кул селтәде. Үз танавыннан ары күрмәде, өтәләнеп йөрмәде...

Парлы ялгызлыкның иге-чиге күренмәсә дә, Мәрвия өчен яшәү үтә җитди төс алды: балаларны аякка бастыру! Кирәк тирәкне ега ди!

«Бәхет иренемә тиде, тамакка тимәде». Йокыны качырган мондый уйлар еш кунак как сөяккә калган Мәрвиядә... Кан йотты, үкенгән көнгә төште хатын. Сабыры төкәнгән саен, төн пәрдәсе астында ишелде елап. Беркем дә хатадан хали түгел... Пётрга күрсәтмәде елаганын...

Кылт итеп исенә төште Мәрвиянең. Нәни вакытта әнисе, кызның тән кызуын төшерәм дип, юкә чәчәге төнәтмәсе эчергән иде. Төшми дә төшми тән кызуы. Күрше хатыны әрем, кычыткан керткән. Әнисе әрем һәм кычыткан төнәтмәсе эчерергә җыенган иде, хәл эчендә ятучы әбисе почмактан авыз салды:

– Эчермә әрем суы, кычыткан суы, язмышы әрем кебек ачы, кычыткан кебек усал булыр. Томаннар аша чалымлап булмый...

Рәхмәт, Петя, син – яхшы мөгаллим, бу тормыш-ормышта үземә генә ышана алганымны шәп төшендердең. Кире кабатлыйсы юк. Тешләсәң, өз дигәнсеңдер...

Әнә биш яшьлек Евгения әтисенең эш бүлмәсен шакый – ачучы юк, ишек астыннан карап шыңшып тора – дәшүче юк...

Пётр үзе өчен генә яшәде, үз хаҗәтен генә кайгыртты. Аңа комачауламагыз. Кызы да үсеп бетте инде: хәл-әхвәлләр сорашырга соңарып бара Пётр...

Мәрвия өйдә генә түгел, эшендә дә Мария Сергеевна булды. Үз ролен шундый яхшы уйнады ки, хәтта аның татар кызы икәнлеген сирәкләр генә белде. Тел дә, гореф-гадәт тә, кием дә, яшәү рәвеше дә башкача... Мария Сергеевна... Үкчәсенә басып килгән Евгениягә дә шундый ук өлеш тиде...

Их! Яхшы китап укыган саен, нидер дөрес түгел икәнлеген аңлый ул. Үзе эшли торган китапханәдәге бөтен яхшы китапны укып чыкты инде. Чираттагы романда әйтерсең Мәрвиянең хәлләре сурәтләнгән... Автор тырышкан! Мәрвиягә генә түгел, бар адәмгә аңлашырлык, калку сурәтләгән! Укыган саен, нидер эчне пошыра...

Хак: үзем булып яшәмим мин... Калганнарга кычкырып әйтәсе килә килүен: кыйбла алыштыру бик кыйбатка төшә! Кыйбла алмаштыру аз да түгел, күп тә түгел, адәм бәхетенең бәясе икән! Дөньядагы иң зур хата кылынган, төзәтерлек түгел! Аның яртысын түгел, тулы исәп өчен чиреген генә булса да төзәтеп булмый... Кайчандыр башымда җил уйнаган... Үзеңне ничек тынычландырдың? Рәттән бәхетсезләр гаскәре, мин дә шул гаскәр вәкиле дипме? Ә бит күзеңне ачып карасаң, канатларны салындырырлык дәрәҗәдә сурәтең яман...

Сурәтне матурайтыр өчен кыл да кыймылдатмады хатын...

Үзе белде, үзе дәвам итте...

Язмыш аңа хаталарын төзәтү өчен мөмкинлек биргәләп торды. Әнә мәктәпләргә татар теле укытучылары җыялар икән, Мәрвияне шунда чакырдылар.

– Исәнмесез, укучылар, таныш булыйк, мин – Мария Сергеевна!

Мулла кушкан атың кая, олан? Телеңне кире кайтарудан башла, бәлки җуйган асылыңның җеп очы күренер...

Гадәти төн уртасы иде. Ис җыярга да өлгермәгән ир белән хатынны гаҗәпкә калдырып, Пётрның ир вә кыз туганнары килеп керделәр. Аяк киемнәрен дә салмыйча түргә уздылар, инде йокларга җыенган тәне-башы яртылаш ачык Мәрвиягә акаеп карадылар:

– Кая, Машук, күрсәт Пётрның киемнәрен! Ала каргадан хәбәр килде, аның киеме дә, рәтле ыштаны да, бәтинкәсе дә юк икән!

– О-о-о, нинди кунаклар! Исәнмесез, узыгыз, күптән килгәнегез юк иде, әйбәт булды әле. Чәй куям, ашны җылытам. Нишләп төнгә калдыгыз?

– Кием күрсәт диләр сиңа! Гомер бакый зур эштә эшләп, кияргә ыштаны булмасын инде!

Өнсез калган Мәрвия үзен тиз кулга алды. Тыныч кына шифоньерны ачты, элгечләрдәге үтүкләп элгән киемнәрне күрсәтте.

Моны күргән иң олы апасының каш-кабагы җимерелде. Ул янында терәлеп утырган Иванның беләген борып-борып чеметеп алды:

– Иван, нигә түмгәкне тау итеп, абыйның киемнәре юк диеп сөйләдең, бар икән бит!

Апалы-энеле кәҗә сөзешкән кебек бер-берсенә карап тордылар...

Менә шул көннән Мәрвия белән Пётр туганнары арасында тагын бер кат бозлы дивар калыкты, ул йөрәкне тулаем бозга әйләндерде. Мәрвиягә чит кеше келәймәсе мәңге купмаслык булып сугылды...

Пётрның энесе Иван белән бәгыре каткан Мәрвия арасыннан бер түгел, мең кара мәче үтте. Алай гына да түгел, бу нәселнең гомергә дә үзен тиң итмәгәннәрен бөтенләе белән аңлады. Сыерчыклар арасында бер чәүкә... Бетте, барысы да бетте, күперләр җимерелде! Теге күпер кебек, агып китте... Яз сулышын мәңге сизмәслек иттеләр... Зәһәр телләре белән йөрәкләрне яраладылар...

Мәрвия тыныч кына елый башлады.

– Инәдән дөя ясап йөрмәгез, боже, тапканнар проблема...

– Таман гына сезгә! Нинди озын, төз, батыр ир син, Пётр, бәясе бер тиен кечкенә генә сары чебеш алдында баш иеп торасың. Синең хатын Алланың кашка тәкәсеме әллә? Тагын бер шкафны кием белән тутыр. Җитәкче кеше матур киенергә тиеш!

– Мин хәзер матур киенәм. Язын-җәен хатын-кыз кебек шау чәчәкле күлмәк киям. Киемнәремнең исәбе-хисабы юк. Элек кием юк иде, хәзер бар бит инде. Чалбарым булмагач, чыгарылыш кичәсенә дә бара алмаган идем... Митрәйнең дә, Володяның да, Ләксәйнең (Алексей) дә юк иде. Хатынны гаепләмәгез, ул гел уңайга гына сыпырып тора...

– Хе...

– Гайбәт эзләп талган карт-коры кебек йөрмәгез... Боже... Исем китә сезгә. Урам тастымалы булмагыз инде, зыялырак тотыгыз үзегезне. Туганнар исеменә лаек булыгыз. Бу гамәлегез сезне дә, безне дә бизәми. Кыямәт купкан дип торам... Иртәгә-берсекөнгә үзәк универмагка товар кайта, астан гына бирәләр миңа...

Еллар үткәч тә, хәтер иләгеннән төшеп калмаган күренеш: кырым чирүе хәтле туганнары, кыр казлары кебек тезелешеп, ишектән чыгып баралар, үзләре елан кебек астан гына Мәрвияне чагалар:

– Шул чиләк ярым сөяктән торган хатын кисәгеннән куркып, мәҗлестә аракы эчмичә утырасың бит, адәм хуры булып яшисең! Ул әнә өшеми дә, пешми дә! Кодрәтеннән килсә, ирдән бау ишәр иде. Үзең ут авызлы булсаң да, колач салып йөзә алмадың, ләгънәт камыты кигәнсең! Нинди кисәү агачы белән учак тергездең син, кикриксез әтәч?!

Шул көннән Мәрвия урт ашамаска сүз бирде, үз иркем белән ут авызлыга әйләнәм, диде. Үз-үзенә сүз бирде...

Еллар үтте. Гәүдәсе, холкы белән Пётр абзасына охшаган Иван шактый кызның башын әйләндереп йөрде-йөрде дә, Владивостокка китеп, оя корды. Кайсын елатып, кайсын алдап калдырды, кайсы өчен үзе күз яше агызды... Кинә тотмадылар алданып калган кызлары, коры тел белән генә чикләнделәр. Ул исә тыныч кына яңа технологияләр заводына бик зур инженер булып урнашты. Бәхетнең киртәсенә керде: фатир иркен, эш яхшы, хезмәт хакы зур, ике малай үсә, матур хатын янда йөгереп йөри.

Еракларда ала карга көне-сәгате белән ялгышып та хәбәр салмады: көймәсе бер дә комга терәлмәде бугай Иванның... Барысы да яхшы...

Сирәк кайтты туган авылына. Комы коела башлаган Иван берүзе титаклады: һава торышына яраклаша алмаган чирләшкә хатынына да, бандитка әйләнеп барган ике малаена туган авылын күрсәтмәде.

Кырыкка ярылып булмый дип, Пётрлар да авылга кайтуны сирәкләткәннән-сирәкләттеләр. Туганлык җепләре өзелмәсә дә, әкрен генә нечкәрде... Исәпләсәң, исең китәр – соң дәрәҗәгә җитеп тартылды...

Инде Петяларның туган нигезе буш. Картлар артыннан иске йортка йозак эленде, бер туган да нигез яңартырга ашкынып тормады. Ир вә кыз туганнар туган нигезгә түгел, бер-берсенә кунакка кайтып йөрделәр. Сирәк... Ата-ана кире кайтмый торган җиргә киткәнче тукыдылар югыйсә...

Пётр белән Мәрвия күптән инде бер сукмактан юл сапмыйлар, янәшә генә атлыйлар. Яхшы күршеләр кебек көн итәләр.

«Еладыңмы, елмайдыңмы, гыйнвар кызы?» – дип сорамады Пётр. Әордым-бәрдем ир-ат телен, кырлы-мырлы сөйләшүне, кыңгыр карауны, сугып егуны кабул итә алмады инде Мәрвия.

Мәрвиянең янына килеп, ни өчен перчатка киеп оек бәйлисең дип сорамады. Кулларым авырткангa, Петям минем, дияр иде елмаеп хатын.

Урамнан кергәндә, ни өчен һәркөнне күзләрең кызарган була дип тә сорамады. Катеринаның каберенә барып кайттым, кызыбызны сагынам, Петям, дияр иде җылы гына.

Көне буе болында дәрвиш кебек нишләп йөрисең, күзләрең гел дымлы дип сораса, чәчәкләрне үз итәм, яз исе килә, бу болын үзе лалә чәчәгенә охшаган, синең кебек мәгърур, Петям, дияр иде сак кына.

Нигә иртүк су буйларын урыйсың дип әйтсә, йомшак таң җилләре камышларны назлый, уйнап булса да мактамыйсың, каты җилләрдән куеныңа алып ышыкламыйсың, толымыма уралмыйсың, Петям, дияр иде, бераз кызарып Мәрвия.

Учлап дару сәдәфләре йотасың дисә, йөрәккә син җитмисең, тоташ кояш булмаганга йөрәк авырта, томаннар алдакчы икән дияр иде Мәрвия.

Төн уртасында торып утырасың, айга карап сукмак чигәсең, төн ката күктә йөрмә инде дисә, ай – минем сердәшем, әйдә, без дә сөйләшик, мин үзгә түгел, мин шул ук кыз дияр иде кабат кабынырга әзер Мәрвия.

Шундый көчле җил вакытында урамда йөрисең дисә, җилләр минем танышларым, җил агае чәчләремне ефәк дулкынга әйләндерә, чуалта, аннан әкрен генә сүтә дияр иде Мәрвия.

Нигә гел, касә тотырып, салкын су эчәсең соң дисә, бер йотым су җитә миңа, сине сагынган чакларымда эчәргә дияр иде Мәрвия.

Колачыңны җәеп очасың, канатларың кага-кага, нинди инешләргә кушыласың килә дисә, миңа кушылып очсаң, болытларны кочсаң, мин бәхетле булыр идем, Петям, дияр иде Мәрвия.

Соңгы йолдыз батканчы йөрисең, ят, йокла, дисә, йолдыз яктысы күрмәсәм, имгәнәм мин, дияр иде Мәрвия.

Мондый сораулар биреп азапланмады шул Пётр...

Гомумән, Пётр серле күзләргә, йомшак сүзләргә игътибар итмичә, арты белән борылып ятар иде...

Кар кебек ак чәчле Пётр белән Мәрвия күптәннән аерым бүлмәләрдә йоклыйлар...

– Син беренче булып киттең! Читтә йөрисең, күктә очасың, айда йөзәсең! Миндә гамең юк! Әле миңа синең җылың кирәк иде. Бер чабуда өзеп төшердең!

– Юк, син бер селтәнүдә хисләрне үтердең дә теге бүлмәгә күчендең, суыкта туңган агач! Мин түгел, җан китте...

Поездда барганда, чегән хатыны бер сулышта әйткән иде Мәрвиягә: «Эшеңдә мактарлар, өеңдә таптарлар! Хатын-кыз буларак бәхетсез син, йөрәк маем!»

Кара син аны, чегән юравы туры килеп маташа бит. Ир белән хатын арасында булган наз болай да сирәк иде, хәзер бөтенләй юк. Илле яшеннән...

Берсен кумдек, берсен башлы-күзле иттек, инде үзебез өчен яшик дигәндә...

Парлы ялгызлар...

Югыйсә матур пар... Үрнәк гаилә... Тырым-тырагайга йөрмәделәр...

Кеше алдында елмаешып кына торалар... Сер бирәселәре килми...

Бик күп сулар акты... Ни өчен бер телемне бүлешеп тә, бер кешедәй булып яшәмәгәннәрен аңлый хәзер Мәрвия. Ике елга бергә кушылып ага алмый икән шул – икесенә ике сукмак кирәк! Бер үк нәрсәне ике төрле сөйләсәң, ике якка тартсаң, ике агымлы елга буласың икән! Ике төрле дөньяны бер үлчәм белән үлчәп буламы инде, йә?

Ике дөнья, ике сулыш, ике омтылыш, ике хыял, ике максат, ике яшәеш, ике күңел, ике йөрәк, ике җан, ике рух...

Мәрвия китап сүзе белән килешеп тә бетми. Катнаш никахның исәбесаны юк... Йөз ел бергә торучылар да бар, никахтан ук ташлап чыгып китүчеләр дә бар...

Китап сүзе хактыр... Хак булмаса, киштәләр артына качып, Мәрвия лышык-лышык еламас иде. Моны манзара кылган китаплар маңгайларын пуля астына куеп ант итәләр: Мәрвия күптән бәхетенә матәм тоткан...

Сирәк кайтач, кайчандыр мәйдан тоткан Иван Владивостоктан, бил бөгеп сәламләмәсәләр дә, барысында да кунак булып китә. Ул сабыр – тышаусыз тай түгел. Мәслихәт күрмәсәләр дә, кунак алдына майлы калҗа да, чәе дә, мәе дә мулдан куела. Иванның кыяфәтен күрүгә нидер була Мәрвиягә – тәртәгә кушаяклап тибә. Элеккеге кебек авызына су кабып тормый, урт чәйнәми – Петяга да, Иванга да әйтәсен әйтә:

– Көпә-көндез кисмәге белән көмешкә эчеп, башыгыз бетә бит инде, карт керәннәр!

Ирләр эндәшми – тыныч. Төгәлрәге, картлык баса барган саен ишетмәмешкә салышалар. Хатын-кызга каршы эт кебек өреп тормаслар бит инде. Дөрес, соңгы елларда алар да тел яшерми, чөнки итәк-чабуны җыю авырлашты... Тавыш-гауга – йортка, йорттан – урамга, урамнан шәһәргә чыккалый башлады...

Китапларга гына эчен бушаткан Мәрвия тормыштагы бөтен кара сызыкларны искә төшерә: беренче нәүбәттә, аны ничек кимсеткәннәрен, беркатлылыгы белән ат урынына эшләгәнен, төн уртасында өйне тикшереп, гаеп эзләп йөргәннәрен, авыру баланы яратмаганнарын, үзен Мәрвиядән Мария ясаганнарын... Бер сүз артыннан икенчесе иярә, тагын өстәлә, соңыннан көрәк белән көрәрлек була...

– Монда сине беркем биш куллап каршы алмый, көмешкә чөмерергә генә кайтасың. Күчтәнәчкә бит сабыны да тотып кайта белмисең... Үзең дә, мамаң да, Пётр да мине күпме елаттыгыз! Ишек ачык, юл такыр!

Иван кайткан саен бу тавыш. Ияге танавыннан биек Иван Владивостоктагы бай фатиры белән мактана: имеш, бай! Мәрвия дүрт бүлмәле өе, бакчасы, җире, ризык тулы базы, мунчасы белән мактана. Икәү дөньяларга сыймыйлар... Ике тиенлек сүзләр югыйсә...

– Әле миңа ясин чыкмадыгызмы? Каф тавы артында булсагыз да, кайтам – кан тарта! Абый белән кендекләребез ябышкан, без бит бер карында яткан, бер телемне бүлешеп үскән кардәшләр! Әлмисактан туган хакы олы! – дияр иде капкадан ук Иван.

– Юк әле, кырып-себереп түкмәдек. Кул сузымы ара булмаса да, кайтасың да төшәсең, кайтасың да киләсең! Владивостоктан тычкан күзенә сибәрлек конфет алып кайтсаң, ни була? Аракы төяп кайттыңмы? Мәтәлчек атып эчә-эчә, хатыныңны гүргә илтеп тыктың инде, хәзер минем үлгәнне көтәсезме? Малайларың азып-тузып йөри!

Шулай йомшак кына урынына утырта мактанчык Иванны каш-күз җимергән Мәрвия.

Өч көн дәвам итә бу тавыш, чөнки төгәл өч көн Иван монда кунак була. Аннары тавыш капыл туктый. Ызандашлар кизү тора – колакларын ике-өч көнгә тасрайтканнар. Әнә йон батыр кунак буш биштәрен аскан, койрыгын сыртка салган, урыс капкасыннан чыгып бара...

– Ярар, башка кайтмамын! Туганлык келәймәсе сугылмаган булса, талчыбыктай берегеп үсмәгән булсак, аяк та басмас идем. Йомышың төшмәсен лә...

– Кирәгең бер тиен! Буш бугаз кебек борын чөереп йөрмә! Килгән юлың тап-такыр! Үкчәңне майла! Гарык!

– Кайт, туганым Иван, син – минем өчен иң кадерле кеше, минем тиле хатын сүзенә карап йөрмә! Телен кыскартырмын мин аның! Соңгы елларда җәһәт тел кашырга махирланып китте... Мыскалга салынмаган ефәк кебек кыз Мәрвия кыяр карачкысына әйләнде! Кул-аягын бәйләп илтеп ыргыта алмыйм бит! Теге еллардагы ачуыннан арына алмый бугай ул. Менә бөтен нокта да шунда! Башмак җылысы да калмады аңарда... Суынды тәмам...

– Бүген – өем, иртәгә – гүрем...

– Выжт!

– Кулны йөрәккә куеп әйтәм, Маша, Иван кайткач, өч көнгә кая да булса олак! Мигә кадак каккан шикелле чукып торасың! Узасы узган, тычканы тузган бит инде! Евгения мичкә бәрәңге булса да тәгәрәтер, тамакны тук итәр...

Ел саен бер театр, ел саен бер сәхнә, бер үк артистлар, бер үк рольләр, бер үк грим...

Урам чатыннан Иванның шәүләсе күренүгә үк халык бушлай тамаша карарга әзерләнә: кемгә – бәлеш, кемгә – шеш... Хәтта мич башында кабырга җылытып ятучы Зиннәт тә йорт себергән булып өеннән чыга...

...Ә быел тыныч. Гадәт буенча ачыла торган пәрдә ачылмады. Югары мөнбәрдән нотыклар сөйләнмәде, гайрәткайтаргыч гаепләү актлары укылмады... Берсен-берсе галәм рисвае итмәделәр...

Ни булган соң?

Ни хәл бу?

Ни булсын...

Йөз чөереп йөргән Иван каты авырып киткән. Хәлләре мөшкел икән. Тиздән үләсең дигән сүз ука белән чигелгән...

Йөгәнне каты тоткан Мәрвия дә каты авырып киткән. Күп калмаган икән.

– Уңсам – уңам, туңсам – туңам! Курку чолгап алды мине. Мәскәүгә барырга кирәк диделәр. Гомер җебемне йөз җитмеш алты меңлек операция саклап кала диделәр, Пётр. Минем китапханәче пенсиясе ипи-тозга да җитми, акча бир. Минем үләсем килми, терелтегез мине!

Пётр сүз битлеге өчен генә дәвам итте:

– Котырган акчалар түгел, бирермен. Евгения Мәскәүгә операциягә алып барыр.

Мәрвия, әзрәк сулу алгач, дәвам итәргә көч тапты:

– Әле үләм дип мөһер басмаган да, алай да сүз куертып тормыйм, әйтеп куям: үлсәм, татар зиратына әбием янына күмәрсез... Аллаһыма тапшырам! Бер тамчы вакыт калган кебек. Кулларымны тотып кара әле, куян кебек калтырыйм. Тәнем өркә... Әҗәлдән дә, синнән дә...

– Набат сукма! Үлгәч, кая ятсаң да, бер түгелме, барыбер җир астында черисе! Боже!

– Юк, Аллаһ хакы өчен Пермьгә, әбием янына күмегез!

– Күз күрер... Үлем турында алдан сөйләмә! Мәскәү коткарыр сине, кайгырма, боже!

Мәрвиянең күз аллары караңгыланып китте: теге дөньяга ничек күчәр? Аллаһ беләнме, Боже беләнме ?

Ни чәчсәң, шуны урырсың, дигәннәр борынгылар. Дөрес тә әйткәннәр икән! Кешенең бөтен бәхетсезлеге үзеннән соң догачы калдыра алмауда икән!

Күз терәп торган кызы догачы булырмы? Ләкин ул ике-өч тапкыр әтисе белән чиркәүгә барды... Ә Мәрвия... Мәрвия... Чабып барып, Пётрның кулыннан йолкып алмады бит Евгенияне... Капка төбенә чыгып озатып кала иде...

– Мин сезнеке түгел, мин әтинеке...

Кемгә үпкәлисең – оясында ни күрсә, очканда шул булыр!

Мәчеткә кергәндә дә яулык бәйләмәде Евгения. Евгения Май чабулар, Нардуган, Кырау куулар, Яфрак бәйрәме, Покрау күреп үсте. Анда да йолаларның асылына төшеп түгел, өстән-өстән генә карап. Ярар, аларны белсен, Пётр үз бурычын үтәгән, ә син үзеңнең вазифаңны үтәдеңме, Мәрвия?! Гаетеңне, уразаңны, корбаныңны, намазыңны, хаҗыңны, зикереңне, тәсбихеңне күрсәттеңме, ана?

Евгениягә Покрау да, Корбан да кирәк түгел!

Билгесез рухлы буын... Адашкан буын... Югалган буын... Кыйбласыз буын... Бер якны да мәгъкуль күрми хәзерге буын! Ни уңга, ни сулга! Ә бит нинди зур байлыктан мәхрүм калып баралар чит сыбызгыга биегән балалар! Ата-ана, әби-баба сүзен сукыр бер тиенгә дә куймыйлар... Әйтә башласаң, сүзне читкә боралар, мең сылтау табалар, сыртларын бирмиләр, үлчәүгә сыймаслык кыланалар. Иманның әсәре дә булмаган буын үз телендә сөйләшеп дога кылачакмы?! Кызганыч, ләкин бу – бүгенге чор сурәте!

Бу чор сурәтен бары тик гаиләдә бишектән сеңдерелергә тиешле иман гына коткара ала! Бары тик ана сөте, гаилә җылылыгы белән бирелә торган иман гына! Бары иман гына кыйбланы турылый ала! Башка берни дә түгел! Эзләмәгез читтән коткару!

Иреннәреңне канатканчы тешлә! Разбуй сал, хатын! Миең күгәреп чыктымы, башыңны ташка ор! Син гаепле! Гаилә җылысы, рух бөтенлеге өчен ана җавап бирә! Нәсел-нәсәпсез калдың дип пышылдый сукыр сизем! Алай гына да түгел, фәлән-төгән дип фетнә кубара!

Акыл җитмәслек хәл кылдың дип фетнә куптара сукыр сизем. Мәрвия, бер кочак кыйммәтне Пётрның бусага төбендә үк коеп калдырдың! Гомумкешелек кыйммәтләренең тамырлары йөрәгеңә бер дә берекмәгән

идеме соң?! Ничек бер мизгелдә аларны югалта алдың? Нигә әйдәп баручы бу көчләр адәм баласын хаталардан саклап кала алмыйлар икән? Алай гына да түгел, алар бит кешене кеше итеп яшәтә торган алтын бәясенә торган кыйммәтләр! Бер тапкыр бармак янадылар, син куркып калдың, мирасыңны юкка чыгардың! Газиз әбиеңнең бәддогасы куркытмады, чит әнинең бармак янавы куркыттымы?!

Көн саен иртәнге намаздан соң кырык тапкыр «әль-Фатиха» сүрәсен укы диде әбиең, укыдыңмы ул доганы, Мәрвия? Намаз, дога сүзе кайчан онытылды? Намаз укысаң, сине сырып алган начар уйлар табан шомартырлар иде. Догалар авырудан да саклар иде! Доганың көче зур аның!

Әбиеңнең ядкарь итеп калдырган көмеш беләзеген озын торыклы Евгения кызың өстәл тартмасына шудырды, беләзек урынына тату ясатты... Димәк, форсатны тәмам качырдың! Күзең ачык: шул тартмада әбиең биргән догалар да тузан җыеп ята. Әһә, турысын әйткәч, тырнакларыңа хәтле тирләдеме? Елына бер тузанын сөртеп аласың дога китаплары өстеннән...

Кылган гамәлләрен мыскалга салып үлчәгәндә, туган авылыма әнием янына күмегез дип оран салган өйдә мыштым Иван да. Нигәдер, Владивостоктагы затлы зиратта затлы чардуган астында ятам димәгән. Нигәдер аталарының малын сатып баеган ике башкисәр малайларына да гәүдәсен ышанып тапшырмаган! Нигәдер күз суын түгеп гомер иткән хатыны яныннан дә үзенә урын алып калмаган булган... Әгәр башында күзгә кырып салырлык уе булса, ул гомер иткән гаиләсеннән рухи яктан аерылмас иде, фикерләрен чуалтмас, олтыракка да ярамый торган иргә әйләнмәс иде. Уйлап карасаң, адәми зат гаиләсенә җилем белән ябыштырган кебек ябышып яшәргә тиеш. Соңгы минутта авызыңа су салучы булсын өчен! Әҗәл бугазлаганда ясин чыгар өчен! Ә ул бүген инде исеме дә калмаган авылына кайтып үләр өчен махсус машина яллаган. Анда кул күтәреп чукыныр кешеләр бар!

Эх! Түшләрен төеп, улларына әманәтен әйтер иде ата кеше! Уллары аталарының каберенә чәчәкләр утыртыр, су сибеп торырлар иде! Дини йолаларын үтәрләр иде! Димәк, гаиләдә йөрәкләрне тоташтыручы җеп замана җилендә аяусыз черегән...

Авыруны әллә кайдан ерактагы авылына кайтарыр өчен оешма йөз илле мең сораган... Килешүдә акка кара белән маршрут (А ноктасыннан Б ноктасына), вакыт язылган махсус машина – йөз илле мең сум. Ике якның да имзасы ярылып ята.

– Менә адрес. Инде череп ауган булса да, тавык алачыгы хәтле калган туган нигеземә алып кайтыгыз. Мине әтием, әнием, әбием, бабам янына күмегез. Туган нигез чакыра, валлаһи! Патша сарайларында гомер итсәң дә, череп ауган нигез, туган авыл туфрагы тарта икән! Әҗәл күкрәгемә хәтле менде инде, хәлем кыл өстендә... Заводта мине чакма ташы диләр иде, чакматаш та үлә икән! Үлем сәгатем озак булмас... Мама яткан түшәккә салыгыз, аның исе тәнемә сеңсен! Аннары чәчләремне кырыгыз. Тыныгызны да чыгармыйча, үлгәнемне көтеп торыгыз...

– Үлгәнегезне көтеп торган өчен тагын егерме алты мең түләгез.

Табан терәп тартыша алмаган, чәчәген койган булса да, фырт киенгән Иван. Килешү кәгазенә тагын егерме алты мең өстәгәннәр...

Ышанасызмы-юкмы, үләр өчен нәкъ йөз җитмеш алты мең! Акчасын түләгән, калтырый-калтырый имза салган һәм аңын югалткан инде күзләре калайлана башлаган Иван.

...Менә Пётр Иванны күмә. Озата кайткан врачның табутка иелгәндә кесәсеннән килешү кәгазе төшеп китә – калын хәрефләр белән йөз җитмеш алты мең дип язылган!

– Боже, түшәк хастасы Марияне үлемнән коткара торган операция өчен дә йөз җитмеш алты мең кирәк булды! Хәйран-вәйраннарга калдырырлык нинди хикмәт бу!

Әгәр... Әгәр бизмәнгә салып үлчәп карасаң, күрәсең: дөньяга сыеша алмаган ике бәндәгә бер төрле сумма кирәк булган... Берсенә – калыр өчен, берсенә – китәр өчен! Аллаһы каршында үлем шәүләсе эзәрлекләгән бар кеше дә тигез! Әнә, кодрәтен күрсәтү өчен бер селтәнүдә тигезләп куйган! Икесе бер сәгатьтә киттеләр! Икесенә дә өчәр аршын җир җитә! Менә ни diләр икән бизмәннәр!

Икесе дә тигез... Икесе дә тигез... Икесе дә тигез...

Күктә очканнар да, җирдә үрмәләгәннәр дә Тәңре каршында тигез! Борыныгызны күтәрмәгез, ата-ана, туган, тирә-күрше, олылар хакын хаклагыз, хәрәмгә кызыкмагыз, шәфкатьле булыгыз, нәфесегезне йөгәнләгез, тайгак юлга басмагыз, хәләл мал белән яшәгез, гамәлләрегезне Аллаһының ризалыгы өчен кылыгыз ди икән бизмәннәр...

Ни дисеннәр бизмәннәр?! И адәми зат, дөньялыкта урын вә мал бүлешмә, ничек кыл бөртексез әйбер белән килдең, шулай китәсең ошбу җирдән, диләр. Кардәш хакын, намусны, гаилә җепләрен бернинди бизмәннәргә салып үлчәп булмый! Юк андыйларны исәпләүче бизмәннәр! Туганлык хисләрен нәфес басып китә алмый! Андый үлчәү юк!

Ә намусыңны үлчи аласыңмы? Җаныңны, рухыңны, иманыңны, күңел кәгъбәңне нинди бизмәннәрдә үлчәп була?

Туган як туфрагын үлчәп буламы? Юк! Юк! Мәңге юк! Җирсеп кайткан һәр баласын куенына ала туган туфрак...

Үзебезнең ямьсезлегебездә нигә көзгене гаеплибездер диләр күрмешне күргәннәр...

Тузан бөртегедәй эзебез калмый җирдә, ә төкерек чәчә-чәчә кемнедер гаеплибез.

Пётр, Иванны күмгәндә, ярты зиратка хәтле кулларын сузып чукынды:

– Боже, Иван, боже! Боже синең белән, Ваня туганым! Синең өчен молиться буду!

Пётрның ирләргә хас булмаганча илереп елаган тавышын кызы Евгениянең тавышы басып китә:

– Папа, мама үлде!

...Шул ук көнне өйләдән соң Мәрвияне дә күмәләр. Талканы коры Пётр үзе такмаклап елый, үзе Иван белән янәшә кабергә бер уч туфрак ташлый:

– Боже, Машук, боже! Боже!

# БИКЛӘР АЧЫЛЫРГА ТИЕШ*

**(Айгөл Әхмәтгалиеваның «Бик» повестенда әхлакый-фәлсәфи катлам)**

Меңьеллык традицияләре булган татар әдәбияты талантлы каләмнәргә бай. Һәр гасыр безгә мәшһүр әдипләре белән мәгълүм. Иң фаҗигале, яшәү өчен иң авыр чорларда да әдәбият мәйданы буш тормаган. XX гасыр ахыры – XXI йөзнең беренче яртысы булган аралык та чыгарма түгел. Яңа гасыр башында татар сүз сәнгатенә үзләре яшәгән чорның сулышын, аның көнүзәк әһәмиятле проблемаларын яңгыратырга яңа буын талантлар килде. Аларның иҗаты чын мәгънәсендә татар әдәбиятына тематик-проблематик яңарыш алып керде, яңа рух өрде. Шуларның берсе – М.Кашгарый исемендәге халыкара премия лауреаты, китап сөючеләргә дистәләрчә повесть һәм хикәяләр, драма әсәрләре, лирик парчалар бүләк иткән Айгөл Әхмәтгалиева. Аның беренче әсәрләре үк укучыларда һәм тәнкыйтьтә зур кызыксыну уятты, тиз арада укучылар ихтирамын, мәхәббәтен яулады. Әсәрләрендә әдәбият өчен мәңгелек темалар күтәрелсә дә, алар сафлык, яңалык белән өретелгән. Аның каләменнән төшкән һәр әсәр көтеп алып укыла.

Айгөл Әхмәтгалиева – тирән белемле язучы. Ул тормышны, татар чынбарлыгын, аның көнкүрешен, чор вазгыятен, тарихны яхшы тоемлый. Милләтнең бишеге саналган Актаныш якларында туып-үскән язучы һәр әсәрендә туган теленең байлыгын, аның җегәрен исбатлый.

Язучы иҗаты белән танышлыгым «Синең өчен яшим», «Мин гашыйк булдым» җыентыкларында урын алган хикәя һәм повестьлардан башланды. «Бәллүр богау» повестенда автор гомере буе театрда артистка булып эшләгән Фаягөл исемле героеның хатирәләре аша шәхес культы, сугыш афәте вакыйгаларын торгыза. Бу җыентыкта дистәгә якын хикәя урын алган. Автор шушы кыска жанрда идея-тематик яктан типиклаштыру осталыгын күрсәтә. Безнең карашка, алар арасында «Төсле моң» хикәясе сыман сәнгать җәүһәре итеп эшләнгән әсәрләр урын алган. Аларда һәр сурәтләнгән деталь үтә төгәл сайланган. «Мин гашыйк булдым» җыентыгындагы повесть һәм хикәяләр яшүсмерләр өчен язылган. Мин фәкыйрегез дә әлеге әсәрләргә гашыйк булдым. Язучы адәм баласының яшүсмерлек чорында була торган психологик нечкәлекне зур осталык белән сурәтләгән. Тәҗрибәле, шомарган каләмле булсалар да, байтак язучылар яшүсмерләр, яшьләр дөньясына А.Әхмәтгалиева кебек кыю рәвештә керә алмый. Ул әлеге әсәрләренең һәрберсендә үзенең тирән белемен, яшүсмерләр тирәлегендәге яңалыклардан хәбәрдарлыгын күрсәтә. Аларның ихтыяҗларын күздә тотып, бүгенге заманга хас хәлләрне кызыклы, мавыктыргыч, гыйбрәтле сюжетка кора.

Айгөл Әхмәтгалиева иҗаты тематик-проблематик яктан көннән-көн колачлана һәм фикерләренең фәлсәфи-әхлакый, сәяси-иҗтимагый яңгырашы, сәнгатьчә тәэсире көчәя бара. «Казан утлары» журналының 2021 елның соңгы санында дөнья күргән «Бик» повесте – шуның бер дәлиле.

«Бик» повесте вакыйгаларны бәян итү ягыннан күптавышлы. Төп хикәяләүче – Галия исемле кыз. Аның белән бәйле хронология тәртибендәге сюжет сызыгы – геройның үсеш-үзгәреш тарихы. Сюжет җебен герой күңелендәге эчке каршылык сузып бара. Галия Казан университетында гуманитар юнәлештә белем ала. Грант отып, Германиянең Регенсбург

* Татарстан Республикасы Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстан Республикасында яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе тарафыннан оештырылган II әдәби бәйгедә «Әдәби тәнкыйть, рецензия» номинациясендә беренче урынга лаек булган мәкалә.

каласына килгән. Автор унтугыз яшьлек героеның холкына ярашлы булган сызыклар, детальләр белән эш итә. Галия образы гаҗәеп төгәл, ягымлы, табигый сыйфатлар белән күз алдына бастырылган ки, әйтергә кирәк, бу образга да гашыйк булдым. Автор характер тудыру, аны индивидуальләштерү осталыгын тулы көчкә күрсәткән. Аның белән бергә хыял-өметләр, ихласлык, биек омтылышлар тулы романтик яшьлек чорымда сәяхәт иттем. Кызның һәр гамәленнән, хәрәкәтләреннән, үз-үзен тотышыннан, киенү-бизәнү рәвешеннән яшьлек бөркелә. Сөйләмендә дә тормышка ашкынган яшьлек авазы. Ясалмалылык юк. Галиянең эчке дөньясы гаҗәеп бай. Җанлы хәрәкәттәге әлеге сурәт кайчандыр үз чорында татар укучысы сокланган Такташның Алсуын («Алсу» поэмасы), Г.Кутуйның Галиясен («Тапшырылмаган хатлар» повесте) хәтерләтә. Персонажның чит илдә белем эстәү вакыйгалары әсәрнең урын-вакыт (хронотоп) яңгырашын киң мәйданга чыгара. Шул сәбәпле, Галия образы ярдәмендә автор заманның үтә катлаулы проблемаларын яңгырата алган. Галия килгән уку йортында дөньяның төрле кыйтгаларыннан җыйналган студентлар белем ала. Кыз шулар белән тулай торакта яши. Әле ул яңа яшәү урынына, яңа танышларына ияләшеп кенә килә. Һәр үзгәлеккә ихластан гаҗәпләнә. Укучы аның катнашында барган хәл-әхвәлләр сурәте аша башка милләтләрнең яшәү рәвеше, холык-фигыле, менталитеты, гореф-гадәтләре белән таныша.

Автор әдәбият өчен һәрдаим актуаль булган мәңгелек фәлсәфи-әхлакый тема күтәрә. Әсәрнең идея-проблематикасы «бик» сүзенә барып тоташа. Әлеге образ-деталь төрле чор-заман проблемаларының нокта – фокусы. Ул һәр вакыйгада, һәр күренештә урын ала. Кабатланган саен аның мәгънәви вазифасы киңәя, яңа төсмерләр белән байый. Ул бер-берсеннән ерак чорларны очраштыра. Үткән-хәзерге-киләчәк чорларны бер-берсенә бәйли. Бик – төрле сыйнфый-иҗтимагый төркемнәрнең фаҗигасенә гомумиләштерелгән бәя дә. Ул дөньякүләм иҗтимагый-сәяси яңгыраш ала, гомумкешелек масштабына җиткерелә. Узган гасырның 30 еллардагы ил күләмендәге репрессияләр, бер гаепсез килеш төрмәләрдә газапланган, хаксызга юк ителгән миллионнарның язмышы, Икенче Бөтендөнья сугышы корбаннары, милли кысулар, сугышта хәбәрсез югалганнар – болар хакында хакыйкать халыктан яшерелгән. Әлеге хакыйкать бик астында. Хәзер дә әлеге бикләр ачылмаган әле.

Әсәр бикнең яшәү-көнкүрештәге вазифасына кагылышлы эпизод белән башланып китә: кыз бүлмәсен бикли. Япкач та, үзеннән-үзе бикләнә торган бикнең ачкычын алырга оныта. Ә бүлмәсендә плитәдә шулпа кайный. Кыз бүлмәгә керә алмаса, эшләр хөрти булачак. Кыз үтеп баручы бер алман егетен күреп ала да аннан ярдәм сорый. Галия әлегә алманча иркенләп сөйләшә алмый. Шулай да, Райнер исемле әлеге егет белән аңлашып, бикне ачалар. Шул рәвешле, беренче вакыйгадан ук бу деталь гомумиләштерү көчен күрсәтә. Димәк, бергә берләшеп, бикләрне ачарга була.

Әлегә кыз яңа җирдәге тормышны үтә кызыксынып күзәтә, туган илендәгесе белән чагыштыра. Яңа күргәннәренә өстенлек бирә. Чөнки монда барысы да кеше яшәеше өчен җайлаштырылган. Һәр җирдә немецларга хас төгәллек, сакчыллык, игътибарлылык, тәртип ярылып ята. Яши башлавының беренче көннәрендә үк аңа тулай торакның хаусмайстеры герр Отто футболка бирә. Адашса яисә берәр хәл-мазар килеп чыкса, шушы футболкага язылган адрес белән чакырылган таксист яшәгән урынга китереп куя икән. Кызга монда бик күп әйберләр, шул исәптән укыту системасында ирек тә нык ошый. Кием мәсьәләсендә дә гадилек, уңайлылык ягы алга чыгарыла, артык чабаланасы юк. Кызның яшәү өчен уңайлы бу илне яңача кабул итәсе, әнисе һәм Миңлегөл әбисе сөйләгәннәрне, мәктәптә тарих буенча өйрәнгәннәрне кире кагасы, үткәннәрдән качасы килә. «Ерак бабам Газизулланың, Германия белән сугыштан кайтмавын, хәбәрсез югалуын, Әхтәм бабамның әсирлеккә эләгүен сәбәп итеп, мин бу илне дошман күрергә тиешме? Хәзерге Германия белән Гитлер икесе ике төшенчә ләбаса. Артка әйләнеп карау кирәкме? Йозакка биклә дә куй, ачкычын ыргыт. Кая ташлаганыңны оныт. Үткәннәр калсын шунда, бикләнеп». «Дайте мне наслаждаться свободой! Иркен суларга мөмкинлек

бирегез миңа! Лассен зи михь майне фрайхайт генисен!» Тәвәккәл, кыю, максатчан кыз үзенең хыялларына ирешәчәгенә ышана.

Галия исеменнән сөйләнгән вакыйгалар тоташтан бирелми. Аның күргәннәре-белгәннәренә, кичереш-тойгыларына бәйләнештә хикәяләүгә чиратлашып, автор, Миңлегөл әбисе, Газизулла, Әхтәм бабайларының рухы тавышлары кушыла. Мондый төр хикәяләү, гомумән, әдәбиятта психологизмны тирәнәйтү, эстетик тәэсир ягыннан гаять отышлы булып санала. Әдипләр әлеге алымны тел-сурәтләү осталыгын күрсәтү өчен дә яратып кулланалар (мәсәлән, М.Кәбиров «Сары йортлар сере» әсәрендә сәнгатьчә тәэсиргә өлешчә шушы композиция алымы белән ирешә). Бу әсәрдә әлеге алым берничә яктан отышлы булып тора. Беренчедән, әгәр илне тетрәткән, халыкны пыран-заран китергән вакыйгалар, проблемалар хакында Галия әбисеннән, әнисеннән, дәресләрдә ишеткәннәрне искә төшерү рәвешендә генә сөйләсә, бу әсәрнең эстетик тәэсирен, ышандыру көчен бермә-бер киметер иде. Автор – алда әйтелгәнчә, кеше психологиясен сурәтләүдә тәҗрибәле әдип. Ул гомернең теге яки бу чорына хас психологик үзенчәлекләрне яхшы тоемлый. Галиянең әле бу катлаулы чорларны бәяләрлек тәҗрибәсе дә, тарихилык хисе дә юк. Икенчедән, Миңлегөл әбисе, Газизулла, Әхтәм бабайларның язмышы үтә фаҗигале хәлләрдән тора. Бу вакыйгаларда кеше рухының әрнүле авазы, әрнүле йөрәк сүзләре. Автор яңа романтик пафос дулкыны белән әлеге тәэсирнең киеренкелеген йомшарта, көчәнешен киметә. Әсәр вакыйгаларын тасвирлау төп хикәяләүче тавышыннан икенчесенә күчә, кабаттан, җаен туры китереп, урынына кайта. Музыка сәнгатендә түбән һәм югары, йомшак һәм каты, тибрәнүчән һәм кысылучан пафослар, тоннарның чиратлашуы көйне ничек тудыра, автор бу проза әсәрендә дә шундый алым белән эш итә.

Әсәр тукымасына кертелгән тарихи хатирәләрнең һәрберсендәге тема-проблема үзе бер төгәлләнгән вакыйгалы новелла-кыйсса сюжетына нигез булыр иде. Ләкин монда автор аларга бары үзәк проблеманың тарихи җирлеге, сәбәбе вазифасын йөкли.

Әсәрдәге тарихи катлам 1939 ел вакыйгалары белән башланып китә. Автор, тарихи фактларны образга төргәндә, мөмкин кадәр төгәллек сакларга тырыша. Баш очында кара болытлар куера башлавын, бүген булмаса, иртәгә кара төндә аның артыннан килеп алачакларын белеп, Газизулла авылдан чыгып китә. Хатыны белән нык тырышлык куеп җиткергән өйләрендә ике төн дә куна алмыйлар. Алар вербовка белән Сахалин якларына юл тоталар. «Бөҗәк урынына югаласы килми аның, бары дөньяга курчак булып түгел, кеше булып туганыңны» раслыйсы килә. Гади генә бәхеткә тиенеп, кеше булып яшисе килә. «Тик... татар ире өчен моны раслау шактый кыйммәт хак сорый иде». Газизуллага кагылышлы вакыйгаларда «караңгы шахталарда күзләре чепиләнгәнче, күкрәген таш басканчы кемнеңдер убыр авызына тутырыр өчен таш кисәргә, кара урманнарда кул тиреләре суелганчы, җаны бугазына җиткәнче агач аударырга; бүтәннәргә дан һәм биеклек яулап бирер өчен адәм ышанмаслык кыюлыклар күрсәтергә, утлар-сулар кичәргә, аннан җаны гарешкә ашкач, тән-күлмәген иңдерер өчен җиде ятның туфрагын үзенеке итәргә» мәҗбүр ителгән меңнәрчә татар ирләренең фаҗигасе тупланып бирелгән. Ишекләр дә, юллар да вакытлыча гына бикләнерме? Әлегә беркем белми. Яңа җирдә инде тормыш җайланды гына дигәндә, мәрхәмәтсез сугыш башлана. Газизулла беренче көннәрдән үк фронтка китә. Хәнифә балаларын кочаклап кала. 1945 елның февраль аенда Сахалинда көчле тайфун алар яшәгән посёлокны юк итә. 170кә якын кеше кар астында калып һәлак була. Гаиләдән бары бер Миңлегөл исән кала. Бу – архив материаллары белән расланган факт. Әсәр тукымасына әлеге вакыйганы кертеп, автор җинаятьчел сәясәтне фаш итә. Җирле хакимияткә тайфун булачагын сейсмологлар хәбәр иткәннәр. Әмма бу халыкка игълан ителмәгән. Кеше кадере булмаган шартларда һәр нәрсә бик астында. Газизулла фронтта хәбәрсез югала. Аның якыннары бистәнең бикле клуб идәнендә җансыз тезелешеп яталар. Кемне гаепләргә бу фаҗигаләрдә? Кем гаепле?! Язмышмы, әләкче якташлармы, сугышмы, табигатьме? Миңлегөл ачынып, шундый сорау бирә. Сугыш бетә. Миңлегөлнең бердәнбер өмете – әтисе хакында «хәбәрсез югалды» дигән

кәгазьдә. Бәлки исәндер... Үткәннәргә тагын ишеге бикле. Беркеме калмаган Миңлегөл туган авылына кайта. Коргаксыган, иңгән, салам түбәләре кайсы кай якка авышкан авыл каршы ала аны. Әтисенең бер-бер хәбәре булмасмы дип, авыл Советы, район комиссариаты ишекләрен кат-кат кага. «Ничек инде әткәем тикле әткәем табылмасын? Кеше бит ул!» 1951 елда шушы ук авылга чыкмаган җаны гына калган Әхтәм кайта. Ул да сугыш башлануның беренче аенда ук ике яшьлек кызын, гөл чәчәге кебек хатынын калдырып, ут эченә чыгып киткән, әсирлеккә эләккән. Кайтса, якыннарыннан беркем калмаган. Ачлык кырган. Шушы ике бәхетсез җан – Әхтәм һәм Миңлегөл кавышалар. Әхтәм бабай рухы булып сөйләнгән өлеш фаҗигалек пафосы белән иҗат ителгән. Вакыйгаларда чолганышта калып, әсирлеккә эләккән солдат язмышы. Яшәү белән үлем арасындагы гомер мизгелләре. Газапларга түзә алмыйча, Әхтәм үз-үзен үтерергә тели. Ләкин ярамый! Мәңгелек җәһәннәм. Үлемнең дә үз сәгате бар. Әхтәмгә «бәхет елмая». Ул җир эшенә коллыкка эләгә. Хәле бераз җиңеләйсә дә, кол булуына җаны кискәләнүенең чиге-чамасы юк. Автор Әхтәм авызыннан төп идеяне яңгырата: «Без күргәннәрнең онытылырга хакы юк». Әсирләрне Америка солдатлары азат итә. Әхтәм кабаттан лагерьга кайтарыла, аннан НКВДның тикшерү-фильтрация лагерына эләгә. Совет тикшерүчеләре һәм Гитлер нацистлары арасында аерма юк диярлек. Үзебезнең ил төрмәсендә дә кимен куймыйлар. Совет кешесе – мәңгелек кол.

Боларны әнисе, әбисе сөйләгәннәр аша Галия бераз белә. Әмма аның бәхетле яшисе килә. Өйдәгеләр сеңдерергә маташканча түгел. «Мин үземчә яшәргә тиеш. Минем хыялларым чиксезлеккә омтыла», – ди ул. Илләр белән илләр, кешеләр белән кешеләр арасындагы мөнәсәбәтләрне артка әйләнеп карамыйча гына кабул итәргә тели. Алга. Бары тик алга! Әлегә аңа ирек һәм кемгәдер тиешле бурыч капма-каршы төшенчәләр сыман тоела. Аңында азат, хөр булуга, шәхси иреккә, шәхси бәхеткә омтылыш никадәр генә көчле булмасын, кеше үзе турында гына уйлап, һәрьяклап бәйсез яши алмавына, бу мәсьәләнең җәмгыять законнарына, сәясәткә бәйле икәненә төшенү хәрәкәте башлана гына әле. Автор дөньяга карашларның үзгәрүен оста итеп мотивлаштыра. Беренчедән, Галия – татар бишегендә үскән, татарлыкны дәвам иткән кыз. Автор моны һәрдаим ассызыклап бара. Аның үзен тәрбияләгән тирәлек, әдәп-әхлак алдында бурычы бар. Икенчедән, яңа урыннарда булу, яңа танышлар белән аралашу аның танып-белү өлкәсен баета.

Автор кызның кичерешләрендә фикер каршылыклары, икеләнүләре тууын дусты Райнерның гаиләсендә кунакта булу вакыйгасыннан башлый. Бу эпизодта сугышларның кешелек язмышына тәэсиренә мөнәсәбәттә фикерләр үтә кыю, мантыйклы, бүгенге көндә аеруча мөһим итеп яңгыраш алган. Сәяси уеннар, берәүләрнең гарип акылы, туймас тамагы, мин-минлеге, нәфесе аркасында кеше язмышлары челпәрәмә килә. «Сугыш үтә рәхимсез. Яки син үзең үтерүче, яки сине үтерәләр». Галия анда Райнерның бабасы герр Вернер белән таныша. Карт аңа үзенең гаилә фаҗигасен сөйли. Аның әтисе 1942 елда Мәскәү янында үтерелә. «Сугыш безне әтисез итте», – ди ул. Сөекле иренең һәлак булуын аңына сыйдыра алмыйча, әнисе акылдан язар дәрәҗәгә җитә. Аны бу хәлдән өлкән улы врач-психотерапевт Руди гына коткарып кала. Кыз Җир шарының икесе ике почмагында кайчандыр кара-каршы торып сугышкан ике дәүләттә язмышлар бер төенгә төйнәлгәненә төшенә. Әбисе сөйләгәннәрне күңеленнән үткәреп, «Кемнәрдер кулында курчак булырга мәҗбүр ителгән ике зат миңа һәрберсе аерым-аерым үзенең хаклыгын исбат итәргә тырыша» дип уйлана ул. Сугыш утын кабызучыларга иртәме-соңмы барыбер җавап бирергә туры киләчәк. Икенче Бөтендөнья сугышының фаҗигаләре өчен тулаем немец халкының да гаепле булуын тануны автор башта шушы карт образына йөкли. Автор шушы ук фикерен дәрес эпизоды белән көчәйтә. Дәрестә алман теле укытучысы: «Сез үзегезнең Ватаныгыз белән горурланасызмы?» – дип сорый. Студентлардан җавап алганнан соң, болай ди: «Без – алманнар, мәсәлән, Германия безнең горурлык дип әйтә алмыйбыз. Чөнки безнең кара тап булып торган үткәнебез бар. Ул – фашистик Германиянең, Гитлер сәясәтенең хурлыклы үткәне».

Дуслары белән Дахау концлагерына сәяхәткә бару Галиянең дөньяга карашларының тагын да тирәнәюенә, киңәюенә тирән эз сала. Алар монда аудиогид белән йөриләр. Чәчләр үрә торырлык вәхшилекне гәүдәләндергән экспонатларны күреп, яшьләрнең йөрәген коточкыч авырлык баса башлый. Дахау турындагы документаль фильмны карап, кинозалдан суырылып чыгалар. Бу урынга ашкынулы рәхәт кичереп килгән кыз-егетләр инде көлмиләр генә түгел, сөйләшә дә алмыйлар. Галиянең күз алдына бабасы килеп баса. Оныгы аның рухына дәшә: «Мин – яңа буын. Яңа гасыр баласы, синең турында да, синең өлешеңә тигән сынаулар хакында да белмим диярлек. Кичер, бабам!» Галия яңа буынның киләчәк еллар каршында бурычы барлыгын тирән аңлый башлый. «Ватан, сугыш, илләр һәм кешеләр – моңа кадәр бу сүзләрне бербөтен йомгак итеп йомарлаганым юк иде», – ди ул. Аның кичерешләре гомумкешелек яссылыгында яңгырый. Кешелек, хәтерне биктән азат итеп, хакыйкатьне торгызмаса, бу хәлләр кабатланачак.

Әйе, үткәннәргә аек мөнәсәбәттән башка кеше тәрбияле була алмый. Тарихи хәтер гомумкешелек кыйммәтләре белән тыгыз бәйләнештә тора. Ул аерым кешенең генә түгел, бәлки бөтен халыкның, җәмгыятьнең иҗтимагый-әхлакый үсешен, мәдәнилеген билгели. Хәтерлелек яшәешнең асылын һәм мәгънәсен тирәнрәк аңларга өйрәтә. Хәтер әлегә исән. Ләкин хәтернең дә гомере кыскара бара шул. Шунсыз инсани һәм иҗтимагый үсеш тукталып, буыннар арасында дәвамчылык, керешү, хәтер чылбыры өзеләчәк. Яшәргә теләгән халык, үткәненнән сабак алып, киләчәккә юл сала.

Кыз уйларыннан гамәли хәрәкәткә күчә: «Әхтәм бабасы кайда булган – шуны белергә кирәк». Ватсап аша әтисеннән «Бабаң Моосбург шталагында булган» дигән хәбәрне ала. Юристлыкка укыган Райнердан шушы урында әсирлектә булганнарның документын таптыра.

Кыз тынгысызлыгын югалта. Сүз катып шаяртырга маташкан Мирога да: «Комачаулама. Мин уйлыйм, – дип, кырт кисә. – Сукмакларым мине Германиягә алып килгән икән, димәк, тикмәгә түгел. Мин монда үземне табарга тиеш». Аның әле Газизулла бабасының язмышын ачыклыйсы бар. Аның хәтер булып яшәгән рухы саклана. Әлегә аның хәбәре бикле шкафларда тузан җыеп ята.

Хәбәр бар. Ваемсызлык, куркаклык, саранлык, хөсетлек, нәфес биге астында гына ята ул. Ул бикне ачар кешеләр – оныклар, оныкчыклар бар. Газизулла рухы моңа ышана. Аның рухы белеп тора: берәм-берәм илгә кайталар алар.

Галия бабасы Газизулланың да язмышын ачыклаячак. Кыз көчен, белемен, хезмәтен, акыл эшчәнлеген кая сарыф итәргә белә. Аның алган тәрбиясендә бөек хисләргә омтылыш һәм сәләт, табигатендә холык ныклыгы, күңелендә ныклы урын ала барган иман бар. Әлегә Галия уйлана әле. Райнер аңа алманнарга хас төгәллек, тәртип, кыскалык белән мәхәббәтен аңлаткан. Тик Галиянең ярты җаны Казанда. Моны ул Райнерга аңлата алмас. Аның иркенләп сөйләгәнен Казандагы дусты Вәлид кенә сабырлык белән тыңлый. «Чит җирдә ничек кенә матур, уңайлы, рәхәт булмасын, минем үземә кайтыр сукмакларым бар. Үзем тапкан, үзем ачкан сукмаклар».

Һәр иҗат кешесе кебек үк, Айгөл Әхмәтгалиева да – халкының вәкиле. Ул тарихи вакыйгаларны милли психологиядән торып бәяли. Аның миллияте – үз динен, үз милләтен алда тоту, үз милләтенең тәрбияләренә, гореф-гадәтләренә иярү, үзеңнекен тану, шушы хисләрне башкаларның йөрәгенә беркетү. Милли фикерләү, милли характер үзенчәлекләрен әдип әсәр тукымасында бик табигый ассызыклап бара. Монда автор чагыштыру, янәшәлек кебек алымнардан нәтиҗәле файдалана. Алман гаиләсенә кунакка Галия тәмле ризыклар ашарга өметләнеп бара. Ләкин гаҗәпкә кала. Монда кунак өстәле буш. Кунак киләсе булса, үзләренең гаиләсендә ничек әзерләнгәнне искә төшерә. Иртә таңнан табын әзерләү, милли ризыклар пешерү. Өйдәгесен искә төшереп, авызыннан сулар килә. Ач булса да, хәләл түгеллеген чамалап, тыйнак кына баш тартырга туры килә.

Автор милли горурлык мәсьәләсенә дә һәрдаим зур игътибар бирә. Милләтең турында горурланып сөйләр өчен аның үткәнен, күренекле шәхесләрен белергә кирәк. Галия

исә вакыт-вакыт: «Тарихтан, сәясәттән белемем белән артык мактана алмыйм», «Авыз тутырып, башка милләт кешеләренә сөйли алмыйм», – дип, үзен битәрләп ала. Әнә, Райнер үз тарихын яхшы белә. Халкының һәр тарихи шәхесе хакында горурланып сөйли. Горур табигатьле Галиянең дә сер бирәсе килми. Бик изаланып Галилей, Бруноларга кадәр Җирнең Кояш тирәли әйләнгәнен әйткән төрки шагыйрьне искә төшерергә маташа. Райнерга сиздермичә генә интернеттан карый да горурлык белән Сәйф Сараи исемен чатнатып әйтеп куя. Әсәр тукымасында мондый уйнак шаянлык, нечкә юмор урын алган вакыйга-детальләр аның бизәге булып тора. Галиянең тулай торакта туган көн бәйрәмендә катнашуы да милли горурлык хисләре турында уйлануга этәрә. Музыка мәктәбен бетергән кыз, «Фазыл чишмәсе», «Сәйдәш маршы»н уйнап, дусларын сокландыра.

Әдип бер үк вакытта укучысының аңына төрле халыкларның гореф-гадәтләренә, яшәү рәвешләренә сабырлык белән карау, игътибарлылык, итагатьлелек сыйфатлары кирәклегенә дә басым ясый. Күп әсәрләре күзәтүләренә, кичергәннәренә, тәҗрибәсенә нигезләнгән. Һәр милләттә өйрәнерлек, гыйбрәт алырлык сыйфатлар, хикмәтләр бар. Гел милли гореф-гадәтләр кысаларында йомыклык белән генә яшәп булмый. Фән, мәдәният, икътисад, җитештерү кебек өлкәләрдә башка халыклар ирешкән казанышлар белән танышу гына алгарышка илтә. Әсәрдә шәхескә хөрмәт, адәм балаларының табигый тигезлеге хокукларын тану, кимчелекләргә киң күңеллелек күрсәтү кебек сыйфатларны яклый торган эпизод-детальләр дә урын алган. Галия Аурупа тормышында үзгә холыклы, менталитетлы кешеләрнең четерекле якларын да күрә. Нәрсәдер белән килешергә дә туры килә. Бразилия егете Давиның «зәңгәр» булуын аның үз авызыннан ишетеп чиркана. Шулай да ясалма елмаерга мәҗбүр була. Үзең булып калып, башкаларны да хөрмәтләү – катлаулы әхлакый мәсьәлә. Һәр күренешкә үзенчә карап фикерли белгән кыз үз сүзен әйтергә дә җаен таба. Йөзнең теге ягында булган немец картының интернатта яшәвен ишеткәч: «Гаилә әгъзаларын картлар йортына тапшыру – бездә җинаять, хурлык» – ди. Ауропадагы аталар һәм балалар арасындагы мондый мөнәсәбәткә тискәре карашын белдерә.

Әдәбият белеме дә, укучы тәҗрибәсе дә шуны раслый: язучының укучысына максатчан әйтергә теләгәне, фикерләре текстка кертелгәнгә караганда күпкә киңрәк яңгырашлы була. Һәр укучы әсәрнең яңа кырларын, язучы күздә тотмаганнарны да ача. Үтә таләпчән укучылар кимчелекләрне дә сизәрләр. Алар бардыр, әлбәттә. Шушы уңайдан мин фәкыйрегезнең шәхси фикере бар. Мин язучы түгел. Әмма язучының һәр әсәрен ваклыклары белән уйлавын беләм. Ни-нәрсәне ният иткән – каләменнән шул тезелә. Әсәр дөньяга килгән икән, аны яңа туган сабый сыман кабул итәргә кирәктер. Ә менә язылганчы, ул зәгыйфь тумасын өчен, осталар ихлас киңәшләрен бирергә тиешләр. Тормыш рәхимсез. Яшәеш – ул көрәш. Әдәбият мәйданында да шулай. Нишлисең, зәгыйфьләр, йомшаклар, көчсезләр тормыш арбасыннан үзләре төшеп кала. Шуңа күрә тәнкыйть фикерләреннән тыелам. Вакыт күрсәтер. Шулай да китап итеп чыгарганда, авторга бер киңәш мәгъкуль: әсәрнең азагындагы шигырьне, гәрчә ул бик эчтәлекле булса да, төшереп калдыру отышлырак булыр иде. Чөнки бу шигырь повестьне тигез ритмик эздән чыгара һәм публицистикага этәрә сыман.

Йомгак ясап әйтсәк, Айгөл Әхмәтгалиева – рухы, фикерләве, тел-стиле, хис-тойгылары ягыннан бай шәхес; чынбарлыкны тирән тоючы һәм аны сәнгатьчә югары кимәлдә күз алдына бастыра белүче талантлы каләм иясе. «Бик» повестенда тормышта күзәтүләреннән, рухи тәҗрибәсеннән бөртекләп җыелган материалны, яшәешнең фәлсәфи-әхлакый мәгънәсе турында уйлануларын, башкаларны кабатламыйча, идея-тематик яктан бүгенге көндә гаҗәеп актуаль яңгырашлы итеп калыпка салган. Укучыга мондый бүләкне Константин Паустовский «Алтын роза» дип атаган.

**Лилия ХӨСНЕТДИНОВА,**
*филология фәннәре кандидаты.*

# «ТЕЛНЕҢ БАШКА ЯШӘЕШЕ»: ТУГАН ТЕЛ ЯКИ ЧИТ (БАШКА) ТЕЛ

*Нафи Григорьевич Джусойты белән хыялдагы әңгәмә*

*Бу язманың жанрын аның авторы «эссе» – Нафи Григорьевич Джусойты белән хыялдагы әңгәмә дип куйган. Улданай Максут кызы Бәхтегәрәева (Бахтикиреева) – күренекле галимә, филология фәннәре докторы, Россия халыклар дуслыгы университетының (РУДН) рус теле һәм мәдәниятара багланышлар кафедрасы профессоры. Ул – рус һәм «башка» иҗади би- һәм транслингвизм, тәрҗемә гыйлеме, тел сәясәте буенча дөньякүләм танылган белгеч, ике- яки күптелле авторларның әсәрләрен башка мәдәният үрнәге буларак өйрәнү тәгълиматын тәкъдим иткән, Чыңгыз Айтматов иҗаты мисалында тел-сурәтләү һәм образлылык чараларының бер мәдәни-семиотик системадан икенчесенә күчү механизмын тасвирлаган шәхес.*

*Мәкаләдә «телнең башка яшәеше» («языковое инобытие») мәсьәләсе хакында авторның уйланулары чагылыш тапкан. Әйтергә кирәк, ул 2015 елда язылган. Бу вакытта татар укучысы өчен рус телле авторлар иҗатын, әсәрләренең телен билгеләүдә бөтенләй үзгә ситуация күзәтелә иде. Татар зыялылары мондый әсәрләрне «чит мәдәният» җәүһәре, рус әдәбияты үрнәге дип карауны алга сөрделәр. Әмма вакытлар узган саен хәл үзгәрә башлады. Соңгы берничә елда Мәскәү әдәбият институтларында рус телле һәм татар чыгышлы язучыларның әсәрләрен татар әдәбияты контекстында караган диссертацияләр языла башлады. Татарстандагы фәнни эзләнүләрдә дә рус телендәге татар чыгышлы авторлар язган текстларда милли дөнья сурәте элементларын барлау омтылышы активлашты. Шушы ноктадан, У.М.Бәхтегәрәеваның «үз» һәм «чит» оппозициясе янына «башка» категориясен тәкъдим иткән язмасы татар укучысына да кызык булыр, иҗади һәм тәнкыйди фикерләүне кузгатыр дип ышанабыз.*

**Редакциядән**

*«Мин бер нәрсәгә инанганмын: дөньяда үз туган телендә язмаган әдип юк... Әсәрләрен үз туган телендә иҗат итмәгән кеше бөтенләй язучы түгел яки әдәбият ярдәмендә көн күрүче талантлы коммерсант... Һәр кеше, бигрәк тә язучы өчен туган тел ул – үзе яхшырак белгән, тирәнрәк тоемлаган, үзенең уйларын һәм хисләрен, үзенең кичерешләрен һәм хыял дөньясын төгәлрәк, ачыграк, тулырак белдерә алган тел. Минә шундый билгеләмә, минем фикеремчә, үз туган телләрендә иҗат итмәгән язучыларның язмышына гүяки өретелгән фаҗига элпәсен салдырырга... һәм тагын бер хорафатны – чит телдә, әгәр син тумыштан шул этник бердәмлеккә карамыйсың икән, тел ягыннан тулы канлы әсәрләр язарга мөмкин түгел дигән карашны кире кагарга сәләтле».*

**Нафи ДЖУСОЙТЫ.**
*«Язучы өчен туган тел ни ул?»*

Исеме Көньяк Осетия чикләреннән чыгып китеп, еракларга мәгълүм булган галим Нафи Григорьевич Джусойтының «телнең башка яшәеше» турындагы фикере еш кына рус телле (рус булмаган) әдәбиятны өйрәнүчеләр тарафыннан кулланыла. Үземнең бу хакта уйлануларымны мин бер яклы гына бәяли алмыйм. Мондый каршылыкны үзләренең фәнни проектларында рус булмаган халыкларның рус телле әдәби текстларын өйрәнгән элеккеге аспирантларым да сизә шикелле. Болар – филология фәннәре докторлары һәм кандидатлары М.Б.Амалбекова – Казакъстан, Е.Н.Кремер – Россия, С.А.Гринберг – Белоруссия, О.А.Валикова – Казакъстан, Л.П.Дианова – Россия.

Каләмгә тотынуымның максаты исә бүген борчыган уйлануларым белән уртаклашу.

1. Сүзне «чит телдә, әгәр син тумыштан шул этник бердәмлеккә карамыйсың икән, тел ягыннан тулы канлы әсәрләр язарга мөмкин түгел» дигән «хорафат»тан башлыйм. Әмма «хорафат» чын мәгънәсендә яшәү көченә ия икән. Моның дәлиле – Нафи Григорьевичны шәхсән белгән, аның фәнни һәм иҗади эшчәнлеге хакында югары фикердәге Казакъстан галиме, филолог, шәркыять (Кытай мәдәнияте) белгече, илче, җәмәгать эшлеклесе Морат Мохтар улы Ауэзовның мәшһүр «Көндәлекләр»ендәге (2011) фикерләре. Әйтергә кирәк, «Көндәлекләр», М.М.Ауэзов рус телендә язган барлык хезмәтләр кебек үк, авторның бу телне камил белүен, тема, эчтәлек, жанр һәм тел чаралары ягыннан стиль берлегенә ирешү һәм аны саклау осталыгын ачык күрсәтә. Мондый осталык туган телле зыялыларның барысына да хас дия алмабыз.

«27/VI/1978. Рус телендә язам, әмма «русча түгел». Рустеллелек – милли үзаң формалаштыру коралы. Хәзергә моңа «яңа тарихи бердәмлекнең» рус булмаган компонентларын ассимиляцияләүдәге уңышлары белән илһамланган партия-дәүләт аппараты игътибар итми әле. Кавемдәшләребез арасындагы тарихи оптимизм хисе кысрыкланганнар да күрми …» [*Ауэзов М.М. Дневники. Алматы, 2011.* С. 237].

«1977 елның гыйнвары. Минем рус телем – гади генә кечкенә учак, әмма аның уты билгеле бер күләмдә мәгълүматны һәм әңгәмәдәшләрнең йөзләрен яктыртырга җитәрлек. Казакъ сүзен рус телендә иҗат итү өчен <…> тырышырга мөмкин, әмма бу тел һәрвакыт минем өчен чит тел булып тоела, ул минем кырыслыгымны белдерә ала, әмма мәхәббәтне нечкә, тирән, интим алдында хисләр көчсез. <…> Хәтта тормышымның бары тик рус телендә генә аралашып яшәлгән вакытларында да мин аңа үземнең иң тирән кичерешләремне ышанып тапшыра алмадым. <…>. Моның артында аңлы позиция, аңлы төркилек хисләре тормый иде. Без, рус телле казакълар да, дөньяны туган телнең авазлары, ритмы, көе, билгеләре ярдәмендә үзләштерә башлаганбыз бит. Тик безнең рус телебездә балалар сүзләренең, иң беренче, иң олы, иң изге сүзләрнең лексик катламы тулы көченә кулланылмый» [*Ауэзов М.М. Дневники. Алматы, 2011.* С. 193].

Бу ике язма һәм алардан башкалары да Н.Г.Джусойты күрсәткән нәтиҗәләрне раслап киләләр. «Телнең башка яшәеше»ндә булу бер үк вакытта үз халкыңның «тел яшәешенә» кайту белән үрелә[1] – бу М.М.Ауэзовның уникаль «тел биографиясе». Ул үзенең сөйләм аңында казакъ телен тергезә / активлаштыра. Психолингвистлар моны казакъ теленең сөйләм аңында өстенлек алган «төш»кә әйләнүе, ә элек өстенлекле булган рус теленең сөйләм аңының читенә, периферияга китүе дип аңлатырлар иде. Бу процесс җиңел генә бармый, әмма ул – чынбарлык. Башка телнең «чит» булуын, туган халкың каршында җаваплылыгыңны аңлау «маргинальлекне» җиңәргә һәм үзеңне эшлекле «милли мәдәният субъекты» буларак табарга ярдәм итә. Минем карашымча, М.М.Ауэзовның «телнең башка яшәеше»ндә халәте, беренче чиратта, үз халкына,

[1] Хәзерге казакъ халкын аерым бер күләмдә ике компонентлы дип атау арттыру булмас дип исәплим [*Кодар А. Зов Бытия. Алматы: Таймас, 2006. 528 с.*].

аның фәненә һәм мәдәниятенә, «аны тездән күтәрүгә» хезмәт итә: моның дөреслегенә ышану өчен ул рус телендә язганнарны уку да җитә. Биредә исә сүз, нигездә, аның башка телдә иҗат итү мәсьәләләренә багышланган монографиясе турында бара. Бу хезмәттә Н.Г.Джусойтының «Литературная газета»да (1957, 17 окт.) яңгыраган тезисы күңелдән уздырыла: «Бер генә милли әдәбият та башка телдә барлыкка килмәгән һәм яши алмый» *[Джусойты Н. О национальном стиле и национальном языке // Литературная газета, 1957, 17 октября].*

М.М.Ауэзов «Ике тармакны да бер милли әдәбиятка кертә торган критерийлар бармы? … Башка теллелек милли әдәбиятны үстерүгә каршы килгән фактор түгелме?» дигән сораулар күтәрә [*Ауэзов М.М. Иппокрена. Хождение к колодцу времен. Алматы: Издательский дом Жибек жолы, 1997. С. 108*]. Аларга һәм шулар белән кисешә торган башка сорауларга җавапларны ул үзен танып белә торган этномәдәни мохиттә, аның максатчан эш-гамәлләрендә таба: «Бу гамәлләрнең эчтәлеген конкрет шартлар билгели һәм үткәндәге тәҗрибә алар өчен ниндидер еракта калган охшаш хәл кебек тоела, шуннан артык түгел. Шул ук вакытта тарихи фактлар төрле мәдәниятләрнең үзара йогынтысы вакытында шәхеснең аерым тибы формалаша, аның эшчәнлеге белән тел ситуациясенең торышы, аның тискәре яки уңай перспективасы бәйле була дип күрсәтәләр.

Сүз «маргиналь шәхес» турында бара, ул этник яктан үзенеке булган мәдәниятне тыштан, читтән карап, шуңа күрә масштаблы кабул итә. Бу мәдәният язмышында аңлы рәвештә катнашырга теләгән очракта, ул аның хәлен һәм башка мәдәниятләр белән мөнәсәбәтләрдәге перспективаларын бөтенлекле аңлау сәләтенә ия була.

Шушы сыйфат аркасында маргиналь шәхесләр тарихта күп тапкырлар аерым бер мәдәниятне яки аның башка мәдәниятләр белән үзара бәйләнешләрен үстерүдә актив эшлеклеләр ролен башкарганнар» [*Ауэзов М.М. Иппокрена. Хождение к колодцу времен. Алматы: Издательский дом Жибек жолы, 1997. С.108*].

Шушы фикерне киңәйтеп, монография авторы нәкъ менә «маргинальлек» ситуациясенең «этник чыгышыңны аңлау һәм милли үзаң» төшенчәләрен аеруга китергәнлекне әйтә. Аның фикеренчә, дөньяга караш позициясе тотрыклы булган чын иҗади шәхес маргиналь ситуациядә милли үзаңга килә, үзендәге маргинальлекнең ике яклы билгесезлеген җиңеп чыга. Бу очракта милли тел аның өчен иҗтимагый ролен арттыруга юнәлдерелгән объектка әйләнә, гәрчә үз практикасында ул дөньяви максатларына ирешү чарасы буларак яхшырак белгән телне еш кына өстен күрә.

«Милли мәдәният субъектлары буларак үзен тапкан һәм маргинальлек дәрәҗәсен узган иҗади шәхесләрнең гомуми эшчәнлеге ахыр чиктә шул мәдәниятнең ике «тармагы» арасындагы каршылыкларны бетерүгә һәм үсешенең гомуми бурычларын хәл итүгә ярдәм итә» [*Ауэзов М.М. Иппокрена. Хождение к колодцу времен. Алматы: Издательский дом Жибек жолы, 1997. С. 208–209*].

Миңа М.М.Ауэзовның түбәндәге нәтиҗәсе дә урынлы тоела: «...мәдәниятләр арасындагы тирән бәйләнешләр шартларында әдәбият башка милләт телендә дә яшәргә мөмкин. Әмма шул ук мисаллар телнең «башка яшәеш» вакыты чиксез түгеллекне дә күрсәтә. Һәм монда без Н.Джусойтының хаклы булуын күрәбез, аның тезисы, берсүзсез кабул ителү өчен болай яңгырарга тиеш иде: «...милли әдәбият... башка милләт телендә, ахыр чиктә үзенең шушы рәвештә яшәешен җиңәргә омтылмаганда... яши алмый». [*Ауэзов М.М. Иппокрена. Хождение к колодцу времен. Алматы: Издательский дом Жибек жолы, 1997. С. 110*].

Бу нәтиҗә уникаль галим Ю.М.Лотман һәм күптелле язучы (рус-алман-казакъ), тәрҗемәче һәм тәнкыйтьче, «туган әдәбиятны туган телдән башка үстерү мөмкин түгел» дип санаган, әмма «аның үсешенә ярдәм күрсәтүне, аңа хезмәт итүне башка тел ярдәмендә дә башкарырга була» дип исәпләгән Герольд Карлович Бельгер (1934 – 2015, Алматы) хезмәтләрендә дә күпмедер күләмдә дәлилләнә [*Бельгер Г.К. В тенетах*

*стереотипов // Помни имя свое. Статьи и выступления о литературе и культуре российских немцев. Алматы: Гылым, 1999*. с. *85*].

Күренекле рус телле осетин әдәбиятын өйрәнүче И.С.Хугаев карашлары башкаларга караганда М.М.Ауэзов позициясенә иң якынидыр. И.С.Хугаев әйтүенчә, милли транслингваль әдәбият (милли әдәбиятның «башка телдә яшәеше») туган телдә милли әдәбият яшәгән һәм туган тел булган вакытта гына мөмкин (логика шундый: транслингвизм булсын өчен кемендә лингвизм булуы шарт; әгәр лингвизм юк икән, – «транслингвизм» төшенчәсе реаль эчтәлеген югалта) [*Хугаев И.С. О границах и критериях национальной транслингвальной литературы // Вестник Владикавказского научного центра. 2013. Т.13. № 1. С. 2–6*].

Урта гасырлар төрки әдәбият гарәп һәм яңа фарсы телләрендә яшәп, «башка телдә яшәеш»тән Йосыф Баласагунлының «Котадгу белек» һәм Алишер Нәвоиның мәшһүр бишлеге кебек сүз сәнгате асылташларының төрки сөйләм нигезенә чыгуы М.Ауэзовка әдәбият үзенең башка телдә «яшәеш формасын» җиңә ала дип исбатларга мөмкинлек бирә. Тагын бер дәлил сыйфатында ул ирланд этносы белән бәйле мисал китерә: «Бу закончалык мәдәниятләр бәйләнешенең барлык очракларында да күзәтеләме? Юк, һәм монда без бәйләнешләрнең ике яклы табигатенә тап булабыз. Мисалга, инглиз телле әдәбиятка Свифт, Гольдсмит, Лоренс Стерн, Оскар Уайльд, Бернард Шоу, Джордж Мур, Джеймс Джойс кебек талантлар биргән ирланд этносының менә инде берничә йөзьеллыклар дәвамында ирланд телендә әдәбияты юк» [*Ауэзов М.М. Иппокрена. Хождение к колодцу времен. Алматы: Издательский дом Жибек жолы, 1997. С. 111*][2].

Монда тел һәм этник үзенчәлекләрнең туры килмәве (яки туры килүе) законлы күренеш булуын билгеләп үтәргә кирәк. Күргәнебезчә, хәзерге вакытта да ирланд халкының милли рухы чын мәгънәсендә сынмаслык һәм сыгылмаслык, шуңа да карамастан, ирланд әдәбияты (шул исәптән халык тарихына караган әсәрләр дә) VI гасырдан башлап латин, кайвакыт борынгы һәм урта ирланд телендә барлыкка килә, ә XVIII гасырга ирланд телендә әдәбият югалу чигенә җитә һәм ирланд теленең «башка телдә яшәеш» дәвере башлана, аерым алганда, ирланд әдәбияты инглиз телендә иҗат ителә[3]. Беренче бөтендөнья сугышы елларында ук Британия империясе премьер-министры Д. Ллойд Джордж болай ди: «Тел милләтне билгеләгәндә җитәрлек билге булып тормый. <…>. Ирланд халкының шактый өлеше борынгы телен оныткан һәм күп гасырлар дәвамында баскыннар телендә сөйләшкән, соңгыларын аларның үз телләрендә ачуланган» [*Хухуни Г.Т., Валуйцева И.И. Межкультурная адаптация художественного текста: Монография. М.: Прометей, 2003. С. 8–9*].

Без югарыда телгә алынган коллегаларыбыз-филологлар (күпчелеге лингвистлар) М.М.Ауэзовның түбәндәге нәтиҗәсен хуплыйлар: милли әдәбиятның башка мәдәният телендә яшәве мөмкин, әмма аның чиге бар; ул чик тарихи, геосәяси характердагы төрле шартларга, аерым алганда, тел идеологиясенә һәм тел сәясәтенә бәйле.

2. Бу өлештә Н.Г.Джусойтының түбәндәге фикеренә бәйле уйланулар белән уртаклашасы килә: «Һәр кеше, бигрәк тә язучы өчен туган тел ул – үзе яхшырак белгән, тирәнрәк тоемлаган, үзенең уйларын һәм хисләрен, үзенең кичерешләрен һәм хыял дөньясын төгәлрәк, ачыграк, тулырак белдерә алган тел. Менә шундый билгеләмә, минем фикеремчә, үз туган телләрендә иҗат итмәгән язучыларның язмышына гүяки өретелгән фаҗига элпәсен салдырырга сәләтле...» [*Джусойты Н.Г. Что это такое – родной язык писателя?// Книга друзей. Нальчик: Эльбрус, 2003*].

Бу өзектә, минем фикеремчә, аерылып тора торган кисәк – «гүяки». Фаҗигалелек аермачык бит. XX гасырның икенче яртысында тел төзелеше совет җәмгыятен

[2] Мисал буларак Франческо Петрарканың иҗат тәҗрибәсен дә телгә алыйк: ул шигъри әсәрләрне туган телендә – итальян, ә фәнни эссе һәм публицистиканы латин телендә (Рим империясендәге рәсми тел) язган.

[3] Шунысын да билгеләп үтәргә кирәк: Европа Берлегенең язма тәрҗемәләр Генераль дирекциясе ирланд телен торгызу турында карар кабул итте.

гомогенлаштыруның асылы булып, рус телен тормышның барлык өлкәләренә кертү махсус дәүләт декретлары, карарлар һәм указлар аша алып барылды[4]. Совет тел сәясәтенең түбәндәге тезислары тормышка ашыру өчен мәҗбүри булды: тирән идеологик характердагы, барлык милләтләрнең һәм телләрнең тигез хокуклы булуы турында; рус телен «икенче туган тел» дип карау яки «ике туган тел» турында тезис, ул турыдан-туры «милләтләрнең чәчәк атуы һәм якынаюы» турында марксистик тезис белән бәйле; рус теле аша СССР халыклары телләренең гомуми лексик фондын киңәйтү кирәклеге һәм рус теленең халыкара лексиканы кертүнең бердәнбер юлы булуы; рус һәм милли телләр арасында вазифаларны бүлү турында (телләрнең паритетлыгын игълан итү иҗтимагый вазифаларның бер үк күләмдә булуын гарантияләмәсә дә); милли һәм рус телләренең үзара бәйләнешенә нигезләнгән гармонияле яшәве турында.

Шулай ук «шапирография» ысулының (профессор А.Б.Шапиро) – рус грамматикасының кайбер күренешләрен башка телләр грамматикасына механик күчерүнең зарарлы йогынтысын да искә алыйк. Бу шартларда, Нафи Григорьевич кебек үз туган телен яклап, аның өчен көрәшүен дәвам иткән пассионар шәхесләр булу да мөһим: «Без – осетин зыялылары һәм осетин хакимияте – ахмаклык эшләдек: узган гасырның 60нчы еллары башында хәтта башлангыч авыл мәктәпләрен дә рус телендә укытуга күчердек. Шуның белән туган телне «атып үтердек» – балаларыбызны телне тоемлаудан мәхрүм иттек. Безгә барлык осетин тулы булмаган урта мәктәпләрендә туган телдә укытуны кайтарырга кирәк.

Без моны алдагы елларда эшли алабыз һәм эшләргә тиешбез яки үз телебезне, мәдәниятебезне һәм милли киләчәгебезне аңлы рәвештә, үзебезнең чамадан тыш ахмаклыгыбыз аркасында үтергәнебезне танырга тиешбез» [*Джусойты Н.Г. Мир спасут книги и преданность идеалу справедливости // Интернет-ресурс. Режим доступа: http:// osetia.kvaisa.ru/1-rubriki/03-vstrecha-dlya-vas/nafi-dzhusojtymir-spasut-kniga-i-predannost-idealu-spravedlivosti/*].

Минем фикеремчә, СССРдагы күпчелек милли телләрне «атып үтерү» милли зыялылар һәм хакимият гаебе түгел. Осетин халкы күп кенә башка халыклар кебек үк ассимиляциягә һәм автохтон халыкларны аннигиляцияләүгә юнәлтелгән драматик хәлләрдә исән калу юлын сайлаган.

Совет чорының тел төзелеше һич кенә дә уңышсыз булып чыкмый. Тулы буыннар өчен, аерым алганда – иҗат әһелләре, язучылар өчен, аның тел аңында өстенлек алган тел туган телгә әверелә. «Туган тел» гыйбарәсендәге хис катышкан мәгънәләрне алып ташлаганда, чыннан да, тел аңында автохтон тел, тумыштан билгеләнгән этнос теле өстенлекле түгел. Бу мәсьәләдә Нафи Григорьевич хаклы. Моны лингвист-галимнәр фикере дә раслый: «когнитив процессларны һәм структураларны оештыру ысулы булып анадан биологик читләшү һәм социаль аралашуга күчү процессында үзләштерелгән бер генә тел тора ала. Теләсә нинди башка тел, ул никадәр иртә үзләштерелсә дә һәм субъект аны ничек кенә үзләштерсә дә, туган тел дип атала алмый» [*Шахнарович А.М. Родной язык: онтогенетический подход // Русский язык в СССР. М., 1991. № 7. С.* 17]. Норма буенча кешенең ике әнисе булмаган кебек ике туган теле дә була алмый. Әмма «өйрәнгән тел <...> кеше тормышында туган телдән мөһимрәккә әйләнә ала, тик туган тел, үги телгә караганда, аны азрак яраткан очракта да, ана теле булып кала» [*Костомаров В.Г. Еще раз о понятии «родной язык» // Русский язык в СССР. М.: 1991, № 1. С. 11*].

[4] Мәсәлән, ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм Халык Комиссарлары Советының 1938 елның 13 мартындагы «Милли республикалар һәм өлкәләр мәктәпләрендә рус телен мәҗбүри өйрәнү турында» карары рус телендә укытуны 1 сыйныфтан алып РСФСР территориясендә, ә башка республикаларда 3 сыйныфтан мәҗбүригә әйләндерә. Рус телендә укыту-методик әдәбият булдырыла, милли мәктәпләр ябыла. Әйтик, зурлыгы буенча икенче урындагы Совет Казакъстанында 1955 елдан башлап рус телендә укыта торган мәктәпләрдә казакъ телен укыту гамәлдән чыгарыла. Башкалада – Алма-Атада – 1980 еллар уртасына кадәр бердәнбер 12нче казакъ мәктәбе эшли. Телне үзгәртү төрле чаралар ярдәмендә, шул исәптән СССР территориясендә эшче көчләрнең планлы бүленешенә таянган халык миграциясе хисабына башкарыла.

Россиянең танылган рус телле галимнәре фикеренчә, туган телен югалтканнарның күбесендә тамырларының үз этносына бәйлелеген тану хисе яши, ә этник телне күп кенә ике телле кешеләр җитәрлек дәрәҗәдә белмәгәндә дә туган тел дип атыйлар. Әгәр тел үзендә конкрет халыкның элгәрге буыннары тәҗрибәсен саклый һәм кан составында ниндидер генетик билгеләрелешкә ия дигән караштан чыкканда, үзләштергән телне туган тел дип атап булмавы аңлашыла («Язның унҗиде мизгеле»ннән радистка Кэт очрагы искә төшә). Конкрет субъектның тел аңында чит тел өстенлек итүе аркасында, ул аңа бар серләрен дә ышанып тапшырырга һәм үзенең барлык яшерен хисләрен аның ярдәмендә белдерергә дә мөмкин бит.

Үзгә ассоциацияләр дә хәтергә килә. Ф.Искәндәрнең соңгы повестьларыннан берсе «Пшада»ның төп герое үлем алдыннан соңгы көн дәвамында пшада сүзенең нәрсә аңлатканын исенә төшерергә тырыша. Совет генералы, сугыш батыры, көндәлек тормышта кирәге булмау сәбәпле, абхаз телендә сөйләшмәгән этник абхаз үзенең уйларында кабат-кабат әлеге сүзгә кайта. Һәм китәр алдыннан гына: «Пшада – җилсезлек!» – аның миендә ялкынланып, күкрәгенә ниндидер көчле нәрсә бәрелә, һәм туган теле, бәрелеп ватылган карбыз кебек, аның алдына сүзләрнең караңгы орлыкларын сибә-сибә таралып китә!»

Генералның уйларында туган теленә әйләнеп кайткан соңгы көне мәшһүр философ М.К.Мамардашвилиның табигый (ана) тел феномены турындагы нәтиҗәсен актуальләштерә: «Чөнки мин әйткән материя өзлексезлек, чиксезлек үзлегенә ия: кая гына барсак та, без анда үзебезнең аның эчендә яшәвебездән арына алмыйбыз. Кая гына килеп җитсәк тә, без бу чиксезлекнең эчендә калабыз» [*Мамардашвили М.К. Законы инакомыслия // Здесь и теперь. №1. М., 1992. С. 85*].

Нафи Григорьевич тарафыннан игътибарсыз калдырылган «башка телдә яшәеш»нең фаҗигалелеген күрсәтү максатыннан, Россиядән читтә дә танылган, билгеле бер «этник оя»га карамаган галим һәм язучының романнарыннан берничә өзек китерәсем килә. Аны модернизм һәм колониальлек буенча Оксфорд библиографиясе авторлары болай тәкъдим итәләр: «Мәдинә Тлостанова – үзбәк-адыг чыгышлы, Мәскәүдә яшәүче филолог һәм философ, деколониаль эстетика һәм гендерлык проблемалары белән шөгыльләнә» [*Бахтикиреева У.М. Встречи с Мадиной // Тамыр. № 1(30), 2012. С. 3*].

М.В.Тлостанованың әти-әниләре Мәскәүдә уку дәверендә очрашкан (әтисе – кабарда, МДУның философия факультетын тәмамлый; әнисе – үзбәк, МДУ каршындагы Азия һәм Африка илләре институтында укый, һинд мәдәнияте белгече, әдәбиятчы), «совет кешесе» формалашкан дәвер яшьләре булалар.

Билгеле мәгълүматларга караганда, алар «руслык»ка төрлечә караганнар. «Көн уртасында Мөнәвәр[5] Родоны[6] күләгәле верандада тапты. Ул, тырышып, ниндидер сәер шигырь өйрәнә, аны кат-кат кабатлый иде: «Нелепо ли ны бяшеть, братіе, начяти старыми словесы трудныхъ повестіи о пълку Игореве»…

<…> Родо иске карагачның җир өстенә калыккан тамырларына абынды, әмма төшке ашны җиргә төшермәде, күпсанлы кенәзләр исемнәрен атаганда да ялгышмады: «…старому Ярославу, храброму Мстиславу, иже зареза Редедю предъ пълкы касожьскыми, красному Романови Святъславличю …».

<…> «живыя струны въскладаше, они же сами княземъ славу рокотаху» дигән сүзләрне кабатлап сарайга килеп җитте <…>

Аның «нелепо ли ны бяшеть» урынына Нәвои, Бабур яки Лүтфи сүзләрен яттан әйтәсе килде. Бу белемсезлекне ничек капларга, бу мәҗбүри тагылган, һәрвакыт ниндидер авыр гаеп хисе уята торган белемсезлекне? <…> Чөнки аның читкә омтылуы – киселгән тел, өзгәләнгән мәдәни традиция, тапталган иман, катлаулы һәм өстәвенә җентекләп яшерелгән этник һәм социаль чыгыш – барысы да берсе-берсенә өстәлә

[5] Мөнәвәр – Родоның әнисе. Икесе дә М.Тлостанованың «Залумма Агра» романы геройлары.
[6] Минемчә, Родо – М.Тлостанованың әнисе образы.

барып, аңа иске һәм яңа Бинкентка якынаерга комачаулыйлар. Ул үзен башка кешегә аталган һәм аны белү һәм хәтердә саклау хокукыннан да мәхрүм ителгән дип хис итәме? Бер үлчәү касәсендә – традиция, әмма заманча белем алу һәм үсү, статус, социаль дәрәҗәгә ирешү өчен мөмкинлекләр булмау. Икенчесендә – рус теллелек, үз дөньясы белән элемтәләрен югалту, шул ук вакытта гарип совет социумында уңышка ирешү вәгъдә ителә. Бу чын сайлау түгел, ә уйдырма, ләкин Родо барыбер гомер буе шуның өчен үзен гаепләде» [*Тлостанова М.В. Залумма Агра: Роман. М.: Издательство «Спутник +», 2011. С. 228–231*].

Күп кенә рус булмаганнарның язмышында көчле совет тел идеологиясе, «Залумма Агра» романының төп героинясы Магда фикеренчә, «табигатькә, кланга беркү хисен җуя <…> ә чынбарлык бөтенләй башка бердәмлекләр тәкъдим итә <…> безнең сайлау мөмкинлегебез юк иде» [*Тлостанова М.В. Залумма Агра: Роман. М.: Издательство «Спутник +», 2011. С. 257*].

Башка дәлил булып М.Тлостанованың беренче «Сезнең дөньяда мин – үтеп баручы» романыннан өзек (Дина Дамиан псевдонимы белән басылган) хезмәт итә ала: «<…> ир-ат йөткереп куйды һәм көчле акцент белән, әмма русча сорады: «Ә ни өчен сез туган телдә язмыйсыз? Бу ничек мөмкин соң? Тел – фикернең йорты, Хайдеггер әйтмешли, һәм аны ата-бабалар телендә язарга кирәк. Нинди язучы инде сез, кхе-кхе, әгәр дә сез туган телегезне белмисез икән <…>.

<…> Мин кайнарланып, озак кына телнең бары тик чара гына булуы, һәркем үзе яшәгән урында ничек яши һәм уйлый – шулай яза икәнлекне һәм үзем өчен, ничек кенә ачы булмасын, рус теленең туган тел булуы, кайвакыт тема да нинди телдә язарга кирәклеген күрсәткәнлекне, шуңа күрә инглиз телендә дә язуымны, «туган тел» төшенчәсе искергәнлекне, ниһаять, Хайдеггерга мөрәҗәгать итеп, туган тел өчен көрәшергә чакыруның көлке һәм сәер булуы турында сөйләдем» [*Дамиан Дина. В вашем мире я – прохожий … М.: Ком-Книга, 2006. С. 167*].

«Башка тел» – роман героинясы өчен «туган тел», ягъни өстенлекле, ул танып белгән чынбарлыкны тасвирлау өчен төп корал булып чыга. Тел билгеләнүе һәм этник үзбилгеләнү мондый ситуациядә тирән каршылык халәтендә булырга мөмкин.

Әмма роман авторы белән хәл тагын да катлаулырак. Магданың француз антропологы белән сөйләшүе – моңа дәлил:

«– Сез этник яктан якын кешеләр арасында үзегезне ничек хис итәсез?

– Берничек тә түгел. Үзеңне яхшы хис итү өчен үз булырга, телне белергә, гореф-гадәтләрне, кыйммәтләрне аңларга кирәк, мин моннан мәхрүм.

– Ә сез туган телегезне белмисезме?!

– Юк, гәрчә минем очракта нинди телне туган тел санарга кирәк икән?

– Рус телен, шулаймы?

– Әйе, шулай булып чыга.

– Димәк, сез рус милләтеннән!

– Юк, барысы да сез уйлаганча түгел!

– Ничек инде, Европа телләрен санамаганда (алары – чит тел), русча гына сөйләшәсез. Монысы саналмыйдыр. Әмма үзегезне шулай тотасыз: сездә һәр нәрсә русныкы! <…>

– Ә сез нигә каршы? Фикерегезчә, сезне нәрсә үзегезне рус түгел дип санарга мәҗбүр итә?!

– Мин мәкаль белән җавап бирим, рус мәкале түгел, Африкадан: Ягуар тыштан чуар, ә кеше – эчтән.

Сезгә мәсьәләнең шулай куелышы ничек тоела? – Юк-юк, кача алмассыз! Аңлатып бирегез. <…>

– … Мин рус була алмыйм. Рус мәдәниятендә, менталитетында, тормышка мөнәсәбәтендә мин кабул итә алмый торган күп кенә нәрсәләр бар. Алар минеке

түгел. Чит. Гәрчә башкалардагы да – минеке түгел, аңлыйсызмы? Әгәр минем ачык билгеләнгән этник үзаңым булмаса, ул вакытта рус үзаңлымын дигән сүз түгел әле. Мине ниндидер кысаларга кертеп урнаштырырга кирәкми! <…>

– … гәрчә мин бу аермага төшенә алмасам да, кызык. Үз һәм чит арасындагы чик, сез кабул итә һәм кабул итми торганны бүлгән сызык кайда?

– Мин моны үзем дә төшенеп җитмим, ышаныгыз. Бу кисешә торган һәм кире кагылган чикләр буталып беткәннәр.

Минем урыным кайда? Безнең урыныбыз кайда? Күрәсең, читләр арасында. Беркем дә үз өендә булмаган җирдә. Өй булмаган җирдә. Мин кем булырга, кемгә әйләнергә икәнне сайларга теләмим. Мин ниндидер бер гади һәм ачык бердәмлеккә омтылмыйм. Мин – күптөрле, һәм бу – минем бердәнбер коткаручым. Һәм урын да юк. Җирдә андый урын юк. Шуңа күрә качып булмый. Мөмкин түгел.

Әйләнә-тирәдәгеләр минем белән нишләргә, кая кертеп төркемләргә икәнен белмиләр. Тышкы кыяфәт үзенчәлеге барысын да күмеп китә. Коллекционер инстинкты җиңә. Үзгәлек үзенә җәлеп итә, әмма ул һәрвакыт юкка чыгару омтылышы белән үрелә.…» [*Тлостанова М.В. Залумма Агра: Роман. М.: Издательство «Спутник +», 2011. С. 359–363*].

Хәзерге рус телле матур әдәбияттан мондый мисалларны күпләп китерергә мөмкин. «Телнең башка яшәешендәге», ягъни «контакттагы әдәбият» авторларының әсәрләре һәр җирдә, төрле илләрдә кызыксыну уята.

Шулай итеп, меңьеллыклар чигендәге фән һәм мәгариф дөньясында тикшерүче, галим, югары мәктәп укытучысы шәхесенә турыдан-туры бәйле эпистемологик үзгәрешләр күзәтелә. Тиз үзгәрүче чынбарлык галимнәрнең, бигрәк тә гуманитарийлар тикшеренүләренең нәтиҗәләрен шик астына куя. Шулай да яңа теорияләр һәм концепцияләр тәкъдим итү кирәклеген аңлау бар. Бу шартларда яңа мәгънәләр формалаштыра, яңа белемнәр булдыра алган галим шәхесенең кыйммәте аеруча мөһим.

Нафи Григорьевич Джусойтының ачык позициясе «телнең башка яшәешен» аңлауга һәм тасвирлауга яңача якын килү юлларын эзләүне көн тәртибенә куя. Әлегә мин бу өлкәдә нигездә интеллектуаль дәлилләр эзләү белән генә шөгыльләнәм. Осетин халкының бөек улы, галим, фән һәм туган тел рыцаре, язучы һәм тәрҗемәченең какшамас позициясен барлык эмоциональ мәгънәләре тирәнлегендә аңлау минем экзистенциаль үзаңыма да тәэсир итәр дигән өметем бар.

**Улданай БӘХТЕГӘРӘЕВА,**
*филология фәннәре докторы, профессор.*

# КҮК АСТЫ ИЛЕННӘН – КАЗАНГА

Гасыр йөзен билгели торган, үз милләтенең күркәм сыйфатларын башкаларга таныта алырдай асыл затларның һәр халыкта да сирәк, әмма нәкъ үз вакытында тууы табигый фалдыр, мөгаен. Менә шундый зыялы мөхтәрәм шәхесләрнең берсенә – Миркасыйм ага Госмановка – агымдагы елның 31 маенда 90 яшь тулган булыр иде. Аның бакыйлыкка күчүенә инде ундүрт елга якын вакыт узып та китте.

Кем иде соң ул Миркасыйм Габделәхәт углы Госманов?

Бу сорауга җавап эзләп, аның гомер юлын күздән кичерсәк, бу юлның ике өлештән торуын күрербез: гомеренең беренче өлеше Ерак Көнчыгышта узса, икенчесе Көнбатыштан аерылгысыз. Ул 1934 елда Кытайның Шенҗаң вилаятенә (Шәркый Төркестанга) кергән Голҗа шәһәрендә дөньяга килә, рухы имгәтелмәгән даирәдә үсә. Туган төбәгендәге татар мәктәбендә җәдидчеләр идеяләрен гамәлгә ашыручы мөгаллимнәрдән белем ала. Шәрык мәдәнияте традицияләренә тугрылык саклаган, бу уку йортында балаларны төрле дөньяви фәннәр белән таныштырганнар, гарәп, латин һәм кириллица графикасын укырга өйрәткәннәр. Ә 1917 ел инкыйлабына кадәрге чордан сакланып калган тарихи ядкарьләребез гарәп хоруфатлы икәнен искә алсак, шәкертләргә бер үк күләмдә өч графиканы өйрәтү, борынгыдан килгән мәдәният чылбырын өзмичә, язма мирасны бербөтен итеп үзләштерергә мөмкинлек тудыра. Аннан ул туган шәһәрендә совет дәреслекләре буенча белем бирә торган рус мәктәбен тәмамлый.

Төбәк килешүе нигезендә алынган концессия булган Голҗага төрле милләт, нигездә, төрки халык вәкилләре – казакъ, кыргыз, үзбәк, төрекмән һәм руслар килеп төпләнгән була. Олылар да, бала-чагалар да үзара төрле телләрдә аралаша. Мохитнең йогынтысы Миркасыймны да читләтеп узмый: ул төрки телләрне дә үзләштерә, рус телендә дә иркен сөйләшә. Ә ул өйрәнгән ана теле исә, чит-ят сүзләр дип игълан ителгән, шәркый мәдәни бәйләнышларның «шаһитлары» гарәп, фарсы төшенчәләреннән «чистартылмаган» була. Шуңа күрә ул хәзерге әдәби әйләнештән төшеп калган алынма сүзләрнең мәгънәви палитрасын үзе өчен балачактан ачкан.

Төрле катлам, төрле буын кешеләре белән мөгамәлә итүнең серләре дә аның канына халыклар «казаны» Голҗада табигый рәвештә сеңгәндер. Шул сыйфаты Миркасыймга төрле төбәкләрдә йөргән чакта, олыгайган апа-агайларга тел ачкычлары табарга ярдәм итә. Кадерләп саклаган язма ядкарьләрен алар чит-ят кешегә ышанып биреп җибәрә.

Ирекле шәхес булып формалашкан, җәмгыятьтәге вакыйга-мөнәсәбәтләрнең төрле булуына гына түгел, ә төрлечә бәяләнергә мөмкин икәнлегенә иртә төшенгән, эчке үзәгенең көче-ныклыгы бөркет карашында чагылган 24 яшьлек егет, Кытай чикләрен узып, казакъ далаларында тормыш тәҗрибәсе туплый. Советлар иле мәгариф системасы таләпләрен үтәп, кичке мәктәп тәмамлап, аттестат алгач, 1958 елда Көнбатышка, мәркәзи Казанга юл тота. Максаты – университетның тарих-филология факультетында татар теле һәм әдәбияты бүлегендә белем эстәү. Ихтимал, аның язучы буласы килгәндер...

Студент Миркасыйм күп яклары белән: бигрәк тә тормыш тәҗрибәсе, төрки һәм рус телләрен бер үк дәрәҗәдә әйбәт белүе, гарәби язмаларны су кебек эчүе,



*Татар халкы тарихы кафедрасында фикер алышкан чак. 1997 ел.*

XIX-XX йөз башында язылган әдәби әсәрләр, халкыбызның фольклоры, дастаннары белән балачактан таныш булуы белән төркемдәшләреннән күпкә аерылып торган. Ике курсны тәмамлаган бәйсез ихтыярлы егетнең Борынгы һәм Урта гасыр язма мирасыбызны тирәнтен өйрәнер дәрәҗәдә әзерлеге дә, җегәре дә барлыгын яхшы аңлаган укытучылары аңа факультетның тарих бүлегенә күчәргә тәкъдим итә. Бу бүлекне тәмамлап, ул моңарчы бирәү дә ирешмәгән «архивовед» дигән белгеч икәнлеге теркәлгән диплом ала.

М.Госмановның күпкырлы эшчәнлеген күздән кичергәндә, Анна Ахматованың тирән мәгънәгә ия «небывалая осень построила купол высокий» дигән сүзләре искә төшә. Сәләте, гыйлеме, максатчанлыгы буенча кавемдәшләре арасында тиңдәше булмаган, зыялы татар мохитендә күптән «күренмәгән» инсан – Миркасыйм ага Госманов – гомерен чыганакчылык, археография, историография, палеография һәм башка ярдәмчел тарихи фәннәр белән бәйли. Меңъеллык язма мәдәни мирасыбызны – борынгы кульязмаларны һәм күчермә китапларны – максатлы рәвештә эзләве, туфракка әйләнүдән коткарып, бер кулга туплавы, шул язма ядкарьләрне тирәнтен өйрәнүе белән ул тарих сәхифәләрендә җуелмас мәрмәри эз калдыра. Әлхасыйль, Миркасыйм аганың тюрколог-галим буларак чыганакчылык фәненә, тарих белеменә керткән өлеше, күренекле шәхесләребезгә багышланган фәнни-популяр китаплар сериясен әзерләү, бастырып чыгару эшен башлап җайга салуы һәм бүтән бик күп өлкәләрдә ирешкән казанышлары Казан шәһәренең, университетның, халкыбызның, ил-йортыбызның гөмбәзен киңәйтте һәм биегәйтте.

Ул – 470кә якын хезмәт авторы, бу санга монографияләр, мәкаләләр, тәрҗемәләр, истәлекләр, юлъязмалар керә. Шулар исәбеннән ике зур фәнни иҗади әсәре – «XVII-XVIII йөздәге татар тарихи чыганаклары» (Казан, 1972) һәм «XIV-XVI йөздәге Җүчи олысының ярлыкаш актлары» (Казан, 1979) аны чын галим итеп дөньяга танытты. Нәкъ менә телгә алган шушы китапларда тарихчының профессиональ йөзен билгеләгән сыйфат: чыганакны укый, аңлата, анализлый һәм информатив мөмкинлекләрен көтелмәгән яктан ача белү осталыгы бар тулылыгы белән чагыла. Бу монографияләрендә ул кульязмаларны ориенталистлар моңарчы мөрәҗәгать итмәгән, гамәлдә кулланмаган революцион методик алымнар ярдәмендә тел, хронология, текстология, кодикология, палеография, сфрагистика, дипломатика кебек фәннәр күзлегеннән чыгып җентекләп өйрәнә. Аларда китерелгән мәгълүматның ни дәрәҗәдә дөрес


*Миркасыйм Госманов белән Искәндәр Гыйләҗев. 2004 ел.*

хәбәр бирүләрен дәлилле итеп ачыклый. Фәнни эзләнүләре белән төрки халыкларның олы тарихының асылын ачып, әтрафлы итеп тасвирлауга, Россия дәүләтенең тарихи җирлеген ачыклауга, татар дәүләтчелеге – Җүчи олысы тарихын объектив бәяләүгә нигез тудыра. Билгеле, гаҗәеп күпкырлы эшчәнлеген, шәхесе масштабын, дөньяга карашын, стратегик фикере мантыйгын тояр-колачлар өчен галимнең хезмәтләрен укырга-өйрәнергә кирәк. Бу кыска язмада Миркасыйм аганың мәдәният тарихында, иҗтимагый тормышта тоткан урынын тәфсилле яктырту мөмкин дә түгелдер. Максатыбыз аның кеше, шәхес буларак кайбер сыйфатларына гына тукталуга кайтып кала. Бәхәссез ки, еллар узган саен тарих, археография, әдәбият белеме, чыганакчылык, текстология өлкәсендә һәм дә публицистикада ул биләгән «тәхет» югарырак, биеккәрәк күтәрелә барачак. Аның эшчәнлеген җентекләп анализлау, һичшиксез, киләчәктә күләмле махсус монография кысасында башкарылыр.

Миркасыйм ага, аспирантураны тәмамлагач (1964–1967), хезмәт юлын университетта СССР тарихы кафедрасы ассистенты буларак башлый, тиз арада өлкән укытучы, аннан доцент итеп сайлана, кандидатлык һәм докторлык диссертацияләрен яклый, доцент һәм профессор дигән фәнни дәрәҗәләр алуга ирешә. Россия тарихы, татар палеографиясе, Идел-Урал буе халыклары тарихы чыганаклары буенча дәресләр алып бара.

Фәнни һәм укытучылык эшчәнлегеннән тыш, аңа административ вазифалар да йөкләнә: ул тарих факультеты деканы урынбасары, кафедра җитәкчесе, Казан дәүләт университетының уку-укыту эшләре буенча проректоры (1985–1991) итеп билгеләнә һәм вакытлыча ректор вазифаларын да башкара.

Миркасыйм аганың исемен еш кына «беренче», «яңа» дигән төшенчәләр белән төрләндерәләр иде. Дөрестән дә, ул инициативалы, төрле яңалыкка юл ячучы булды, алга карап яшәде. Әйтик, 1878 елда Казан университеты каршында барлыкка килгән «Археология, тарих һәм этнография җәмгыяте»нең күркәм традицияләрен тергезеп, РСФСРның татарлар яшәгән төбәкләренә археографик экспедицияләр оештыру зарурлыгын ул күтәреп чыга. 1963 елда максатчан эзләнүләрдә гади катнашучы ролен башкарса, 1964 елдан башлап 25 ел дәвамында экспедицияләрне үзе җитәкли. Университет китапханәсенә саклануга 10 меңнән артык төрле шәркый, шул исәптән татар телендә иске имляда язылган китаплар күчермәләрен һәм кульязмалар алып кайтып тапшыра. Ул гына да түгел, борынгы кульязмаларны тасвирлый һәм тирәнтен өйрәнә алырдай белгечләр әзерләү мәсьәләсен университетның Гыйльми советында күтәреп чыга.

Ул заманда китапханәнең кульязмалар сакланган бүлегендә дүрт хезмәткәр эшли иде, шуларның икесе (Альберт абый Фәтхиев һәм Диләрә апа Абдуллина) – Шәрык секторында. Алар уку залында дежур тора, экскурсияләр алып бара, төрле белешмәләр төзи, күргәзмәләр оештыра, гомумән, вазифалары бихисап иде. Билгеле, гарәп хуруфатындагы татар телле кульязмаларны алар һәрдаим тасвирлый килделәр, ә гарәп, фарсы, монгол, госманлы, кытай телендә язылганнарын сыйфатлы теркәү эше,



*Сулдан уңга: Разил Вәлиев, Миркасыйм Госманов, Надир Дәүләт, Марсель Галиев. 2009 ел.*

нигездә, киләчәккә кала барды. Шушы хәлдән чыгу юлын эзләп, Миркасыйм ага 1986 елда университетның Фәнни-эзләнү бүлеге каршында археографик төркем оештырды, 1988 елда бу төркем нигезендә археографик фәнни эзләнү лабораториясен ачуга иреште. Казан университетының тарих факультетын, Ленинград университетын тәмамлаган, шәркый кулъязмаларга «керә» алырдай яшьләрне, тәҗрибә туплаган аксакалларны да шул лабораториягә эшкә җәлеп итте.

Тарих факультетына кергән абитуриентлардан Татарстан тарихы буенча белгечләр әзерләү өчен махсус төркем оештыруны тәкъдим итүче һәм бу ниятне гамәлгә ашыручы да, шул студентлар белән 21 елдан артык (1968–1989) җитәкчелек итүче дә ул булды.

Университетта яңа факультетлар – экология факультеты, татар филологиясе, тарихы һәм көнчыгыш телләре факультетын ачу да аның исеме белән бәйле. Миркасыйм ага Казан университетында татар халкы тарихы өйрәнелмәве гайре табигый хәл икәнен исбатлап, университетның Гыйльми советында махсус доклад ясый. Күренекле профессорлар физик Борис Кочелаев, математиклар Борис Лукич Лаптев белән Рәис Гатич Бухараев, юрист Давид Исаакович Фельдман һ.б. үз чыгышларында аңа теләктәшлек белдерәләр, хаклы булуын раслыйлар. Нәтиҗәдә, 1988 елда ул үзе 1982 елдан башлап җитәкләгән Совет чорына кадәрге СССР тарихы кафедрасының бер төркем укытучыларыннан торган аерым татар халкы тарихы кафедрасын оештырды һәм аны 2002 елга кадәр җитәкләде. Соңрак ул Татарстан Республикасы Фәннәр академиясен оештыруда да актив катнашты.

1980 нче елларда ВУЗ укытучылары көнкүрешенә төрле технологик казанышлар керә башлады. Кафедраны барча кирәк-ярак белән университет тәэмин итсә, археографик лабораториягә исә Миркасыйм ага үзе откан грант акчасына компьютер, сканер һәм принтер алдырды. Юкса башкача да эш йөртү мөмкин иде, ә ул лаборатория хезмәткәрләренә эш шартлары тудыруны кирәк тапты. Ул гына да түгел, кафедрага механика-математика факультетыннан яшь укытучыны чакырып, заманнан калышырга ярамый дип, барыбызны да компьютер белән таныштыруны да оештырды.

1980 нче елларда университетка Германиядән, Кубадан студентлар, ә 1990 нчы елларда Германиядән, Венгриядән, Төркиядән, Тайваньнан һәм башка илләрдән стажировкага, аспирантурага, Миркасыйм абый җитәкчелегендә диссертация язарга ниятләгән яшь белгечләр, конференцияләрдә катнашу максатыннан галимнәр килә башлады, чит ил университетлары белән элемтәләр урнашты. Безнең офыкларыбызны киңәйтү йөзеннән, инглиз, алман телендә чыккан әдәбиятны укый алырлык дәрәҗәгә җиткерү максатыннан Миркасыйм ага тарих һәм татар халкы тарихы, әдәбияты һәм көнчыгыш телләре факультетлары укытучылары өчен инглиз һәм алман телләре курсларын оештырды, Германиядән килгән Маргарет ханым төрек теленнән дәресләр бирде. Бу башлангычның матур нәтиҗәләре озак көттермәде, укытучыларыбыз чит илләрдә стажировкалар узды, фәнни проектларда катнашты, чит ил архивларында эзләнүләр алып барды.

Миркасыйм аганың кыяфәте кырыс, аның күз карашыннан күпләр куырылып килә, хәтта тотлыга башлый иде. Гаҗәеп әсмани көчкә ия карашында иреклe, имгәтелмәгән рухы, үз-үзенә ышануы, иманы-дене, үз дәрәҗәсен белүе чагыла. Эчке энергетикасының җегәренә, җитмәсә, кысылган иреннәре арасыннан авазларны өстәмә көч биреп иреккә чыгаруы да өстәлсә, аның тирәли ниндидер күзгә күренми торган өрфия божра хасил булгандай тоела башлый иде. Ул божраны күпләр үтә алмады. Ә үтеп чыгу насыйп булганнар исә, туры сүзле, хаклыкка тугры, яшьрәк чакта кызып та киткәли торган, чын ир-егет сыйфатларына ия бу гаҗәеп «җылы» кешене, мәрхәмәтле укытучы, киң эрудицияле остаз, искитмәле шәп җитәкче буларак искә аладыр. Вакланмас, сүз җыймас, тикшереп бимазаламас, хисап тотар вакыт җиткәч кенә эш нәтиҗәсе белән кызыксыныр. Кирәк икән, һәркайсыбызны аерым чакырып алып, «талкып» ташлар, тик андый очраклар һәрвакыт уртак бер сер булып кала килделәр.

Үзе туплаган коллектив әгъзалары һәм укучылары гына түгел, аның белән хезмәттәшлек иткән һәркемне аңа рәхмәтле иткән тагын бер мөһим сыйфаты – аның җаваплылыктан курыкмавы булды. Миркасыйм абый кул астында эшләгән хезмәткәрләр аның «киң» җилкәсе ышыгында аларның мәнфәгатьләрен, иминлекләрен кайгыртучы, «хәвеф-хәтәрдән яклаучысы» бар икәнен белә, аның аталарча мөнәсәбәте чагылышын җәмәгате Салисә апаның, кызлары Айсылу белән Диләрәнең мөгамәләсеннән дә чамалый иде.

Әңгәмәдәшен ул «магнитлый» һәм ара калдыра белде. Кешене ул һәрчак игътибар белән бүлдермичә, «Флотский» тәмәкесе тутырылган төрепкәсен суыра-суыра тыңлый (исәнлеге какшагач, ул фильтрлы сигаретка күчәргә мәҗбүр булды), кирәк булган очракта әңгәмәдәшенең буталчык фикерен тәртипкә салырга ярдәм итә. Аналитик акыл, зирәклек, фикерләү иҗтиһадлыгы Миркасыйм агага табигать тарафыннан бирелгәнгә күрәдер инде, аның белән киңәшергә теләүчеләр, теге яки бу проблемага карата фикерен ишетүгә мохтаҗлар, интервью алу максаты белән килүчеләр – аспирантлар, галимнәр, язучылар, журналистлар – галимнең кабинетыннан өзелмәде. Хәтта кафедра әгъзалары көндәлек мәшәкать-сорауларны чишү максатыннан мөдирнең хәер-фатихасын алыр өчен чират көтәргә мәҗбүр иделәр. Ул проректор булып эшләгәндә дә гозер белән килүчеләр үзләрен борчыган проблемаларның уңай чишелешен табып чыгуларын секретарь ханымның гаҗәпләнеп бәян иткәне байтак булды.

Үзен көтеп торучылар булмаганда, тәнәфестә яисә лекция тәмамлангач, кафедрага кергән укытучыны кабинетына чакырып гәпләшергә дә ярата иде ул. Кәефенә, ачыкланырга тиешле сорауның асылына карап, эндәшүе төрлечәрәк яңгырар. Альта Хаҗиевна Мәхмүтовага ул гел бертөрле, үз итеп, «әйдә әле» дияр. Башкаларга исә, мөмкин кадәр кырыс кыяфәт чыгарып: «Кереп чык әле» – дисә, җитди сөйләшү көтүен аңлап була, әгәр «әйдә, җегетем» яисә миңа: «әйдә, марҗа, кер әле» дип чакырса, Миркасыйм абыйның кәефе шәп, димәк, ниндидер хезмәтен тәмамлап килгән. Андый вакытта Кандалый, Акмулла (аларның әдәби мирасларын ул, өйрәнеп, басмага әзерләде), Дәрдемәнд, Утыз Имәни кебек һәм без бөтенләй хәбәрдар булмаган шагыйрьләрнең шигырен укыр, «Йә, кем язган?» дип «имтихан» алыр, җавап бирә алмагач, өметен өзеп, кулын селтәр дә үзе яңа нокта куйган мәкаләсендәге төп фикерләрен тасвирлар һәм... реакция көтәр иде.

Бер ара, чит ил галимнәре персональ чакыргач, ул конференцияләргә еш барды. Әйләнеп кайткач, кафедра утырышында кайда булганын, кайсы галим нинди темага чыгыш ясавын, ишеткән-күргәннәрен тәфсилләп сөйләр, сувенирлар өләшер, тыңлаучылар исә ул алып кайткан күчтәнәчләр белән чәйләп алыр иде. Миркасыйм ага, гомумән, сәяхәткә бик теләп кузгалучанлыгы белән аерылып торды. «Мин учыма укмашкан кан йомарлап туганмын», – дия иде. Кендек әбисе: «Бу бала илләр гизәр», – дип әйткәнен, ярым шаяртып, хатирәләрен яңартып алганы да булды. Кем белә, юкка гына борынгы төрки халыклар, монголлар, венгрлар Тәңренең тамгасы белән туган

мондый бала сәмави фатиха хозурында яшәячәк дип ышанмагандыр. Бәлки шуңа күрә Миркасыйм абый тотынган эш һәрчак йогышлы, Күк ихтыярыннан җилкенеп, нәтиҗәле тәмамлангандыр да...

Аның фән өлкәсендәге абруен күзаллау өчен тарих һәм филология өлкәсендә докторлык һәм кандидатлык дәрәҗәсе бирү буенча җәмгысе җиде гыйльми совет әгъзасы, республикабызның Милли китапханәсе һәм Милли музее советлары, Россия Фәннәр Академиясенең Археографик комиссиясе әгъзалары булуын, 1998-1999 елларда аңа Россия Фәннәр академиясенең Көнчыгышны өйрәнүчеләр җәмгыятенең президенты вазифалары йөкләнүен, Татар энциклопедиясенең фәнни редакция коллегиясе рәисе, Тарих институты гамәлгә ашырган җиде томлык Татар тарихын әзерләүдә редколлегия әгъзасы, төрле журналлар редколлегиясе, төрле мәхкәмәләрдә (театр, китапханә, шәһәр советы) фәнни консультант булуын әйтеп узу да җитәдер.

Миркасыйм ага Госмановка бирелгән исем-дәрәҗә-бүләкләр дә шактый. Ул – «Татарстан Республикасының атказанган фән эшлеклесе» (1984), «Россия Федерациясенең югары белем бирү атказанган хезмәткәре» (2003), «Казан университетының атказанган профессоры» (2004). Галим ирешкән казанышларны гадел бәяләү күрсәткечләре арасында «Казанның меңъеллыгы истәлегенә» (2005), Республиканың «Фидакарь хезмәт өчен» медальләре, Халыкара даими алтаистика конференциясенең (PIAC) Алтын медале (2008) дә бар. Ниһаять, ул мөселман халыклары мәдәниятен өйрәнүгә керткән өлеше өчен Ислам конференциясе оешмасы каршындагы Халыкара тикшерү үзәге (IRCICA) тарафыннан 2008 елда бүләкләнгән өч кешенең берсе була. Җәмәгатьчелек тарафыннан аңа «татар мәгърифәтчесе» дигән исем бирелү дә очраклы түгел. Чөнки аның кылган гамәлләре, фәнни, әдәби эшчәнлеге халык ихтыяҗларын канәгатьләндерү максатыннан башкарылды. Үзе әйткәнчә, ул «сүз урынына эш кирәк» дигән кредога буйсынып яшәде. «Җаның теләгән эш белән шөгыльләнү – үзе бер ял», – дип әйтә иде...


2010 елның октябрендә татарның асыл улы, күз угында торткан бихисап эшләрен тәмамламыйча, ял итәргә өйрәнә алмыйча, безнең арадан китеп, мәңгелеккә, мәдәниятебез тарихына ашты. Чын фикер иясе Миркасыйм агага булган хөрмәт-ихтирам хисе вакыт узган саен ныгыр, тирәнәя-киңәя барыр, чөнки ул калдырган иҗади һәм фәнни мирасның асылына, еллар үткәч, нәтиҗәлерәк төшенербез шикелле.

**Динә МОСТАФИНА,**
*Казан (Идел буе) федераль университетының Татарстан тарихы, антропология һәм этнография кафедрасы доценты.*

# САЛЛЫ ХЕЗМӘТ

Милләтнең үзаңын саклауда һәм үстерүдә тарих мөһим вазифа үти. Танылган тарихчы Җәүдәт Сәлим улы Миңнуллин халкыбызның шанлы үткәнен өйрәнүгә зур өлеш керткән шәхес буларак билгеле.

2023 елда Татарстан китап нәшриятында аның мәкаләләре тупланган җыентык* дөнья күрде.




Әлеге хезмәткә галимнең татар, рус, төрек телендәге язмалары кертелгән. Алар үз чорында вакытлы матбугатта: «Казан утлары», «Ялкын», «Совет мәктәбе» (хәзерге «Мәгариф»), «Азат хатын» (хәзерге «Сөембикә»), «Безнең мирас», «Татарстан», «Народы Азии и Африки» (хәзерге «Восток») журналлары, «Татарстан яшьләре» газетасы битләрендә дөнья күрә.

Мәкаләләр тематик яктан 5 төркемгә бүленгән. Татар тарихы, археографик эзләнүләр, татар шәхесләре, китапханәләр, хәйриячелек мәсьәләләренә багышланган язмалар китапның эчтәлеген тәшкил итә.

Китап фотосурәтләр белән дә баетылган. Фотолар ярдәмендә төрле елларда уздырылган археографик экспедицияләр барышы белән танышырга мөмкин. Шул җөмләдән, Җәүдәт Миңнуллин җитәкчелегендә уздырылган археографик экспедицияләргә дә күз салып була. Сурәтләр арасында фәнни конференцияләрдә ясалганнары да бар.

«Татар тарихы сәхифәләреннән» дип аталган бүлеккә халкыбызның тарихы хакындагы мәкаләләр тупланган.

«Крепостнойлык тарихыннан бер сәхифә» исемле мәкаләдә Ж.Миңнуллин «татарларда крепостнойлык бөтенләй булмаган» дип исәпләгән кешеләргә киресен дәлилли. Шуның өчен ул бер мисал китерә: «Атаклы тарихчы һәм фикер иясе Шиһабетдин Мәрҗани бастырып чыгарган һәм шушы көнгә кадәр шундый бердәнбер татарча документ дип саналган 1788 елгы хосусый акттан күренгәнчә, Казанның Иске Бистәсеннән йомышлы татар Йосыф Динмөхәммәт улы шул ук бистәнең Исмәгыйль Апанай Хафиз улына 100 сум бәрабәренә 5 крепостноен, җирен һәм печәнлекләрен сата».

Галим крепостнойлык мәсьәләсенең аз өйрәнелүе хакында да искәртеп уза.

Аеруча зур кызыксыну уяткан мәкалә «Ялкын»ның өч абыйсы» дип атала. 1994 елда язылган бу мәкалә журналның 70 еллыгына багышланган. Язмада тарихчы Октябрь революциясенә кадәр үк даими басылып торган балалар журналлары турында мәгълүмат бирә: «1907 елда беренче карлыгач, «Ялкын»ның тәүге абыйсы – «Тәрбиятел этфаль» («Балалар тәрбиясе») дөньяга килә. Ул Мәскәүдә 1907 елның 1 гыйнварыннан 1 мартына кадәр чыгып килгән. Журналның мөхәррире һәм нашире – Мөхәммәдзаһит Шамил,

* Төзүчесе – Ләйсән Миңнуллина.

ә җаваплы сәркатибе классик язучы Фатих Әмирхан була.

«Ялкын»ның уртанчы «абыйсы» – шигъри исемле һәм бай эчтәлекле «Ак юл» журналы Казанда 1913 елда чыга башлый. Ул Фәхрелислам Агиев наширлегендә һәм мөхәррирлегендә дөнья күрә. Журнал 1916 елда чыгудан туктый.

1917 елның март аенда Казанда «Балалар дөньясы» журналы – «Ялкын»ның кече «абыйсы» дөнья күрә. Журналның сигез саны гына билгеле».

Җыентыкта шулай ук татар халкының мигъмарият җәүһәрләре турында да кызыклы мәгълүмат бирелә. Үзенең мәкаләләрендә Җ.Миңнуллин Кече манара, Кара пулат турында яза:

«Кече манара – Шәһре Болгарның хәзерге вакытта чагыштырмача яхшы сакланган тарихи-архитектура истәлеге. Риваятьләрдә сөйләнгәнчә, манара «изге болгарлар» җирләнгән урында төзелгән һәм тирә-юньдәге төрбә-мавзолейлар белән бербөтен корылмалар комплексын тәшкил иткән. Манара янындагы каберлек татар риваятьләрендә «Хан зираты» дип тә йөртелә.

Кара пулат. Бу серле һәм мәһабәт бина Шәһре Болгарда гына түгел, ә бәлки илебездә Урта гасырлардан калган иң күренекле тарихи-архитектура ядкарьләреннән санала. Бина XIV гасыр урталарында төзелгән. Ни өчен бинаның исеме «Кара пулат»? Бу исем каян килеп чыккан? Риваятькә мөрәҗәгать итик: дәһшәтле хөкемдар Аксак Тимер Шәһре Болгарны яулап ала, халыкның олысы-кечесе кылычтан үтә. Болгар ханы Габдулла гаиләсе белән әлеге бинага кереп бикләнә. Канечкеч илбасарлар, бинаны бүрәнәләр белән әйләндереп алып, ут төртәләр. Хан гаиләсе һәлак була. Шулвакыт мәйданга җыелган халык бина түбәсенә менеп баскан ханның зирәк һәм искиткеч гүзәл төпчек кызын күрә. Аксак Тимер кызны үзенә хатынлыкка алырга теләвен белдерә. Ләкин горур кыз бу тәкъдимне кире кага. Әмма дошманнарга әсир төшкән абыйларын күргәч, аларны коткару өчен Аксак Тимергә ризалык бирә. Утны сүндерәләр, кыз куйган шарт буенча, ике абыйсына да яхшы аргамак бирәләр. Атка атланган абыйлары күздән югалгач, батыр кыз янып бетмәгән бүрәнәләр өстенә сикерә. Бинаның каралыгы риваятьләрдә әнә шулай аңлатыла. Әмма бинаның Кара пулатка әверелү сәбәбе башкада: XVIII гасырда рус монахлары, бу бинаны үз хаҗәтләренә җайлаштырып, Казан, Тәтеш һәм Спас базарларында сату өчен балык, дуңгыз ите ише нәрсәләр ыслаганнар. Андый эшләрдән соң бина кара сөремгә батмыйча калмаган, әлбәттә».

Кайбер мәкаләләрен, нигездә, Уфа белән бәйле булганнарын, Җәүдәт Миңнуллин Хәсән Гобәйдуллин белән берлектә яза. Әлеге тандемның иҗат җимеше буларак берничә мәкалә өлгергән: «Галия» мәдрәсәсе», «Истәлекле бина», «Шәрык» матбагасы», «Уфа татар гимназиясе», «Аксаков йорты», «Госмания» мәдрәсәсе», «Җәйге театр».

Җәүдәт Миңнуллинның фәнни дикъкатен хәйриячелек, иганәчелек, меценатлык мәсьәләсе аеруча җәлеп итә. Һәм бу хәл бер дә гаҗәп түгел, җәмгыятебез хосусый милек белән базар мөнәсәбәтләренә корылган икътисадлы дәүләттә көн күрә башлагач, хәйриячелек, меценатлык мәсьәләсе аеруча калкып чыга. Бу хәл бүгенге көндә дә дәвам итә. Безнең чорыбызда, XX гасыр башындагы кебек үк, иганәчелек канат җәергә тиеш. Җ.Миңнуллинның бу теманы яктыртуы бер дә очраклы түгел. Галимнең күп кенә мәкаләләре шул темага багышланган: «Добрые люди из Заказанья», «Проблема вакфа: история и современность», «Золотопромышленники Рамиевы». Әлеге мәкаләләр «Из истории татар» бүлегендә урын алган. Ул бүлектә рус телендә язылган мәкаләләр тупланган.

«Археографик эзләнүләр. Археографические изыскания» бүлегендә урнаштырылган «Мирас бөртекләп җыела» дигән мәкалә Р.Мәрданов белән берлектә язылган:

«Инде килик сәфәребезнең төп максаты булган кульъязмаларга. Табышларыбыз гадәти, традицион характердагы ядкарьләрдән гыйбарәт. Аларның мәгълүм өлешен дини язмалар, кульъязмалар

алып тора. Коръән Кәрим, Һәфтияк, төрле күләмдәге догалыклар, пәйгамбәрләр тарихына багышланган язмалар, дини васыятьнамәләр, бөтиләр, салаватлар – әнә шундый ядкарьләр. Мондый кульъязмалар халкыбыз яшәгән һәр төбәктә табыла, һәм бу табигый да. Икенче зур төркем – әдәби мирасыбыз үрнәкләре. Алар арасында Әбелмәних Каргалый, Һибәтулла Салихов, Габделҗәббар Кандалый, Мифтахетдин Акмулла, Муса Җәлил кебек татар әдәбиятында тирән эз калдырган күренекле каләм ияләренең әлегә кадәр билгеле һәм билгеле булмаган әсәрләренең күчермәләре, аларның тәрҗемәи хәлләренә кагылышлы башка язма чыганаклар да бар».

Җыентыкның зур күләмен татар шәхесләренә багышланган бүлек алып тора. Әлеге бүлектә Сабир Алимов, Нәкый Исәнбәт, Ризаэддин Фәхретдин, Муса Җәлил, Фазыл Туйкин, Багъбостан Мөэминова, Шакир Мөхәммәдиев, Фатих Кәрими, Җәүдәт Фәйзи, Дәрдемәнд, Шиһабетдин Мәрҗани, Ибраһим Хәлфин, Вәли Зәбиров, Миркасыйм Госманов, Мифтахетдин Акмулла, Исмәгыйль Гаспралы исемнәре яктыртыла. Шиһабетдин Мәрҗанигә багышланган мәкаләдән өзек китерик: «Халыкта, баланың азрак шаян һәм шук булуын мактап, «Балаң булса – шук булсын, шук булмаса – юк булсын» дигән атаклы мәкаль бар. Сәламәт табигатьле Мәрҗани дә бала чагында шаяруны, уйнауны, шук уеннарны башлап йөрүне яраткан. Мәрҗанинең шуклыкларыннан түбәндәге вакыйга теркәлеп калган. Ул, кәгазьдән битлек ясап, карчыкларны куркытып йөри икән. Шулай бервакыт, битенә битлек куеп, берәүнең капкасы буена төшәргә дип, капкадан чыгып килә икән. Карчык, битлек кигән Мәрҗанине җен дип уйлап, куркуыннан кулындагы көрәге белән аның башына кундырган. Мәрҗани, бу вакыйганы исенә төшереп: «Күземә утлар күренде. Башым ярылды дип уйладым. Әле дә ярылмаган икән», – дип көлеп сөйли торган булган».

«Яшь чагында бик таза егет булган Шиһабетдин Мәрҗани, тирә-юньдәге авыл Сабан туйларында көрәшеп, үзен «Көрәшче Шиһаб» дип таныта. Авылдашлары – ташкичүлеләр – аның белән бик горурланганнар, күрше авылларда Сабан туйлары, җыеннар булганда, Баһаветдин хәзрәттән үзләре белән Мәрҗанине дә җибәрүне үтенгәннәр. Бары тик авылның диндар картлары гына «мужиклар белән көрәшеп, имгәнеп бетә» дип борчылганнар. Әмма Мәрҗани аларны тыңламый, Сабан туйларында көрәшүен дәвам итә. Бервакыт ул 19 яшьлек чагында, тирәякта «Ибрай батыр» дип даны таралган мәшһүр көрәшче белән бил алышып, Ибрай батырны җиңүгә ирешә. Көрәш мәсьәләсендә Мәрҗани үз кагыйдәләрен булдыра. Әйтик, ул егылганнар белән түгел, егучы баһадирлар белән көрәшүне яраткан. Үзеннән бер мәртәбә егылган кеше белән көрәшмәгән. Һәм үзен еккан кеше белән дә көрәшмәгән. Һәркемнән өстен, һәр җәһәттән беренче булырга яраткан Мәрҗани батыр кала алмаган Сабан туйларында начар кәеф белән йөргән».

Китапның чираттагы бүлеге «Китапханәләребез – халкыбыз байлыгы» дип исемләнгән. Җыентыкны «Хәйриячелек – цивилизацияле җәмгыятьнең асылы» бүлеге йомгаклый. Биредә XIX-XX гасырларда иганәчелек тарихы яктыртыла.


Китап ахырында автор турында мәгълүмат-белешмәлек урнаштырылган.

Әлеге саллы хезмәт атаклы галим Җәүдәт Миңнуллинның күпкырлы эшчәнлеген сурәтли. Җәүдәт Миңнуллин татар халкының тарихын өйрәнүгә зур көч куйган, һәм аның хезмәте һичкайчан онытылмас.

**Ихтыяр КЫЯМОВ,**
*Казан федераль университетының I курс студенты, КФУның «Рухият» түгәрәге әгъзасы, татар теленнән X Халыкара олимпиаданың Гран-при иясе.*

# МӘҢГЕЛЕК САГЫШЛАР ЯРЫНДА...

Рәмис Аймәт шигърияте бүгенге татар поэзиясендә үзенең фикер колачы белән дә, сәнгати эзләнүләре, жанр мөмкинлекләре ягыннан да үзенчәлекле урын тота. Аның иҗаты күңел лирикасын, фәлсәфи һәм гражданлык лирикасын да, публицистик поэзия үрнәкләрен дә, истәлекләрне дә колачлый, татар шигъриятендә шагыйранә илһам чыганагы булган мәхәббәт, туган авыл, туган җир, милләт, туган тел язмышы – аның иҗатында сызлану һәм сагыш объектына әверелә. Шуңа да сагыш, сызлану һәм чарасызлык мотивлары Рәмис Аймәтнең поэзиясен үтәли сызып бара. Әмма бу татар поэзиясенең һәр этабында күз уңында булган тема-мотивларны, кичерешләрне ул моңа кадәр чарланган алымнар белән түгел, үзенә генә хас эзләнүләр, үзенчәлекле образ-сурәтләр ярдәмендә ача, яңа экспериментлар ясый. Ул кеше йөрәгенең аң-акыл белән танып, аңлап бетереп булмаслык киңлекләренә барып чыга, инсани рухтагы шул биеклек, бөеклекләр турында җырлый. Шуңа да Рәмис Аймәт татар поэзиясендә һәрдаим эзләнүчән, тынгысыз, идея-эстетик дәрәҗәсе югары булган затлы поэзия вәкиле булып калка. Аның иҗатының йөзен билгеләгән бу сыйфатлар «Мәңгелек сагыш» (2023) китабында да актуальлеген югалтмый.




Әлеге җыентыкта шагыйрьнең соңгы елларда язылган күңел лирикасы, фәлсәфи лирика һәм гражданлык лирикасы үрнәкләре тәкъдим ителә. Гражданлык лирикасында иң төп мәсьәләләр булып тел, милләт, халык тормышына бәйле проблемалар күтәрелсә, күңел лирикасы үрнәкләрендә лирик геройның шәхси кичерешләре үзәккә алына, фәлсәфи лирикада шагыйрь кеше дигән олы затның яшәү мәгънәсе нидә, без дөрес юлдамы, нигә болай дигән сорауларга җавап эзли. Әмма боларның бөтенесен мәңгелек сагыш мотивы, чарасызлыкта калган, сызланган, ялгызак лирик герой һәм олы югарылыкка ия Сүз, шигърият, гамь бергә туплый. Юкка гына җыентык «Егылма, Сүз! Түз....» юллары белән ачылмый. Сүзгә егылма, сыгылма, елама дип мөрәҗәгать итү аша шагыйрь бу дөньяда кешенең генә түгел, олы хакыйкатькә ия Сүзнең дә чарасызлыкка тап булуы турында сөйли. Тәүраттан алынган «Әүвәл булган Сүз» юлларының эпиграф итеп куелуы, шигырь текстында кабатлануы Сүзне илаһи югарылыкка күтәрә һәм кешелек җәмгыятендә илаһи күренешләрнең дә кыйммәте югалуын сурәтләү аша шигырьдән алган тәэсирне көчәйтә. Шул ук вакытта шигырьнең беренче һәм соңгы юллары лирик геройның рухи кыйммәтләрнең югалмавына өметен «җемелдәтеп куя», шул өмет шигырьне каймалап ала:

*Егылма, Сүз! Түз! Сиңа дип язылган*
*ошбу гомер.*
*Дәвам ит юлың, яраңны кысыплар*
*бәйлим дә бер...*
*Тел очымда гел бер сүрә тибри:*
*«Әүвәл булган Сүз...»*
*Булырсыңмы Ахырда да җанга якын, изге, үз?*

Әлеге шигырьнең җыентыкны ачып

җибәрүе үзе үк укучыны фәлсәфи дулкынга көйли, әйтерсең лә *«Санаулы сәгатьләр / Текелди тек тә тек / Бу дөнья фани ул, / Хакыйкать – мәңгелек»* юллары аша мәңгелек кыйммәтләр, Хакыйкать хакында сүзнең беренчел булачагын искәртеп куя.

Фәлсәфи лирика үрнәкләрен хакыйкатьне эзләүче, мәңгелек кыйммәтләр хакында уйлап сызланучы лирик герой, ялгызак фәлсәфәче, хисләр ташкыны хакиме бер бәйләмгә туплый. Бу лирик герой яшәү мәгънәсен рух бөеклегендә, хакыйкатькә омтылышны саклап яшәүдә таба, әмма яшәештә, кешеләр тормышында үзенә фикердәшләр тапмый. «Үзсурәт» шигырендәге *«өнсез өмет үзәнендә өметен җуйган хыялый хыялсыз, өмет, ышаныч белән тулы автобусны көтеп, зар-интизар булган юлдашсыз юлчы, Ялгызлык чоңгылыннан чыгарга омтылып, өметсез өметкә кулын сузган Бөек Чарасызлык, Бәхет Сарае корырга талпынган тантаналы канат җиле, Хакыйкать белән Имансызлык көрәшендә хаклыкны көтеп тилмергән сабырлык чаткысының кодрәтле очкыны»* сурәтләре шушы ялгызак лирик геройның төрле халәтләре кебек кабул ителә. Кысыр вәгъдәләр, өметсез өметләр, хыялсыз хыяллар чолганышында яшәп тә, югарыга омтылу, Хакыйкатькә өмет белән карау – иң ихлас, кеше рухының бөеклеген саклап торган асыл сыйфатлар итеп күтәрелә. Рухи кыйммәтләрнең, олы омтылышларның кешелек тормышындагы яшәү кануннары белән бәрелеше лирик герой күңелендә сагыш һәм сызлануны китереп чыгара. Әмма шигырьдә бу халәт якты бер моң белән өретелә: рухи яктан бөек кеше яшәешне алга этәрерлек олы көчкә ия дип кабатлый шагыйрь, кодрәтле очкын образы шуңа ишарәли.

Шушы ук мотивлар шагыйрьнең «Рухка эндәшү» шигырендә дә үстерелә. Рухка адреслап язылган шигырьдә лирик геройның сагышы рухи коллык һәм чарасызлык белән аңлатыла. Күпнокталар, таләп итү тойгысы, Рухка аталган риторик эндәшнең кабатлануы хис-кичерешне киеренкеләндерә һәм үстерә, таләптән ялваруга, аннан кабат таләпкә, аннан лирик геройның өметенә күчеш шушы киеренкелекне, хис-кичерешләр алмашын тәэмин итә. Шигырьнең соңгы строфасындагы *«Бар әле безгә менәсе / Хыялым кыясына. / Ышанамын, шул кыяга / Исемем уясыма»* юлларында рух бөеклеген саклаган кеше генә хакыйкатькә ирешә һәм үз хыялларын тормышка ашыра ала дигән идея калкып чыга.

Җыентыкка тупланган күп шигырьләрдә Мәңгелек сагышның сәбәбе яшәешнең, кеше тормышының чиклелеге белән бәйләп куела. Мондый шигырьләрдә символлар, ассоциатив сурәтлелек актив кулланыла, кагыйдә буларак, шагыйрь су, йолдыз, күк, җил, чишмә, таң кебек романтик образ-символларга мөрәҗәгать итә һәм аларны яшәешнең чиклелеген, мәңгелекнең дәвамлылыгын җиткерүгә кора. Мәсәлән, «Миннән башка гына» шигырендә лирик герой кеше тормышының гаҗәп кыска, вакытлы булуы, мизгел эчендә югалуы турында сөйли. Аңардан соң да яшәешнең дәвам итүе, мәңгелек төшенчәләрнең генә түгел, матди кыйммәтләрнең дә яшәячәге (*«Дөнья һаман шулай дәвам итәр / Миннән моң да... алтын күгәрмәс..., Миннән соң да җиргә башын салып, / яңа орлык чыгар тишелеп...»), буыннар хәтеренең кыскалыгы («Киткәч кенә... Әгәр хәбәр салсам, / Таң җиленнән хәлем кем сорар?..») хис-кичерешне тагын да киеренкеләндерә. «Авыр сулый-сулый, җир өстендә / Кичке кояш беткәч сүрелеп, / Моңсагышка чумган тын бакчама / Ак күләгәм карар үрелеп»* юллары лирик геройның яшәүнең кыскалыгына сагышлануы, әмма язмышка, мәңгелек кануннарына буйсынырга мәҗбүр булуы турында сөйли. Авыр сулый-сулый, ак күләгә кебек образ-тезмәләр шуңа ишарәли. Ә инде шигырьнең соңгы строфасында «Миннән башка гына» тезмәсенең күпнокталар аша кабатлануы сызланулы сагышны соң дәрәҗәдә тирәнәйтә, укучыга уйлану өчен урын калдыра.

«Хушлашу» шигыре дә беренче карашка мәхәббәттән китү кебек аңлашылса да, яшәешнең чиклелеге мотивына корыла. Сүнеп барган учаклар – гомернең

кыскалыгын, бу җирдәге яшәешнең чиклелеген ассызыклый. «Эзләмәгез мине...» шигырендә дә сагыш кеше гомеренең чиклелегенә бәйле ачыла. Әмма шигырьдәге китү үлем мәгънәсендә кабул ителми, ә кешеләр арасында, кешеләр тормышында аңлау, яклау, теләктәшлек тапмаган индивидуалист, ялгызак шәхеснең үз хыяллары дөньясына юл алуы кебек аңлашыла. *«Эзләмәгез мине, беркайчан да эзләмәгез мине»* гыйбарәләрен кабатлау, билгесез затка риторик эндәш, күпнокталар, бер яктан, хис-кичерешне киеренкеләндерүгә юнәлтелсә, икенче яктан, кешеләр арасында аңлау тапмаган ялгызак лирик геройның үпкәсен, әчке газапларын, яшәеш кануннарына кагылышлы фикерләрен калкыта:

*Сагындыгызмы?.. Сагынырсыз!*
*Мин башка шул, башка оядан.*
*...Эзләмәгез мине беркайчан да,*
*Кайтмаска (!) дип киттем Дөньядан!..*

Әнә шулай яшәүнең кыскалыгы, шушы бер көнлек фани дөньяда хакыйкатьтән читләшү, рухи кыйммәтләрне югалта бару, имансызлык, гаделсезлек, ялган, мәкер, икейөзлелек белән очрашу, кешелекнең туры юлдан читләшүе, яшәү мәгънәсен югалтуы, яшәеш дигән олы юлда упкын алдында, билгесезлек чоңгылы каршында калуы мәңгелек сагышның сәбәбе булып калка.

Икенче бәйләм шигырьләрдә телгә мөнәсәбәт, милләтнең битарафлыгы, милләт җанының үлеме шагыйрьне мәңгелек сагышка сала. Милләт язмышы мотивы ачык беленеп торган шигырьләрдә тел язмышын, туган халкы тарихын үз күңеленә сыйдыра алган лирик герой алга чыга. Мисал өчен, «Гыйбрәт булсын сезгә бу югалту» шигырен алсак, төн, упкын, сазлык, канлы канатлар, авыз тулы кара кан образлары, «бөек идем, боек итәм» кебек контраст сурәтләр татар теле язмышына, шуңа бәйле лирик герой халәтенә бәя бирүгә юнәлтелә. Татар теле исеменнән сөйләү, шигырь текстындагы әрнү хисенең дә татар теленең кичереше буларак җиткерелүе һәм татар халкының үзенә карата булган мөнәсәбәтенә бәйле ачылуы текстны киеренке дулкынга көйли.

«Йолдыз ташы» шигырендә текстның беренче өлешендә бирелгән йолдыз ташы образы татар язмышына метафора төсен ала. Таш образы, бер яктан, җимерелгән татар тарихына, икенче яктан, татар халкының ныклыгына, өченче яктан, язмышының авырлыгына ишарәли. «Бүрелек» шигырендә бүре образы аша автор татар халкының яшәешендә алга торырга тиешле төп сыйфатлар итеп Акыл, Бердәмлек, Тугрылык, Гаделлек кебек сыйфатларны калкыта. Татар халкының шушы сыйфатларны югалтуы сызлану катыш сагыш тудыра. Яисә «Безнең язмыш» шигырендә татар халкының язмышы кара елан, кара дулкын, ялгыз күке кебек символик образларга бәйле ачыла. Милләт язмышына бәйле текстларда Р.Аймәт Тукай образын да шушы яссылыкта ача. Мәсәлән, «Тукай карашы», «Ишетелә Тукай ютәле» кебек шигырьләрдә Тукай тавышы, Тукай ютәле кебек образ-сурәтләр, бер яктан, милләт язмышын ачып бирсә, икенче яктан, татар халкын яклаучы, саклаучы, кисәтүче, татар укучысын татлы йокысыннан уятучы кебек мәгънә төсмерләрендә уйнатыла.

Китапка тупланган күп кенә гражданлык лирикасы үрнәкләренең лирик героен «Тормыш поезды» шигырендәге *«Чылбырланган вагоннарда барган зынҗырлы җаннар»* гыйбарәсе белән характерлап булыр иде. Бу лирик герой дөньяны үзгәртә алмавы, җәмгыятьтәге яшәеш кануннарының камил булмавы өчен сагышлана, мондый яшәешне җәза дип атап, һәркемнең тормыш поездында Сагыш дигән тукталышка килеп җитәчәген искәртә. Мисал өчен, Г.Тукайның «Өй түрендә җил елый...» юлларын эпиграф итеп алган «Гыйбрәтле сынау» шигыре таҗлы вирус, интернетка бәйлелек кебек җәмгыятьтәге «заман чирләре»нә мөнәсәбәт белдереп язылган. Кешенең алар каршында көчсез булуы, чарасызлык сагышка этәрүче төп сыйфатлар төсен ала. Интертекстуаль бәйләнешләргә корылган шигырьдә Тукай иҗатына мөрәҗәгать аша шагыйрь «җил елау»ның үзгәрмәвен,

бары сәбәпләренең генә башка булуын искәртә.

Күңел лирикасы, табигый ки, лирик геройның үз халәтен, үз кичерешләрен, күңелен борчыган шәхси хис-тойгыларны укучыга җиткерә. Шуңа да мондый шигырьләрдәге Сагыш авторның үз шәхси кичерешләре белән тыгыз бәйләнештә ачыла. Лирик геройның хис-халәтен иң киеренке чиккә күтәрү, романтик, ассоциатив образ-сурәтлелекне шушы максатка буйсындыру «Ялвару», «Сине эзлим», «Чакыру», «Элегия», «Җавапсыз мәхәббәт», «Бер истәлек», «Китәсең...» кебек күпсанлы мәхәббәт лирикасы үрнәкләрендә аеруча ачык чагыла. Бәхеткә ирешүнең мөмкин түгеллеген төшенү, мәхәббәттә дә аңлау таба алмау, сөйгән ярны югалту, аңардан аерылу күңел лирикасы үрнәкләрендә хисләрнең сызланулы, сагышлы булуына китерә. Ләкин барыннан да бигрәк лирик геройны мәхәббәтне югалту яки аннан аерылу Мәңгелек сагышка сала:

*Тузан булып җиргә ятармын да...*
*Җеп тә өзәр хәл юк... арылган...*
*...ак тасмадай яткан төнге сукмак*
*Алып китә мине ярымнан.*
(«Ак тасмадай яткан төнге сукмак...»)

Шунысы үзенчәлекле: Р.Аймәтнең мәхәббәт лирикасында сөйгән ярдан аерылу, гомумән, Мәхәббәтнең югалуына тиңләнә. Иң катлаулы кичерешләр чолганышында калганда да, чарасызлык халәтендә, яшәү һәм югалу, мәхәббәт һәм хыянәт чигендә тибрәлгәндә дә, сөйгән яры, әнисе, туган авылы белән хушлашканда да, Р.Аймәтнең лирик герое ялгызак, рухи матурлык җырчысы булып кала, шушы авырлыкларны җиңәр көчне үз йөрәгеннән, үз җаныннан, үз күңел дөньясыннан эзли һәм таба.

Әнә шулай лирик геройның эмоциональлеге, ялгызлыгы, аның язмышына туры килгән халәтне атлап чыгуның мөмкин түгеллеген, бары аны кичеп кенә чыгуның мөмкинлеген аңлау халәте һәр шигырьдә детальләп ачыла *(«Упкыннардан калкам кыя булып, / Тугарылам шөбһә, шикләрдән. / Уталкыннар аша чыгам кичеп, / Чистарынам явыз көчләрдән»)*. Шуңа да Р.Аймәтнең җирдә үзенә тиң башка кешене таба алмыйча мәңгелек сагышка уралган лирик герое, бу җиргә, яшәешкә сыешмыйча, ямь, гамь табалмыйча, хыялга омтыла. Шуңа да Мәңгелек сагыш китапны бербөтенгә туплаган лейтмотив кына түгел, лирик геройның мәңгелек күңел халәте төсен ала.

Шулай да шагыйрь үзе күргән, теләгән, көткән яшәешнең киләчәк буыннарда кабатланачагына өметләнә әле, юкка гына китап битләрен түбәндәге юллар япмый: *«Килер әле, килер, ышанамын, / Имин генә булсын ил-көннәре, / Җилфердәүдән туктамасын бары / Өметемнең ап-ак җилкәннәре»*. Әйе, чыннан да, бу шигырь китабының көче, матурлыгы – кеше җанының, рухының, йөрәгенең кеше акылы җитмәслек киңлекләргә, аң ашмас биеклекләргә, тойгы ирешмәс гүзәллекләргә омтылышын, шуңа бәйле өмет-хыялларын җырлауда!

**Нурфия ЙОСЫПОВА,**
*филология фәннәре докторы,*
*КФУ профессоры.*

# «ЧЫЛБЫРДАГЫ БЕЗНЕҢ УРЫН...»

*Чаллы төбәгендә әдәби хәрәкәтне киң җәелдерү өчен күп эш башкарыла.*

*Яшь каләм тибрәтүчеләрне үзенә җыйнаган «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсенең эшли башлавына былтыр көз аенда 60 ел булды!*

*Кама-Чулман буйларында зур төзелеш әле купмаган чорларда ук, 1963 елда Чаллы районының «Коммунизм байрагы» газетасы каршында әдәби берләшмәгә нигез салына. Берләшмә газетаның баш редакторы Хәнәфи Мәннапов башлангычы белән оештырыла. Җитәкче итеп Казан педагогия институтын тәмамлап, Бикләнавылы мәктәбенә эшкә кайткан яшь шагыйрь Хәниф Хөснуллин билгеләнә. Оештыру җыелышында Татарстан Язучылар берлегеннән шагыйрь Зәки Нури катнаша.*

*Җитмешенче елларда зур төзелеш башлангач, талантлы иҗат көчләре туплана, әдәби мохит көчәя, тарихка «Ләйсән» исеме белән кереп калган данлыклы әдәби-иҗат берләшмәсе төзелә.*

*1970 еллар азагында шәһәребезгә килеп, «Ләйсән» әдәби берләшмәсендә үзенең шәхси шигърият мәктәбен нигезләргә өлгергән күренекле татар шагыйре Кадыйр Сибгатуллин болай дип яза:*

*Мәңгелеккә үтеп бара торган*
*кешелекнең без бер буыны.*
*Алып кара,*
*өзеп ташлап кара*
*чылбырдагы безнең урынны!*

*Бу шигъри юллар безгә кабат-кабат, үткәннәрне онытып, киләчәккә барып булмавын искәртә. Тарихны үзгәртә алмаган кебек, берләшмә эшчәнлегенең бер генә чорын да сызып ташлап булмый.*

*Әдәби сәхифәләрне актара башлауга, төбәгебездә якты эз калдырган күренекле, талантлы күпме шәхеснең исеме хәтердә яңара, күңелгә якын, таныш сурәте күз алдына килеп баса: Эдуард Касыймов, Газиз Кашапов-Үзиле, Ямаш Игәнәй, Рахмай Хисмәтуллин... Тагын килеп, Кадыйр Сибгатуллин, Альберт Сафин, Нәҗип Мадьяров, Заһирә Гомәрова, Ирек Диндаров, Шамил Шәйдуллин... Бүгенге көндә татар укучысын матур иҗатлары белән җәлеп иткән күренекле әдипләр Факил Сафин, Айдар Хәлим, Фәүзия Бәйрәмова, Мансур Сафин, Вахит Имамов, Рәшит Бәшәр, Данис Хәйруллин, Мирһади Разов, Амур Фәләх, Рафис Сәлимҗановлар белән горурланып яшибез. «Ләйсән»дә чыныгу алып, зур әдәби дөньяны колачлаган Галиәхмәт Шаһи, Нияз Вәлиев, Айрат Суфиянов, Сирень Якупова, Әлфия Ситдыйкова, Айгөл Әхмәтгалиева, Фидаил Мәҗитов һәм башка үзенчәлекле әдипләр яши шәһәрдә.*

*Иҗади берләшмәдә каләм чарлаган егет һәм кызларның байтагы бүген татар әдәбиятының иң мәртәбәле биеклекләренә күтәрелде. «Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсе менә инде алтмыш ел дәвамында, Кама буе төбәгенең иҗат көчләрен үз тирәсенә туплап, алар өчен әдәби мәктәп ролен үтәп килә. Яшь һәм башлап язучылар иң элек «Ләйсән» шифасын тоеп, көч туплыйлар, иҗат биеклекләренә үрләү өчен шунда канат яралар.*

*XXI гасыр башында әдәби-иҗат берләшмәсе әгъзалары һәм аларның иҗат үрнәкләре белән якыннан таныштыруны максат итеп куйган «Ләйсән тамчылары» (2007), «Ләйсән» – моңлы бишегебез» (2009), «Моң дулкынында» (2011), «Әдәби Чаллы» (2014), «Әдәби Чаллы күгендә» (2016) исемле китаплар дөнья күрде.*

**Роза ХӘМИДУЛЛИНА,**
*«Ләйсән» әдәби иҗат берләшмәсе җитәкчесе.*

## Туган авылым – Тәкмәгем

Кендек каны тамган җирем,
Туган авылым – Тәкмәгем.
Мин бит синдә авыз иттем
Иң беренче икмәгем.

Әнкәм сөте белән кергән
Сиңа булган мәхәббәт.
Тузаныңны иснәсәк тә,
Безгә шулкадәр рәхәт.

Әткәем белән әнкәем
Синдә гомер иттеләр.
Җиде кызга бәхет теләп,
Мәңгелеккә киттеләр.

Урамнарың иңләп-буйлап,
Синдә тәгәрәп үстек.
Хәер-фатихаңны алып,
Төрле якларга күчтек.

Еллар җитсә, кунак көтеп,
Туган йорт табын кора.
Синдә кичкән яшь гомерләр,
Үткәннәр сагындыра.

**Дилбәр ӘХӘТОВА**

## Син – кояшым

Син – кояшым минем, кояшым,
Җылы, сихри нурың коясың.
«Башка ярлар кирәк түгел», – дисең,
Синең җылың килә тоясым.

Син – кояшым минем, кояшым,
Кайнар кочагыңда эримен.
Тәннәремдә җаным барында
Беркемгә дә сине бирмимен.

Син – кояшым минем, кояшым,
Сине сөеп юктыр туясым.
«Мәңге бергә булыйк», – дип, иңемә
Йомшак кулларыңны куясың.

**Гөлнар ӘХМӘТШИНА**

* * *

Юк, мин беркем түгел сиңа.
Бары сихри наз гына.
Җилдәй исеп, көтмәгәндә
Каг(ы)лып китәм аз гына.

Юк, юк... сиңа беркем түгел,
Җил булып кына калам.
Гел дә ишетәсең килгән
Җыр булып туа алам.

Күреп туймас төшең булсам,
Башка кермәсәм бүтән?
Юк, кирәкми... Гомереңнән
Бары сер булып үтәм.

**Гөлсәрия БАСЫЙРОВА**

## Кәгазь кораб

Язлар җитсә, ага гөрләвекләр,
Басу-кырда эри ак карлар.
Ярсып аккан язгы ташу кебек
Шаулап акты, үтте яшь чаклар.

Ни кызганыч, үткән гомерләрнең
Бер мизгелен булмый кайтарып.
Аккан суга карап уйланамын,
Күңел дәфтәрләрем актарып.

Кышлар үтә, язы, җәе җитә,
Сизелми дә вакыт узганы.
Әйтерсең лә безнең үткән гомер –
Җил очырган юлның тузаны.

Өметләнәм язлар җиткән саен
Кайтыр диеп, бәлки, яшь чаклар.
Хыялларым төяп, ерганакта
Агып китә кәгазь кораблар.

**Разиф ДӘҮЛӘТ-БИКБАУЛЫ**

## Өмет

Язмышымның күгендә,
Гомеремнең көзендә,
Бер мизгелгә яктырып,
Өмет янды йөземдә.

Хисләр ташып буталды,
Йөрәгемә уралды.
Айлы төн матурлыгы
Күңелемә юл алды.

Моңнар җилдә таралды,
Хисләр янә яралды.
Иңдә канат, ак хыял
Чиксез күккә юл алды.

Йолдыз диңгезен гизеп,
Ялгыз айга баш иеп,
Таң йолдызын пар иттем,
Син – мәхәббәтем диеп.

Язмышымның күгендә,
Гомеремнең көзендә,
Ялт иттереп бүген дә
Кояш чыкты күгемдә!

**Гөлия ГЫЙЛӘҖЕВА**

## Сөю гөле

Ромашкалы аланнарда йөрим,
Күңелемә иңә аклыгы!
Яшьлегемнең сихри истәлеге,
Яктылыгы, җаным сафлыгы!

Таҗларына кагылырга кыймыйм...
Бер-бер артлы күпме өзгән бар!
Керфекләре ниләр дәшәр диеп,
Уйланыплар күпме түзгән бар!

Сөю көткән җанның сусауларын
Ак тылсымчым баса алырмы?
Назлы гөлнең таҗын саный-саный,
Әллә тагын сорап карыйммы?

**Рушания ГЫЙЛӘҖЕВА**

## Сагынып кайтам

Болын сукмакларын җырлап үтәм,
Чәчкәләргә моңым сарсын дип;
Елга буйларында үскән таллар
Йөрәгемә кереп калсын дип.

Моңа хәтле белмәгәнмен, ахры,
Авыр икән синнән китүләр.
Олы юлдан гына бармый кайчак
Яңа сукмак салып үтүләр.

Җәйге иртә кичкән туган ягым,
Бигрәк матур булган болыннар;
Койрыкларын чәнчеп уйный-уйный,
Болын таптап үтә колыннар.

Ап-ак болытлардан күзем алмый,
Хәтфә келәмендә ятамын.
Истәлекләр җыйнап китәмен дә
Кабат сагынып сиңа кайтамын.

**Рузилә ҖАМАЛИЕВА**

## Гомер агышы

Әкрен генә, җайлап кына,
Ап-ак мамык кар ява.
Гомер дә бит, шулай җырлап,
Ага да алга ага.

Йә ул елга булып ага,
Ярларга кага-кага.
Йә давыллар булып дулый,
Яфраклар йолка-йолка...

Йә яңгыр булып ява ул,
Бар дөньясын чылатып.
Үзәкләргә үтеп кереп,
Өшеттереп, елатып...

Яңгырның була җылысы,
Кояшлысы, төрлесе:
Җаннарны дәвалый торган
Салават күперлесе!

Ак чәчәкләр булып ява
Гомернең кай өлеше.
Һәркемнең үз җае белән,
Өлешенә – көмеше...

Әкрен генә, җайлап кына,
Ап-ак мамык кар ява.
Гомер дә бит, шулай җайлап,
Ага да алга ага!..

**Зөлфия ҖИҺАН**

## Ишкәксез көймә

Ялгыз гына киләм яр буеннан,
Кайнар комда ялгыз эз кала.
Су буенда әллә кая дәшеп,
Бер ишкәксез көймә чайкала.

Әй, ишкәксез көймә, син дә инде
Ишкәкләрең кая югалттың?
Ишкәкләрсез болай ялгыз гына
Кайсы тарафларга юл алдың?

Шул ишкәксез көймә кебек мин дә
Тормыш дулкынында чайкалам.
Ишкәкләрсез мин нишләрмен икән,
Давыл кубып, ялгыш каплансам?

Әй, ишкәксез көймә, бирче киңәш,
Батмый гына ничек йөзәргә?..
Ишкәкләрсез генә йөзә-йөзә,
Кереп барам тагын көзләргә...

**Гүзәлия ИСЛАМОВА**

***

Тормыш гүзәл, әгәр сөя белсәң,
Җанга терәк – ихлас ярату.
Яшәвеңә тирән мәгънә өсти
Саф хисләрдән сабый яралу.

Килер җанда әби-бабам каны,
Онытылмас изге догалар.
Күңел сөйгән милли йолаларым
Бала белән янә туарлар...

Яңа алмаш килә, горур атлар,
Саф хисләрен саклап йөрәкнең.
Язмышын да илем белән бәйләр,
Киләчәге булып милләтнең.

Эх, мизгелләр...
Гомер бушка түгел...
Яңа сабый туа. Мин – яңа!
Тәүге сулыш белән үлемсезлек –
Мәңгелеккә күчү башлана.

**Зинфира КӘРИМОВА**

***

Тәрәзәмдә иртәнге нур
Күзләремә кагылды.
Күңел түрләремә үтеп,
Иркәләде җанымны.

Хисләремнең ефәк җебе
Сагыну чигеп моңая.

Кояшлы яңгырлар аша
Шәүләң балкып елмая.

Күзләремә кагылдымы
Синең нурың таң тугач?
Минем күңелем – сихри бакча,
Куагында – сандугач.

**Зөлфия НИГМАНОВА**

## Җил булып җил елый бу якта

Уңга да, сулга да карамый чапканда,
Тормышны тартканда җигелеп,
Дусларсыз, ялгызың сагышта калганда,
Нигәдер буласың җил кебек.

Уйласаң, җилгә соң ни тора, аягы-кулы юк,
Башы да, тәне дә гел җилдән.

Уйлап та тормыйча китә дә белә ул,
Сагышлы, кайгылы бу җирдән.

Җил йөрде бу якта, ул хәзер еракта...
Елады чит якта елакка.
Еракта-еракта, зур таулар артында,
Минем дә күңелне елата.

Кешенең, югыйсә, тәне бар, җаны бар,
Нигә дип читләрдә яшәргә?!
Җил булып җилнең дә кайчакта, кайчакта
Читләрдә «күзләре яшьләнә»...

**Равил МОСТАФИН**

## Тузганак – кояш чәчәге

Сары чәчәк сипкән алан
Алтын бизәк белән тулган.
Тузганак чәчәкләренең
Һәр таҗына кояш сыйган.

Табигатьнең бу яменнән
Күңелемә моңнар тама.
Аланда булган гүзәллек
Бар дөньяны нурга мана.

Илһам алып чәчәкләрдән,
Йөрәгемә назлар сибәм.
Тузганаклы аланыма
Ел саен сагынып киләм.

**Фәридә СӘХӘБИЕВА**

## Хөрлек сөям

Сыймыйм һичбер кысаларга,
Салмагыз ла калыпка!
Мин ат түгел, кигертмәгез
Муеныма камыт та.

Хөрлек сөям! Мин кол түгел,
Чикләмәгез ирекне!
Хак Тәгалә сөймәгән күк
Харам белән ширекне.

Аккан чишмә юлын таба,
Булмый буып туктатып.
Дәрьяларга кушылырга
Юлын сала уратып.

Иҗат юлын кысмагыз ла,
Алга куеп киртәләр!
Кояшны да бикләп булмый
Һәркөн туа иртәләр.

**Гөлфия ФӘЙЗЕРАХМАНОВА**

## Сөю уты

Мин җәйләрдә, ә син көзгә
Кереп барасың.
Ничек үлчик йөрәк белән
Йөрәк арасын?
Синең акыл хисләреңнән
Гүя тартына.
Күңелең аңа буйсынмый –
Миңа тартыла.
Чит түгел шул син үзең дә
Минем күңелгә.

Сине күрсәм, бөтен дөньям
Нурга күмелә.
Мөмкин түгел бу сөюдән,
Ахры, качарга.
Карар кылдым күңелемне
Сиңа ачарга.
Тәрәзләрен ачып куйдым,
Төшсен яктысы.
Утын күреп, дуслар килсен,
Сөю яклысы...

**Гөлназ ХӘСӘНҖАН**

## Яратам

Җәй аенда болыннарда
Чалгы җырын яратам.
Тау астыннан челтерәгән
Чишмә моңын яратам.

Урманнарның тынлыгында
Уйланырга яратам.
Шул тынлыкта икәү калып,
Моңланырга яратам.

Салкын кышта күбәләктәй
Кар яуганын яратам.
Озын өй кыекларыннан
Су тамганын яратам.

Алтын көздә алмаларның
Кызарганын яратам.
Сандугачлы аяз таңның
Хозурлыгын яратам.

Янымдагы дусларымның
Асылларын яратам.
Табигатьнең һәр мизгелен,
Фасылларын яратам.

Бөекләрнең, даһиларның
Гадилеген яратам.
Кешеләрдә, дус-ишләрдә
Гаделлекне яратам!

Яратам, яратам, яратам!..

**Флорит ХӘМИТОВ**

## Туган нигез

Туган нигез, ялгыз калдың
Зәңгәр тәрәзәң белән.
Тәрәз төбендә якты моң
Сирпелә яран гөлдән.

Хыялымда сиңа кайтып
Гөлләремне үстерәм.

Балачактагы бәхетле
Көннәремне кичерәм.

Авылым, җылы кочагында
Мине ятим итмәдең.
Кычыткан ашап үссәм дә,
Күңелемнән китмәдең.

**Асия ХӘСӘНОВА**

## Монда калам

Сагындырыр чал Чулманың,
Чаллыяр – туган калам.
Беркая да китмим диеп,
Сүз бирә газиз balaң.

Синнән кадерлерәк җирне
Җыенмыйм эзләргә дә.
Кышларыңа да гашыйк мин,
Язларга, көзләргә дә.

Туган җир көмеш тә диләр,
Тиңлиләр алтынга да.
Сине ташлап, мин үземне
Ник салыйм ялкыннарга?!

Әткәм-Әнкәм, дус-ишләрем
Синдә яшиләр, калам.
Терәгең булырга теләп,
Мин мәңге монда калам.

**Зәбир ХӘЛИМОВ**

## Җанга җитми әнкәм догасы

Җанга җитми әнкәм догасы,
Борчуларны кая куясы?
Гомер буе саклап яшәтте бит
Әнкәемнең изге догасы.

Җанга җитми әнкәм догасы,
Аяк асты бәла-казасы.
Барлык явызлыкны җиңеп килде
Әнкәемнең изге догасы.

Җанга җитми әнкәм догасы,
Ничек бар(ы)сын җайга саласы?
Әнкәем юк, догасы да килми,
Ничек итеп яши баласы?

Җанга җитми әнкәм догасы,
Кергән төшне ничек юрасы?
Кисәтүләр килә, аңламыйбыз –
Кабат җитми әнкәм догасы.

Җанга җитми әнкәм догасы,
Сынауларны ничек узасы?
Гомер узган саен күбрәк аңлыйм
Саклаганын әнкәм догасы.

**Зөлфия ХӘЙРУЛЛИНА**

## Төш

Бер төн шулай төш күрәмен...
Бик куркыныч... Саташам...
Имеш, гаять зур сәер кош
Канны имеп маташа.
Ташлаган тирән чокырга,
Чыгармый беркая да.
Көн дә килеп кан суыра,
Тук тамырны таба да.
Үтерми дә ул үземне,
Тота кан эчәр өчен.
Тик тереләр каны гына
Арттыра икән көчен.
Ашатуы, җан сакларлык
Калдык-постык аш кына.
Ризасызлык күрсәткәндә,
Томшык төшә башыңа.
Томшыгыннан агу тама,
Аңны төреп томанга.
Коллыгыңны онытасың,
Ябылсаң да зинданга.
Кайчакларда айныйсың да
Үз хәлеңне аңлыйсың.
Яктылыкка омтылышта
Баш күтәреп карыйсың.
Ә өстә күкнең бары тик
Кечкенә бер кисәге.
Анда синең азатлыгың,
Бәйсезлегең – ... кичәге.
Тартыласың зәңгәр күккә...
Дивар биек, шома...
Аяк-кулың берегә алмый,
Кирегә таба шуа.
Җан авазы ишетелә
Гаҗизлек ыңгырашында.
Кара томшык бию бии
Чак айныган башымда.
Менә шулай саташтырды
Бер төнне күргән төшем.
Ни дип юрыйм? – Юрап бирче,
Аңлата белгән кешем.

**Айрат ШӘЙХЕТДИНОВ**

## «Кичер» сүзең соңга кала...

Беләсеңме, гомер уза...
Көмеш туйлар быел кышта,
Ни кызганыч, булмый калды,
Хыянәтең аваз салды.
Мәхәббәтем бәллүр кебек,
Чәлпәрәмә килеп калды...


Күрәсеңме, гомер уза...
Су агышына бер кара,
Агышында күрче, дустым,
Сөю, назың китеп бара.
Тормышыбыз ямен инде
Киткән юлдан борып кара...

Сизәсеңме, гомер уза...
Биргән вәгъдәң синең кайда?
Тормышыбыз җиткән чакта,
Гомер көзең килгән чакта,
Хыянәтең чәчәк атты,
Йөрәгемә хәнҗәр какты.

Ачы яшьләр карны яра,
Көмеш туйлар булмый кала.
Ялгыз эзләр карда яна,
Йөрәгемдә тирән яра,
Мәхәббәтем сүнеп бара,
«Кичер» сүзең соңга кала...

**Фәйрүзә ШӘРИПОВА**

# ХӘТЕРЕМДӘ МӘҢГЕ КАЛЫР ТУГАН ҖИРЕМ...



*Җәмил Яһудин*

Самара шәһәрендә журналист, төбәкне өйрәнүче Фәрид Ширияздановның рус һәм татар телләрендә язылган «Подвиг длиною в жизнь. Село Старое Фейзуллово. Время, события, люди» исемле яңа китабы басылып чыкты. Китап фаҗигале язмышны җиңеп, тиңдәшсез тормыш батырлыгы күрсәткән якташыбыз – шагыйрь, рәссам-график Гакыйль Сәгыйровның тууына 85 ел тулуга багышланган һәм герой яшәп иҗат иткән Иске Фәйзулла авылы тарихы турында язылган.

Гакыйль Сәгыйров урын өстендә яткан килеш карандашны тешләренә кысып язарга, рәсем ясарга өйрәнә, Н.К.Крупская исемендәге Бөтенсоюз сәнгать институтында укый, Шәйхи Маннур, Сәхаб Урайский, Гаяз Исхакый исемендәге әдәби премияләр иясе, рәсемнәре өчен «Филантроп» халыкара бүләк лауреаты. «Гакыйль Сәгыйров – безнең илдә генә түгел, дөнья күләмендә кеше исеменә мәдхия булырлык шәхес. Ул – фаҗигале язмышны җиңү үрнәге», – дип бәяли Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, актёр, режиссёр, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы Әхтәм ага Зарипов.

Гакыйль Сәгыйровның «Тормыш җиле», «Айбагарлар», «Кабатланмас моң», «Ике кояш», «Шатлыклы иртә», «Йөрәк сере» дип исемләнгән шигырь һәм рәсем җыентыклары татар мәдәниятен, әдәби мирасыбызны баеткан кадерле китапларга әверелделәр. Аның шигырьләрендә яшәргә омтылыш һәм һәрнәрсәдә үзе катнашырга теләү өстенлек итә. Аның иҗаты үзе яшәгән Иске Фәйзулла авылы белән аерылгысыз рәвештә тыгыз бәйләнгән.

Билгеле, авыллар гомергә яшәү нигезе, тормыш чыганагы булган. Иң сәләтле, тормышта уңышка ирешкән шәхесләр, галимнәр, дәүләт эшлеклеләре, хәтта ил башлыклары да авылларда туып үскәннәр. Иң ныклы һәм үтемле тәрбияне гомер-гомергә авыл табигате, авыл хезмәте биргән. Шуңа күрә мин нәсел тамырларым Иске Фәйзулла (Иске Җүрәй) авылына тыгыз бәйләнгән булу белән горурланып яшим.

Әтием Габделхәй Яһудин, бабам Абзалетдин, аның әтисе Баһаутдин бабам кебек мин дә шушы авылда туганмын, беренче тәпи басканмын һәм шунда телем ачылган. Һәркемгә үзенең туган җире якын булган кебек, мин дә Иске Фәйзулла авылы турындагы истәлекләрне хәтеремдә кадерләп саклыйм. Шуңа да авылыбыз тарихы турында китап язылу хәбәре минем күңелемә аеруча хуш килде. Китапны кулга алгач, Габдулла Тукайның: «Кая барсам, кайда торсам, нишләсәм дә, хәтеремдә мәңге калыр туган җирем» дигән шигъри сүзләре искә төште. Авыл урамындагы чылбырдай тезелгән күлләр, аларны уратып алган биек таллар, эшчән, киң күңелле халкы хәтердә яңарды. Ә инде күренекле шагыйрь, рәссам Гакыйль Сәгыйровның монда яшәп иҗат иткән һәм шунда җирләнгән булуы изге хисләрне тагын да көчәйтте.

Балачак истәлекләре хәтергә нык сеңеп, гомер буена саклanучан була. Әнием

Сәрвәриянең Иске Җүрәйгә башлангыч сыйныф укытучысы булып килгәч эшләгән мәктәбе, фронттан яраланып кайткан әтием Габделхәй белән тормыш корып җибәрүе теркәлгән авыл Советы бинасы күз алдына килә. Бина янәшәсендәге күл буенда агачтан сикереп су коенган вакытлар, авыл урамында яланаяк йөгереп йөргән чаклар искә төшә. Шунда ук әбиемнең печән төялгән «уфалла» арбасын тартып баруы һәм аның кече улы Дамир абый белән, арба тәгәрмәче биеклегендә генә булсам да, шул арбаны арттан этешеп баруыбыз күз алдында. Янәсе, ничек тә әбигә ярдәм итәргә тырышабыз!

Нечкә буйлы, ябык кына гәүдәле Хәдичә әбием, ире Абзалетдин һәм олы улы Габделәхәт сугышта һәлак булгач, биш баласы белән 45 яшендә тол кала. Чиксез авырлыклар кичеп, балалары Габделхәй, Мәгүзә, Равил, Гөлсем һәм Дамирны йөрәк җылысын биреп үстерә. Әтисез калган гади авыл балаларына сугыш вакытында һәм сугыштан соңгы елларда кием, ризык, китап һәм дәфтәр җитми. Үсә төшкәч, алар бер-берсенә ярдәм итешеп, югары белем алалар, укытучылар, җитәкчеләр булып, югары профессиональ биеклеккә ирешәләр, әти-әнисенең исемнәренә, гаилә фамилиясенә тап төшерми эшлиләр, зур абруйлы булалар.

Басмадагы Гакыйль Сәгыйров рәсемнәрен караганда, әтием һәм әбием сөйләгәннәр, кечкенә чагымда халыкның авырлыклар кичереп яшәве һәм шулай ук тормышның акрынлап уңай эзгә баса баруы да күз алдыннан узгандай була, андагы күп нәрсә тирән уйланулар тудыра. Гади, ләкин үзенә генә хас булган алымны кулланып язылган рәсемендә кояшсыз күк, яфраксыз агачлар, таушалган йортлар, бушап калган кош оялары белән авыл тормышының никадәр авыр булуы турында сөйли кебек ул.

Туган авылым хәзер зур булмаса да, мин аның искиткеч тирән һәм гыйбрәтле тарихы барлыгын, анда җәдитче ахун Нуретдин хәзрәт Шаммасов яшәвен, авылның мәгърифәт учагы булуын белеп, башка кыйммәтле ачышлар да ясадым. Ахырда авылга, анда гомер кичергән әби-бабаларыма карата булган хөрмәтем дә бермә-бер артты.

Кызганыч, ашкынулы гомер узганда, дәверләр һәм буыннар алышынган чорда матур истәлек булырлык гыйбрәтле вакыйгаларның күбесе онытыла, югала бара. Башка җирләрдәге кебек, бу авылдагы хәлләрне дә теркәп баручылар булгандыр булуын, тик аларның күп кенә истәлекле язмалары хәзерге көнгәчә сакланмаган, югалган. Заманында гөрләп яшәгән бу авылда өч мәчет, өч йөзләп йорт булуын, анда бер мең ярымлап халык яшәвен белүчеләр дә хәзер инде юк диярлек.

2000 елдагы җанисәп буенча авылда 150 йорт булып, анда 372 кеше яшәсә, хәзер инде бу саннар тагын да кимеде. Менә шундый уйлар борчыганда, туган авылымның үткәннәре турында язылган югары сыйфатлы китап басылуы – минем өчен зур куаныч булды. Аның эчтәлеге белән танышканда да күп кенә кыйммәтле яңалыклар таптым. Мәсәлән, бабабыз Абзалетдинны, аның олы улы Габделәхәт абзыйны күрергә насыйп булмаганга, алар турында мин ишетеп кенә белә идем. Ә бу китапта Абзалетдин бабам, аның гаиләсе, балалары һәм туганнары турында кайбер тарихи документлар да булуын күреп, аеруча куандым.

Алардан Абзалетдин бабайның 1928–1930 елларда авыл Советында эшләп, аның рәисе итеп сайлануын, соңрак колхоз председателе булганлыгын белеп, авыл тарихында тирән эз калдыруына горурлык хисләре кичердем.

Эзләнүләр вакытында Яһудиннар гаиләсенең күршесе булган Габделхак Халитов шуны исенә төшерде: колхоз рәисе Абзалетдин, аның улы Габеләхәт 1942 елны сугышка алына, аларның сугышта һәлак булулары турындагы хәбәр авылга 1943 елда килә.  СССР Оборона министрлыгының архив документларыннан бабам  Абзалетдин Баһаутдин улы Яһудинның 1942 елны Кызыл Армия сафларына чакырылуы, марш ротасы составында 3 нче Удар армиянең Великие Луки шәһәре

тирәсендә фашистларга каршы сугыш алып баручы 257 укчы дивизиясе составында сугышып, 1943 елның 11 февралендә һәлак булуы ачыкланды.

Әтиемнең абзыйсы Габделәхәт Яһудинның исә 1944 елда үз кулы белән язган анкетасы һәм «Щорс» исемендәге партизан отряды командиры имзалаган характеристикасы табылды. Бу документлардан аның 1942 елда фронтта булып, күп кенә солдатлар белән бергә чолганышта калуы, соңыннан Минск өлкәсендәге «Щорс» һәм «Победа» партизан отрядлары сафында көрәшүе, батырлык күрсәткәне өчен I дәрәҗә «Бөек Ватан сугышы партизанына» медале белән бүләкләнүе билгеле булды. Аның батырлыклар күрсәтүе турындагы документлар Белоруссиянең Минск шәһәрендә, партизаннар хәрәкәтенә багышланган музейда саклана.

1944 елның 13 июлендә 901 кешедән торган 4 партизан отряды Кызыл Армия частьларына кушылгач, эвакогоспитальдә дәвалана һәм 1944 елның сентябрендә марш ротасы составында 5 нче армия карамагына җибәрелә, 3 нче Белоруссия фронтындагы 371 укчы дивизиясенең 1231 укчы полкы составында сугыша. Бу полк Белоруссия, Балтыйк буе, Көнчыгыш Пруссияне фашистлардан азат итүдә катнаша, ә 1945 елның 29 апрелендә Көнчыгыш Пруссиядән Маньчжуриягә, япон гаскәрләренә каршы сугышка җибәрелә. Кызганыч, Габделәхәт Яһудинның һәлак булган һәм җирләнгән урыны әлегә билгеле түгел. Тик шулай да, никадәр озак вакыт үткәч, әтиемнең якын туганының билгесез булган язмышы ачыклануы безнең өчен зур куаныч һәм иң кыйммәтле табыш булды.

Мондый хәбәрдән соң әтиебез, инде шактый олыгайган булса да, Белоруссиягә барып, партизаннар музеенда булган документлар белән танышып, абыйсының рухына багышлап догалар уку хыялы белән яшәде. Тик аңа бу изге хыялына ирешергә насыйп булмады. Үзенә 94 яшь тулыр алдыннан, каһәрле коронавирус белән авыруы сәбәпле, бакыйлыкка күчте.

Авыл тарихын, нәселебез язмышын күзаллаганда, ирексездән тирән уйлар, нечкә хисләр тугач, үткәннәргә карата төпле нәтиҗәләр дә ясала. Мәсәлән, әтиебез Габделхәй һәм әниебез Сәрвәрия – икесе дә укымышлы, илебезнең, халкыбызның алдынгы фикерле патриоты булып, кешеләр белән уртак тел табып яшәделәр, аралашучан, ачык йөзле, киң күңелле, эшчән иделәр, шулай ук безне һәм башкаларны да шул рухта тәрбияләргә тырыштылар. «Гаилә педагогикасы» нигезләрен үз вакытында әниебез салган, ул һәрвакыт әтиебезнең абруен ныгыта иде. Кайвакыт ул үзе дә мәсьәләне хәл итә алыр иде, ләкин әтинең эштән кайтуын көтәргә куша, әти ничек әйтсә, шулай була иде.

Еллар үткәч, әти-әнинең безнең өчен дә, башкалар өчен дә иң якты үрнәк булуы тагын да ныграк беленә. Без лаеклы шәхесләр булсын һәм лаеклы тормышта яшәсен өчен аларның бар көчен биреп тырышуларын да тирәнрәк аңлыйсың.

Бу хакта Мөхәммәд (с.г.в.) хәдисләрендәге: «Кеше үзеннән соң изге эшләр, якты истәлекләр һәм тәрбияле балалар калдырса, аңа оҗмах түрендә урын әзерләрмен» дигән сүзләре хәтергә килә. Әлбәттә, бу безнең әтиебезгә, әниебезгә, алар кебек изге кешеләргә кагыла дигән тулы фикердә торам.

Минем дәүләт органнарындагы эшем кеше тәрбияләү, җинаятьчелекне булдырмау, җәмгыятьтә патриотизм хисләрен көчәйтү белән бәйле булганга, әтием тәрбиясенең әһәмиятен психология һәм педагогика күзлегеннән чыгып та югары бәялисем килә.

Әлбәттә, Фәрид Шириязданов язган Иске Фәйзулла авылы тарихы турындагы китапның да тәрбияви яктан әһәмияте бик зур. Китап архив материалларына, олы буын кешеләрнең истәлекләренә һәм элгәредән сакланган язмаларга, фотоларга нигезләнеп тупланган. Ул илебез тарихында тирән эз калдырган шәхесләр турындагы һәм үткәндәге башка якты истәлекләрне хәтердә яңартып, аларны киләчәк буыннарга

да җиткерү өчен дә кыйммәтле язма чыганак булачак. Монда тарихны бүгенге көн белән чагыштыру һәм киләчәк турында фикер йөртү өчен дә тулы мөмкинлекләр бар. Шул ук вакытта бу китап Татарстаннан читтә төпләнгән татар авыллары тарихын, анда яшәгән халыкның гореф-гадәтләрен, телен саклау максатын куеп эшләнгән. Бу хезмәт киң катлау укучыларга юнәлтелгән. Хәзерге вакытта бу китап туктап уйланырга, үткәннәргә әйләнеп карап, төпле нәтиҗә ясарга мөмкинлек бирә. Анда кешенең милли үзаңын үстерү, хәтерен баету, фикерләү офыгын киңәйтү һәм уйларын җайга салу өчен дә җирлек бар.

Тормышта юнәлеш бер яклы булганга, үткәндәге хаталарны берничек тә кире кайтып төзәтеп булмый. Бу очракта халык мәкален искә аласы килә. «Надан кеше үз хаталары аркасында акылга утырса, акыллы кеше башкалар хатасын күреп, шуннан гыйбрәт алып, ялгышлардан саклана» дип әйтелә анда.

Татар халкында үткәннәргә хөрмәт белән карау бик борынгыдан килә. Мәсәлән, элгәре һәр аңлы кеше ким дигәндә җиде буынга кадәр үзенең бабалары турында белеп яшәгән. Моңа карап, аның җәмгыятьтә тоткан урыны, халык арасында абруе билгеләнгән. Шуңа күрә һәркем үз нәселе, авыл халкы һәм үзенең дәвамчылары алдында зур җаваплылык тоеп яшәгән. Чөнки аның даны яисә яман аты җиде буынга кадәр үзенең балаларына, оныкларына кагылган. Ни кызганыч, соңгы дәвердә тезгенсезлек дулкыны шактый зыян китереп узганнан соң, халык арасындагы бердәмлек тә шактый какшады, битарафлык көчәйде. Шунысы куанычлы: хәзер җәмгыятебездә төбәк тарихын өйрәнүчеләр хәрәкәте җанланып, кешеләрдә үз нәселе белән кызыксыну көчәя бара. Кайбер җирләрдә шәҗәрә бәйрәмнәре дә үткәрелә башлады.

Татар халкы тарихына багышланган, тарихи аренада протоболгар кабиләләре барлыкка килүдән алып, Казан ханлыгының җимерелүенә кадәр безнең ерак бабаларыбыз тормышындагы барлык мөһим вакыйгаларны, алар үсешенең төп юнәлешләрен һәм характерын синхрон рәвештә үз эченә алган «Народы Среднего Поволжья и Южного Урала» *(Казан, «Мәгариф»,1995)* дип аталган фәнни китап авторы, галим, Татарстан Республикасының атказанган мәдәният хезмәткәре һәм атказанган фән эшлеклесе, күп томлы «Татар энциклопедиясе»нең җаваплы мөхәррире Гомәр Сабирҗановның да тамырлары менә шушы Иске Фәйзулла авылы белән бәйле.

Борынгы татар халкының көчле рухлы булуы – бөтен дөньяга билгеле хәл. Тик хәзер тормыш нигезе, яшәү чыганагы булган татар авылларының күпчелеге аяныч хәлдә. Шуңа күрә аларда яшәгән халыкның тарихын, телен саклап, киләчәген кайгырту бүгенге көндә иң мөһим бурычларның берсе булып тора.

Минем исәбемчә, бу китап иҗтимагый оешмаларда, китапханәләрдә, мәктәпләрдә һәм халык арасында киң кулланылышта булырга тиеш. Аның бөек якташыбыз истәлегенә, авыл язмышын кайгыртуга багышланган икәнен исәпләгәндә, бу – аеруча мөһим мәсьәлә.

Форсаттан файдаланып, туган авылым тарихын саклауга күп хезмәт куйган китап авторы Фәрид Ширияздановка олы рәхмәтемне белдерәм. Аңа киләчәктә дә татар авыллары тарихын өйрәнү һәм саклау юлында зур уңышлар телим.

**Җәмил ЯҺУДИН**

# ГАДЕЛЛЕК САГЫНДА

*Редакциябез кунагы – Башкортстан Республикасы Адвокатлар Коллегиясе әгъзасы, отставкадагы прокурор, юстициянең өлкән киңәшчесе, Башкортстан Республикасы Ижтимагый палатасы эксперты, Россия Юристлар ассоциациясе әгъзасы Динар Наил улы Шакиров.*

**– Динар Наилович, үзегез белән якыннанрак таныштырыгыз әле.**

– Мин Башкортстанның Шаран районы Ярәмкә авылында туып үстем. Әтием белән әнием моңлы, җыр-моңга мөкиббән кешеләр иде. Әнием клуб мөдире булып эшләде. Шуңа да без абыем Илдар, апам Резеда белән иҗади мохиттә тәрбияләндек.




*Динар Шакиров гаиләсе белән.*

Әти-әнием, яшьлек елларында ук «Дуслык» вокал ансамбле һәм театр түгәрәге оештырып, күрше районнарда концертлар, спектакльләр куеп йөрделәр. Ул елларда үзебезнең авылга да артистлар күп килә иде. Мин көндез, клубны ачып, артистларны каршы ала идем. Әнкәй аларны бәлеш пешереп сыйлый, аралашалар, җырлашалар. Шулай итеп, гомер юлы җыр-моң белән үрелеп барды. Әнкәем «СССРның мәдәният отличнигы» медаленә дә лаек булды. Әле бүгенге көндә дә, яше сиксәнгә якынлашса да, «Яшь йөрәкләр» ансамблендә җырлап йөри. Ни кызганыч, моннан берничә ел элек әтием вафат булды. Җәннәт әниләрнең аяк астында диләр. Вакытым, җаем булган саен, әнием янына кайтырга ашыгам, һәркемне әниләрен ташламаска, хәер-фатихаларын алып калырга өндим. Җырлы-моңлы, иҗади гаиләдә тәрбияләнүемнең нәтиҗәседер – татар телендә шигырьләр укырга яратам, Бөтендөнья татар конгрессы белән тыгыз элемтәдә торам. Казанга барырга мөмкинлегем булганда, бик дулкынланып, сөенеп барам. Уфаны да яратам мин, ләкин Казанны милләтебезнең мәркәзе итеп кабул итәм, ул күңелемә бик якын! Бирегә килгән саен, милләтемә тагын нинди файда китерә алам икән дигән уйлар күңелне били!

Һөнәри эшчәнлегемә килгәндә, егерме ел прокуратура системасында, шуның 15 елын район прокуроры булып эшләдем. 2020 елда отставкага киттем һәм адвокатлык эшчәнлеген башладым. Һөнәри юнәлешне үзгәртүнең катлаулы яклары да булмады түгел, ләкин бүгенге эшчәнлегем белән канәгатьмен. Прокурор эше артык күп көч һәм энергия таләп итә иде, ахыр чиктә, ул миңа күңел канәгатьлеге китерми башлады. Адвокатлык эшенә керешкәч, кешеләргә ярдәм итә алуым белән горурланып куйдым, тормышым ямьләнеп киткәндәй булды.

**– Хәзер сез хокук өлкәсенең кайсы юнәлешендә эшчәнлек алып барасыз?**



*Динар Шакиров уллары белән.*

– Аерылышу процессы, милекне бүлү, балалар белән аралашу тәртибен билгеләү, юл-транспорт һәлакәтләре буенча мораль зыянны компенсацияләү мәсьәләләрендә ярдәм итәм, төрле категориядәге җинаять эшләре буенча зыян күрүчеләрнең һәм гаепләнүчеләрнең хокукларын яклау белән дә шөгыльләнәм. Прокуратурада эшләү, хокук саклау органнары, судлар, дәүләт хакимияте органнары белән хезмәттәшлек итү тәҗрибәсе минем бүгенге адвокат эшчәнлегемдә бик булыша.

**– Нинди мәсьәләләр буенча еш мөрәҗәгать итәләр?**

– Күпчелек хатын-кызлар аерылышу мәсьәләләре буенча килә. Гаилә таркалганнан соң, ир-ат үзенең элеккеге хатынын һәм балаларын матди яктан тәэмин итәргә тиеш. Әмма мондый мисаллар бармак белән генә санарлык. Хатын-кызлар еш кына элеккеге тормыш иптәшеннән куркалар, бу чорда алар юридик яктан да, эмоциональ яктан да ярдәмгә мохтаҗ. Минем фикеремчә, ир белән хатын арасында мәхәббәт тә, хөрмәт тә калмаган икән, бу никахны «балалар өчен» дип кенә сакларга тырышырга кирәкми. Чөнки бу очракта син инде үз тормышың белән яшәмисең. Балаларга кагылышлы мәсьәләләрдә исә мин һәр ситуацияне, үзем дә әти буларак, йөрәгем аша үткәрәм. Балалар темасы минем өчен бик авыр. Әти-әни хокукыннан мәхрүм итү, алимент түләтү, баланың яшәү урынын билгеләү...

**– Хокук белгече нинди сыйфатларга ия булырга тиеш?**

– Билгеле, клиентларның мәнфәгатьләрен югары дәрәҗәдә яклау өчен, үз белгечлегең өлкәсендә законнар һәм процесслар турында тирән белемгә ия булырга кирәк. Шулай ук ул клиентларга катлаулы юридик аспектларны ачык һәм аңлаешлы итеп аңлату, каршы яклар белән нәтиҗәле аралашу һәм суд органнарын үз позицияләреңә ышандыру мөһим. Бернигә карамастан, адвокат клиент мәнфәгатьләре өчен ахырга кадәр көрәшергә әзер булырга тиеш. Нәкъ менә шушы сыйфатларның бергәлеге уңай нәтиҗәләргә ирешергә мөмкинлек бирә.

**– Динар Наилович, буш вакытларыгызны ничек үткәрәсез?**

– Профессиональ эшчәнлектән тыш, тормышымның башка өлкәләренә дә вакыт бүлеп куярга тырышам. Дэн Браун, Пауло Коэльо, Эльчин Сафарли, Ремарк, Джек Лондон, Михаил Шолохов, Михаил Булгаков әсәрләрен яратып укыйм. Спорт – тормышымның аерылгысыз бер өлеше. Минем өчен ул – энергия чыганагы.

**– Ничек уйлыйсыз, уңышыгызның төп сере нәрсәдә?**

– Хезмәтеңне ярату, үзеңә ышану, игелекле, намуслы булу, яңалыктан курыкмау – бөтен сер шунда. Мин журнал укучыларына да шуны телим. Һәрхәлдә, хыялланырга һәм хыял-максатларыңны тормышка ашырырга омтылырга, үзгәрешләрдән курыкмаска киңәш итәм. Ишекнең икенче ягында нәрсә барлыгын беркайчан да белеп булмый. Иң мөһиме – курыкмаска. Без кичәге көнне инде кире кайтара алмаячакбыз, әмма иртәгә булачак вакыйгалар турыдан-туры үзебезгә бәйле. Журналның барлык укучыларына иминлек һәм уңышлар телим.

*Әңгәмәдәш* – **Алинә ХӘБИБУЛЛИНА.**

## Нурия Измайлованың Рәдиф Гаташка язган хатлары

*22 февраль, 1980 ел*
*Мәскәү*

Исәнме, Рәдиф!

Сәлам белән, Нурия.

«Казан утлары» тәки килде. Укыдык минем шигырьләрне, ошады. «Унбер җәлилче» белән «Утыртасы иде...» өчен асубо рәхмәт: мин аларны бирәү дә бастырырга теләмәс дип уйлаган идем, ташка басылгач, ару гына булганнар тагы. Тик минем ир «Унынчы җыр»га бәйләнеп йөри. Аның бер танышы бар, ярым татар, ярым мари, аларның институтында эшләгән, әле пенсиядә. Ул да «Казан утлары»н ала. Минем шигырьләрне укыган да Вилләрнең лабораториясенә шалтыраткан. «Вил с женой живёт? – дип әйтә ди. – Я прочёл стихи его жены, очень грустные, очень печальные, неужели она с ним несчастна?» – дип әйтә ди. Лабораториядәге хатыннар Вилгә әйтеп биргәннәр. Хәзер минем ир куркып йөри инде, авылда да укырлар да шулай дип әйтерләр дип. Шаярып кына, билгеле.

Бик зур рәхмәт сиңа. Тик киләсе ел өчен өр-яңа шигырьләр язылмый бит әле. Журналга китапка керәсе шигырьләр дә ярыйдыр инде; басылмаган булгач, барыбер яңа бит. «Азат хатын»нан хәбәр юк әле. Мансур да язмый, аның журналы барып чыкмадымы әллә? Мескен, бик кайгырыр инде барып чыкмаса. Күрсәң, сәлам әйт. Миңа хат язсын. Күке язмый. Шәүкәт Галиевка хат яздым әле сорашып, бәлки җавап бирер. Шулай инде ул, читтәге кешене кем уйласын.

Монда хәзер яз исе килә. Гадәттәгечә, болытлы, тик икенче төрле. Эч пошкан чаклар еш булса да, яз яз инде, күңел дә күтәрелеп китә кайчак. Ялгыз гына, тыныч кына йөреп ятам шунда. Шигъри фикерләр килә дә китә, килә дә китә... Хәтерем юк бер дә. Соңгы вакытта әллә нинди сагыну хисләре: Уфаны, Казанны күрәсе килә, гомер үткән җирләрне бер әйләнеп чыгасы килә. Әллә картлык галәмәте, әллә үләр вакытым җитә инде, тәүбә-тәүбә...

«Казан утлары» ничава чыккан. Тик сезнең корректорларыгыз бик начар, әй, һәрвакыт хата тулып ята. «Чиләк» урынына «җиләк» дисеңме, «мастер» урынына «мистер» дисеңме... Күп. Нишләп журналыгызның тиражын арттырмыйсыз? Кешеләр ала алмый интегә, ә сез 6 миллион татар халкына 100 мең дә тираж ясамыйсыз.

Мәскәү үз урынында бугай. Центрга барганым юк. Безнең тирәдә ару, тыныч кына. Марҗалар белән талашкалыйм. Бүген дә бер торгашка бер татар әбиенә бәйләнеп тора, шуның белән әрләшеп кайттым әле. <...> Ярый, сүгенә башладым бугай. Сау бул. Семьяңа сәлам.

*Нурия.*

***

*6 декабрь, 1982 ел*
*Мәскәү*

Саумы, Рәдиф!

Күп сәлам белән, Нурия.

Хатыңны алган идем, зур рәхмәт. Үзем әллә нишләп хат та язмыйм соңгы вакытта. Кәеф тә юк, чирләбрәк тә торам. Апатия, халтура, ялкаулык һ.б. Үземнән бигрәк канәгать түгелмен. Бернәрсәгә дә сәләтем дә юк, бер җирдә дә урын тапмыймын, ә гомер үтеп китте дияргә була. Язганнарымны күрәсем дә килми, кеше ничек укыйдыр шуларны. Кешеләрнекен укып та тәм вә ямь тапмыйм. Яшьлек үтү шушы икән. «Ашның тәме, тормышның яме калмый», – ди иде минем нәнәй, хәзер әнкәй шулай ди, инде миңа чират. Мин алардан иртәрәк картаям, ахры.

Көннәр дә шундый – гел болыт, гел салкын. Ни кыш, ни көз. Күзләрне иркәләрлек бер генә күренеш тә юк. Кешеләрнең йөзләре дә, сүзләре дә канәгатьсезлек, зарлану, акча, чүпрәк-чапрак мәшәкате тулы. Кайда ул безне алдап, дөньяга китергән «прекрасная жизнь»? Алдадылар барысы да: Алласы да, патшасы да.

Союзга расладылар. Инде билет кына аласы калды бугай. Бер шатлык та юк. Өч ел ярым буена сузылгач, нинди шатлык калсын? Кешене «выжатый лимон» ясап бетермичә, бер шатлык та бирмиләр. Нигә шулай кыланырга инде? Лаек булса – ал кешене, лаек булмаса – алма. Имеш, ул ярты гомерен аптырап уздырырга тиеш: кичәмме сират күперен, кичмимме дип. Ух, ачу килә!!!

Ярый, үзең турында яз. Риммага сәлам.

*Нурия.*

***

*15 ноябрь, 1984 ел*
*Мәскәү*

Саумы, Рәдиф!

Сәлам белән, Нурия.

Бүген Маратның эштә утыра торган көне. Әле аңа шалтыраттым да сиңа хат язам. Мин синең үтенечеңне үти алмадым, әй. Марат әйтә: «Свободного экземпляра нет», – ди. Беренче экземпляр архивта ди, үзләре бастырганның икенчесе «у художественных редакторов» ди (нишләптер). Кайбер шигырьләрне табарга булыр иде, «нужно долго копаться, конец года, много срочных дел» һ.б. «У него всё нормально, скоро сам увидит» – ди. Кермәгән шигырьләреңне ничек тә алып җибәрермен мин сиңа, «отложим до следующего раза», – ди. Баргач, үзем булса да карап алырмын. Аларның азапланасы килми инде. Минем дә тәрҗемәчегә ярты кулъязма гына бирелгән, калганын һаман җибәрмәдем әле. Менә яңа ел башлансын да, үзем барып алып җибәрермен димен. Шунда синекен дә алырга тырышырмын.

Үзегездә ни хәлләр? Быел Мәскәүдә күренмисең.

Язасыңмы?

Минем малайның тагын пневмония (инде өченче тапкыр) булды. Инде бакчага йөртмәскә уйладык. Яңадан өйдә. Миңа ireккә чыгарга язмагандыр инде. Аның белән язып та булмый бит ул. Әзрәк проза язгалыйм шунда. Әнә Солтан ару дигәч, күңел күтәрелде әле. Аның нидер җитми дигәнен аңлыйм, профессионализм җитми. Аннан соң прозаны ашыгып язам мин, шулкадәр күп язарга кирәк, чыдамлыгым җитми кат-кат уйлап, төзәтеп утырырга. Бальзаклар, Дюмалар шикелле – утырам да шатыр-шотыр машинкада... Черновик язарга әлеге дә баягы түземлелек кайда?

Үзеңнең язып караганың бардыр инде. Бик серьёзный, сабыр кеше кирәк прозага.

Семьяң исән-саумы? Сәлам әйт. Малайларга да сәлам.

Ярый, хәзергә сау булып тор. Уңышлар телим.

*Нурия.*

***

*1 июль, 1985 ел*
*Мәскәү*

Саумы, Рәдиф!

Күп сәлам белән, Нурия.

Син ул шигырьләрнең үзеңә ошаганнарын гына сайлап ал, калганы калсын. Мин бит сиңа яңа язганнарны җибәрәм, вакыт сынавын үтмәгәннәрне, алар шулайрак була инде... Яз язылганны көз алып карасаң, таманга килә дә соң, авылга кайтып киткәнче җибәрим дип ашыгып ташлаганмындыр. Үзең беләсең, кайчак кемгәдер укытасы да килә, ә мин кемгә укытыйм: ир белгеч түгел, ә публика монда тегеләйрәк...

Син ул кадәр пессимист булма – Толстой Шекспирны яратмаган бит әле, ни әйтсә дә, без – профессионаллар, бер-беребезнең язганыннан кимчелек табуыбыз гаҗәп түгел. Юк, субъектив караш кына дияргә җыенмыйм, синең миңа доброжелатель икәнеңне дә, поэзияне аңлавыңны да беләм, тик «акыл сату, күп белү» дигән бәяне аңлап бетермим: фикер әйтергә тырышкан теләсә нинди әйберне дә шулай квалифицировать итәргә була бит. Акылны ул кадәр начар нәрсә дип әйтмәс идем мин. Кем ничек, мин үзем әдәбиятта акыл, фикер, фәлсәфә булырга тиеш дип саныйм. Һәм аларны эт тә төшенә алмаслык итеп «образга төреп» яшерүне дә кирәк санамыйм. Ә болай «образ юк» диюең турында уйланырга кирәк кебек: миндә образ ягы, чынлап та, ярлырак, чамасын белгәндә, анысы – әйбәт нәрсә.

Дөресен генә әйткәндә, поэзиядә бутала башладым мин: тәмам аптыраш, кешенекендә дә, үземнекендә дә. Матбугатта күренгән шигырьләрне укып карасаң, шаккатмалы: шигърият шушы микән соң әллә дип икеләнә башлыйсың... Дөрес, икеләнү тудырмаганнары да бар арада, сүз дә юк. Тик күбесе!.. Ә үземнекеләр белән тагын шулай: Казанда (шул исәптән, «Казан утлары»нда да) кире кагылган шигырьләрне русчага тәрҗемә итәләр – әллә күпме подстрочник арасыннан нәкъ шуларны сайлап алып; мактыйлар да әле! Ахыры ничек булып бетәр, билгесез, әле ничек булганын гына әйтәм. Ни хәл итәсең, абсолют дөреслек, әлеге дә баягы, юк! Бик кыен шул хәл! Булса иде ул!

Акыллы кешеләрнең сүзен тыңлап, үз башың белән хәл итәргә – шул гына кала.

Ә «безнең хаталарны кабатлау» хакындагы сүзеңнең кем турында, ни турында икәнен белеп бетермим. Шуны гына әйтәсе килә: ул яктан мине «яхшы саклыйсыз». Күп кенә шигырьләрне (Казанда чыккан) укып карыйм да: «моны мин язсам, басмаслар иде», – дим. «Что дозволено Цезарю, не дозволено быку» диләрме әле? Минем бәхетсезлегем дә, бәхетем дә шунда. Шигырьләрем мүкләнеп беткәч кенә чыга (йә чыкмый), шуңа күрә «ашыгып» язсам да, матбугатта чыкканчы «уйланырга» вакыт күп кала. Ел саен китап чыгаручы түгелмен, үзең беләсең.

Китап дигәннән, теге «Алтын тарак» ару чыккан, тик берничә урында бозганнар, бигрәк тә «Табигать-Ана кочагында»ны. Сибгат Хәким, чынлап та, хат язган иде. Алай «үстерергә кирәк» дигән сүз күрмәдем, ни турында соң ул, нәрсәне үстерергә?

Сиңа тагын бер кат рәхмәт йокыдан уяткан өчен. Мөгез терәп, үз позициянңдә генә торырга кирәк дип санамыйм мин, кешене дә тыңларга кирәк (кешесенә карап).

Фәизнең яшел тышлы китабында сине тискәре булмауда гаепләве белән килешә алмыйм. Чама белергә кирәк – шул гына, нишлисең, ак һәм кара төс юк. Юк, мин үз-үземә каршы килмим, яхшы белән начарга аеру мөмкин түгел димим, тик аның өчен (киңәшләргә дөрес бәя бирер өчен дә) үз дәрәҗәң югары булырга тиеш. Менә шул хакта баш ватам – дәрәҗә җитми, дәрәҗә (уровень)...

Үзебез ару. Малай бер атна бүлнистә ятып чыкты – ангинадан соң абсцесс булып, шуны кистеләр. Вилнең эше һаман бетми, авылга кайтып китә алмыйбыз. Шушы арада бер якка булырга тиеш инде.

Синең, нәрсә, кәефең начар? Менә дигән япь-яшь, чип-чибәр егет әле син! Танавыңны төшермә. Әнкәй әйткәндәй, Ходай исәнлек бирсен, башкасы чукынып китсен.

Күп яза торгач, ручканың карасы да бетте.

«Казан утлары»ның май саны килде. Укырга бернәрсә юк, әй. Ну, чыгарасыз хәзер журналны! Ярар, син бу теманы өнәп бетермисең.

Римма исән-саумы? Сәлам әйт. Мәскәүгә килсә, керсен, бер дә күренми.

Ә син ул кадәр бетеренмә.


Ярый. Хуш, сау бул.

Белгәннәргә сәлам.

*Нурия.*

*Кыям Миңлебаевның тууына – 95 ел*

# ТАТАРЧАСЫ БАРЫБЕР КЫЗЫКЛЫРАК...



Без бит, узган гасырның алтмышынчы-җитмешенче елларында туган балалар, «Белмәмеш маҗаралары»н татар язучысы язган дип белеп үстек. Төн йокыларын калдырып укырга мәҗбүр иткән менә шул әсәрнең авторы Николай Носов дигән рус язучысы икәнен без соңыннан гына белдек. Аны гел безнеңчә итеп, саф татарча итеп тәрҗемә итүче Кыям Миңлебаев исемле абый булып чыкты. Үсә төшкәч, әсәрнең оригиналын да укып карадык, юк, татарчасы барыбер кызыклырак, остарак итеп язылган.

Гомумән, үзенең иҗат гомерендә ул Л.Толстойның «Балачак», «Үсмерчак», «Егетчак» повестьларын, «Казаклар» әсәрен, А.Толстойның «Михнәтле заман» трилогиясен, «Инженер Гаринның гиперболоиды», «Аэлита» романнарын, В.Шишковның ике китаптан торган «Хәсрәт дәрьясы» романын, В.Катаев, Т.Сёмушкин, Н.Носовның аерым әсәрләрен, чит ил язучыларыннан Э.Войничның «Кигәвен», Г.Гарсиа Маркесның «Ялгызлык», Ж.Амадоның «Габриэланың гыйшкы» романнарын һ.б. авторларны тәрҗемә итте.

Башка халыкларның әдипләрен татарча сөйләтә белүче күренекле тәрҗемәче, язучы, журналист Кыям Сәлахетдин улы Миңлебаевның (1929–2005) тууына 95 ел. Хәер, галим дип тә өстәсәк буладыр, чөнки ул татар телен дә, рус телен дә фәнни югарылыкта белүче, һәр сүзнең семантик сүрүләрен нечкәләп тоя алучы каләм иясе иде. Педагог дип тә өстик, чөнки Кыям ага, Казан университетында тәрҗемә осталыгы дәресләре алып барып, үзенең еллар буе туплаган тәҗрибәсен шәкертләренә өләште. «Тәрҗемә – сәнгать ул» дигән китабында исә әнә шул тәҗрибәсен киң катлау укучылар даирәсенә дә биреп калдырды.

К.Миңлебаевны без әдәбият тәнкыйтьчесе дип тә һич икеләнмичә әйтә алабыз. Фатих Хөсни, Гомәр Бәширов, Гариф Галиев, Әнвәр Давыдов, Әнәс Галиев, Эдуард Касыймов, Саҗидә Сөләйманова, Гарәфи Хәсәнов, Гадел Кутуй, Җәмит Рәхимов кебек әдипләр иҗатына багышланган язмаларында ул әдәбиятыбызның иң четерекле мәсьәләләренә туктала, язучы иҗатының үзенчәлекләрен, кабатланмас якларын җайлы гына итеп ачып бирә.

Без аның романнары, хикәяләре, нәсерләре белән халык күңеленә кергән язучы дип тә беләбез. Бөек рәссам-сынчыбыз Бакый Урманченың тормыш юлына һәм иҗатына багышланган «Бакый», «Акыллы атын мактар» романнары, «Нәптәй галава», «Газиз авылым», «Тәүге сабак», «Ахырзаман», «Минем әти» кебек әсәрләре аны татар әдәбиятының олпат әдипләре даирәсенә күтәрде.

Журнал укучылар игътибарына Татарстан радиосы фондында сакланган кадерле бер язма тәкъдим ителә. Бу – Кыям Миңлебаевның «Бакый» романыннан өзек. Сез аны күренекле нәфис сүз остасы Айрат Арсланов укуында ишетерсез. Әйдәгез, QR-код ярдәмендә сайтыбызга кереп, балачактан бүгенге көнебезгә кадәр безне озатып килгән, шәхес булып формалашуыбызга зур өлеш керткән әдип Кыям Миңлебаевка рәхмәтебезне әйтеп тыңлыйк.

*Хәйдәр Бигичевның тууына – 75 ел*

# ҖЫРЧЫ ЯНАРГА ТИЕШ...



Бөек җырчыбыз, Татарстанның халык, Россиянең атказанган артисты, Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты Хәйдәр Бигичевның тууына – 75 ел.

Татарстан радиосы фондында җырчының 120дән артык музыкаль язмасы саклана. Аларның байтак өлешен халык җырлары, композиторыбыз әсәрләре, рус һәм чит ил классикасы, опералардан арияләр тәшкил итә. Тагын әле җырчының иҗатына багышлап әзерләнгән тапшырулар, искә алу кичәләреннән һәм Хәйдәр Бигичев исемендәге җыр фестивале лауреатлары концертларыннан алынган язмалар аерым бер урын алып тора. Ә инде туган көннәре, юбилейлары уңаеннан төзелгән концертларны, әдәби-музыкаль композицияләрне санап чыгу өчен генә дә шактый зур урын кирәк булыр иде.

Ә хәзер исә без журнал укучылар игътибарына 1990 нчы елларда әзерләнгән гаҗәеп кызыклы бер тапшыру тәкъдим итәбез. Аның авторы – җырчының якташы, ул вакытта әле Татарстан радиосының яшь мөхәррире (хәзер без аны атаклы продюсер, Рәшит Ваһапов исемендәге фонд җитәкчесе буларак беләбез), җырчының якташы Рифат Фәттахов, мөхәрире – Сиринә Латыйпова. Бу язмага тукталуыбыз юкка түгел, чөнки бередә, беренчедән, без җырчының газиз тавышын ишетәбез, икенчедән, ул шәхес буларак та, җырчы-иҗатчы буларак та ачыла.

Тапшыруда Хәйдәр Бигичев татар халык җырларын да, композиторларыбыз әсәрләрен дә оста башкаручы, күренекле опера җырчысы булып күз алдына килеп баса. Хәйдәр Бигичевның милли музыкага, җыр сәнгатенә, шул сәнгатьнең хәл-халәтенә кагылышлы фикерләре әле бүген дә актуаль яңгырый.

Ул болай ди: «Халык җырлары – һәркем өчен бетмәс-төкәнмәс иҗат чишмәсе. Тик соңгы вакытта халкыбызның шушы бөек рухи мирасына карата салкынча караш борчый мине. Бередә мин иң элек җырчыларыбызның үзләрен гаепләр идем. «Тамашачы хәзер халык җырларын тыңламый, аңа шау-шулы җыр булсын, аңа шлягер давай», – дигәннәр белән һич тә килешеп бетә алмыйм. Әйе, кайбер катлау тыңлаучылар арасында халык җырларына булган мәхәббәт сүрелә бара. Ләкин моңа кем гаепле соң? Тыңлаучының зәвыгы түбәнәйгән, зәгыйфьләнгән икән, димәк, без үзебез аны шундый итеп тәрбияләгәнбез...»

Хәйдәр Бигичевның түбәндәге сүзләре күпләрне сискәндерә:

«Безнең кайбер җырчыларга ихласлык җитеп бетми шикелле. Җырчы иң элек үзе янарга тиеш. Чын күңелеңнән, йөрәгеңне куеп җырлаганда гына, тыңлаучы йөрәгенә юл таба аласың, аның йөзендә үз фикердәшеңне күрү бәхетенә ирешәсең. Кабатлап әйтәм: ихласлык – җырчы өчен иң төп таләп...»

Җырчы янарга тиеш... Ил гамьнәрен иңнәренә алган шагыйрьләр кебек янарга тиеш. Фәкать шунда гына аның җыры халыкның күзәнәкләрендә яшеренеп сакланган генетик хәтерен уята алачак.

Тапшыруны Флёра Хәмитова алып бара.

*Сәхифәне «Татарстан» радиосының шеф-мөхәррире* **Нәсим АКМАЛ** *алып бара.*



Әмирҗан
Моталлапов

# УЕНЫ-ЧЫНЫ БЕРГӘ

## Юктан калган

Кара көзнең караңгы киче җир өстен каплап килә. Район газетасы редакциясе, эш сәгате чыгарга санаулы минутлар гына калган. Кайтырга җыенганда гына, элек урам аша күршедә яшәгән Фәрит килеп керде. Гадәт буенча исәнлек-саулык алыштык. Сизелеп тора: егет бераз төшергән.

– Нинди йомыш белән, Фәрит? – дип сорыйм тегеннән, моңа кадәр аның бу тарафка аяк басканы булмаганга аптырап.

– Казаннан килгән зур язучыларны күрергә кирәк иде миңа, – дип җавап бирде егет җитди кыяфәт белән.

– Бу арада гына килүчеләр юк бит әле. Кайчан киләчәкләрен дә әйтә алмыйм. Бездән сорап йөрмиләр бит... Шулай да Риза абый Ишморат кайтырга тиеш, – дим моңа.

– Кем соң ул?

– Кем булсын! Танылган драматург.

– Миңа драматург кирәкми.

– Сиңа язучы нигә кирәк соң? Нинди йомышың төште? – дип кызыксынам, моңа кадәр китапка артык исе китмәгән егетнең әдәбият әһелләре белән очрашасы килүенә гаҗәпсенеп.

– Повестьны укытасы бар иде. Роман-повесть язган авторлар кирәк миңа, – ди Фәрит, мине тәмам хәйран калдырып.

Моңа кадәр уч төбе хәтле хәбәр дә язып карамаган кешенең повесть яздым диюенә аптырамый хәлең юк, билгеле.

– Язу-сызу белән танышлык бездә дә бераз бар бит. Казан язучылары килгәнче, миңа укыта тор, зыяны тимәс, – дип киңәш бирәм егеткә.

– Язылмаган әле ул, башта гына йөри, – ди Фәрит, маңгаена чиртеп.

– Соң, Казан язучылары синең башыңны ярып укырга тиешләрмени? Кәгазьгә төшерелмәгән язма әсәр булмый!

– Хәзер төшерәм мин аны. Төшерергә оста без. Редакциядә генә яза беләләр дисеңме әллә?! – дип үпкәләп чыгып китте элекке күршем.

...Егерме елдан артык вакыт узды, Фәритнең бер хәреф тә төшергәне юк әле.

## Күршеләр

Имаметдин белән Кираметдин Мерәс авылында урам аша күршеләр булып яшәгәннәр. Имаметдин авылда хәллеләрдән саналган. Йомышы төшкәндә, Кираметдин әүвәл аңа кагыла торган булган. Менә көннәрнең берсендә ул янә Имаметдинга кергән дә бурычка акча сорый икән.

– Акча сәкегә җәелгән киез астында булыр, карап ал шуннан, – дигән күршесенә Имаметдин.

Кираметдин киезне күтәреп караштыра да:

– Монда акча юк бит, Имаметдин, – ди.

– Бәй, син теге вакытта алган акчаңны кертмәгән идеңмени соң? – дигән була Имаметдин, гаҗәпсенгәндәй итеп.

– Кертмәгән идем шул әле...

– Алайса, акча юк инде. Керткәч, бирермен, – дип чыгарып җибәрә Имаметдин күршесен.

## Күрербез

Районда хуҗа яңарган саен безнең рәисне алыштыралар. Хикмәтнең нидә икәнен тәмам төшенеп җиткән юк. Сәбәбен табалар да икенчене китереп куялар. Безгә дисә, берсе дә ярамаслык түгел шикелле.

Әйтик, Садрины ялга озаткач, Тимерханны куйдылар. Беренче көннән үк эшкә чат ябышты.

– Яшьләрне калдырам. Сабый чактан ук балаларны авылны яратырга өйрәтәм, – диде дә ипподром төзергә керешге. Эшләр хәтәр хутка китте. Нәселле атлар кайтартылды. Аларны күреп, малайларның гына түгел, кызларның да күзендә ут уйный башлады. «Балаларга шөгыль табыла», – дип, ата-аналар да куанды.

Әмма өстә тик ятмыйлар шул. Районда тагын әвеш-тәвеш, безнең хуҗалыкта тагын яңа рәис. Бу юлы Габдрахманны куйдылар. Килде, тотынды. Башка сыймаслык җитезлек күрсәтте егет. Күз ачып йомганчы, ипподромның казыгын да калдырмыйча сүттереп ташлатты.

– Ат бәясе – алтын бәясе. Ат алганчы, «КамАЗ» алам. Файдасы күбрәк тияр. Тузан туздырып чабып йөрү өчен ат туйдырып ята торган заман түгел, – дип аңлатты ниятен.

– Ә балалар? – дип, ата-аналар авыз ачканнар иде, рәис тиз томалады:

– Без ипподромсыз да үстек әле. Мәктәптәге «конь»нар, «козёл»лар да бик җиткән, – дип кырт кисте...

Кышка кергәндә, тагын рәис яңарттык. Монысы да искитмәле җитез булып чыкты. Яңа ел алдыннан төзелешне бөтен киңлегенә җәелдерде. Мәктәп ихатасы, идарә тирәсе, буш урыннар төрле корылмалар, хайван һәм кош сыннары белән тулды. Биек-биек чыршылар кайтартып утыртылды, аларда утлар кабынды. Авылга ямь керде. Күренеп тора: яңа рәис авыл, аның халкы турында янып-көеп кайгырта. Аеруча балаларның күңелен күрергә тырыша...

Тик сөенеч тагын озакка бармады. Кояш туры карый башлаганда, бөтен нәрсә җимерелә, ишелә иде инде. Ни хәл итәсең, боздан гына салынганнар иде шул алар. Шулай да мәһабәт бер сарай гына бирешмәде. Җәй җылысында дүрт катның берәрсе ишелсә иде, ичмасам! Халык хәйран

калды. Имеш-мимешләр таралды. Мәсьәләгә белгечләр ачыклык кертте: рәиснең хан сарае тыштан – боз төсле, эчтән шыгырдап торган нарат бүрәнәләрдән, ди.

Тагын рәис алыштыру көтелә, ди. Яңа рәис эшен тагын бу сарайны сүттерүдән башлар микән инде?

## Туганлык

Гыйздеҗамал – егерме елдан артык инде кибеттә сатучы. Өстендә әүвәлге төсен күптән югалткан, үзе белән яшьтәш, катып беткән халат булыр. Кибет идәне, кайчан керсәң дә, абынып егылмалы булып укмашып каткан пычрак иде. Сатучының кулы да мунчадан-мунчага гына юылмады микән әле?

Халык күп еллар шул кулдан ризык сатып алып яшәде. Җирәнүдән чиргә сабышучылар да булды, диделәр. Андыйлар Гыйздеҗамалга сиздермәскә тырышып, күрше авылдагы кибеткә йөрде. Әгәр Гыйздеҗамал сизенә калса, бүтән аның күзенә чалынмавың яхшырак.

– Мин саткан ризык ярамыймыни? Нигә күрше авылга чабасың? Минекен ошатмыйсың икән, кибеткә башкача аяк басасы булма, – дип, җәнҗал чыгара.

Үзе югында Гыйздеҗамалның тетмәсен тетәләр: элеп алып, селкеп салалар. Әмма күз алдында төчеләнәләр. Аның һәр әйткәненә ризалашып баш кагып, мөһер сугып торалар. Каршы әйтүнең хикмәтсезлеге һәркемгә мәгълүм. Теле генә түгел, «тотка»сы да ныклы иде аның.

– Минем белән булышып кына карагыз, Фәлән Фәләнечкә әйтеп хөперттерермен үзегезне, – дип, авызларын каплый ризасызлык белдереп тел кузгаткан кешеләрнең.

Җае чыкккан саен Гыйздеҗамал Фәлән Фәләнеч белән якын туган икәнлеген, аралашып яшәүләрен сиздерергә тырыша. Сәүдә җитәкчеләре дә сатучының ныклы «тоткасы» барлыгын беләләр. Аның исемен атауга ук сәүдә җитәкчеләренең тез буыннары калтырый башлый иде. Гыйздеҗамал белән берәүнең дә сүзгә керәсе килми, Фәлән Фәләнечтән шүрлиләр.

Гади халыкның Фәлән Фәләнечкә бик исе китми анысы. Сатучы белән еш кына бәхәскә керәләр, шапшаклыгын йөзенә бәреп әйтәләр. Кулларыннан килсә, Гыйздеҗамалны бүген үк урыныннан очыртырлар иде дә, тик тотка аларда түгел шул. Ә җитәкчелек «Пенсиясенә кадәр күп калмады, тиздән котылабыз» дигән ышанычта торды. Тик алар уйлаганча килеп чыкмады.

– Пенсия яшендәгеләрне эштән куу турында закон юк. Мин сау-сәламәт, эшлим әле, – дип, мәсьәләне кабыргасы белән куйды. Тагын шөлләделәр. Урынында тагын ул калды.

«Гыйздеҗамалны кузгатырлык көч юк икән», – дип өмет өзгәндә генә, тегене сатучылыктан чыгарып куймасыннармы?! Хикмәт шунда: Фәлән Фәләнеч белән «туганлык» җепләренең очы табылган бит, рәхмәт төшкере! Гыйздеҗамалның шәһәрдәге бертуган апасы Фәләнечнең сеңлесендә идән юа икән. Менә шушы «туганлык» белән Гыйздеҗамал авылдашларының гына түгел, сәүдә җитәкчеләренең дә күзләрен томалап яшәгән булып чыкты.

## Аерма

Ике дус очрашкач, берсе мактанасы итеп:

– Мин шигырьләр язам, – дигән.

– Язгач, нигә газетага җибәрмисең? Басылып чыгар, без дә укыр идек, – дигән икенчесе.

– Кыенсынам. Тыныш билгеләрен куя белмим бит.

– Шигырен яза белгәч, тыныш билгеләрен генә куя белер идең әле.

– Язу сәләте өстән бирелә, ә грамматиканы астагылар өйрәтә. Аерма бармы? – ди яшь шагыйрь.

– Бар икән шул, – дип килешергә мәҗбүр була әңгәмәдәше.

## Аңламый калмас

Газета редакцияләрендә урта белем белән эшләүчеләрнең теләкләрен тормышка ашыру юнәлешендә зур эш башланды – 1959 елда Казан университетының тарих-филология факультеты каршында читтән торып белем бирә торган журналистика бүлеге ачылды. Шактый өлкән булсак та, кабат парта арасына утырдык.

Немец теленнән Эмилия Адальбертовна Бауши атлы фрау укытты. Чыпчын алман хатын-кызы. Апабыз төгәллек ярата иде. Сынау һәм имтиханга үзе өйрәткәнчә генә әзерләнүне һәм җавап бирүне таләп итте. Авызыңны ул кушканча ачмасаң: «Иртәгә килерсең, кабат әзерлән», – дип кенә җибәрә иде. Текстны сүзлексез тәрҗемә итә алучыларны да сүзлек төзеп килергә мәҗбүр итә иде.

Бездән бер курс түбән укыган Госман Гомәр мөгаллимәнең кырыс таләбенә артык игътибар биреп җиткермәгән, күрәсең. Кире бора башлагач, телгә килгән:

– Мин – бала-чага түгел. Обком органында эшләүче журналист. Обкомга жалу белән барачакмын, – дип, фрауны шөлләтергә уйлаган. Укытучының исе дә китмәгән. Ул:

– Бар, улым, бар. Табеевның үзенә туры кер. Фикрәт – минем шәкертем. Ул мине аңламый калмас, – дип, Гомәрне чыгарып җибәргән.

Нишләсен Гомәр, имтиханга бик тырышып әзерләнми чарасы калмаган.

## Бәхетсез икәнсең

Кайсыдыр бер юбилярны тәбрикләү мәҗлесе бара. Чиратлап котлыйлар. Мактау сүзләренең иге-чиге юк. Менә юбилярның хатынына чират җитә. Ул да, башкаларга кушылып, ирен күккә чөеп мактый башлый:

– Ул миңа ныклы терәк, ышанычым. Мин дә кәефен бозмаска тырышып кына яшим. Безнең йортта һәрвакыт тынычлык, дустанә мөнәсәбәт хөкем сөрә. Сүз әйтешү, үпкәләшүнең ни икәнен дә белмибез...

Хатын тантаналы нотыгын тәмамлагач, юбиляр янәшәсендә утырган ир:

– Кызганам мин сине, дускай, гомерең бик хикмәтсез уза икән, – ди.

– Ничек инде? – дип гаҗәпләнә хуҗа.

– Хатын белән тарткалашуның ләззәтен дә татымыйча яшисең бит, – дип җавап бирә кунак.

# ӘДӘБИ СКАНВОРД

| | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| ... Баттал | | Габдрахман Әпсәләмов романы | | | | | |  | | |
| | | | | Шагыйрь Рәдиф ... | | Һади ... | | | | |
| Теркәгеч | | Әмирхан Еники хикәясе | | | | | | | | |
| | | Нияз Акмалның тәүге шигырьләр китабы | | Гурий Тавлин трилогиясе | | Дәрдемәнднең чын исеме | | | | |
| | | | | Өлкән рухани | | | | | «.... кыңгырау моңнары» (җыр) | |
| | Төрле төстәге | | | | | Шагыйрь Яков Ухсайның милләте | | | | |
| | | | | Фаяз ... (публицист, тәнкыйтьче, шагыйрь) | ... Колмый | | ... Зәки / Грузиннарга кардәш халык | | | |
| | | | Жанна д'... | | Сибгат Хәким поэмасы | | | | | Башкортстандагы район |
| Чандыр, ябык / Каеш прәшкәсе | | Ефәк агачы | Сәгыйть Рәмиев шигыре | | | | ... Карнай (башкорт әдибе) | | | |
| | | | | | ... Чехов | | | | ... Садриев | |
| | ... Кинҗәбулатов (башкорт шагыйре) | | Һәдия Дәүләтшина романы | | Язучы ... Искәндәр | Табын түрендә | Очлы тау түбәсе | Гөлчәчәк Галиева повесте | Шагыйрь Мирһади Разов туган авыл | |
| | | | | | | | Пешекче, ашчы (иск.) | | | |
|  | | | | Нәни Тукай | | | | | Шагыйрь Рифкать Закиров туган авыл | Иван Тургенев повесте |
| | | | | | | | Фирдүс Гыймалтдинов романы | | | |
| | | | | Эмиль ... (француз язучысы) | | Язучы Ибраһим ... | Борынгы Римда бакыр тәңкә | | | |
| | | | | | | | ... Ярмәки | | | |

**Рәис ГАБДУЛЛА** *төзеде.*

***Үткән санда чыккан сканворд җаваплары. Сулдан уңга:*** *«Гозер», Осип, Сәхаб, Асия, жанр, Ганс, «Оран», кын, Гуно, Гайдук, эпилог, Хәлил, акын, Олег, Али, кок, Грасс, Лиана, Суфиян, Гир, Инин.* ***Өстән аска:*** *дог, ахак, «Рух», Олуг, Жан, Блок, фин, Госманов, «Ил», Лир, элегия, Захар, Гранин, Кави, Ан, робагый, Ла, Сафин, Санд, Окас, Сирин, «Ургыл», ясак, Нил.*

# ХУШ, ЛИЛИЯ!



Уйламаганда-көтмәгәндә, хезмәттәшебез, «Казан утлары» журналының мөхәррир-корректоры **Лилия Илгизәр кызы Гатауллина** вафат булды.

Л.Гатауллина 1964 елда Арча районы Субаш-Аты авылында туган. КДУның журналистика факультетын тәмамлады. 1990 елдан редакциябездә эшләде, гомерен «Казан утлары»на багышлады. Эшен һәрвакыт җиренә җиткереп башкарды. Киштәләрдә аның күз нурлары түгелгән том-том журналлар калды. Ул – Татарстанның атказанган матбугат хезмәткәре, «Казанның 1000 еллыгы» медале иясе.

Без тыйнак, кешелекле, һәрвакыт ярдәмгә әзер торган, күңеле һәркемгә, шул исәптән журналыбыз авторларына, дусларына, язучыларга да ачык булган ихлас хезмәттәшебезне югалттык.

Хуш, Лилия! Без сине онытмабыз! Сагынырбыз, Лилия!



*Язучы, байтак еллар «Казан утлары» журналы редакциясендә эшләгән Шамил Маннапов Лилиягә яңа чыккан китабын бүләк итә. Узган гасырның 90 нчы еллар башы.*



*Татарстанның халык язучы Гариф Ахунов якташы Лилияне үз итә иде. Күрешсәләр, сөйләшер сүзләре бетми иде. 1998 ел.*



*«Казан утлары» редакциясе хезмәткәрләре. Утырганнар (сулдан уңга): Шамил Маннапов, Лилия Гатауллина, Рашат Низамиев, … Басканнар: Наис Гамбәр, Шаһинур Мостафин, Флёра Сабирова, Гөлзада Бәйрәмова, Рәдиф Гаташ, Тәслимә Сибгатуллина.*



*Легендар язучы Фәнис Яруллинда кунакта.*



*Хезмәттәшләр (сулдан уңга): Мансур Вәли-Барҗылы, Сәвия Хәкимова, Марат Закир, Лилия Гатауллина, Тәгъзимә Шиһабиева. Утырганы – Камил Кәримов.*



*Түгәрәкләнгән чагыбыз. Сулдан уңга: Фәнил Гыйләҗев, Рөстәм Галиуллин, Лилия Вагыйзова, Камил Кәримов, Вакыйф Нуриев, Айсылу Имамиева, Наил Кадыйров, Элеонора Җамалиева, Фирүзә Җамалетдинова, Лилия Гатауллина, Рамил Ханнанов. 2018 ел.*

*Фотолар «Казан утлары» журналы архивыннан алынды.*

## ТӨРКИ ӘДӘБИЯТЛАР ФЕСТИВАЛЕ

Казанда Мөхәммәдьяр исемендәге төрки әдәбиятлар фестивале булып узды. Анда Азәрбайҗан, Казакъстан, Кыргызстан, Үзбәкстан илләреннән, Башкортстан, Саха (Якутия), Чувашия, Дагстан, Кабарда-Балкар, Карачай-Чиркәс республикаларыннан язучылар, каширләр катнашты: кунаклар Хөкүмәт йортында Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары Ләйлә Фазлыева белән очрашты, Милли китапханә белән танышты, Татарстан Фәннәр академиясе «Төрки халыклар әдәбияты: тарихы һәм бүгенгесе», «Халыклар дуслыгы – әдәбиятлар дуслыгы: хезмәттәшлек перспективалары» дигән темаларга сөйләшүдә, түгәрәк өстәл утырышларында катнашты, Г.Камал исемендәге Татар дәүләт академия театрында Татарстанның халык язучысы Әмирхан Еникинең тууына 115 ел тулуга багышланган «Җиз кыңгырау» дип аталган кичәне тамаша кылды.

Халыкара төрки әдәбиятлар фестивале кысаларында Татарстан Язучылар берлегенә 90 ел тулуга багышланган тантаналы мәҗлес булды. Анда фестивальгә килгән кунаклар да катнашты. ТР Премьер-министры урынбасары Ләйлә Фазлыева Татарстан Язучылар берлегенә ТР Рәисе Рөстәм Миңнехановның Рәхмәт хатын тапшырды. Аны Берлек рәисе Ркаил Зәйдулла кабул итеп алды. Тантанада язучыларны ТР Дәүләт Советының мәгариф, фән, мәдәният һәм милли мәсьәләләр комитеты рәисе Айрат Зарипов, ТР мәгариф һәм фән министры Илсур Һадиуллин, ТР Рәисе каршындагы мәдәниятне үстерүгә ярдәм фонды башкарма директоры Нурия Һашимова, Бөтендөнья Татар конгрессы башкарма комитеты җитәкчесе Данис Шакиров, ТР мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин, Казан шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Гүзәл Сәгыйтова һ.б. котлады, бүләкләр тапшырдылар.

## ТУКАЙ КӨННӘРЕ

Габдулла Тукайның тууына 138 ел тулу уңаеннан Казанның Тукай скверындагы һәйкәленә чәчәк салу тантанасы булды. Анда Татарстан Республикасы Рәисе Рөстәм Миңнеханов, ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Казан мэры Илсур Метшин, әдәбият-сәнгать әһелләре, галимнәр, җәмәгатьчелек вәкилләре катнашты.

* * *

Казан Кремлендә ТР Рәисе резиденциясенең Тантаналар залында Габдулла Тукай премиясенең быелгы лауреатлары игълан ителде. Быел бу олуг бүләккә шагыйрь Ләис Зөлкарнәй, сынчы Кадим Җәмитов, ТР Дәүләт хоры җитәкчесе Миләүшә Тәминдарова, язучы, тәрҗемәче Борис Вайнер лаек булды. Лауреатларга бүләкне ТР Рәисе Рөстәм Миңнеханов тапшырды.

***

Габдулла Тукайның туган көнендә Шагыйрьнең М.Җәлил исемендәге Татар дәүләт опера һәм балет академия театры янындагы һәйкәле каршында Шигырь бәйрәме үткәрелде. Анда Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, Татарстан Республикасы мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин, Г.Тукай исемендәге премиянең быелгы лауреатлары Борис Вайнер, Кадим Җәмитов, Миләүшә Тәминдарова, Ләис Зөлкарнәйне котладылар. Бәйрәмдә Татарстанның халык шагыйрьләре Рәдиф Гаташ, Ренат Харис, Равил Фәйзуллин, Зиннур Мансуров, Газинур Морат, шагыйрьләр Ләбиб Лерон, Сания Әхмәтҗанова, Рәмис Аймәт, Илсөяр Иксанова, Ольга Левадная, Рифә Рахман, Нәҗибә Сафина, Йолдыз Миңнуллина, Фәнил Гыйләҗев, Эльвира Һадиева, Булат Ибраһимов, Рифат Сәлах, КФУ студентлары Айзат Вахитов, Гөлназ Әхмәдиева, җырчылар Рөстәм Нәсыйбуллин, Айгөл Хәйри, Гөлсирин Абдуллина һ.б. чыгыш ясадылар. Шигырь бәйрәмен шагыйрьләр Рүзәл Мөхәммәтшин белән Дания Нәгыйм алып барды.

***

Арча районы Яңа Кырлай авылында язучылар катнашында Шигърият бәйрәме булып узды. Кунакларны Арча районы башлыгы Илшат Нуриев сәламләде. Кунаклар Тукайның туган авылы Кушлавычта да булды, шагыйрьнең туган йорты нигезендә куелган бюстына чәчәкләр салды, әтисе Мөхәммәтгариф ка-

берен зиярәт кылды. Бер төркем язучылар, Балтач районы Сасна Пүчинкәсе авылына кайтып, Габдулла Тукайның әнисе Бибимәмдүдә каберен зиярәт кылды. Район мәктәпләрендә укучылар белән очрашты. Соңыннан район Мәдәният йортында каләм әһелләре катнашында әдәби кичә булды.

### ЯҢА МУЗЕЙ

Казандагы 155 нче гимназиядә Татарстанның халык язучысы Нурихан Фәттах музее ачылды. Аны ачу тантанасында Казан шәһәре башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Гүзәл Сәгыйтова, Татарстанның халык шагыйрьләре Рәдиф Гаташ, Зиннур Мансуров, Татарстанның халык язучысы Вахит Имамов, язучылар Зиннур Хөснияр, Эльмира Шәрифуллина, Камал театры артистлары Равил Шәрәфиев, Дания Нуруллина, Зөлфирә Зарипова, Тинчурин театры артисты Зөфәр Харисов, әдипнең хатыны Руфина Фәттахова һ.б. Нурихан Фәттахка бәйле истәлекләр белән уртаклашты, гимназия җитәкчелегенә рәхмәт әйтте.

### ЮБИЛЕЙЛАР

КФУның Филология һәм мәдәниятара багланышлар институтының Актлар залында филология фәннәре докторы, КФУның атказанган профессоры, Россиянең һәм Татарстанның атказанган фән эшлеклесе, фән һәм техника өлкәсендә ТРның Дәүләт премиясе лауреаты, Россия Гуманитар фәннәр академиясе академигы, Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, Гаяз Исхакый, Җамал Вәлиди исемендәге әдәби премияләр лауреаты Хатыйп Миңнегуловка 85 яшь тулуга багышланган «Гамьле яшәеш үрнәге» дип аталган кичә булды. Юбилярны КФУ ректоры Ленар Сафин һәм коллективы исеменнән проректор Екатерина Турилова, КФУның Г.Тукай исемендәге Милли мәдәният һәм мәгариф югары мәктәбе деканы Рамил Мирзаһитов, Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, ТР Дәүләт Советы депутаты Рамил Төхвәтуллин, Бөтендөнья татар конгрессыннан Ирек Шәрипов, Фәрит Уразаев, Рәүф Хәсәнов, Г.Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты директоры Ким Миңнуллин (ул ТР Фәннәр академиясе президенты Рифкать Миңнеханов котлавын да ирештерде), Татар энциклопедиясе һәм төбәкне өйрәнү институты директоры Искәндәр Гыйләҗев, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының методик ярдәм секторы җитәкчесе Ләйсән Гайфуллина, галимнәр Фоат Галимуллин, Марсель Бакиров, Флёра Сәйфуллина, Энгель Таһиров, Татарстанның халык шагыйре Рәдиф Гаташ, язучы, «Безнең мирас» журналының баш мөхәррире Ләбиб Лерон, музыкант, композитор Геннадий Максимов, «Тәртип» радиосының баш мөхәррире Ризәлә Исмәгыйлева, якташлары – Зәй, Сарман районнары вәкилләре һ.б. котлады. ТРның Премьер-министры урынбасары – ТРның Мәскәүдәге тулы вәкаләтле вәкиле Равил Әхмәтшин, Казакъстан Республикасының Казандагы генераль консулы Ерлан Исхаков видеокотлаулар җибәрде. Кичәне Илфак Хафизов белән Ризәлә Гыйләҗева алып барды.

* * *

Казандагы К.Тинчурин исемендәге татар дәүләт драма һәм комедия театрында язучы, тарихи романнар авторы, ТРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты, ТРның атказанган мәдәният хезмәткәре Вахит Имамовка 70 яшь тулуга багышланган «Чын татарның аты бар» дип исемләнгән иҗат кичәсе булып узды. Кичә Тинчурин театры артистлары сәхнәләштерүендә юбилярның иҗат һәм тормыш юлы сәхифәләрен бәян итү белән башланды. Бәйрәмдарны Татарстан Язучылар берлеге рәисе Ркаил Зәйдулла, «ТАТМЕДИА» Республика һәм массакүләм коммуникацияләр агентлыгы җитәкчесе Айдар Сәлимгәрәев, ТРның мәдәният министры урынбасары Дамир Натфуллин (ул ТР Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиевның В.Имамовка Рәхмәт хатын ирештерде), Бөтендөнья татар конгрессының башкарма комитеты җитәкчесе Данис Шакиров, ТР Мәгариф һәм фән министрлыгының милли мәгариф идарәсе җитәкчесе Илгиз Халиков, Татарстанның халык артисты Әзһәр Шакиров, Чаллы шәһәре башкарма комитеты рәисе урынбасары Рөстәм Хуҗин, Язучылар берлегенең Чаллы бүлеге җитәкчесе Факил Сафин, якташлары – актанышлылар һ.б. котлады.

### КОТЛЫЙБЫЗ!

16 июнь – ТР Дәүләт Советы Рәисе урынбасары, ТР Рәисе каршындагы Татар телен һәм Татарстанда яшәүче халыклар вәкилләренең туган телләрен саклау, үстерү мәсьәләләре комиссиясе рәисе **Марат Әхмәтовка** 70 яшь.

23 июнь – язучы, журналист **Әмирҗан Моталлаповка** 90 яшь.

2024 елның 13 маенда 79 нчы яшендә Татарстан Язучылар берлеге әгъзасы, шагыйрә, сәнгать белгече, ТРның Г.Тукай исемендәге Дәүләт премиясе лауреаты **Розалина Гомәр кызы Шаһиева** вафат булды.

Мәрхүмәнең җәсәде Казандагы «Курган» зират комплексында җирләнде.

*Сәхифәне* **Вакыйф НУРИЕВ** *әзерләде.*

# В ЭТОМ НОМЕРЕ:

*«Проза и поэзия»: повесть Л.ГИБАДУЛЛИНОЙ «Алиф лям мим»,
повесть Ф.АБДУЛЛИНА «Благоухали на родной земле», рассказ С.ШАМСИ «Рябина»,
рассказы Р.ГАЛИУЛЛИНА; стихи Х.ШИРМАН, М.ВАФИНА, Ф.ГИЛЯЗОВА,
Г.ГАЙНУТДИНОВОЙ.
«Новые имена»: стихи Г.МУРТАЗИНОЙ.
Литературный конкурс «Нравы отчего дома...»: рассказ А.ГАЛИЕВОЙ «Что покажут весы?»
«Литературная критика»: статья Л.ХУСНУТДИНОВОЙ.
«Публицистика»: статья У.БАХТЕГАРАЕВОЙ.
«Память»: статья Д.МУСТАФИНОЙ.
«Обзор книги»: статья И.КИЯМОВА, статья Н.ЮСУПОВОЙ.
«Литературные объединения»: стихи членов Челнинского литературного объединения
«Ляйсан» с предисловием Р.ХАМИДУЛЛИНОЙ.
«2024 год – Год семьи в России»: статья З.ЯГУДИНА.
«Современник» беседа А.ХАБИБУЛЛИНОЙ с Д.ШАКИРОВЫМ.
«Памятные письма»: письма Н.Измайловой Р.Гаташу.
«Бесценные голоса»: статьи к 95-летию К.Минлебаева и 75-летию Х.Бигичева.
Рубрику ведёт Н.АКМАЛ.
Юмор-сатира: юморески А.МУТАЛЛАПОВА.
Литературный сканворд. Составил Р.АБДУЛЛА.
Фотоархив: «Прощай, Лилия!»
Дневник общественно-культурной жизни.
На наших обложках: Закабанная мечеть г. Казани, фото И.АБРАМОВОЙ;
историк, кандидат исторических наук Дина МУСТАФИНА.*

# IN THIS ISSUE:

*«Prose and poetry»: story by L.GIBADULLINA «Alif lam mim»,
story by F.ABDULLIN «It was fragrant on the native land»,
short story by S.SHAMSI «Mountain ash», short stories by R.GALIULLIN;
poems by H.SHIRMAN, M.VAFIN, F.GILAZOV, G.GAYNUTDINOVA.
«New names»: poems by G.MURTAZINA.
Literary contest «Moral of ancestral home...»: story by A.GALIEVA «What will the
weigh-scales show?»
«Literary criticism»: article by L.KHUSNUTDINOVA.
«Publicism»: article by U.BAKHTEGARAEVA.
«Memory»: article by D.MUSTAFINA.
«Book review»: article by I.KIYAMOV, article by N.YUSUPOVA.
«Literary Associations»: poems by members of the Chelny Literary Association «Laysan» with
foreword by R.KHAMIDULLINA.
«2024 the Year of the Family of Russia»: article by Z.YAGUDIN.
«Contemporary» interview by A.KHABIBULLINA with D.SHAKIROV.
«Memorial letters»: letters by N.Izmailova to R.Gatash.
«Priceless voices»: articles dedicated to the 95th anniversary of K.Minlebaev and
the 75th anniversary of H.Bigichev.
The column is led by N.AKMAL.
Humor-satire: humoresques by A.MUTALLAPOV.
Literary scanword. Compiled by R.ABDULLA.
Photo archive: «Goodbye, Lily!»
Diary of public and cultural life.
On our covers: Zakabannaya mosque. Kazan, photo by I.ABRAMOVA;
historian, candidate of historical sciences D.MUSTAFINA*

---

*Тышлыкның беренче битендә:* Казанның Кабан арты мәчете.
*И.АБРАМОВА фотосы.*

*Тышлыкның дүртенче битендә:* тарихчы, тарих фәннәре кандидаты Динә МОСТАФИНА.